# казан утлары

3

МАРТ . 1978

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

3

МАРТ
1977

## Бу санда

Ш. МАННУР. Чын сөю бармы? Лирик повесть 3
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Сер алдым. Шигырьләр . 74
Ф. ЧАНЫШЕВА. Әнкәй килә минем каршыма. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 78

ОЧЕРКЛАР

Җ. КӘЛИМУЛЛИН. Егет булсаң — даның китсен 80
А. ЛИТВИН. Революция солдаты . . . . . . 89
Ш. ХАММАТОВ. Әдәбият һәм сәнгать елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . . 94

К. БУЛАТОВА. Яз, газиз углым. Шигырьләр . 106
Н. МАДЬЯРОВ. Кыска шигырьләр . . . . . . 108
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Болыннарда атлар утлый. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 111

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Н. ГЫЙМАТДИНОВА. Су хикәяте. Хикәя . . . 113
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Җыр язалар Чаллы кызлары . . . . . . . . . . . . . . . 129
С. ШӘРИПОВА. Игенче. Шигырьләр . . . . . 130
Ф. ХӘЛИУЛЛИНА. Туган җирем. Шигырьләр . 130
Р. ФАХРАЗИЕВА. Авылымда икмәк исе. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 131
В. ХӘБИБРАХМАНОВА. Җилләр иссә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 132
Т. СӘГЫЙТОВА. Осталар өй сала. Шигырьләр . 134

СӘНГАТЬ

В. ЛУКЪЯНОВ. Халык җыры — тәрбия чарасы. 136

ХАЛЫК ИҖАТЫ

Л. ҖАМАЛЕТДИНОВ. Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым . . . . . . . . . . . . . . 139

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. ӘХМӘТҖАНОВ. Татар шәҗәрәләре . . . . 147

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

И. Нуруллин, Р. Фәйзуллин. «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе . . . . . . . . . . . . . 153

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Т. ГАЛИУЛЛИН. «Туган җирем, сөйгән ярым» 169
Р. ЯГЪФӘРОВ. Акыл һәм шигърият китабы . . 171

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Фатих Сәйфи-Казанлы . . 174
Л. ИХСАНОВА. Дәрҗия Аппакова . . . . . 176
С. ШАКИР. Истә, һаман да истә . . . . . . 177
Н. ГАМБӘРОВ. Учак җылысы . . . . . . . 180

БЕЗНЕҢ САФКА

Ш. ГАЛИЕВ. Альберт Яхин . . . . . . . . 184
А. ШАМОВ. Лирон Хәмидуллин . . . . . . 184
И. ЮЗЕЕВ. Роберт Миңнуллин . . . . . . . 186
Ә. ЕНИКИ. Мансур Вәлиев . . . . . . . . 186

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Төрекчәдән ике мәсәл . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 2/XII-1977 ел. Басарга кул куелды 10/II-1978 ел. ПФ 07013. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91000 экз. Заказ Б-453. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Шәйхи Маннур

# ЧЫН СӨЮ БАРМЫ?

ЛИРИК ПОВЕСТЬ

### Яшьлек бакчасы



Сәер икән бу пенсиягә чыгу дигәннәре. Көне-сәгате килеп җиткәнче, «кайчан да кайчан» дип көтә-көтә, сабан туенда чабасы ат шикелле ашкынасың. Әллә кайларга бармакчы, әллә кайчангы дусларыңны, әллә кайчан йөргән җирләрне күрмәкче булып, әллә ничә төрле планнар корып куясың. «Гел бәйрәм дә — гел гүләм» булыр сыман тоела. Көне килгәч инде, бик үк ышанып җитми торасың да, киенеп-ясанып, чал мыекларыңны майлы төкерек белән дигәндәй бөтереп, үзеңне озату кичәсенә гаять җитди кыяфәттә барып керәсең икән. Әйтерсең бөтен заводта синнән дә важный кеше юк! Җыелышны ачып, президиумга менгерәләр, бик тәмле сүзләр кояшлы яңгыр булып ява, чиреге генә дөрес булса да — өч тәүлек буе айный алмый исереп йөрерлек! Хәтта бүләк тә биргән булалар әле. Иллә дә күңелле икән соң бу! Атна буена шулай эчтәге сабан туе сүрелми икән. Аннары, айный төшеп, эч поша башлый. «Туктале, бу бит ялга чыгу гына түгел, эштән чыгу, заводтан китү дигән сүз. Кырык ел шомарткан сукмагыңа чирәм үсәчәк бит хәзер!» — дип, кара кайгыга төшәсең. Өеңдәй үзләшеп беткән шул цехыңнан аерылу хафаландыра. Әйтерсең анда синнән башка берни дә эшли алмаячаклар. Билгеле инде, бу хәсрәтләреңне кешегә ача калсаң, ике бармагы белән генә маңгай читенә чиртеп, көлемсерәп куячак: ни түгелме, янәсе, акыл тартмаңдагы берәр шөребең төшеп калмаганмы?

Әлбәттә, кысыр кайгы инде бу — үзең дә сизеп торасың. Шулай да күңел борсалана, алгы аяклары белән җир тырный, сабан туена чыга алмый калган сука аты диярсең. Минем болай гамь чигеп йөрүне карчык белән килен бик тиз сизеп алды тагы:

— Син инде базардан ит белән бәрәңге генә алып керсәң икән, зинһар... — ди карчык, бик ягымлы гына итеп. — Кайтышлый кибеттә әйбәт кенә сөт белән каймак туры килсә, бидон белән банкы да кирәк булмас микән?.. И-и, онытыла язган икән, эремчек тә алырга тырыш инде, вак шәңгә пешермәкче булган идек, ә кефир белән икмәкне икенче чыгуыңда алырсың инде...

Әнә кая китте бит эшләр хәзер! Чабасың да чабасың, асылынган телеңне җилкәңә салып. Эшләгән цех мин киткәч урыныннан күчәр ин-

де, дип кайгырыр вакыт та калмады, муенга биш камыт киертеп, борынга авоська дигән борынчык элеп куйдылар... Шулай да бер көнне цехка барып, «Ник тегеләй, ник болай?» дибрәк йөри башлаган идем, партком секретаре эндәшеп алды. Исәнлек-саулык сорашты да болай диде:

— Карагыз әле, иптәш Сабитов, җыелышларга һәм башка җәмәгать эшләренә монда йөрү сезнең өчен бик уңайсыз түгелме? Сез бит ерак яшисез, троллейбус белән килгәндә дә ярты сәгать кирәк, дип зарлана торган идегез элек. Әллә, мин әйтәм, үзегезнең күршедәге йорт идарәсенә генә күчерик микән сезне учетка?.. Якын да, уңайлы да булыр иде.

Баштарак: «ник тә мик» дип, маңгайга тай типкәндәйрәк торган идем дә, аннары төшенеп алдым тагы тел төбен: алай икән... бик оста аңлатты бу! Миннән котылырга икән боларның исәбе. Аңламаслык түгел, аңладым. Хәзер абзагыз унөченче йорт идарәсенең «төп актив»ларыннан берсе булып санала...

Ярар, көннәр дигәнең һаман уза бара.Тик торып интегәсе түгел, дөнья мәшәкате муеннан. Шулай да, челтәр борынчык киеп дүле-дүле чабудан әзрәк бушану әмәлләре дә күренә башлады. Иртүк чыгып китәсең дә, карчыкның, кызларның, киленнең бөтен «боерык»ларын җиренә җиткереп, теле салынган мәһмәй шикелле өйгә кайтып керәсең. Табын тутырып утырабыз да төшке ашны уздырабыз. Үзең ташыган азык-төлектән пешерелгән аш искиткеч тәмле була икән!

Аннан соң инде, карчыктан рөхсәт сорарга әллә ничек уңайсызланып, үз иркең белән генә урамга таясың. Җәйнең озын көннәре, чиллә вакытлары хәзер. Мең дә мең тапкыр таптаган тузанлы, бензин исле урамнардан әллә ни йөрисе килми, шыгырдавык аяклар ял сорый. Атлый торгач, шәһәр уртасындагы җыйнак кына — түгәрәк кенә дигәндәй, бакчага килеп керәсең. Әллә ни күз явын алырлык нәмәрсәсе дә юк инде аның. Шулай да үзенә күрә ярый. Исемен дә зурдан купканнар: «Яшьлек бакчасы» дип атыйлар аны.

Урталыкта асфальт мәйдан бар. Аның тирә-ягы буйлап арка терәкле яшел эскәмияләр тезелеп киткән. Шуларның берсенә килеп утырасың. Мәйдан үзәгендә борынгы стильдә эшләнгән фонтан күренә. Бер колачка дигәндәй сыенган нимфа сыннарының баш очында сырлы-бизәкле киң сай табак. Табак уртасында киртләчләп коелган кукшин, аның үзәгеннән күтәрелгән металл көпшәдән су бөркелеп тора. Әкрен генә искән җил аны, вак кына яңгыр тамчыларына әйләндереп, төрле якларга сибәли. Кайчакта кояшлы көнне дә шул «яңгыр» битләреңне чылатып, салават күпере нурларын уйнатып китә. Фонтан итәгендә төрле чәчәкләр утыртылган һәм чит-читләрен яшел үлән җәймәсе каймап алган бик зур түгәрәк клумбасы да бар. Әнә шуннан борыннарга әз-мәз генә хуш ис тә килеп куйган сыман булгалый кай кичләрдә...

Юк, ярый бу бакча, ярый. Бер почмагында нәниләр өчен комлык та бар. Анда алар бик рәхәтләнеп казыналар. Нәкъ шәһәр уртасында булгангамы, үтеп-сүтеп йөрүче дә, болай гәп сугып утыручылар да җитәрлек. Минем шикелле алтмыш-җитмештән узмыш егетләр дә шактый күренә. Шул ук чамага җитеп баскан әби-сәби туташлар да, каен төбенә төшкән көртлекләр шикелле, каршыдагы эскәмиядә үзләренә бер оя булып кеткелдәшә бирәләр.

— Сызгырыгыз әле шуларга бе-ер! Тамак кырып җибәрегез, ичмаса-а!— дип ялварган була минем яндагы Зәйдүк карт.

— Шыжгырыең да... авыждагы шыбыжгы ватылган би-ит! — дип куя икенчесе. Юри генә әйтә, билгеле. Шулай да чынга якын яңгырый...

Озакламый аралашып киттек, бергәләп домино сугар әшнәләр дә табылды. Кичке якларда ул уен монда бик кызып китә, эскәмия саен чат та чот! Караңгы төшеп, домино шакмагындагы ак төрткеләр пәри күзләре булып җемелди башлагач кына таралышабыз. Мәгәр тора-ба-

ра бу тере уенның кызыгы китте. Исерекләр килеп тыгыла да: «Әйдә, яртыга уйныйбыз, яртыга!»—дип йөдәтергә тотына. Ә минем өянәк бар: шундый бәйләнчек алкашларны күрсәм, аллергиям кузгала, төкерә башлыйм, аннары — җикерә башлыйм. Алай да китмәсәләр, борын төпләренә җиткерә башлыйм. Билгеле, алкашны җилтерәтеп җиргә сылау берни дә түгел, сыек бит ул, мәмертек. Ләкин аның белән кул пычратасы килми. Сасысы килгән күк тия башлый. Ник бу хәтле күбәйде соң шулар?!

Шуннан без шахматка бирелеп киттек. Минем ул тикле әвәслек тә юк иде бу уенга, ну, мат бирә-бирә өйрәттеләр. Акбаш Шәңгәрәй дигәнебез бик тә кыҗрап, комагайланып уйный арада.

— Башладык, алайса, бисмилласы белән, — дигән булып беренче йөрешен ясый да, — әйдә, барабыз, йөреп сөйләштек, яме! — дип, сине тыкырдата башлый. Шул арада тәмәке кабызып җибәрә. Аны суырып бетерүгә канфит суырырга тотына. «Допинг, допинг!» — дигән була үзе. Ә инде тоткан фигураңны кире алырга маташсаң:

— Юк инде, дускай, «тоттың — йөрдең» көенә уйныйбыз. Алдан ук сөйләштек ич! — дип, сине кире алмаска мәҗбүр итә. Берәр урында төртелебрәк калса: «Тә-әк дип әйткән китапта»,— дигән була. Уйлап-уйлап утыра да: «Ә менә бу мескен пешканы мондарак күчерсәк, ничек булыр икән?» — ди дә, синең атың белән ладьяң кабыргасына китереп төртә. Китте икесенең берсе! Вәт җүнсезне, нишләтте бит, күрми дә калдым!

Шуннан инде ул сабыйларча канатланып авызын ера да тагын бер этлек эшли:

— Кара-ле, кем, мулла Сабит. «Комганда су бар иди, Сабит тәһарәт алдый» дип укыталар иде безне яшь чакта. Синең дә укыганың булдымы шуны? — дип сораган була. Авыз ачарга да өлгермисең, ул сина икенчесен китереп кыстыра:

— Ә менә моннан сезнең король хәзрәтләренә безнең Фәрҗиябикә бер шахсытып алса, ничек булыр икән? — дип кеткелдәгән була. Корольне чигереп тә өлгермисең, син абайламый да калган аты белән ферзеңне ашап, тагын шах ясый. Король мескенең иң почмакка кереп поса.

— Алайса, менә монда Матильдә була торгандыр инде, — дип, фирзәсен синең корольнең борын төбенә үк илтә дә куя. — Безнең сөйкемле патшабикәбез сезнең шәүкәтле королегез белән кавышып та өлгерде, чын мәхәббәт икән үзләрендә! — дип көлгән була әле.

Шуннан тагын тотынасың, тагын оттырасың. Тирәгә «зәхмәт» кагылганнар җыела. «Мин дә мин!» — диләр. «Чүпкә чыгу» уены китә. Шәңгәрәйне һаман чүпкә чыгара алмыйлар. Ә вакытның ничек убылганын абайламый да каласың. Бер заманны тактага иелгән баш очында гына таныш тавыш яңгырый:

— Үлеме син, тереме син?

Бактың исә, карчыгың басып тора икән каршыңда! Ә тирә-як дөнья кап-караңгы булган.

— Төн уртасы җитә бит инде! — ди ул гыйбрәтле генә тавыш белән. Ә тактада уен бетмәгән!

— Хәзер, хәзер, — дип тагын сыгылып төшәсең.

— Өйгә кертмим, — ди карчыкбикәң. Һәм дөп-дөп басып күздән югала. Җир селкенгәндәй булып кала. Кузгалмыйча булмый. Күгәрченкәең, өеңә кайткач, дөнья кубарып Сафура бураннары уйната башласа, ни кылырсың?!

Иртәгесен тагын килеп җитәсең. Бу шахмат дигән нәрсәдән дә йогышлырак, кызыграк, акыллы һәм матуррак тагын берәр уен бар микән дөньяда? Сабыйларча куаныч белән рәхәтләнеп, туйганчы көләсең, янасың, көясең, я булмаса бөтен дөньяларыңны онытып, шахмат тактасына бөгелеп төшәсең. Өстән яңгыр ява, яфраклардан баш очыңа, ки-

емнәрендә, уен тактасына шыбырдап тамчы коела. Җилкәнә каплаган гәзитләр җебеп-таралып җиргә төшә, асфальтка җыелган су аякларына үтә башлый. Юк, һәнүз туктый алмыйсың. Ә Шәңгәрәй дигәнең хәйләкәр: андый көннәрне кәкре таяклы, үзе белән бер яшьле зонтик була аның кулында. Шуны баш очына күтәрә дә, тәмәкесез өзлексез пыскытып, һаман уйный бирә. Бер заманны тәмәкесе бетә моның. Кесәсеннән буш капны тартып чыгара да:

— Ах, чикунмыш, — дип куя зарлы тавыш белән. — Ашап та бетергәнмен, унбишне алып чыкканыем бит, унбишне-е!

Шуннан соң тирә-яктагыларга тилмергән күз белән карый:

— Кая, егетләр, юкмы берәрегездә? — ди. — Яз алмаска, көз бирмәскә берәрне тыңлап тормассызмы?

— Менә, «Север» гына бар миндә, — ди берсе.

— Ярый, ярый, — ди Шәңгәрәй, аны авызына кабып. — Биргәннең битенә карамаска кушкан китапта. Бик шәп, сары май тәмнәре килә!..

... Тагын шул исерекбашлар харап итте эшне, тагын тыгыла башладылар!

— Әйдә, — имеш, — «большой приз»га уйныйбыз.

Нәрсәдер анысы тагы?

Көн саен шушы бакчада айкала торган чулак Хашиян бар. Әрмән фамилияле булса да, татар малае диләр үзен. Юк, сугыш инвалиды түгел, тумыштан шундыймы, әллә шул «салдым» белән бер кулсыз калганмы, — шайтан белсен. Алланың бирмеш көне исерек, үзе беркая эшләми. Тамагын кем туйдыра дисәң — «Маханы» бар икән. Анысы кем дисәң, әнисе икән. Әнисен шулай дип атый! Әнисе эшли, туйдыра, өсбашын карый, ә бусы теләнә-теләнә, җылый-җылый аның актык тиеннәрен суырып, алкашлыкта йөри. Бер кесәсендә шешә, икенчесендә стакан була аның. Шешә төбе яларга йөрүче үсмерләрне аулаграк аллеяга ияртеп китә дә, бер тәңкәләрен суырып алып, бер стакан суррогат белән «сыйлый» үзләрен. Алкаш булса да хәйләкәр, бакыр акча корты!

Иң элек менә шул килеп кысыла, аның артыннан бүтәннәре. Барысы да Фишергә табынган була тагы.

— Ул, имеш, бушка уйнамый шахматны, әнә миллионер булды хәзер. Башы бар, чүлмәге эшли!..

Тик үзләренең генә башлары юк боларның. Фишергә табынсалар да, «большой приз»дан башканы уйлап чыгара алмаганнар. Анысы нәрсә икән дисәң, шул ук өч тәңкә икән, «бер яртылык» дигән сүз.

Әдәм баласының җелегенә төшәр өчен яралгандыр бу алкаш дигән кортлар. Уен барган эскәмияне сарып алалар да, кайсы чүгәли каршына, кайсы менеп утыра эскәмия сыртына, ята синең җилкәңә һәм шуннан тактага кул суза: «Менә болай йөр, тегеләй йөр!» имеш. Түзәр әмәл калмагач, берсенең сыйрагыннан күтәреп җибәргән идем, арт якка мәтәлде дә төште. Менә купты ихахай. Тегенең әбечәнә тиде, гау күтәрде бу. Өркетмәкче була, янәсе, мине. Радиода эшләүче бер акыллы егет бар, Дәмин исемле. Шул егет җилтерәтеп кенә алды да тегене, өс-башын, бүреген «каккалап» дигәндәй, иплэп кенә әлхәм сүрәсе «укыта-укыта» озатып җибәрде бакчадан. Хәер, аның белән генә барыбер котыла алмадык. Тәки шулар бөтен дус-ишнең җанына тиде бит. Берәү дә шахмат күтәреп чыкмый хәзер бакчага, тукталды уен. Фонтан тирәсеннән бөтенләй икенче урынга китеп утырабыз хәзер, яңа кешеләр арасына.

Баштарак шактый күңелсезләнеп калганыек, тора-бара ләчтит сатарга өйрәнеп киттек тагы. Әллә кайчан ишетеп оныткан мәзәкләрне искә төшерәбез. Узган-барганнарны инә күзеннән үткәреп, элекке «кө-

фер почмагы»ндагы шикелле гайбәт чәйнәп тә калабыз. Шулай да күбесенчә матур кызларга сокланып утыра егетләрең.

— Аптырыйм мин шуңа, — дип зарлана башлый Хәйбери камисар. Әле җитмеш биш тирәсенә яңа гына басып килә торган яшь кенә «егет» ул безнең. — Хәер, аптырамый хәлең дә юк, — дип өсти аннары, — шул хәтле күп хәзер матур кызлар, атлаган саен күзеңә килеп керәләр. Ник алар берсе дә булмады икән без җитлеккәндә? Валлаһи менәтерә, әзме-күпме күзгә чалынырдай, кулга тотардай бер матур кыз заты юк иде әле ул чакта. Әллә нидә бер булганы да безнең ишене күрә торганнардан түгел иде. Юк, ни генә дисәгез дә, чибәр хатын-кыз бик күбәйде хәзер. Хәтта безнең туташлар да башкалардан калышмый, ут уйнатып торалар. Элекке камыт аяклар, тәбәнәк буйлар, атлаган саен очрап торган шадраларның берсе дә күренми башлады. Белмим, бәлкем миңа гына шулай тоела торгандыр, шулай да үзегез уйлап-сынап-үлчәп карагыз әле, мин ялгышмыйм микән?..

— Аның үлчәвен каян табасың инде, камисар? — ди Шәңгәрәй, мыегын бармак мөгезе белән генә сыпырган булып. — Белмим шул, шушы бакча уртасында «матурлык үлчәү кабинеты» ачып җибәрсәк кенә инде... Безнең яннан узган һәрбер кызны шунда кертәсең дә, беләгенә пута бәйләп, кан басымы үлчи торган аппарат шикелле нәмәстәкәй белән матурлыгын сынап карыйсың. Әгәр дә мәгәр...

— Әйе, әгәр дә мәгәр, — дип аның сүзен бүлдерде шалтыр Шакир. — ул эшне, мин әйтәм, Шәңгәрәйгә тапшырсалар бигрәк тә белгеченә туры килә инде. Көн-төн шуннан чыкмыйча, кызлар матурлыгын анализлап кына ятачак...

— Әй, шалтырый да инде бу Шакир, — дип сузды Акбаш. — Кая инде ул безгә хәзер. Җәмилә әбиегезнең кан басымын да рәтләп үлчәп булмый. Аппаратын да алган булганыек врач кушкач, өйрәткән дә булганые, юк — онытмым. Бу склероз дигәннәре дуамал котырып китте бит хәзер. Бөтен нәрсә хәтердән чыга. Иртә белән урамга чыгасы булсам, аласы әйберне, теге-бу йомышны бер кәгазьгә теркәп кесәгә салам. Ә кичен өйгә кайтып, аяк чишенгәч кенә искә төшә: кәгазь шул көйгә кесәдә яткан, берсе дә эшләнмәгән ул эшләр! Ә өченче көн бигрәк әдәм көлкесенә калынды. Базарга чыктым, бик озак сайланып йөри торгач, сатулаша-сатулаша хакын да килешкәч, бер урында бик әйбәт, бик эре бәрәңге үлчәттем алты кило. Акчасын да түләдем. Шуннан килеп бәрәңгемне авоськама тутырыйм дисәм, кулымда бернәрсә юк. Уң кесәгә тыгылдым — юк, сул кесәгә сугылдым — юк. Чалбар кесәләрен, тагын әллә кайларны айкадым — юк! Ә бит Җәмилә әбиегез кулыма тоттырган иде ләбаса. Гарьлектән җылардай булып, бәрәңгене сатмый торуын гозерләп, өйгә чаптым. Марҗа түти минем кыланышка ышанмыйчарак көлеп калды, ә мин юл буе үземне тетәкли киләм: «Бер дә бүтән түгел — төшереп калдырганың инде син аны! Ай, җил баш!» — дим.

Ишек ачып, тупсаны атласам, ни күрим: чекерәеп күзгә керердәй кызыл авоська ята аяк киенә торган урындыкта! Ә-әй, буш чүлмә-эк, пинжәк кигәндә шунда куеп торыйм дигән идем шул мин аны, һәм шунда ятып та калган. Җен ачуларым кубып, кулга шул каһәр суккан кызыл авоськаны шытырдатып кыстым да, тагын чыгып чаптым базарга...

— Нәрсә ул сетка! — дип куя Хәйбери камисар мыскыллы сыман тавыш белән. — Менә мин тешсез чыгып киткәнмен әле, ә үзем татар ашлары йортына барам, имеш! Һәм кайчан искә төште дисегез әле сез: аш алырга чират килеп җиткәч! Ә каршымда ике матур кыз тора: берсе соса токмач, икенчесе бирә өчпочмак. Мин көн саен алар кулыннан ашыйм. Кассиршалары да бик матур, өчесе дә елмаешып кына торалар. Мин дә бик рәхәтләнеп елмаям аларны күргәч һәм иелә-сыгыла исәнләшкән булам. Бу юлы да шул теләк белән авызны гына ерган идем — быжгырып җил кереп китте эчкә.

— Ишәнмешеж, кыжлар! — дигәнемне сизми дә калдым. Шундук учым белән тешсез авызны капладым да чыктым-тайдым чираттан. Тегеләрнең шаркылдап көлгәннәре генә ишетелеп калды... Пилмәннигә кереп, аягүрә генә тамак туйдырырга туры килде...

— Әй, сөйләп тә утырган була инде болар! — диде Сәлим, гел тегеләрне юкка чыгаргандай итеп. — Берсе, имеш, авоськасыз, икенчесе, имеш, тешсез. Шул да булдымы сүз? Ние бар моның шаккатарлык? Менә мин нишләгәнне белсәгез иде сез! Менә ул инде — да!

Эскәмиядәгеләр муеннарын бар да аңа таба суза төште. «Бик өркетмәкче була бит әле бу, нәмәрсә кыланды икән?» — дип уйладык. Башта тәмәке кабызды Сәлим, тирән итеп, ашыкмый гына бер суырды. Төтенен өскә чыгарды, агач яфракларына җиткәнче карап торды, аннары көлемсерәп куйды.

— Бер көнне кояш баеп килгәндә бик сөйкемле генә бер ханым янына күрешмәгә барырга чыктым, — дип башлады Сәлим бик яшерен сер сөйләгән әкрен тавыш белән. — Алгы ишектән йөгереп кенә менеп трамвайга кердем, урын бирделәр, утырдым, трамвай кузгалып китте. Барабыз, барабыз, нигәдер күңел көяләкләнә минем. «Өйдә туры килмәс микән әллә, коры йөреп буш кайтырым микән?» дип уйлыйм. Алай дисәң, алдагы көнне сүз куешу булган иде. Димәк, өйдә булырга тиеш. Ә күңел һаман борлыга. Нәрсәгә икән соң? Әллә, нәни генә бүләгем бар иде, шуны алмаганыммы? Юк, алганмын, уң кесәдә ята. Карыйм — таяк та кулда. Соң нәрсә җитми? Ныклабрак карасам — чалбар балагымның берсе асылынып төшкән! Жу-у итеп китте йөрәк: аяк юк! Таяк бар, аяк юк! Ашык-пошык кабаланган арада аяксыз чыгып киткәнмен өйдән! Инде нишләргә хәзер? Ничек анда барып керәсең? Юк, булмый болай. Тиз генә туктаттырдым да, сикердем дә төштем трамвайдан. Йөгерә-йөгерә өйгә кайтып, аякны киеп чыктым һәм таксига утырып кына сөйкемле сөеклем янына китеп бардым!..

Бакчаны күтәрердәй гөрләп көлде халык.

— Маладис, капитан, оста ялганладың! — дип кычкырдылар.

— Юк, — дигән була үзе, күзләрен челт-челт йомып. — Валлаһи, дөрес!

— Аяк белән таяк дөрестер дә бит, ә «сөйкемле сөекле»? — дибез.

— Анысы да дөрес! — дип куйды Сәлим, кукырая төшеп, — а што, булмас дисезме?

— Чү, энем, — диде Акбаш. — Гандәлифә килен ишетә күрмәсен, яме.

Тагын бер көлештек.

Бездәге хәтернең «төпсез янчыгы» турындагы мәзәкләр бетә торган түгел. Шуларны сөйләп көлешә-көлешә утыра торгач, кояшның инде агач башларына чалкан ята баруын да сизмәгәнбез, эссесе дә сүрелә төшкән, җиләсләнеп тә киткәндәй булды. Шул чакта аркылы сукмакларның берсеннән яшьләр төркеме мәйданга килеп чыкты. Иң элек аларның чегән туендагыдай чуар киемнәре күзнең явын алды. Малайлары — нәкъ кызлар кофтасы төсле кычкырып торган җете буяулы, эре-эре чәчәкле, ә кайсылары — урманлы, сулы, пароходлы, тракторлы, бакчалы, полклаган гаскәрле дигәндәй, күлмәкләр кигән, чәчләре дә җилкәләреннән түбән төшкән, техаскаларының агарып беткән төбенә тез күзләренә әллә ничә ямау ябыштырылган, балак очлары махсус кискәләнгән, чачаклары җиргә сөйрәлеп килә. Шулай да аларны кызлардан аерырга була. Берсенең сакал-мыегы Мазепаны хәтерләтә, икенчесе — Кочубейне, өченчесе — Тарас Бульбаны искә төшерә. Бары да классик типлар! Берсендә гитара, өчесенең кулында төрле маркалы транзистор, аларда өч төрле музыка яңгырый, карлыккан тамак белән шул тартма эченнән ниндидер шашкын ритмга такмаклаучы бер җырчы

«үтерәләр!» дип кычкырган шикелле тоела. Яннарында ике-өч кыз күренә. Чәчләре малайларныкыннан күп кыскарак, кофталары «гәзиттән» тегелгән, күн чалбар белән күн жилет кигәннәр, итәкләре, култык төпләре озын-озын чачаклы. Аякларында Казан суы буендагы дамба биеклеге платформа... Шулай итеп, кызлары да, егетләре дә, безнең ише карт-коры күзлегеннән караганда, мөмкин хәтле көлкерәк итеп киенергә тырышканнар. Һәм теләкләренә ирешкәннәр дә...

Безнең арадан берәү бер сүз кузгатмый, барыбыз да шуларга карап торабыз. Ник шул хәтле йотылып һәм текәлеп карыйлар соң бу картлар? Үз яшьлекләрен күрергә телиләр мәллә?

Алдан баручы озын буйлы егет гитарасын башка бер ритмга күчерде дә дыңгырдатыбрак чиртә башлады, без бер дә көтмәгәндә җыр яңгырады:

Симпатичный, заграничный
Зәңгәр сөрмә күзләре.
Политика түгел микән
«Люблю» дигән сүзләре?..

Ахырын кабатлап, безнең турыдан уздылар да сукмакның аргы башындагы эскәмия аркасына менеп кунакладылар, киртәгә тезелгән чәүкәләр шикелле чыяк-чыяк килештеләр. Аннары, хәтта безгә ишетелерлек итеп, «чап-чоп» үбешергә тотындылар. Әйтерсең болар әле генә ниндидер цирк сәхнәсеннән төшкәннәр дә бу бакчага килеп кергәннәр һәм андагы уеннарын һаман дәвам иттерәләр иде...

Әле һаман тып-тын гына муеннарын сузып, аларны карап утырган алтмыш-җитмешле егетләр, ниһаять, уянып киткәндәй, телгә килделәр.

— Менәтерә, вәт, — дип куйды берсе.

— Замана ахыры килсә нәләр улгай,
Дөньяга төрлү-төрлү фитнә тулгай... —
дип әйткән китапта, — диде Шаңгәрәй көлеп.

— Менә-менә, нәкъ үзе! — дип җөпләгән булды Шакир. — Кайчандыр без дә шулай чәч җиткереп, кайтарма якалы күлмәк киеп, билгә каеш буып, шакмаклы кепканың олы козырегын үрә бастырып кына йөри башлагач, комсомолга кереп алганнан соң ходай тәгаләнең ак сакалын да берәм-берәм йолыккаларга тотынгач, безнең авылның Кәфтәрия әби дә, нәкъ әнә шул мөнәҗәтне әйтә-әйтә, безне өркетә һәм «имансыз китәчәк кяферләр!» — дии каргый иде.

— Күрәсең, буыннан-буынга килә инде мондый сикереш, — диде Шаңгәрәй. — Ул чакта безне аңламыйлары, хәзер без аңламыйбыз бүгенге яшьләрне.

— Юк, алай түгел! — дип каршы төште Хәйбери. — Мин уналтыдан акларга каршы киттем, үзем теләп. Аңладылар. Утызынчы еллар комсомолын да аңладылар, хәзергеләрен дә. Кая куясыз чирәм җир күтәргән яшьләрне? Кая куймакчы буласыз КамАЗчыларны, Себер түрләрендәге мәңгелек баткакларны актарып, магистраль сузучы БАМчыларны? Һи-и, аларны саный китсәң — миллионнар түгелмени?

— Туктале, камисар, кызмале син алай ук, — дип, үзе кыза башлады Шаңгәрәй. — Бик тирәнгә батырасың төрәнеңне. Аларын кем аңламас та, кайсы кыз кочакламас, дип әйтергә була. Ә менә мондыйларын нишләтәбез? Болары да әз түгел бит. Әнә бит күрдегез, көпә-көндез, бөтен кеше күз алдында «чуп та чуп»! Ул гынамы соң әле, ничәмә тапкырлар күрдем инде: трамвай тукталышында кочаклашып үбешеп торалар, эчкә кергәч тә авызларын аера алмыйлар. Нәрсә бу? Гыйшыкмы? Саф мәхәббәтме? Ай-һай, дусларым, без бит сезнең белән сөю-ярату дигән нәрсәне күңел түребездәге иң изге, иң яшерен сер итеп саклый идек түгелме? Йөрәкнең саф ялкыннары белән үзең генә януны бәхеткә саныйсың. Андый нечкә хисләрне башкалар күзенә күрсәтергә оялансың. Тупасланып, бөтен нәфислеге җуелудан куркасың. Ә болар?..

— Ай, рәхмәт, Шәңгәрәй дус, вәгазең бик кайнар чыкты, егет йөрәкле икәнсең әле,— дип куйды Таһир ага. Һәр вакыт кырый урында утыра ул, шуннан гына колак сала, ә сүзгә аз кушыла үзе. Бүген әле беренче тапкыр авыз ачуыдыр аның. — Ә шулай да, җиләк суын бераз гына күбрәк йөгертмисең микән, дим. Безнең гыйшык-мишык хәлләре дә гел генә син әйткәнчә ал да гөл булды микән соң?

Елмаешып куйдык.

— Әһә, эләктердеме? — диде берсе.

— Ә дәлилең? — дип кычкырды Шәңгәрәй. — Безнең сөюләр дә боларныкы кебек иде димәкче буласыңмы? Кушылмыйм! Безнең беренче сөюләр саф иде, изге иде, якты иде, мәңге онытылмас җыр иде...

— Юк, боларча булды дип мин дә әйтмим, — диде Таһир агай кабаланмый гына.— Мәгәр төрлечә була иде, дим. Әйбәте дә, яманы да.

Бу мәсьәлә барыбызны да кинәт кыздырып җибәрде, әлеге яшьләр турындагы баягы сүз көрәштерү бөтенләй онытылып, яңа бәхәс китте. Акбаш әйткәнчә, саф сөю, изге сөю, чын сөю безнең яшьлектә чынлап та булганмы, бармы ул, юкмы? Шул хакта баш вата башладык. Бу безнең өчен бик мөһим проблемага әйләнде. Бу проблеманы хәл итү безнең эше «яшь этәчләр» өчен яшәү-яшәмәү мәсьәләсе белән бәйле булып китте. Шул бәйне чишми торып, беркая ычкыну, хәтта Яңа бистәгә сәфәр кылу да мөмкин түгел иде. «Егетләр» җиң сызганып эшкә кереште. Һәрберсе шул проблеманы чишү өчен үзенең мәхәббәт фронтында ниләр майтарганын бәйнә-бәйнә сөйли башлады.

— Яртыны куймасагыз да маташтырыйм әле,— дип тотына берсе.

— Булдыралмыйча, сүз боламыгы пешерә башласам, авызга тиз генә чүпрәк тыгарсыз, — ди икенчесе.

Шулай да, бөтенесе берьюлы сөйләп тәртип бозмасын өчен, өч кешелек комиссия сайланды. Беренче сүзне Хәйбери камисарга бирделәр.

Ә ул ашыкмады. Иң әүвәл этбаш капкачлы челемен көйрәтеп җибәрде, аннары тамак кыргалап, борын сызгырткалап алды, тик шуннан соң гына сүзенә кереште.

## Ике дус

турында сөйләячәген аңлаткач, болай дип башлады.

— Май урталары булгандыр, көннәрнең чәчәк исе белән исергән чагы иде. Авылдагы карт күршем Гафар абыйдан хат килеп төште. Карчыклар кулы белән язылган.

«Кайтып килә алмассыңмы, Хәбибрахман дустым, бер атнага гына булса да, — дигән. — Дөнья мәңгелек түгел икән... Сагындым, сүзләрем бар сиңа...» — дигән.

Ул байтактан бирле инде инсульт дигән хәзерге заман чире белән авырып йөри иде. Аңлап алдым мин моның хәлен һәм, озакламый, «Бөгелмә — Чистай» машинасы белән юлга чыктым.

Дөньяның әле тузан утырмаган саф яшел көннәре. Учлап-учлап сипкән энҗе чыклы салкынча иртә. Үрле-түбәнле асфальт юлдан авыр көпчәкләр тигез генә тәгәри бирә. Кырыйдагы кыр чәчәкләреннән кузгалган ак күбәләкләр, яулык изәп безгә сәлам биргән шикелле, җиңел канатларын җилпи-җилпи, читкә табарак очып китәләр. Артка карасаң, ялтыравык асфальт юл, аксыл-кара ефәк тасма сыман булып, көпчәк асларыннан сузылып кала. Шул сырлы көпчәкләр тәгәрәгән саен, хәтер тасмалары да сүтелә-сүтелә күз алдыннан кино булып узалар...

Минем әле үсмер чак иде, әзме-күпме грамыт эләктергән малай. Базар түбән түгел, солдаткаларга хат язу белән ат чыккан дип әйтергә була. Хәер, кызлар хаты да яздыргалыйлар иде миңа. Бигрәк тә өч

кеше. Берсе шушы Гафар абый, икенчесе аның яшьтәш дусты Бәһау абый, өченчесе Гөлбәдрия дигән бик сөйкемле генә, яман телләргә яманаты кермәгән бик инсафлы гына бер кыз. Ул хатлар барысы да нәкъ шул замандагыча бер төсле диярлек языла иде. «Әлхат малхат сән җаныйга сәлам хат...» Калганын үзегез беләсез инде...

Үзләреннән нинди сүзләр язарга кирәклеген берсе дә әйтми, ул хатлар кем кулына барып керәчәген дә белмисең. Хәер, шулай булмый хәле дә юк, ничек алар «фәлән егеткә», «фәлән кызга» дип шул тикле зур серне минем кебек бер сыбызгы малайга әйтеп торсыннар? Бөтен авылга таралсын дипме?..

Юк, мин барыбер әйтмәс идем әйтүен... Алар бит аны бушлай гына яздырмыйлар, шактый тамызалар «әҗерен». Олы гәүдәле, егетләрчә төзек буйлы, кибеткә җыелган яшьләр алдында куллары белән ике потлы гер уйната торган Гафар абый, чалбар кесәсеннән пыртманит алып, ун тиеннек көмеш чыгара да:

— Кулың җиңел булсын, сүзең җилем булсын, хат укыган фәлән тутаң ябышып чыгып, өебезгә килен булсын, — дип, әллә нәрсәләр такмаклы-такмаклый, шул көмешне минем уч төбенә сала. Аннары ике бармагы белән генә минем иякне өскә таба күтәреп куя да сыңар күзен кыса.

— Карале, малай, Хәйбери дус, син үзең дә шактый җегет булып киләсең бит хәзер, — ди. Аннары тагын бер күзен кыса, башын миңа таба ия төшә дә, бик яшерен сер әйткәндәй итеп пышылдаган була: — Сеңелкәш синеке, ычкындырма!

Битләрем генә түгел, колак яфракларым да артык кызу мичтә пешкән коймак шикелле кара кызарып чыкканын үзем дә күргәндәй булам. Җир тишегенә керер идем оялудан!..

Бәһау абый аңардан кайтышрак буйлы, юкарак гәүдәле, кара чәчле, җиде төн уртасындагы караңгыда да янып торгандай кап-кара күзле, ап-ак тешләре балкып китә торган көләч йөзле, теләсә кем белән рәхәтләнеп сөйләшүчән кече күңелле егет. Ул олы бер бакыр суза миңа, тып-тын гына елмаеп. Билгеле инде, ул биш тиен уч төбенә сылангач та, мин борынны тартынкырап куям. Әзсенә минем озын борын. «Икесе дә бердәй асыл егет, югыйсә, икесе дә уңган, икесенә дә кызлар өзәләнеп тора, берсе гармунчы, берсе җырчы. Нигә биш кенә тиен бирә икән соң ул Бәһау абый?» — дип авыз турсайта минем нәфсе. Саран микән әллә ул, дип куя. «Хәлле хәленчә», дигәнне исеннән чыгара. Җитмәгәнмени инде, югыйсә...

Ә Гөлбәдрия түтәйгә мин бөтенләй бушка язам. Моның бик яшерен бер сәбәбе бар. Биек-биекләрдә тирбәлгән тилгән кошның канат очларыдай нечкә генә сыгылып киткән кашларына, житез хәрәкәтле зифа буена, оек-чабата белән дә төз, матур булган аякларының әкрен басып, вак-вак атлап судан кайтканда, үзәкләр өзелердәй нәфис итеп, оетып кына юргалавына гашыйк идем мин. Кешегә белдерү түгел, үземә сиздерергә дә курка идем мин моны.

Әмма Гөлбәдрия түти бушка яздырмый, барыбер үзенекен итә: алмалы чиләкләрен асып безнең турдан чишмәгә узганда мине очрата да, бөркәнчек почмагы эченнән генә өч йомырка биреп китә. Алмасам, казаки кесәләренә сала. Мин кызарам, бүртенәм: «Ю-ук, кирәкмәс-әс», — дим. Ул барыбер ай-ваема куймый.

— Ал, ылан, ал, бер сыйланырсың,— дип, үзәкләр өзгеч итеп елмайган була...

«Ылан» ди бит, үтерә шул сүзе белән, юкларга чыгара, кәтүк буе юеш танауларга тиңли...

Ә мин аны үлеп тә яратам! Печәнлек башына менеп балавыз сыккан чаклар да була торган иде...

Күңел күзе күреп бара: көпчәкләр тәгәрәгән саен хәтер тасмалары

сүтелә-сүтелә сузылып кала. Сузылган саен уйларга батыра, үткәннәрдән «кино» күрсәтә. Һаман бер сорау белән баш ватам: «ник чакырды икән?.. «Әйтер сүзләрем бар сиңа...» диюен ничек аңларга икән?.. Нинди сүзләр булыр ул?.. Без бит, югыйсә, дус дип атаса да, алай ук гомер буе бер табактан нужа шурпасы чөмергән кешеләр түгел. Шул кызлар хаты язудан башка бик үк сердәшләр дә түгел, яшь аралары да бар, тормыш сукмаклары да гел бер үк тау буеннан салынмады. Нәрсә икән бу... Белмим...

Дөрес, армиягә бергә киттек анысы. Бер заманны язга таба безнең тирәләргә Колчак якынлашу хәбәре таралды. Авылларда мобилизация башланды. Безнең Килдебәктән генә дә егермеләп кеше кузгалды. Шулар арасында Баһау абый белән Гафар абый да бар иде. Яңарак кына өйләнгән иде Гафар абый. Туйлап түгел, ябыштырып кына алып кайткан иде Бәдрия түтәйне. Ул чакларда туе кая да ние кая. Мулла абзыйга никах җырлатырлык бер табак ашың булса — шул җиткән. Төрле бирнә-фәлән турында да авыз ачмыйлар, тик усал телле егетләр генә болай дип җырлый иде:

Биекәй тауның башында
Күренә пәри шәһәре,
Быел кызларның мәһәре,—
Бер пөдәүкә бәрәңге...

Шулай итеп, Бәдрия түтәй белән Гафар абыйның кемгә хат яздырып йөрүләре кинәт кенә ачыкланды да куйды. Яратышып йөргәннәр икән алар, яратышып кавыштылар да. Ә мин, үзем аларга хат язып та, шуны белмәгәнмен! Тагын шунысы да сәер әле, Бәдрия түтәй кияүгә чыкканнан соң Баһау абый да хат яздырмый башлады. Боегыпмы, үкенепме йөргән сыман тоела иде ул. Монысын ничек аңларга тәки баш җитмәде минем, үзеннән дә сорый алмый калдым. Әллә ул да шул ук Бәдрия түтәйне яратып йөрде микән? Алай булса, без ике мескен булып чыгабыз түгелме соң? Хәер, минем озакка бармады. Янә бер тапкыр лапас башына менеп, озак кына шыңшый-шыңшый печән чылаткач, узды...

Әйе, армиягә бергә киттек дигән идем. Уналтыны тутырып кына килсәм дә, буй бар иде минем. «Колга» дип, «тилиграм баганасы» дип үртәгән малайлар минем тукмак йодрыкны да авыз иткәлиләр иде.

Без өч кордый, яшьләрне олайттырып, үзебез теләп язылдык: Мәрдән, Хәсән, мин. Совет властеның нәрсә икәнен әз-мәз аңлый башлаган чак иде инде. Тегеләрне дә мин котырттым. Тик без гел бергә йөри генә алмадык. Өйрәнүләрдән соң фронтка җибәрелгәндә төрле частьләргә бүлендек. Һич уйламаганда-көтмәгәндә, мин Баһау белән Гафар абыйлар взводына туры килгән булып чыктым. Алар да ике дус, бергә булырга тырышканнар, ахры... Бәхет инде бу болай булгач, җан рәхәте — өч авылдаш бергә! Күңел үсеп китте минем. Үсмәслек тә түгел, Чистай буйларына килеп җиткән Колчакны кире борып куа киттек!

Эх, ул көннәр! Атнасын елыңа биргесез чаклар! Хәер, сез ул заманнарны үзегез дә беләсез инде, яшьтәшләр, артык төчеләндереп тормыйм, тик шунысын гына әйтмичә булмый: иярле-йөгәнле ат өстеннән дә төшмәдек, пулеметлы тачанкаларда да чаптык, атналар-айлар буенча җәяүләп тә бардык Себер түрләренә. Без эчмәгән сулар калмады, без кичмәгән таулар калмады. Һәм без:

Тын океан ярларында
Бетердек сугышларны!..

— дип җырлый-җырлый кире борылдык аннан. Дөрес, монысы аның соңыннан кинода булды, әмма барыбер шул чактагы шикелле иде...

Инде бөтен җир өстен дер селкеткән туп тавышлары тынгач, өйләргә кайтып килдек. Мине хәзер «егетнең җелеге» дисәләр дә була кызлар. Егермегә аяк басып кайту бит. Буй-сын да юк түгел, төс-битне дә

ходай бигүк кызганмаган — барысы да үз урынында. Шул хәтле сугышларда йөреп, исән-аман кайту куанычыннан өс-башны да рәтләп җибәрдем. Нәкъ иптәш Фрунзенеке төсле кызыл атламалар салдырып, юка постаудан гына гимнастерка тектереп җибәрдем. Үз башыма гына үлчәтеп, Буденный иптәшнеке шикелле мәһабәт шлем да өлгерттем. Аныкы шикелле үк озын итеп шинель дә ясаттым. Ничә әйтсәң дә, доброволис бит абзагыз! Аннары килеп, бер Врангель әфисәреннән салдырып алган хром итек тә бар иде капчыкта. Гел минем аякларга үлчәп теккән диерсең! Кайткач ике-өч көн йөрдем микән шул киемнәр белән, юк микән — «Хәйбери камисар» дигән исем дә тактылар үземә. Белмим, кызлармы, шаян егетләрме, әллә безнең ишене мыскыл итәргә яратучы кулак малайларымы чыгаргандыр бу кушаматны, әмма ничек кенә булмасын — ябышты да калды ул миңа. Үзем дә каршы килмәдем, хәтта бик яратып, ишеткән саен күңелем үсеп, бик кадерләп кенә йөртә башладым мин ул кушаматны. Кая гына барсам да, үземнең «Хәйбери камисар»лыкны белдерә торган булып киттем. Менә сез дә аны минем авыздан ишеткәнсездер инде, мөгаен...

Әйе, шулай итеп, без исән-аман авылга кайтып кердек. Тик Баһау абый гына юк иде безнең арада. Ул Дәлни Вастук сопкаларын алган сугышларда егылып калды. Гел сугышлар бетәр алдыннан гына... Сулдан кереп, уңнан чыккан диделәр пулесен, йөрәк тирәсеннән, имеш. Аңына килә алмады. Тау астындагы бер каланы алгач, бар корбанны бергә җыеп, туганнар каберенә күмдек. Олылап. Туп залплары белән...

Качып-посып калган аклардан каланы әрчегәндә бер подвалда мичкәле эчемлеккә тап булган идек. Егетләр түзмәде, бер мичкәнең төбен приклад белән генә суккалап, котелокларына агыздылар, безгә дә бер котелок эләккән иде. Шул кичне без Гафар абый белән гомердә беренче тапкыр кызыл шәраб тәмен татып карадык... Баһау абыйга багышлап.

Шунысы сәер, өйдән чыкканнан бирле гел караңгы йөз, туң чырай белән йөргән Гафар абый әнә шул чакта кыска гына беравыкка елмаенкырап куйгандай итте, күзләренә сизелер-сизелмәс кенә яктылык чыккандай, яшерен бер тантана иткәндәй булды. Шул эчемлектән идеме ул — һич аңлый алмадым сәбәбен. «Әллә җылавы шулай булды микән аның, әллә яшь бөртекләре шулай җемелди микән?» дип уйладым. «Әллә дустының үлеменә шулай куанамы?» дигән әшәке бер шик тә килеп керде башка. Алла сакласын, андый әдәм буламы соң?..

Гомер буе аңламадым шул чакта булган хәлне, сорарга да ничектер кыюлык җитмәде...

Сугыш җирендә өч нәрсә кирәк бит солдатка: ашарыңа булсын, атарыңа булсын, өеңнән хат килеп торсын. Шул өч терәк булса, синең хәсрәтең юк, чыраең якты, үзең куәтле. Баһау абый әнә шундый көр күңелле егетләрдән иде, аның кисәк кенә дошман пулесенә дучар булып, җиргә капланууына да ышанасы килмәде. Мәңге уенчак күңелле, якты чырайлы, җор телле егет үләргә тиеш түгел шикелле тоела иде...

Ә Гафар абый менә әллә нишләде. Авылдан чыгып киткәч бөтенләй үзгәреп, аны-моны сөйләшмәүчән коры телле, суык чырайлы, эченә тау хәтле кара кайгы йоткандай сүлпән-салпы хәрәкәтле бер кешегә әйләнде ул. Әйтерсең егет чактагы юмарт телен дә, ике потлы гер уйната торган җитезлеген дә, кешеләргә йомшак-җылы күз белән карап елмая торган гадәтен дә — барысын бергә иске капчыкка тутырып, иске өйләренең мич астына ташлап киткән! Кайгысы бар диер идең, әледән-әле ата-аналарыннан, Бәдрия түтидән дә хатлар килеп тора. Миңа укыта, бик әйбәт хатлар. Яшь бикәчен сагына диер идең, сагынган кеше ул хакта әчтән генә тынып калмый. Йә ул җыру белән әйтеп бирә аны, йә ул хат язырганда миннән тездерер иде сандугач теле белән әйтелә торган сүзләрен. Ә бу — ләм-мим. Аталарына язган хатта «хәләл җефетемә дә сәлам» дип куйдыра да, шуның белән вәссәлам. Әллә ата-ана-

ларыннан тартына микән? Алай дисәң, аерым хат та яздыра ала бит ул. Юк, аңламассың кешене...

Баһау абый турында да кайгыру, кызгану сүзе ишетмәдем мин аның авызыннан. Мәете өстендә кул күтәреп дога кылды да тынып калды. Ә бит яшьтәше иде ул аның, бергә каз көтеп үскән дусты иде. Берсе гармун уйный, берсе өздереп җырлый, яшь кызларның йөрәк давылларын дулатып, әби-бабайларны йокыдан уятып, кайтмас яшьлекләрен сагынудан күз төпләрен чылаттырып йөргән атаклы егетләр иде. Буе ике чакрымга сузылган авылның бер башында кичке шәфәкъ сүнүгә тальян телле гармун белән көмеш чыңлы җыру яңгырап китсә, хәтта авылның икенче башында да:

— Әнә, Гафар белән Баһау чыкты! — дип сөенә иде яшьләр.

Менә шундый дуслар була торып та, күңеле йомшаганын сизмәдем мин аның... Юк, аңламый башладым мин Гафар абыйны, сугышларны бетереп өйгә кайткач та аңламадым. Аның урынында икенче берәү булса, «авылда бер матур!» дигән дан тоткан Гөлбәдрия түтине, шул тикле ихлас күңел белән сагынып, кыл очыдай яманат чыгармыйча, зар-интизар булып, аны дүрт күз белән көтеп алган яшь сөеклесенең кайнар кочагыннан тагын чыгып китәргә риза булыр идеме?.. Ә Гафар абый аны, озак та үтмәстән, тагын ялгыз башы саргаерга калдырды да, егерме беренче елны тагын безнең белән Себергә китеп барды. Без инде сигез тамак. Бер имана белән ел чыгу мөмкин түгеллеге әллә каян күренеп тора. Ә Гафар абыйга бит ул чактагы ачлыктан артык куркыр урын да юк иде. Дүрт иманалы, ат-тунлы хәлле кешеләр, эш кешеләре иде алар. Белмим, ни өчен китеп барды ул берүзе? Гөлбәдрия түтине үзе белән алса ни була? Өйләрендә бит җитеп килгән сеңлесе кала ата-анасын карарга...

Хәер, каян белеп бетерәсең кешенекен? Ник хатыныңны да алып чыкмадың дип, сорамассың ич аннан. Аннары килеп, юллар да аерылды безнең: без киттек Кәлчүгингә, алар китте Чирмехау шахтыларына...

... Хәтер тасмалары шунда өзелеп кала шикелле... Ә хәзер менә, ничәмә еллардан соң ул мине яңадан исенә төшергән. Озын гомер кичергән карт яудаш. Ниләр сөйләмәкче икән ул миңа? Нинди сүзләре бар икән?..

Авыру кешенең туп-туры үзенә килеп төшү уңайсыз тоелды. Әти ягыннан ерак бер чыбык очы пләмәш калган авылда. Хәлим исемле. Шуларга кунакладым. Күптән кайткан юк иде туган якларга. Үзегез беләсез, күңелне нечкәртеп җибәрә шул. Күз төбе тишелгәндәй була, юеш тама башлый, шайтан алгыры... Кыстадылар. Сыйланмадым. Гафар абыйның хәле авырлыгын ишеткәч, баш тарттым, тамактан үтмәде.

Тумачыйның кече малае мине Гафар абыйларга илтеп куйды. Абый дип әйтүе дә әллә ничек аны хәзер: ул да ак чәч, мин дә ак чәч. Сакалмыекны күрсәтмибез. Яшьтәш дип тә булмый, ул миннән олырак...

— Нихәл, кордаш абый? — дип эндәштем мин аңар.

— Синме, Камисар дус! — дип, ике кулын сузды ул миңа яткан җиреннән. Алар калтырый иде, берсе миңа сузылып җитә алмыйча салпаеп төште, ул аны икенче кулы белән тотып алды. Тавышы да, шул куллары шикелле, калтырап чыкты, сүзләре бүлгәләнеп, авыр әйтелде. Кайчандыр таза, мәһабәт гәүдәле егет ач яңаклы булып суырылган, күзләре зураеп өскә калкынган, авыз-борын тирәләре ничектер кызарып, шешенкерәгән сыман күренә иде. Хәл-әхвәл алыштык. Хәер, болай да хәлләр күз алдында иде...

Урам буе өендә ята икән карт. Ян тәрәзәсе ачык. Агач яфраклары аркылы төшкән кояш нуры тәрәзә төпләрен челтәрләгән. Шомырт белән алма чәчәге кушылган хуш ис сизелә өйдә. Тәрәзә пыяласына бәре-

лә-бәрелә бал корты безелди, җылаган тавыш чыгара. Ачык тәрәзәдән тышка ычкынырга юл тапмый, күрәсең...

Мин янына килеп утыргач, Гафар абый карчыгын эчке өйләренә чыгарып җибәрде.

— Бар, сиңайтәм, самавар куй, кунакны чәй белән сыйларбыз, — диде.

Гөлбәдрия түти түгел иде бу. Мин ул карчыкны танымадым. Аңа ияреп, бер бәләкәй кыз бала да чыгып китте, анысы оныклары булгандыр инде. Ялгыз икәү генә калдык.

Кордаш абый олы итеп сулыш алды бер.

— Яландагы ялгыз имәнне яшен сукты бит, Хәбибрахман, — дип куйды ул аннары сүзләрен аралап-аралап кына. — Аяз көнне яшен сукты...

Мин ни дияргә дә белмәдем. Үзенә карап әйтә торгандыр инде бу дип, аптырый калдым.

— Алай ук дип инде... — дигән булдым бер дә сүзсез калмас өчен генә.

— Юк, мин чынлап әйтәм: сукты, сукты! — диде ул, хәтта бераз кабалангандай итеп. — Ышанмасаң, менә иртәгә барып карарбыз.

— Ярар, — дидем, — барырбыз. Күңел ачып кайтырбыз бер. Туган якларда булмаганга йөз ел ич!

— Күптән шул... — диде Гафар абый көрсенгән тавыш белән. — Бик күптән.

Озак кына эндәшми торды хәл җыйган сыман итеп. Аннары авыр кыймылдый торган чырай чалымнары белән әз генә елмаенкырагандай итте дә:

— Ә барые бит дөньяны аркылыга-буйга сукалап йөргән чаклар, ә! — дип куйды. Бу юлы аның тавышы күтәренкерәк чыкты. — Барые бит дөньяның иң аргы башының да иң аргы кырыена җитеп, акиян диңгезенең яр читенә аякларны салындырып утырган килеш кенә тәмәке тарткан чаклар! Кояшны, теге солдат шикелле, бастырык белән каерып түгел, ә кылыч белән, ыштыйк белән каера-каера, бөтен ил күгенә меңгереп, җыруларның да иң сагынычлысын гына җырлый-җырлый, үзебезнең Акболак буйларына, әткәй-әнкәйдән дә бигрәк, Аның янына кайтып кергән көннәр...

Аның янына...

Аның янына!..

Әммәдәки дөнья дигәнең әллә ничә төрле бизәкләре белән күзләрне камаштыра торган хәйләкәр шайтан булып күренә миңа хәзер. Бер караганда ул тулып та пешеп килә торган алсу алма тоттыра икән синең кулыңа. Синнән дә бәхетле малай юк! Башың күкләргә тигән. Кулыңа эләккән шул алмаңа сокланып дөньялар гизәсең. Таулар, елгалар аша җиңел генә сикереп чыгардай көч сизәсең үзеңдә. Олы сөенечтән шулай көннәр, атналар буе иләсләнеп йөрисең дә, түмен татып карарга кызыга башлыйсың ул алманың. Гел шикәр дә бал гынадыр шикелле тоела. Авызыңнан сулар китә. Кетердәтеп кенә бер тешләп бактың исә, эченә корт төшкән булып чыга! Йөрәкләрең жу-у итеп китә. Көтмәгәндә шулай алданганыңа үкенүдән ни кылырга, җаныңны кая куярга белми башлыйсың. Кояш нуры сүнә, әйләнә тирәң караңгы җәһәннәм булып кала...

Ә инде икенче бер караганда дөнья дигәнең хәнҗәр суза икән синең кулыңа. Үч кайтарырга куша! Үч кайтарам дип, мәңгелек газапка дучар булганыңны сизми дә каласың икән...

Мәңгелек газап...

Түшкә баскан албасты шикелле гомер буе изде ул мине...

Әйе, дөньялар шаулатып, авылга кайтып төштек. Бәдрия мине сабыйдай саф күңел белән көлемсерәп каршы алды. Ә мин — ачылмадым.

Өзелепләр дә өзелеп сагынган булсам да, якты чырай күрсәтмәдем. «Арумы?» дип кенә куйдым суык кына итеп. Тамак төбеннән кыршылып чыкты ул тавыш...

Һәй-й, заманна-ар диген, гомерләр диген... Узды да китте шунда. Җан теләгәнчә генә яшәп булмады, — дип, уфылдап куйды карт.

Яландагы ялгыз имән күз алдыма килеп басты. Әйе, килгәндә мин аның янынннан узган идем. Яшен гариплэп киткән шул аны. Мәгәр аудара ук алмаган. Аның әле берничә ботагы куе булып яфрак ярып, хәтта шул гариплеген дә каплап тора кебек... Ә Гафар абый гөрселдәп ауган олы усак шикелле ята. Эче куыш аның. Тән җылысы да калмаган, җан җылысы да сүрелеп килә бугай инде...

Башын арткарак ташлый төшеп, күзләрен өскә юнәлтте ул. Күптән тезелгән сары нарат түшәмнең юл араларыннан нидер күрергә, нидер табарга тырышып карый кебек тоелды.

— Үзең дә хәтерлисеңдер инде, Хәйбери дус, иң беренче хатны да, иң актыккынчы хатны да син язганыең бит, кулың җиңел булганые...— дип дәвам итте ул аннары. — Әүвәлгесенә үк булмаса да, икенчесенә каршы бик әйбәт, бик татлы сүзләре күңелдә май булып эри торган хат биргәние бит Гөлбәдрия тутаң. И-и, анысы гынамы соң? Барысы да җан рәхәте бирә торганые. Дөнья йөзләрендә аннан да матур, аннан да сөекле, аннан да йомшак сүзле бүтән берәү дә булмагандыр дисәм, валлаһи газыйм, ялган булмаячак...

Кисәк аның бу сүзләре авыр булып китте миңа, чын күңелдән түгел шикелле... Мин дә Гөлбәдрия түтәйгә сабыйлыктан чыгар-чыкмас чагымда ук биһуш булып йөргән малай бит... Рәнҗетерлек кыз идеме ул! Түзмәдем, кабынып киттем:

— Ник соң алай булгач син аны...

— Аңлыйм, ярты сүзеңнән үк белеп торам ни әйтәсеңне, — дип аркылы төште миңа Гафар абый.— Шунда да шул бөтен бәла, бөтен бәхетсезлек, бөтен кара язмыш безнең...

Мин һаман да берни аңламый идем әле, сүзләренең ясалма түгеллегенә һаман ышанып җитә алмыйм. Ничә тапкыр тимтендем авыз ачарга. «Нәрсәдә соң сезнең ул бәла?»— дип сорамакчы иттем.

Тик Гафар абыйны бүлдерү кыен иде инде.

— Әйт әле, Хәйбери энекәш, — дип сүзен ялгап җибәрде ул, — менә син, түгәрәк бер бакча уртасында биек булып үскән бер алмагачның иң югары ботагында кып-кызыл булып, тулып-мөлдерәп пешкән, бөтен малайны кызыктырып, бөтен авылны сокландырып торган, башкалар арасында бердәнбер булган асыл алманы сиңа бирсәләр, нишләриең, алырыеңмы?

— Һи, җүләр! Кем алмас иде аны! — дидем мин.

— Мин дә алдым... Ә инде шул асыл алманы, таудай куанычың эчеңә сыймаганга бисмилланы әйтергә дә өлгермәстән, кабалана-кабалана тешләп карагач, аның эченә корт төшкән булып чыкса, нишләриең?

— Ыргытып бәрер идем!

— Ай-һай, энем, бәрериең микән?.. Алма әрәм бит, син аны күпме заманнар яратып, аңа кызыгып, авыз суларыңны корытып йөрдең ич! Кулың күтәрелерие микән?.. Әйе, ул мизгелдәге беренче уем минем дә шулай булды. Сикереп тордым да Гөлбәдрия исемле Асыл Алманы сыңар кулым белән һавага күтәреп, җиргә бәрмәкче булдым. Әллә нинди хуш исләр агылган кара толымнары түбән сузылып төште. Күзләрендә курку заты күренмәү, чыраенда олы тынычлык булу мине аптырашка калдырды.

— Үтер, җаным, гаебем юк... — диде тыныч кына итеп.

Гафар абый берхәтле тын алыштырып ятты. Яңадан аның күзләренә куркыныч чаткылар чыкты.

— Ярсыганыем, ач бүредәй каныкканыем. Юк, котырынган арысландай өзгәләп ташлар хәлдә булдым мин аны. «Кем??!» дип акырдым җан ачысыннан. Кияү белән кыз бикләнгән ак келәтне күтәреп чыгарлык булгандыр бу тавыш. Эндәшмәде. Курку билгесе дә югые күзләрендә. Бары тик саф сөю сагышы белән чын тугрылык кына күренәдерие аңарда. Аның болай сүзсез калуы мине тагын да шаштыра төште.

— Җаның җәһәннәмгә олагуын телисеңме?—дидем ачуыма буылып.

— Теләсәң нишләт, җаным. Барысына да риза... Аны әйтү генә җиңеллек бирмәячәк... Тик сиңа тагын да авыррак булачак җан газабы...— диде ул.

Мин һаман шашындым, бугазыннан бугандай кысрыклый бирдем. Ниһаять, әйтте:

— Якын дусың... — диде ул шулай ук тыныч кына.

— Кит аннан! — дип кычкырдым мин Гафар абыйга. — Баһау абыймы? Ышанмыйм! Үтер, ышанмыйм!!

— Мин дә ышанмадым, — диде Гафар абый. — Имән күсәк белән башыма суккандай егылып китә яздым. Ничек ышаныйм? Бергә үстек, яшьтән үк дус булдык. Бер-беребезне бер күз карашудан ук аңлыйдырыек. Ходай минем бармакларга сәләт бирсә, аңа карурман кураедай моңлы тавыш биргән. Уйналмаган көй, җырланмаган җыру калмагандыр. Ничекләр итеп шундый җан дустың синең багалмана нәфсе сузсын? — Булмас! — дип гөрелдәдем мин, дөнья селкетердәй итеп.— Нахак сөйлисең, яла ягасың минем алтын дусыма!

— Каршыма китер син аны, Гафар җаным, — диде Гөлбәдрия тутаң. — Әгәр сүзем нахак булса — йөземә төкерерсең!!.

Мин һаман тирән тетрәнү эчендә идем әле. Шундый әйбәт, кече күңелле, ачык йөзле, тәмле телле Баһау абыйның шул төрле әшәкелек эшләвенә һичләрем генә дә ышанасым килми. Миңа яздырып йөргән хатлары шул Гөлбәдрия түтәйгә булды микәнни соң аның? Яратты микәнни ул аны? Ә яраткан кешеңне шулай мыскыл итеп була микәнни? Мөмкинме шундый кабахәтлек? Вөҗданга сыямы ул?.. Ялгыштым микәнни, шундый әшәке җан булды микәнни Баһау? Нишләргә миңа хәзер: аның теге вакытта хатлар яздырып йөрүен, аларны Бәдрия түтигә биргәндер дип уйлавымны әйтергәме, юкмы? Бу аның йөрәк җәрәхәтен тагын да тирәнәйтеп кенә җибәрмәсме?.. Уйлап-уйлап тордым да, ярамас дип, әйтмәдем.

Исән кулының ике бармагы белән чигәсенә баскан килеш, сүзен дәвам иттерде Гафар абый.

— Гөлбәдрия тутаң шул хәтле өзгәләнеп әйтсә дә, мин һаман ышанмадым. «Ничек булды ул этләшүегез-з!!!» — дип төпчендем тешләремне шыкырдатып, күзләремне акайтып, мыскыллы тавыш белән әйттем.

— И Гафар җаным, никләр рәнҗетәсең мине шундый әшәке сүзең белән! — дип, үкси-үкси җыларга тотынды Гөлбәдрия. — Мунча томаларга төшкәнием, җитен күтәргәниек, таңнан талкыга чыгыласые... Төтенле мунча... Тычкан күзедәй генә сукыр ут. Ишек ачык... Җитен учмаларын аралап йөрим... Абайламый да калдым, кемдер артымнан әләктереп алды да авызга исле май исе килә торган яулык тыкты, кулларга бау салды. Нихәтле генә тыпырчынып, аякларым белән тибенеп, бәрелеп-сугылып карасам да берни кыла алмадым. Тарткалаша торгач, хәлдән таеп идәнгә егылганым гына хәтердә... Кемнеңдер колак төбендә тенә быдыртавына аңыма килгәндә, ул ерткыч минем янда ятадырые. Кулларымның чишелгәнен, авызымда чүпрәк тә булмавын аңлап алдым да, кинәт калкынып күзләремне ачтым. Ул бәндә Баһау булып чыкты...

«Курыкма, җаным, мин сине хур итәчәк түгел. Мин сине үземә гомерлек яр иттем! Берәүгә дә бирмим! — дип җылады. — Яратам бит мин сине, җаным-тәнем фида синең өчен! — диде. — Әйдә, шушы таңдук

мин сине ябыштырып алып кайтам. Шушы иртәдүк никах укытырбыз!.. Мәңгелек, мәңгелек бәхетле гомер!..»

Күп сөйләде ул. Тыңлый алмадым. Көрмәгеннән тиз генә ычкындым да мунчадан чыгып йөгердем. Йокысыз төннәр башланды... Ничәмә-ничә таңнарга сузылган уйлар, капланып җылаулар, мендәрне чебердәткән кайнар яшьләр... Сарылар саргаер хәлгә җиттем. Бер караганда бик ансат шикелле: тот та чык үзенә, «яратам» ди бит. Күпме, күпме хатлар биреп йөрде, алмаган саен үчегеп биргәндәй, су юлына чыксам, чиләккә салып китте, ындырда күрсә, кичен бишмәт кесәмнән исле сабын килеп чыгарые, аның эченнән хат килеп төшәрие... Алай да карата алмагач, аягыма егылып җылады. «Юк», дидем, «сөйгәнем бар», дидем. «Кем?» дип җелегемә үтте, әйтмәдем. Нигә әйтим? Кайчан гына булмасын, һаман син елмаеп торасың ич минем каршымда. Кич урынга ятып күзләремне йомам — югалмыйсың. Йоклап китсәм — төшемдә күрәм. Иртә таңнан уянуга — күз алдымда тагын син. Ничекләр онытыйм мин сине? Ничекләр итеп ятларга яр булыйм? Бөтен җаным-тәнем, бөтен дөньям синең белән тулган икән минем. Кая гына барсам да, синең карашың мине җитәкләп йөртә... Җиде төн урталарында гармун тавышыңны ишетеп уянам. Тыңлап баксам — үле тынлык. Ишетелгән генә икән мин саташкан башка! Шуннан инде мин аңладым: Бәһау мине шундый әшәке көчлек белән үзенеке итәргә тырышса да, аннары инде җиде кат күктәге оҗмах тормышлары вәгъдә итсә дә, барыбер риза булмаячагымны аңладым. Яратмаган кешең белән ничек яшәмәк кирәк?!

Яратканың — җан газизең белән бер төнең дә бер гомер, диләр бугай. Мин дә бу ак келәттәге кара төнемне синең белән каршылыйм. Икебез дә кара кандай кара кайгы эчендә... Якты сукмак таба алырбыз микән без?.. Уйлама, Гафар җаным, акланыр өчен әйтмим бу сүзләрне. Җан кушканны гына әйтәм. Ни кылсаң да синең иректә: теләсәң — хәзер үк куып җибәр, теләсәң — типке астында яшәт, анысына да түзәрмен. Булдыра алсаң — яратышып яшик!..

Гафар абый күзләрен сары түшәмгә төбәлдергән килеш тынып калды. Әлеге кичерешләрдән соң берхәтле сулыш ала кебек иде ул. Озак тоткарланмады, яңадан башлады.

— Гөлбәдриянең менә шушы ихлас сүзләре бүген дә хәтер түремдә балкып яна. Мәңге онытыласы юк. Көненә ничәмә тапкырлар кабатлыйм мин аларны, ничек онытылсын?

«Яратышып яшик»... Нинди матур сүз, ниндәен изге теләк! Кем моңа риза булмас? Мин дә риза булдым. Үз сөйгәнең, үз дигәнең белән яратышып, сайрашып яшәү мөмкинлеге мине дә кызыктырды. Аннан да зур бәхетнең булуы мөмкинмени? Ул якты бәхет каршында әлеге алдану гарьлеге, өлешең тапланунын йөрәкне авырттырып газаплавы, көнчелеккә, кара уйларга бирелү шикелле хәлләр бик бәләкәй, бик вак нәрсәләр булып калган төсле тоелды миңа. «Бәхет нурлары белән юылыр ул тап, эзе дә калмас, бетәр, онытылыр»! дип уйладым. Киләчәк тормышыбызны яшел тау башыннан торып, саф югарылыктан карап күз алдыңа китерү — рәхәтие. Тик моны тормышта булдыру гына кыен булып чыкты. Көч җитмәде. Ир-егетнең беләк көче түгел, йөрәк көче җитенкерәмәде...

Үзем дә сизмәстән, һаман боега бардым, моңая бардым, сөйләшмәс булдым, якты чыраема көзге төн караңгысы иңә барды...

Китек чүлмәк, калган аш,
Сыйлана бир, мескен баш!..

Үз-үземә шундый бәет әйтеп көләдерием хәттәки. «Әллә кайчан бөтен авылга чәчкәндер, мактанып йөрүе башка авылларга да барып җиткәндер инде, бөтен кеше миннән көлә торгандыр, тик мин генә сизмим-

дер ахмаклыкка төшкән баш белән!» — дип, үз җанымны үзем кыйный торган булып киттем.

Булмады, уртак тел, уртак куаныч таба алмадык... Ә тормыш үзенекен итә икән. Беренче бәбиебез булачагын әйтте ул беркөнне. «Кемнән?!» — дип, әшәке, тупас тавыш белән кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым. Коелыплар инде, мескенкәем, тиз генә кече якка кереп посты. Гарьлегеннән өзгәләнеп, тыела алмыйча җылады:

— Никләр генә мине шул хәтле рәнҗетәсең, җаным! Алладан курык, ичмасам!..— дип, юаш тавыш белән ялварулары, таш йөрәкле булсаң да тетрәтерлек иде.

Һаман әшәкеләнә бардым, әшәкеләнгән саен Баһау күз алдыма килеп баса да, «Эт син! — ди.— Шундый оҗмах сылуын ник корытасың, ник киптерәсең? — ди. — Җәберләр булгач, ник алдың? Мин аладырыем аны!» — ди.

Бугазына ябышмакчы булам шунда — юкка чыга! Хәер, бу инде миңа гына шулай тоелгандыр. Ул бит без өйләнешкәннән соң көндезләрен кайдадыр югалып йөрде, күзгә-башка күренмәс булды. Сугып үтерүдән курыкты, ахры, дус дуңгыз!..

Икенче яктан шунысы гаҗәбие: төне буе урамда гармунсыз җыру яңгырый, таң атканчы тынмый, япа-ялгыз башы җырлап йөри. Аның шул карурман курае тавышлы моңы авылның иң аргы урамнарыннан килеп, йөрәк төпләрен актарып ташлый. Тальянымны култыкка кыстырып, ялан аяк чыгып йөгерердәй булам. Ник җырлый ул шулай өздереп? Көнләштереп минем йөрәкне өзгәләр өченме? Әллә үз йөрәген кая куярга белми өзгәләнүдәнме? Әллә Гөлбәдриянең йөрәгендә нидер уятып, үзенә кайтармакчы булып азапланамы? Шуны уйласам, каршына кисәк кенә басып, күсәк белән сугып егардай булам мин ул мөртәт Баһауны! Тотсын менә күке башын! Юк, ул бичара былбыл шундый хәлдә хәзер — синең читлеккә барып кермәгән күк, минем читлектән дә чыгып качарые. Ерак-еракларлагы җиде диңгез артларындагы сәхрә урманнарына качарые, синең белән минем әшәкелекне күрмәс-ишетмәс өчен, ак болытлар артына очып югалырые ул!..

Гафар абый тагын бер мәлгә тынып калды. Болар бар да минем өчен һич көтелмәгән яңалык һәм бик авыр хәбәрләр иде. Гафар абый сөйләгән саен ул кичергән котсыз гомер һаман ачыла барды миңа. Әйе шул, Баһау абыйның япа-ялгыз башы җырлап йөрүләрен мин дә хәтерлим әле.

— Байтал төпкә җигелгәч, тай җаңгызы кешни хәзер, — дип кенә көлә идек ул чагында. Кич саен диярлек кышкы җил белән аръяк урамнардан килә торган ачы җыр өзекләре безнең очны да айкап узуы әле бүген дә истән чыкмаган икән.

...Җырлыйк әле, биш булсын ди,
Уф! Йөрәгем янулары
Басылмагач, нишлим соң,
Нишлим соң?!

Бактың исә, әнә ничек тирәндә булган икән ул хәлләр...

Гафар абый берхәтле сулыш алгач, сүзен яңадан ялгап җибәрде:

— Ярый ла, безнең елгыларны армиягә чакырттылар шул чакны. Баһауны да, Әхәтне дә, Әсгатьне дә... Ә син инде үзең теләп безгә иярдең, — диде. — Сабан басулары яшәреп килгән чагые, «Колчак чыккан», диделәр, шуңа каршы киттек. Сугышка, ут эченә барып керәсе булса да, мин сөенеп бардым эчтән. Китәсе көнне яшьләр көн буе урам гизделәр. Баһау да алар белән җырлап йөрде. Өйләнгән кешегә килешмәсә дә, андый йола булмаса да, гармунымны күтәреп, мин дә урамга чыктым кичен. Баһау белән кара-каршы басып, элеккечә бер сайратасы килгәнне гармунны. Кем белә соң дөнья хәлен, кем үлә дә, кем кала

дигән күк. Сугыш бит ул!.. Дөресен генә әйткәндә, үзем үләрем күк тоелды миңа. Яшьтәшләрем белән, туган авыл белән, баеп барган кояш нуры белән, кичке морҗалардан чыккан күгелҗем төтеннәр белән бәхилләшәсем килде минем...

Ә Баһау чыкмады, күзләремә карарга курыктымы? Әллә... Гөлбәдрия белән хушлашырга киткән чагы булдымы, белмим... Аның урынына син бастың минем каршыга, Хәйбери дус. Синең күкрәктән чыккан үсмер тавыш тибрәндерде ул кичне яшь кызларның күңелен. Сиңа кушылып, бүтән кордашлар да җырлады. Бер дә башкалардан ким йөрмәдек без ул актыкки кичне! Тик Баһау күренмәде...

Ә инде без кереп яткач, төн урталары узып, урамнар тынып калгач, Баһау чыкты. Ул тотынды ялгыз башы моңаерга. Сәер малай иде ул, катышлырак дип әйтимме шунда, белмим. Шул карурман курае тавышыннан агылган моңы белән берүзе бөтен авыл кызын капка төбенә ялан аяк килеш йөгертеп чыгарырга көче җитәдерие бит аның. Мин моны беләм инде, бергә йөргән чакларда мондый хәлләр булгалый иде. Син дә тыңлап яткансыңдыр, Хәйбери дус, ул төнне дә шулай кыланды ул, шулай саубуллашуы булгандыр инде сугышка китүче егетнең.

Тал тибрәнә, тал тибрәнә,
Тал сыгыла җилләрдә шул...
Әйләнеп бер кайтырбызмы
Туган-үскән илләргә...

Гөлбәдрия белән икебез бер түшәктә ятабыз, матчада җиделе лампа яна. Аның яктысы җитми, өй почмаклары яртылаш караңгы. Минем күңел дә шундый. Икебезнең дә күзләр түшәм аркылы әллә кайларга барып терәлгән. Юк, әллә кайларга ук түгел, минем ике күз алдында кечерәк бер түгәрәк якты тора, ул якты уртасында Баһау күренә. Кайсыдыр урам чатыннан җырлый-җырлый килеп чыкты ул.

Никләр күрдем, никләр сөйдем,
Никләр йөрәк ашкынды шул.
Никләр тотып калалмадым,
Утка салдым башымны...

Белмим, аның шул өзлексез түгелгән моңы сихерләдеме, шуның өстенә үзем дә ут эчләренә барып керәсе булгангамы, инде әллә кайчан ук зәмһәрир тәмугысының бозы булып каткан күңел ничектер эреп киткәндәй сыман тоелды. Дөньяга, өй эченә, безнең салкын түшәк өстенә нindидер зәгыйфь кенә җылы нур иңгәндәй булды. Әле һаман түшәмгә карап бер кыймылдаусыз яткан Гөлбәдриягә таба борылды күзләрем. Бик тә моңая төсле күренде ул миңа. Шул минутта ук аның аягына егылып җылыйсым килде. «Моңарчы кылган бөтен тупаслыкларым, бөтен кансызлыкларым өчен зинһар кичерә күр, гөлкәем!» — дип әйтәсем килде. Ир-егеткә хатын-кыз алдында яшь күрсәтү оят дисәләр дә, тыела алмадым. Шундый олы, изге җан бит ул. Шундыен кыен хәлдә дә яраткан кешесеннән баш тартмаган. Баһауга караганда мине артык күргән. Алай гына да түгел, иртәгесен үк Баһауны табып кул бирмәкче булдым: кичерәм гаебен!..

Ә кайсыдыр урам түреннән өзлексез агылган сыңар тавышлы җыру адашкан аккош моңыдай һаман тынмыйдырые әле.

Агыл, болыт, агыл, болыт,
Тауларга кагыл, болыт шул...
Хатлар язмассың микән бер,
Сагынган чагың булып...
Сагынган чагың булып...

Менә шул чакта инде Гөлбәдриянең түшәмгә терәлгән күзләре кинәт зурайды, як-якка борылды да, ай шәүләсе төшкән тәрәзәгә тукталып калды. Ниндидер әчке сыкрау тавышы ишетелгәндәй булды. Миңа гы-

на шулай тоелдымы, әллә чынлап та шулай килеп чыктымы, белмим. Нәрсә дигән сүзе бу аның? Моны ничек аңларга? Ничек итеп моңа түзәргә кирәк? Күздәге яшь шундук кипте, нечкәргән күңелнең ефәк кыллары зеңләп өзелде, таш йодрыктай ачу гына калды күңелдә... Дөбер-шатыр ишек-капка ачып, урамга ташландым. Тапмадым Бәһауны. Тыны-көне бетеп артымнан килеп җиткән Гөлбәдрия кайнар күкрәкләре белән җилкәмә асылынды. Тавыш-тын чыгармады. «Кирәкми, бәгърем, ярсыма...» — дип пышылдый-пышылдый гына өйгә алып кайтты мине...

Иртәгесен авылдан чыгып киттек.

Чаллыга җиткәнче аерым атларда туры килү бик әйбәт булды. Алда да шулай булуын көткәнием дә, барып чыкмады. «Икебез ике якка китәрбез, берең юлына берең аркылы төшәсе булмас, кем үле дә, кем тере, кемгә ни язган...»—дип өметләнүем бушкарак булды. Сугышка җибәреләсе баталиунда сине, мине, аны бер взводка билгеләгәннәр булып чыкты, үзең дә беләсең... Кисәк кенә дөнья тараеп китте. Командирга әйтеп тә карамакчыем, түлке ничек сукалап чыгасың аны? Ул чагында үземнең андый хәлне аңлатып бирерлек тел дә югые миндә. Булса да ни кылырыең, кешегә әйтелә торган сүзмени ул?..

Кулга мылтыклар алдык, сумкаларга патрон тутырып, каешларга бәйләдек, арка капчыкларын астык.

Ипи дә патрон, яшәү дә үлем.

Сәер килеп чыгадырые бу. Сәер шул... Кулга мылтык килеп кергәч, минем күңел дә әллә ничек сәерләнеп китте, хәерсезеңне...

Гомер буе шулай бәхетсез булып яшәрбез микәнни без? Ә бер-беребезне яратабыз ич! Әзме йөреп кавыштык, әзме җырулар түгелде йөрәкләрдән? Мин ул җыруларны гармун белән сайратсам, Бәһау аларны минем өчен тел белән әйтеп бирә дип уйлыйдырыем. Дивана түгел диген инде, ә? Кеше өчен кеше җырлап бирәмени инде сөю җыруын? Оялмаган да бит, мин чын ихлас күңел белән яратып, җаннарымны бирердәй булып йөргәнне белә торып, ул да гыйшык тоткан, имеш! Гыйшык кынамы соң? Үзенеке итәр өчен әнә нишләгән бит. Ата кыргый, ата дуңгыз икән. Менә шуны дус итеп йөр! Җан чиркана, йөрәк куырыла бу әшәкелектән. Гомер буена төзәлми торган җәрәхәт салды, гомер буе кара кан агып торачак йөрәктән... Үләргә кирәк миңа, үлеп кенә котылып булачак бу хурлыктан.

Ятлар белән уртак ярны
Сөйсәң ни, сөймәсәң ни!..

Колак төбемдә шул җыру ертыгы яңгырыйдырые сугышка кергәндә. Мылтык, пулемет, туп тавышлары да күмә алмады аны. Бер туктар әле ул җыру дип, атладым да атладым, бардым да бардым. Калсам да барыберие, үлсәм дә...

Үзең беләсең, акуп казып, җиргә тезелеп ятып сугыша торган иске сугыш түгелие бу. Безнең бәләкәй генә взвод ярты чакрымга дип әйтерлек иңгә сибелеп куадырые акларны. Мин озын буйлы булгач, уң флангыда калдым, сине уртага куйдылар, кече гәүдәле Бәһау сул флангыга эләкте. Ходай үзе кушкандыр инде. Көн дә саен ян-тирәңдә җан көеге булып йөрсә, нишләриең?..

Шулай бардык. Тора-бара син бик тә хәтәр комсомол булып киттең. Көн саен янга килеп, үзем белгәннәрне өйрәтә-өйрәтә, теш төбенә төшә торганыең. Мин үз дошманыбызның аклар, патша әфисәрләре, генераллар, алпавытлар, байлар, иске заман яклы кешеләр икәнен беләдерием инде. Ә менә Бәһауны кая куярга аптырыйдырыем. Ул да дошманым бит минем. Акмы ул, карамы, баймы, алпавытмы, буржуймы? Юк, минем шикелле үк авыл малае. Көн күрмешләре дә безнекечә. Ә үзе дошман. Дошманның да ни төрлесе әле! Минем мыскалланмаган ефәктәй саф көйләй саклап, сөйгән ярымны пычраткан дошман! Бер саф күңел-

ле кыз баланы хурлыкка төшереп, кан җылаткан дошман! Яшәргә тиешме ул дөньяда! Тиешме?! Әйе, мин ул чакта сыйнфый дошман белән шәхси дошман арасындагы аерманы белми идем шул әле. Миңа дошманнар бар да дошман иде.

Син шулай еш килеп безне әгитләгән чакларда, халыкка әшәкелек иткән кара дошманнар хакында сөйли башлагач, сорау бирдем:

— Баһау да миңа кара дошман, алайса?.. — дидем. Син урыныңнан чәчрәп торгандай аягүрә бастың да шаккаткан тавыш белән әйттең:

— Саташтың мәллә, Гафар абый? Ни сөйлисең син? — дидең.

Җавап бирүдән үземне көчкә тыеп калдым. Авыз ачсам — бөтен взвод алдында сүтелеп ташларга туры киләчәгие... Менә шул көннәрдә минем элекке уйларым бөтенесе дә пира-зара килде. «Туктале, — дидем үземә, — ни өчен мин үлем эзлим әле бу башка? Минем ни гаебем бар? Ни өчен мин үләргә тиеш? Юк, мин яшәргә тиеш! Гаепнең төп башы — Баһауда! Гөлбәдрияне көчләп кан җылаткан да — ул, безне хурлыкка салган да — ул. Икебезнең дә саф сөюебезне таптап, бәхетебезне тартып алган да — ул! Моннан да әшәке дошманның булуы мөмкин түгел. Ул үлсен! Сугыш — аны йотсын. Ул исән калып илгә кайтса, безнең якты көнебез тагын караңгы төн булып әвереләчәк! Сугыш аны йотсын!

Сугыш — аны да, синең белән мине дә, бәхеткә каршы дип әйтимме, йотарга ашыкмады. Амур ярларына килеп җиттек. Курку төште күңелгә: исән кайтса?.. Юлга аркылы үскән шайтан таягы кук аяк-кулны һаман чагып торса! Безнең бәхетле тормышны һаман бутап торса? Иөрәкләрдән кара кан тамып торса?..

... Амур аръякларындагы сопка тауларының берсенә атыша-атыша күтәрелгән чакта капланып төште Баһау... Менә шул урын бүген дә күз алдымнан китми минем...

Гафар абый авыр гына ыңгырашып куйды.

— Китми һаман... — дип кабатлады ул.

Минем колаклар үрә басты. «Нәрсә сөйләнә бу, саташа мәллә?» — дип уйладым. Сикереп торып, күзләренә текәлдем. Ул дәвам итте:

— Аны күмгәндә сөенеп тордым. Гомеремдә беренче тапкыр сөенеп тордым әдәм баласы үлгәнгә. Ул минем кара дошманымые. Бүтәнчә булдыра алмадым, Хәйбери туган, — диде. — Бик күп баш ваттым, бик күп атналар, айлар уйладым. Шулай кирәгие, бүтән гайри юл югые минем өчен. Әгәр дә мәгәр ул да исән кайтып килсә, Гөлбәдрия белән безнең тормыш җәһәннәм чокырына әйләнәчәгие аннары. Ә бу фани дөньяда башкалар кук тигез, бәхетле булырга, җырудагыча сайрашып кына яшәргә безнең дә хакыбыз бар иде ләбаса! Бар иде!..

Гафар абый тирән бер сулыш алып куйды.

— Безгә каршы килгән кара дошманнарның барлыгысын да кырыпсебереп түккәч, туган-үскән җирләргә кайтып килдек,—дип дәвам итте аннары. — Зарланыр хәлем юк, Гөлбәдрия тутаң сагынып, чигенә чыккысыз куанып-шатланулар белән каршылады мине. Элекке күңелсезлекләрнең берсе дә булмагандай матур итеп яши башладык без аның белән. Мин киткәндә яңа туып кына калган Идрис улым бишектән төшкәние инде. Суйган да каплаган — үзем. Эре сөякле, үткен күзле булачагы әллә каян күренеп тора...

Гафар абый хәтта елмаеп куйгандай итте. Баласы үзенеке булуга, инде бишектән чыгып дөнья буйлата җәяүләп атлый башлавына сөенә иде ул. Ә минем күзләр һаман аның йөзенә текәлгән килеш. Аның бу хәтле үк зур гөнаһ кылуына бөртек тә ышанасы килми. Мине сынамак өчен генә әйткәндер дип уйлым.

— Ник син үз-үзеңә шундый авыр гаеп ягасың? — дип сорадым мин аптырагач.

Хәзер инде ул гаҗәпләнеп миңа төбәлде.

— Гаеп дисеңме? Гаеп микән соң бу? Ә барые микән бүтән төрле

берәр чара? Шулай бик олы язык кылдым микәнни? — Шундый сораулар белән күмеп ташлады ул мине. Берсенә дә ансат кына җавап бирерлек булмагач, мин сүзсез калдым.

— Ә хәтереңдәме, — дип яңадан башлады ул, — сугышта чакта бит «дус-дошман» турында күп кенә бәхәсләшә торганыек. Шуларның берсендә син ничек дидең?

— Ничек? — мин әйтәм.

— Ә менә ничек: «Ул халык бик чуар төстә бит,— диде Зимагур Галәү. Себер шахталарын бик күп таптаган егет иде ул.— Шуны ничек аерып бетерәсе?»

Озак бәхәсләштек. Ә син, безгә караганда әз генә булса да белдекле егет, болай дидең:

— Халык бәхетен урлаучылар — бар да дошман!

Бу сүзең колакка бик нык кереп утырды минем. Көн уйладым, төн уйладым. Мин кем? Халыкмы, түгелме? Атам-бабам үз көче белән көн күргән. Мин дә авыл эше белән аунап үстем. Мин дә халыкның бер тамчысы булдым. Яр сөйдем, мең алтыннарыңа биргесез бәхет иясе булдым. Кем урлады минем шул якты бәхетемне? Бәһау урлады! Ул безнең икебезне дә мыскыллап бәхетсез итте. Шулай булгач, кем булып чыкты ул Бәһау? Дошман булып чыкты. Кара дошман! Кем хөкем итәргә тиеш аны? Мин хөкем итәргә тиеш аны!

Гафар абый «уф-ф-ф» итеп бер сулыш алды. Түшәмгә төбәлеп тагын тын калды.

Мин дә бик аптырашта идем. Бәһау турындагы хөкеме белән стенага китереп терәде ул мине. Ничек хәл итәргә?..

Карчыгы самавар кертеп өстәлгә утыртты. Табын әзерләп, чынаякларга чәй ясады. Өйләренең ян тәрәзәсен ике якка ачып җибәрде, апак чәчәкләрен җил тибрәткән балан ботагы эчкә керде. Ул чәчәкләрнең әчкелтем хуш исе чәй тәмена кушылгандай тоелды.

Мине әле һаман таныштырмаган карчыгы чыгып киткәч, Гафар абый сүзен алга алып китте.

— Әйе, өйгә кайттым. Сайрашып та гөрләшеп кенә дигән күк, саналмаган көннәр, атналар, айлар яшәдек. Төштәгедәй рәхәт чаклар, бәхетле көннәр булды ул...

Ә бер иртәне, күптән кимәгән иске-москыны киеп, урманга киттем. Диләнке кисәргә. Әбәткә утыргач, кесәдән пычакны чыгарганда нәрсәдер иярер, тастымалга төште. Алып баксам — мөштек. Әллә кайчангы. Әле үсмер чакта ук, самасад тәмәкесен четердәтеп бер суырганда, сары май шикелле тамак төпләренә утырып, тынны каплый башлагач ясалган мөштек. Кипкән имән ботагыннан кырып-сырлап, эчен утлы тимер чыбык белән тишеп, тәмәке кыстыра торган башына җиз балдак кигезеп, икебезгә ике мөштек ясаганые Бәһау. Андыйга кулы остае аның. Менә шул нәрсә кесә төбендә яткан. Менә шуны кулга алуыма, аңа Бәһау кулы кагылганлыгы кинәт хәтергә төште дә утлы күмер тоткандай булып, кулым куырылып китте. Тиз генә каршыдагы учакка ыргыттым. Утка килеп төшкәч, башта четертәп, аннары әллә ничек юеш әйбердәй чыжылдап янарга тотынды ул. Туп-туры булып нечкә генә аксыл төтен чыгара башлады өскә. Күтәрелә-күтәрелә кеше буйлыгы булды. Кеше буйлыгы булгач, шул ак төтен эченнән Бәһау күренә башлады. Ләхәүлә укып, як-ягыма төкерендем, юкка чыкмады. Төсе-бите, кап-кара ике күзе аермачык. Ике кулын як-якка сузган. Өрәгене бу аның. Күзләремне тиз генә читкә бордым. Өрәк һаман югалмады. Күз алдыма баскан килеш, учагы-ние белән әкрен-әкрен каршыдагы тау сыртына таба калкынды да шунда туктап калды. Тагын бордым күзләрне, тагын йомдым четердәтеп. Юк, котылып булмады, өрәк һаман күз алдымнан китмәде...

Менә шул көннән башлап, мин һаман моңая, һаман боега, һаман эчтән сыза башладым. Бу хакта мин эчтән тындым, Гөлбадриягә ләм-мим

бер сүз ычкындырмадым. Ычкындырмасам да барыбер сизенде ул. Пошынды, үзе дә көя башлады.

...Егерме беренче елның языннан ук тамчы бер яңгыр төшмәвен син үзең дә беләсең. Ачлык буласы алдан ук билгеле. Сез әртил булып Себергә җыендыгыз. Сезнең белән мин дә киттем. Нигә киттем? Кешеләр бала-чагасын, ишле симиясын коткару өчен кубынды. Ә мин инде ике баласы булган хатынымны, ата-ананы калдырып, берүзем чыгып киттем. Дүрт имана җир бар, ат-тун бар, симия зур түгел, кыймылдаганда монда да көн күреп буласы. Ә мин киттем... Бер дә китмәсием, әнә шул денсез Баһау өрәге кубарды мине. Юк, куркып түгел, алланың бирмеш көне күз алдымда торган шул өрәктән котылырга теләп киттем...

Кайчандыр үзебез Колчакны куган юллардан илле көн буе бардык, җәяүләп барган шикелле. Шулай да хафаланмадым. Юл ыгы-зыгысы белән әлеге ак өрәк онытылып торды. Күсе күзедәй генә утлы шахтер лампасы белән караңгы җир астына төшүләр, тар ләхеткә ятып күмер чабулар, упшый баракта шау-гөр килеп ятулар да әйбәт булды. Җан карачкысы күз алдымнан китте. Аның урынына хәзер Гөлбәдриям килеп басты, ике кулына ике малаемны күтәргән. «Әтиебез, кайт инде! Без сине бик-бик сагындык бит!» дигән сүзләре дә гел ишетелеп тора колакка. Бу инде мин үзем сагыну галәмәтедер шул хәтле...

Шулай итеп, ел ярым узуга кайтып киттем авылга. Дөрес икән — барысы да сагынганнар. Тегеләре кечкентәй бит әле, ә менә Гөлбәдрия бик тә инде өзелеп сагынган. «Ачлыкны да уздырып җибәрдек, эткәй-энкәйләр дә исән, улларыбыз да тәгәрәп үсәләр. Китмә инде, җаным, беркая да бүтән!» — ди бу. Бик риза, бер дә китәсем килеп кайтмадым. Күп йөрдем, җитәр. Буразнага чынлап торып аяк басар, иген игәр вакыт җитте...

Җитте дә бит җитүен... тик барып чыкмады шул, уйлап кына калдым. Ике-өч ай уздымы-юкмы, тагын чыгып китәргә туры килде. Монысында Донбасска. Шул ук өрәк аркасында. Бу юлы ул бөтенләй котырынып китте: Гөлбәдрия белән икебезнең арада кулларын аркылы сузып тик тора. Мине аңар җибәрми, аны — миңа. Менә бит нишли алла каргаган өрәк! Минем хатынны миннән саклый! Каян килгән? Мондый хәлгә кем ышаныр, әдәм көлкесе!..

Ярый әле, шунысы әйбәт — Донбасска ияреп килмәде. Җан тынычлыгына тиенеп эшли бирәм Суфия шахтасында...

Ел тулар-тулмаста тагын сагына башладым өйдәгеләрне. Матурлыгын әле һаман да саклый белгән Гөлбәдриям, күпереп торган чәч толымнарын таратып, төшләремә керә. Ә малайлар икесе ике яктан итәгенә ябышканнар...

Тагын кайтып киттем авылга. Озак та узмады — тагын Баһау өрәге! Тагын чыгып киттем. Бу юлы инде Уралга...

Шулай авыл белән чит арасында, хатын белән Баһау өрәге арасында киләп сарып йөри торгач, «ябалак шурпасын» чүмечләп чөмерүгә бирелеп киттем. Исерек баштан җиңелрәк була дөнья. Гөлбәдриядән әкрен-әкрен бизә башладым. Ни өчен? Үзем дә белмим, үзем бозыклыктандыр дип кенә уйлыйм.

Ватан сугышында яраланып, медсанбатка эләккәч, карт солдат дип шунда калдырдылар, атлы санитар булып йөрдем. Без казыган каберләр санап кына бетерерлек түгелие. Баһау өрәге дә минем белән бергә йөрде. Тора-бара ул минем җан газабыма әйләнде... Өйгә рәтләп хат та язмый башладым.

Фронттан кайткач та шул ук гадәтләр сузыла бирде минем. Гөлбәдриям сары саргаеп кына үлде, анык беләм!. Анык белсәм дә, күмәргә, каберенә сыңар уч туфрак салырга да кайта алмадым. Арча Мытыесында эшлидерием, бүтән хатын белән торадырыем, исерегием...

Шулай йөри торгач, инсульт сукты мине, чулакка әйләндем, уң кул авызга җитми хәзер... Ярый, рәхмәт улларыма. Әниләре аларны кешелекле итеп үстергән, мине урамда калдырмадылар. Үзләре ерак шәһәрләрдә хезмәт итсәләр дә, ата-бабадан калган менә бу куышны рәткә кертеп, миңа тәрбияче карчык табып, яшәү мөмкинлеге бирделәр. Мин хәзер эчә дә алмыйм, тарта да алмыйм, ире ташлаган хатыннар артыннан чаба да алмыйм. Тәүфыйкка утыртты дөнья. Яр якасына китереп бастырды. Әҗәлнең кулы — муенда. Бүген буамы, иртәгәме... Баһау өрәге һаман минем белән бергә. Аның белән сөйләшеп йөрим мин хәзер. Тик ул эндәшми, ияк кенә кага. Хәер, өрәкләргә сөйләшергә ярамый диләр бит... Аннары миндәге ачуын да исеннән чыгармый торгандыр ул...

Гафар абыйның болай сәер итеп, көлеп сөйләшкәндәй сүзләре күңелгә ятмый башлады минем.

— Әллә ничеккә таба борылды әле сүзең, — дидем мин, ризасызлык белдергәндәй итебрәк. — Уйнап сөйләшәсең шикелле...

— Уйнап, дисеңме? Булыр, булыр, туган, — диде ул исе китмичә генә. — Кеше дигәнең, бер генә юанычы да калмаса, үкереп җыларга да хәленнән килмәсә, үзеннән-үзе көлә башлый. Бу — аның актык көче, актык мөмкинлеге. Әдәм баласының үзе кылган явыз гамәле гомерлек үкенечкә, гомерлек әрнүгә китеп, мәңге басылмас җан газабына әйләнсә, шулай үзеннән көлгән була икән ул. Юаныч таба, янәсе. Баһау мәрхүм дә үзе кылган шул җирәнгеч явыз гамәле өчен җан газабы кичергәнгә шулай көлемсерәп йөргәндер. Баштарак, очрашкан чакларда һаман сүзсез генә көлемсерәп узуын миннән көлүе дип уйлаганыем, үз башыма төшкәч кенә аңладым, үзеннән көлүе булган икән, эчтән зар җылавын күрсәтмәс өчен көлүе. Шул көлүе белән ул Амур якларына хәтле барып җитте, узып та китте. Шул көлүе белән авылга да әйләнеп кайтуы барые, курыктым, Гөлбәдрияне бөтенләй миннән тартып алыр дип курыктым. Әйткән биț ул аңар: «Башым исән булса, барыбер үземә кайтарып алмыйча калмыйм мин сиңе!» — дигән. Ант иткән. Менә шуңар күрә дә Баһау сөзәк таулардан атыша-атыша менгәндә минем пуле, минем куркак пуле... аны җиргә каплады... Мин дә көлдем. Иптәшләр аны күмгәндә көлемсерәп тордым. Баштарак сөенечтән иде бу... Аннары — җир күтәрмәс олы языгымны каплар өчен булды. Ә хәзергесен — үзең күрәсең. Тәмуг утлары төбендә янган җан газабыннан тышкары бәреп чыккан гарип бер шәүлә генә бу. Үкенеч тудырган өрәк...

Мин нәрсә дип әйтергә дә, нинди хөкем чыгарырга да белмәдем.

Артык гаҗәпләнмәдем дә...

Һәр икесе дә җинаять. Тетрәндергеч явызлык...

Мин шулай уйга калып утырганда, Гафар абый кабат авыз ачты.

— Үтенечем шул, — диде ул. — Мин бу олы языкны үзем белән алып китә алмыйм. Тиешле җиренә җиткер, тиешлесен миңа бирсеннәр, күтәрәм...

— Борчылма, Гафар абый, һәр икегезгә дә заман үзе хөкемен әйтер...— дияргә мәҗбүр булдым мин.

— Инде иң актык гозеремне дә тыңла, Хәйбери туган,— диде ул.— Мине Гөлбәдрия тутаң янына күм, зинһар дип әйтәм!..

Монысы иң кыены иде минем өчен.

— Кабул итәрме соң ул? — дип сорадым.

— Итәр, изге күңелле булды ул, олы җанлы. Мин үз гаебемнең барын да аңлатырмын аңар, бәхилләр ул. Безнең беренче саф сөюебез хакына кабул итәр ул мине...

Әнә бит ул дөнья дигәнең ни төрле! Үзең ышанмаган теге дөньяларга да әдәм баласын үзе теләгәнчә җайлап озатырга мәҗбүр итә...

Сүзне Мөслимгә бирде комиссия.

Башта ук: «Вәт мин сөйләсәм...» — дип шәпләнсә дә, ничек башларга белмичә, ык-мык килеп утырды Мөслим.

— Сабагын оныткан малаең! — дип, картлачлар күләргә тотынды. Үзе дә алар белән көлә торгач, тел ачкычы тапты бугай тагы:

— Бик куптәнге хәл инде бу, егетләр, — дигән булып, баш ягалап җибәрде. — Ул чагында миңа унбиш тулып бара иде. Канат үстереп килә торган сары авызлы чәукә баласының дөнья киңлегенә таң калып, оясында пыр-пыр очынгалый торгач, җиргә егылып төшүен күргәнегез бармы сезнең? Нәкъ әнә шул чак иде бу...

Укулар кайчан башлануын белешү исәбе белән сентябрь башындагы бер кояшлы көндә мәктәпкә килдем. Бездән бер генә чакрымдагы күрше авылда. Былтыргы үзебезнең класска керсәм, анда малайлар, кызлар утыра. Күбесе бишенчедә бергә укыган иптәшләр булса да, миңа таныш булмаган яңалар да күренә. Башка авыллардан килгәннәр, күрәсең.

Алар да яшь ягыннан минем белән бер тирә. Хәзер булса, унбиштәге малайның бишенчене генә бетерүе бик сәер тоелыр, «ничә ел бер класста ыштан төбе туздырдың?» дип күзен дә ачырмаслар иде. Ул чакта безгә эзлекле белем эләкмәгән, шуңадыр инде, үзебез колга буе булсак та, уку ягы бармак буе гына иде.

Яңалар белән искеләр берхәтле «иснәнеп» дигәндәй торганнан соң үзләшә төштеләр. Укулар кайчан башлана, быел нинди дәресләр кирәчәк, кемнәр укытачак, кем каян килгәне хакында әңгәмә китте. Аннары яңа малайлардан берсе фортепианога барып тотынды. Безгә аны былтыр өяз каласыннан кайтарткannar иде. Ул үзе рояль белән пианиноның бабасы шикелле карт булса да, матур гына авазлы, нәкъ тальян гармунның «аяклысы». Безне аңарда нота белән уйнарга өйрәтеп тә маташтылар: «До, ре, ми, фа...»ларны байтак кычкырттык. Тик нота гыйлеме безгә йокмады. Кайберәүләр болай гына алдырды, хәтта мин дә бер бармак белән тыкылдатырга өйрәндем!

Исмәгыйль Биков дигән әлеге малай шактый ярыйсы гына дыңгылдата, хәтта ике кул белән дә маташтырган була. Байтагыбыз сокланып аңа карадык һәм янына җыелдык. Кызлардан, мин белмәгән яңаларның берсе, җыр башлап җибәрде, барыбыз да кушылып киттек. «Ком бураны», «Тәскирә», «Уел», «Әрбет», «Тәфтиләү», «Сәҗидә» — ул чакта яңа таралган җырларның берсе дә калмады. Үз тавышым фәләнчә генә икәнен бик яхшы сизсәм дә, башкалардан калышмыйй җырларга, бу яңа көйләрне өйрәнергә тырышам. Аларның матур тавышлары арасында минем ярык бырргы да бик үк бозау мөңгерәве чыгармый сыман. Хәтта моңлы да булып ишетелә үземә. Күңел талгын җилдә очкан күбәләк шикелле тирбәлеп, рәхәт киңлекләрне, чәчәк тулы болыннарны гизә. Ничектер нечкәреп, сафланып, моңсуланып киткәндәй була. Ниндидер җылы дулкыннар өстендә чайкалам төсле. Башкаларга карыйм: алар да җыр белән мавыгып, үзләре дә сизмичә, шундый ук татлы бер хис кичерәләр, ахры.

Бу көйләр, бу уен коралы, бу мәктәп, мондагы укулар һәм бу дөнья үзе — минем өчен бөтенләй яңа. Мин боларны күреп, белеп, ишетеп үскән малай түгел. Мин белгән дөнья бүтәнчә иде, һәм бу стеналардан чыгып өйгә кайтып кергәч тә, мин тагын шул төссез тар дөнья эченә чумачакмын... Бәлки шуның өчен дә миңа монда бик рәхәттер. Бәлки шуңа да мин монда шундый моңсу булып киткәнмендер...

Ниһаять, җырлый-җырлый ялыга төштек бугай, дәртле тавышлар кичке гөрләвекләрдәй әкрен-әкрен үз ярларына кайта башлады. Әлеге Исмай «Әпипә»не уйнап җибәрде, ләкин берәү дә төшеп биемәде. Безнең

як кызлары биегәнен минем, гомумән, күргәнем юк. Хәтта малайлар да биемәде, без дә «чабата» биюен генә беләбез шул. Аннары оялабыз да. Кызлар алдында бит... Юк шул, булмый, әллә нәрсә итәктән тарта. Йөзләрчә ел буена килгән кыюсызлык һаман үз богавыннан ычкындырмый иде, күрәсең...

— Әйдәгез, флиртле уйныйбыз! — диде кемдер кызлардан берсе.

— Әйдәгез, әйдәгез! — диештеләр һәм бары да яңадан өстәл тирәсенә җыелышты.

Нинди уен икән ул? Мин аны күргәнем дә, уйнаганым да юк. Бу инде тагын минем артталык. Белмәгән уен бик кызыклы тоелса да, керешеп китү хәтәррәк: шул белмәвең аркасында көлкегә калсаң?..

Аулак өйләрдә «пута йөртешле» уйнаганда, кайбер йомыкыйрак кызның аркасын шештереп бетерәләр. Ул абайлап өлгергәнче, «шалт!» берне тегенең аркасына ишкән пута белән. Әйләнеп каравына пута әллә кайчан кемнеңдер тез астына кереп киткән була. Эзли башлый, «шалт» икенче яктан. Кызарып, бүртенеп бетә, җылар хәлләргә җитә, бичаракай.

Монда да шундыйрак хәл булмас микән? Шулай да өстәлнең бер почмагына килеп урнаштым: гел үк мыкый булырга да ярамый ич.

Шәйбәк мулласының елтыр күзле һәм «шылтыр» сүзле кызы Заһидә жикет кесәсеннән карта чыгарды да өстәлгә сибеп ташлады. Юк, карта түгел бугай: аннан таррак, озынчарак, арка ягы да чуар түгел. Бар да урелеп берәр карта алды да, ниндидер бер исем әйтеп, икенче кешегә бирә башлады. Мин дә карта алдым. Әйләндереп карасам, аның бит ягы ак икән һәм анда китап хәрефләре белән минем өчен бик сәер тоелган сүзләр басылган:

**Кара карлыган:** «Сезнең күзләр сихерле, исерткләр шикелле».

**Күбәләк:** «Чәчәкләрегезгә кунсам иде, бәхетле булсам иде».

Кара син аны, гелләрем шигырь белән язылган кук!

Уенны миңа аңлатып бирделәр: әйтәсе килгән сүзең булса, шул катыргылардан эзләп табасың да җөмлә башындагы исемне әйтеп, үзең теләгән кешегә бирәсең... Шәһәр уены икән бу, укый ала торган кешеләр өчен генә. Безнең аулак өйләрдә уйный торган түгел.

Кемгә, нәрсә әйтим икән соң?.. Күңел тулы. Мөлдерәмә. Әллә нинди үзем дә белмәгән рәхәт бер моң менә-менә түгелеп китәргә торган шикелле. Тик берәүгә дә атап әйтә торган, өзелеп әйтә торган аерым сүзем юк төсле. Алар һәммәсе дә әйбәтләр, һәммәсен дә яратам мин бу яңа дусларымның. Ә кызлар, малайлар уйныйлар. «Күке», «Канәфер», «Әкәм-төкәм» дигән исемнәр әйтеп, бер-беренә катыргы бирешәләр дә, андагы миңа билгесез сүзләрне укыгач, үзара көлешеп алалар. Кайберләре бер дә көлми. Тиз генә җавап эзләргә тотына. Аларга кызык, ә миңа?..

Мин уйга чумдым. Нигәдер моңсу булып китте. Әнә нинди яңа уеннар, нинди матур көйләр бар икән дөньяда! Мин аларның берсен дә белмим. Ә теге малай? Нинди оста итеп уйный. Кайчан, кайда өйрәнеп өлгергән? Андый уен коралы безнең авыл җирендә күренгән нәрсә түгел бит. Ә мин — бер бармак белән аксак-туксак бер көй! Малайның миңа караганда әллә ни өстенлеге дә юк шикелле. Хәер, өсте-башы рәтлерәк. Кара сатиннан булса да пинжәк, чалбар кигән. Аягында да ниндидер күн заты. Буйга да солы буедай гына миннән калкурак, төс-бите дә ямьсез түгел, авыз-борын, күз-керфек, каш-колак дигәндәй бар да үз урынында, бер дә кыек-мыегы юк.

Ә минем өстә яз көне шушы мәктәптән бирелгән буй-буй ситсыдан сабан туена тектереп кигән бөрмә билле күлмәк, аякта оек-чабата, тезенә ямау салынган чалбар. Гомеремдә беренче мәртәбә чалбар киеп, шушы авылга сабан туена килдем. Малайлар көрәше башланды. Минем дә бик чыгасым килә, тик оялам. Мәйданга Шәвәли Хәсәне дигән мак-

танчык малай баскан. Күңелне шайтан котыртып тора: «Чык инде, чык,— ди,— син аны егасың ич!» — ди. Чынлап та, болай уйнап көрәшкәндә мин аны әйләндереп кенә салам салуын.

Әлеге шайтан мине этеп-төртеп тәки кертеп җибәрде бит мәйдан уртасына. Күзгә ак-кара күренми, килеп җирдәге тастымалны күтәрдем, шундук билләрдән алыштык. Гомердә беренче тапкыр мәйданга чыгып көрәшү! Ашыгам, тиз генә бөтереп атасы килә. Шул ният белән йодрыкны касыгынарак тыгып, билен кысып алдым да, тез чүгеп, уң якка селтәмәкче булдым тегене. Ул күтмәгән якка. Чөнки мин сулагай, минем өчен ул берни дә түгел. Шулай уйлап чүгүем булды, нәрсәмдер «пытырт!» итеп куйды. Бактың исә, тар чалбарның тез күзе песи авызыдай ерылып та чыккан. Шундук дәрт сүнеп, гайрәт чикте дә куйды. Өйдә кубасы тавыш колак төбемдә яңгырагандай булды. Минем шул әйле-шәйле хәлне сизеп алган Хәсән тиз генә әйләндерде дә салды мине. Нинди хурлык! Бердәнбер чалбарың да ертылсын, мәйдан уртасында шапылдап та ят!.. Ул тирәдән ничек чыгып сызуымны сизми дә калдым.

Әллә ничек шундый фартсызрак малай идем инде мин. Төс-бит ягыннан да ходай юмартлык күрсәтмәгән: «песи борын» дип, «чепи күз» дип, җелеккә тияләр иде каз көткән чакта. Мондагы иптәшләр начар түгел: кимсетмиләр, мыскыл да итмиләр. Билгеле, мин алай ук күзе ачылмаган әрлән баласы түгел, теге усал малайлар юри үтереп әйтергә тырышалар иде. Шулай да мин үземне сабакташлар белән тиң куя алмыйм. Аларның байтагысы башка төрлерәк, хәллерәк тормыштан, күбрәк укыганнар, аң ягыннан миңа караганда өстенрәк. Әнә бит шул флиртле уенны да белмим икән мин, ишеткәч авыз ачып калдым, аларның исе дә китмәде: әйтерсең ата-бабадан килгән уен!

Мин шулай үз-үземнән чәчәк коеп утырам, ә күңелле һәм көлкеле уен дәвам итә. Ничектер кушылып китәсе иде бит. Кызларның кайсынадыр үзең башлап берәр шаян сүз кыстырмасаң, кем синең белән кызыксынсын? Әрсезрәк бул, егет!...

Мәгәр әрсезләнергә өлгерә алмадым. Яңа кызларның бая җыр башлаган Рәмзия исемлесе бер дә көтмәгәндә миңа бер катыргы сузды да: «Шомырт чәчәге», — диде.

Мин тиз генә катыргыдан шул исемне таптым да һәр сүзне йотардай булып күз йөгерттем: «Сез нигәдер бик моңлы күренәсез, нindидер сагышыгыз бар, ахры?.. Юату фирештәләре юлдаш булсын сезгә...»

Әлбәттә, мин хәзер бу сүзләр нәкъ шулай иде дип раслый алмыйм, әмма «моң», «сагыш», «фирештә» сүзләре, һичшиксез, бар иде. Мин ул сүзләрнең матурлыгына сокланудан тетрәп киттем. Күктән иңгәндәй көчле, шәфкатьле, исертер дәрәҗәдә татлы булып тоелды ул сүзләр. Кинәт бөтен тәнемә, җаныма ут йөгерде. Ялгышмадыммы дип, тагын бер кат укыдым да, ничектер, күзләрне кыюсыз гына күтәреп, аңа юнәлттем. Ул да, оялчан гына елмаеп, карасу озын керфекләрен түбән төшергән. Шулай да аның зәңгәр күзләре сызылып кына күренеп тора. Алар шундый ягымлы һәм җылы итеп карыйлар төсле, әйтеп аңлатырга сүз табу мөмкин түгел. Аксыл-сары ефәк сыман чәчләренең күкрәгенә сузылып төшкән ике калын толымы, комда яткан нindидер озын алтын балыклардай, ул сулыш алган саен кыймылдап куя.

Йөрәккә май булып ягыла торган мондый әйбәт сүзләрне минем әле үз гомеремдә бер генә тапкыр да ишеткәнем юк иде. Алай гынамы соң? Мондый алтын толымнарны да, кыска калдырып киселгән маңгай чәчләрен дә, сөйкемле керфекләр астыннан оялчан гына карый торган шундый зәңгәр күзләрне дә беренче тапкыр, бары тик хәзер генә күрәм икән. Монарчы мин бернәрсә дә күрә белми торган дөм сукыр булганмын, ахры!

Ни генә дип җавап бирим соң? Өстәлдә чәчелеп яткан катыргыларны кабалана-кабалана укый башладым. Барын да берочтан укып

чыктым бугай, әмма җавап итәрдәй сүз тапмадым. Бар да сыек, суык шикелле. Минем йөрәккә кинәт кабынган утның көчен, кайнарлыгын берсе дә әйтеп бирә алмас төсле! Ә җавапны шул катыргылардан гына табарга кирәк бит. Нишләргә соң? Үзең язарга ярамый, уен бозыла. Бозылса бозылыр! Оек кунычына бөкләп тыккан дәфтәр белән карандашны сиздерми генә тартып чыгардым да, уч төбедәй кәгазь ертып, җавапны үземнән яздым. Нәрсә яздым? Хәзер үтерсәгез дә әйтә алмыйм инде. Кыз аны өстәл астына гына яшереп укыды да кып-кызыл булды, миңа күтәрелеп карарга оялды. Миңа ни кулдан язып, ни катыргыдан булсын, җавап та бирмәде. Мин үзем дә бик уңайсыз хәлдә калдым: әлеге зәңгәр күзләренә яңадан бер карарга, бер кәлимә сүз әйтергә көчем җитмәде.

Ярый әле, уен бетте һәм без озакламый таралыштык. Аксыбы авылы белән Янсыбы арасын гел болыннан кайтасы. Мин ул бер чакрым араны гел җырлап кайттым, хәер, бу ара ун чакрым булса да җырым бетәрлек түгел иде минем. Сентябрь башында болыннар инде шактый шәрәләнгән, көтү таптаган, карт кылган башларына пәрәвез җепләре сарылган була. Ә миңа болын тулы чәчәк, шул чәчәкләр башыннан төрле якка әллә ефәк, әллә ука, әллә көмеш кыллар сузылган булып күренә. Ул кыллардан моңарчы мин һич кенә дә ишетмәгән көчле бер көй агыла. Шуңа кушылып җырлыйм-җырлыйм да (тавыш та матур булып яңгырый бит!), аның сүзләрен кабатлыйм: «...юату фирештәләре юлдаш булсын сезгә...»

Йа ходай, шундый сүзләр дә бар микәнни дөньяда! Безнең авылда мондый сүзләр әйтеп сөйләшкән кеше гел бөтенләй юк! Хәер, кем соң алай сөйләшсен? Шул флирт уены өчен генә чыгарыла торгандыр андый сүзләр. Мин ишетеп үскән сүзләрдә бары тик зар гына, катылык, шәфкатьсезлек кенә яңгырый иде... Ә Рәмзия нинди нечкә күңелле кыз икән: сизгән бит, сагышымны да, моңаюымны да сизгән... Һәм иң матур сүзләр табып, мине юатырга теләгән. Менә кем ул юату фирештәсе! Үзең син, үзең, Рәмзия!

Шундый уйлар белән, кая басканымны да белми кайтам мин. Сукмак буендагы биек тау астыннан чыга торган чишмәләр бар, шуларга туктап иеләм дә кушуч белән су эчәм. Ник эчәм? Көз көне бит, эссе дә түгел. Шулай да изүләр чишек, битләрне җылы җил сыйпый, рәхәтләнеп эчәм! Ә чишмә төбендә аның сурәте күренә, әллә ничә вак тармактан чыга торган суларның бергә кушылып сайрашуында аның тавышы ишетелә, чишмәләрдән аерылып китә алмый торам.

Сез көлмәгез инде, дуслар. Шул чакта хәтергә ничек уелып калган булса, бер чишелеп киткәч, барын да шулай сөйләргә туры килә.

Бер дә теләмәсәм дә, шул көмеш тавыш белән сайрар чишмәләрдән, борма су буйларыннан аерылып, дивана бер хәлдә авылга кайтып кердем, йорт эшенә чумдым. Эш арасында уйлар чуалырга, хисләр сибелергә тиеш иде, югыйсә. Юк, алай булмады, көн буе Мәҗнүн хәлендә йөрдем! Иртәгесен дә, берсекөнне дә шул ук хәл дәвам итте. Күңел түремдә нииндидер күренер-күренмәс бер әйбәт, җылы якты тора кебек. Ул шундый мавыктыргыч: аны якынтынрак, ачыграк итеп күрәсе килә, ә ул ачылып бетми, бик үк якыннан да балкымый, ничектер төнге күкнең ерактагы йолдызы шикелле генә җемелди. Шул ук вакытта бик якыннан һәм нигәдер бик ерактан ягымлы бер тавыш ишетелә. Каян килә ул? Миңа эндәшәме ул тавыш? Әллә мин эндәшәмме кемгә дә булса — һич аңлар хәл юк. Шулай да миңа бик рәхәт иде бу. Һәм мин түземсезлек белән нәрсәдер көтә башладым. Нәрсә көтәм соң? Укулар башлануын көтәм икән: тизрәк, тизрәк!

Ә дәресләр нигәдер сентябрь ахырларында гына башланды. Хәер, ул чакларда әле укуларны беренче сентябрьдән үк башлау тәртибе

кереп тә җитмәгән иде, иске мәдрәсәгә кар яугач кына бара идек бит. Өстәвенә, авыл кешесенең бу айда эше дә муеннан чак була: җитен йолка, күлләргә баса — киндер батыра, ындыр суга, урман кисә, утын ташый, кышка каралты түбәләрен рәтли — бетәсе түгел шундыйлар. Ә безнең шикелле унбиштәгеләргә бу мәшәкатьләрнең юан башы элә-гә башлый бит инде.

Көтә торгач, укулар да башланды. Менә икенче ел инде — малай-лар, кызлар бергә укыйбыз. Гомердә булмаган бу хәлгә безнең артык ис китмәде. Дөрес, беренче кышта кызларны чеметкәләү, чәчләрен-нән тарту, аяк чалу, кычкыртып җылату шикелле хәлләр булгаласа да, тора-бара няләнешеп киттек тагы. Аннары борынга «ис» тә керә башлаган чак ич. Унөчтәге малай булып булмый хәзер! Барысы да ничектер егетчәрәк, җитеп килә торган кызчарак кыланган була...

Без класста унбишләп кенә. Төрлебез төрле авылдан. Унбиш-егерме чакрымнан килүчеләр дә бар. Ә Рәмзиянең Чабышлы авылы мон-нан утыз биш чакрымда икән!

Минем урын аның артындагы партага туры килде. Бу бер яктан яхшырак та булды әле. Янәшә туры килсәм, оялып җаным чыгар иде. Ә болай мин аның матур, тыгыз толымнарына, сөйкемле җилкәсенә, нәни генә алсу-ак колак яфракларына һәм арттан да бик килешле кү-ренгән бөтен гәүдәсенә туйганчы карый алам. Беркемнән оялась да, куркасы да түгел. Шулай да ул урынга туры килеп, нидер югалттым да бугай, ахры, мин. Ник дип әйтсәгез, көлемсерәп торган йөзен күрә алмыйм, саф яктылык тулган күзләренең зәңгәр елмаюын күрә алмыйм-мин аның. Ә елмаймаса, гел ачу белән генә караса, ул чакта ниш-ләр идең? — дигән, сорау да гуып куя тагы.

Ә теге Исмай дигән малай аның белән бер партада утыра, янәшә! Әллә ничек кенә килеп чыкты бу. Рәмзия башта ике-өч көн күршедәге бишенчедә утырган иде, укытучылар аны белеме буенча безнең класс-ка күчерделәр. Шул көнне Исмай аны урындыгы-ние белән күтәреп безнең якка алып чыкты. Бөтен класс гөр-р итеп көлеп торды. Рәмзия үзе дә аякларын тиберчөнә-тиберчөнә көлә иде. Тик мин генә көлмәдем. Бик ачу килде чөнки. Җебегәнлегем өчен үземне тиргәдем, әрсезлеге өчен Исмайны эт иттем эчтән генә. Җитмәсә, ул малай аны үз янындагы буш урынга утыртты. Шуннан соң үзен әллә кемгә куеп, һичнигә исе кит-мәгәндәй муенын як-якка боргалап, кукыраеп кына утырган була баш-лады. Хәер, мин юккарак кытыкланам бугай әле. Бәлки аның күңелен-дә бер этлек тә юктыр, бәлки Рәмзия аңа күз дә төшерми торгандыр...

Тәнәфесләрдә мин Рәмзияне җайлырак бер урында күрергә, үзем-нең бик сагынып килгәнлегемне, ичмаса, бер генә сүз белән булса да аңлатырга тырышып карадым. Булмады, гел башкалар комачау итте. Минем күк кыюсыз малайга аерым бер бүлмә бирсәң дә, авызыннан берәр сүз чыгар иде микән әле. Гомер буе шундый мәми авыз булдым: берәр кыз кинәт бик ошап куйса (ә яшь чакта андый хәлләр булгалый бит), өстәвенә, ул кыз чибәр дә булса, тилебәрән орлыгы ашагандай, күзләремне бүлтәйтеп һичбер сүз әйтә алмый идем.

Ул көнне шулай таралыштык. Бер сүз дә куша алмыйча, бары тик күз карашым белән генә сәламләп калдым мин аны. Бер чакрым юлны кайтуы йөз чакрым булды. Күңелне моң баскан, арканы таш баскан, җиргә хәтле бөкрәйгәндәй авырлык белән атлыйм. Шул ук чишмәләр яныннан узам, шул ук көмеш суларны кушучлап эчеп карыйм: юк, йө-рәгемә ял юк, җаныма рәхәт юк, баш түбәмдә кояш юк...

Кайтып җиткәндә күңелгә ничектер тынычлык иңгәндәй булды: «Туктале, нигә шул хәтле кара көяргә? Иртәгә күрәм ич мин аны! Кү-рәм һәм барын да әйтеп бирәм. Барын да аңлар, әйбәт кыз бит ул. Бәлки үзе дә сагынып беткәндер инде...» — дип уйладым.

Тик бу юану «юату фирештәсе» ннән килмәгән икән шул. Иртәгесен дә, башка көннәрне дә күрдем мин аны. «Исәнмесез» дидем, «Сау булыгыз» дип тә әйттем, әммәдәки сүзләр шуннан арыга китмәде. Ник дисәң, аның йөзе дә элеккечә якты түгел, күзләре дә зәңгәр нур түгеп елмаймый иде. Юк, ул сөйкемле чырай караңгы да түгел, ул күзләр төксе дә карамый, аларда фәкать битараф тынлык кына. Әйтерсең җилнең сыңар сулышы да тибрәтмәгән күл өсте. Әйтерсең теге «шомырт чәчәге» нең сихри сүзләре дә һичкайчан әйтелмәгән!

Нишләргә соң бу малайга хәзер, нишләргә?..

Тел ачып сөйләшергә кыюлык җитмәгәч, язуга күчтем. «Кош теледәй», «уч төбедәй» ләрне дәрес саен язам да парта астыннан Рәмзиягә сузам. Сабак барганда башкалар бик күрми. Ала, укый, җавап бирми. Җавап бирми!

Минем хәлләр тагын да мөшкелләнебрәк китте. Күпме көннәр, атналар буена шулай газапланам инде мин хәзер. Ә бер көнне башыма кинәт шундый куркыныч бер уй килде:

«Әгәр дә флирт уйнаганда шаярган гына булса? Минем шул чактагы мокыт булып утырудан көләргә теләп, юри шундый матур сүзләр белән мыскыл иткән булса?...»

Җаным-тәнем тетрәп китте. Әйе, әйе, мондый усаллыкның булуы бик мөмкин ич! Ничек мин моны шул чакта абайламадым икән? Ничек мин гомеремдә бер ишеткән шундый матур ялган сүзләргә бик тиз эреп төштем икән? Эх, Камырбай, Камырбай!

Билгеле инде, ул мине бөтенләй яратмаган! Хәер, ярату бик олы сүз, әз генә булса якын да итмәгән, ичмаса, фәкать татлы ялган белән мәсхәрә генә иткән!..

Тик бу «ачыш» та миңа җиңеллек китермәде, минем күңелдә ачу да, үч тә уятмады. Киресенчә, ул ямьсез уйларыма ышанмадым мин. «Юк, булмас. Рәмзия андый кара эчле түгел, андый явызлык эшләмәс»,— дидем. Бу уйлар мине берхәтле тынычландырып, айнытып җибәргәндәй булды. Ә бер тәнәфестә, ничектер кара-каршы килгәндә, ул миңа әүвәлгечә саф яктылык белән елмаеп куйгандай итте. Әллә миңа гына шулай күренде, әллә чынлап иде бу. Мәгәр төштәгедәй сихри ул мизгелне кинәт яңгыраган кыңгыравык белән кинәт арадан узып киткән Исмай өзеп ташлады. Класска кереп утыргач, ул Рәмзиягә бик җитди төс белән нидер пышылдап та алды. Моңа да артык борчылмадым: бик үк өтәләнмәскә өйрәнә башладым шикелле хәзер.

Әле генә өзелгән мизгел миңа тагын өмет чаткысы ташлады түгелме? Һәммәкне ачыкланыр, һәммәкне дә әйбәт булыр дигән сабырлык белән йөри бирәм, укый бирәм, берәүдән дә артта түгел. Хәтта кайбер дәресләрдә алданрак та барам әле. Сабак араларындагы шаяруларга да катышмыйм — күңел дә үсми, артык дуамалланырга Рәмзиядән дә тартынам. Нинди дер әчке дөнья беләнрәк яшим хәзер мин. Кешенең шундый дөньясы да була икән! һәм ул дөньям гамьсез дә, караңгы да түгел минем. Анда ниндидер рәхәт яктылык, юандыра торган, каядыр чакыра торган һәм үзем дә белмәгән исемсез бер нәрсә бар шикелле.

Шулай кыш уртасы җитте. Мин хәзер тау буеннан түгел, авыл басуы өсләтеп туп-туры салынган юлдан йөрим. Тирә-як тип-тигез кыр, кышкы суык җил ыжгыра, карлы буран, «җәяүле» буран уйный. Ә мин, һәр көн иртүк, соңга калмас өчен ашыгып атлыйм. Уйда бүген җавап тотасы дәресләр мыжгылдый. Кинәт буран сүрелеп, кояш балкый башлый. Шул чагында каяндыр еpактан тургай сайраган тавыш ишетелә. Аптырап башымны күтәрәм, күккә карыйм — бер генә нокта да күренми. Ә тургай һаман сайрый. Күзләрне никадәр текәп карасам да, тапмыйм мин аны. Нәрсә табыйм соң? Кыш уртасында нинди тургай сайрасын? Ул бит минем җүләр колакка гына ишетелә, минем са-

ташкан күңелгә генә шулай тоела. Үземнән-үзем көлә-көлә һаман атлыйм, һаман атлыйм. Ә тургай тавышы авыл урамына барып кергәнче һаман тынмый да тынмый...

Авылга кергәч, тургай җыры кинәт өзелеп калды, нindидер моңсулык туды, юксыну туды. Нигә болай булды соң әле бу? Аяклар авыраеп китте хәтта. Озын урамның беренче борылышын узуга зур яшел түбәле мәктәп бинасы күренде, шундук Рәмзия сурәте күз алдыма килде. Җәһәтрәк атлый башладым. Дәрес башланганчы ничек тә аны коридорда күрермен шикелле тоела. Бәлки берәр сүз әйтә алырмын, бәлки ул әз генә булса да тагын елмаеп куяр...

Әммәдәки берсе дә юк... Мин коридорга кергәндә звонок булган, алар инде класста иде. Чабатаны чишеп ташлап, сак кына адымнар белән бүлмәгә кердем дә үз урыныма барып утырдым. Рәмзиянең сары ефәк толымнарына сәлам бирдем, үзенә әйтәсе сүзләремне аларга сөйләдем. Бер дә ачулы сыман түгел иде ул толымнар: бик инсафлы, бик сөйкемле булып кына тыңлыйлар минем күңел серемне. Әгәр Рәмзия үзе сизми торган булса, мин ул толымнарны гел сыйпап, гел сөеп кенә торыр идем!..

Шулай дөньядан «түнеп» утыра торгач, беренче дәрес узып та китте. Коридорга чыгып чапкынларга тотындык. Миргаян дигән бер малай бар минем, дус булыбрак йөрибез. Унбиш чакрымдагы Мәкчен авылыннан килеп укый. Шул дус коридорның аргы почмагына кысты да мине, «серле» бер хәбәр әйтеп салды.

— Беләсеңме, — диде ул бик мәгънәле пышылдап, — кенәген кич белән без Рәмзияләргә кереп утырганыек, бергәләп урыс теле дәресен хәзерләргә дигән булып... Беләсеңме, шунда теге Юаш Илдерхан Рәмзиягә хат төртте. Үзе миннән яшергән була, ә мин барыбер күреп тордым, андыйга күз очлы минем!

Бу хәбәр нигәдер артык кытыкламады мине. Бердән, Илдерхан да кеше бит. Шундый беркатлы, юаш холыклы, авылча гади кыланышлы, дәресләреннән уртачарак кына бара торган бу малайның күңелендә ни булмас? Икенчедән, бик балаларча шаянлыкны ярата ул. Белмим, үзен шактый җитди тоткан Рәмзия аңа карар микән?

— Гаҗәп түгел, — дидем мин, искитмәгәндәй итеп кенә. — Илдерхан кемнән ким дә, Рәмзиягә кемнең күзе төшмәс? Алай кич утыруларга йөргәч, синең үз башың да әле җил тегермәне шикелле әйләнми микән шул тирәдә?..

— Әйттең сүз! — диде Миргаян кызарып-бүртенеп. — Рәмзия, имеш! Нәрсәсен табасыз соң шул кыек тәренең?!

Минем кинәт тел тешләнде. Әшәке сүзне күтәрә алмыйм. «Шалт!» итеп шундук авызына берне саласы килде, сулагай кулның йомарланып өлгерүен дә сиздем, ә тәвәккәллек җитмәде. Сугыш китәчәк иде. Бер сугу белән генә туктый алмыйм мин, тукмап ташламыйча тынмаган булыр идем. Ярый әле, тыелып калып, класска тиз генә кереп киттем...

Табигыять укытучыбыз җыланнар турында сөйли. Аларның ничек яшәве, төрләре, оя кору, йомырка салу турындагы сүзләре колакка ишетелә, башка менеп җитми. Башта бөтенләй бүтән нәрсә. Күз алдында Миргаян тора. Укытучы сөйләгән җыланнарның иң явызы төсле булып күренә ул. Рәмзия турында шул хәтле әшәке сүз әйткәндә ничек теле кормады икән аның, ничек авызы чалышаймады икән?

Кай җире кыек булсын ул кызның? Әллә мин генә күрмимме? Бөтен буй-сынын, төс-битен уйдан кичерәм. Юк, аның зифалыгында бер генә кимчелек тә таба алмыйсың. Үчлек белән генә әйтә торгандыр: үзе кәрлә буйлы карама кискәсе бит ул. Шундый малайлар һәр вакыт кешедән көлгән була ич!

Алай әшәке мыскыллап кына Рәмзияне барыбер юкка чыгара ал-

мый ул. Гел миңа карамасын да, гел елмаймасын да, әмма Рәмзия барыбер әйбәт ул, барыбер якын ул. Шуннан соң Миргаян белән бөтенләй сөйләшәсе дә килми башлады. Ә шуңа, үзе дус иткәндәй күренүгә карап, серемне ышанган идем әле. Бер әмәле дә табылмагач, ничәдер «кош телен» Рәмзиягә аның аркылы бирергә туры килгән иде. Әнә нинди булып чыкты ул. Җитмәсә, шуның аркасында бөтенләй әдәм хурына кала яздым. Ярый әле, башкалар сизмәде.

Ничек дисезме? Гел уйламаганда. Көннәрдән бер көнне, тәнәфес вакытында парталар арасында чапкынлый идек, күрәм: иләндә бәләкәй генә итеп бөкләнгән бер кәгазь кисәге ята. Күз төшкәч, алып сүтеп карасам — йа алла, берьюлы ике «кош теле»! Берсе — минеке, аның эченә салынганы — Миргаяннныкы! Тиз генә класстан, коридордан ук ычкынып, ишегалдындагы лапаска йөгердем. Бәхеткә, һичкем юк, укый башладым тегенең язуын:

«Аппакай, алмакай! Ник син минем бер хатыма да җавап бирмисең? Мин генә яратам бит сине. Ул чабаталы, «чөнки» борынлы малайның мин биргән язуларын укып та карама. Мин аларны ул йөдәткәнгә генә сиңа сузган булам. Исмайга да карама, ул әшәке малай. Синең өчен үзәге өзелгән егет бер генә ул! Кулында каләм, җибәрә кайнар сәлам, исеме фәлән...»

Шаккатып тик торам утыннар арасында. Кымшана да алмыйм. Чистый юха икән бу, ике яклы пычак! Алай гынамы? Берәүне дә кешегә санамый икән! Рәмзияне үзе «кыек тәре» дип атый, ә үзе шуңа гыйшык хаты яза! Исмай — әшәке, янәсе. Ә шул әшәке авылдашы белән бер фатирда тора, бер табактан ашый. Мин — чабаталы. Янәсе, ул бай малае! «Чөнки» борынлы дигәне ни икән?.. Ә-ә, төшенәм: мин тактада хисап чыгарганда чөнки сүзен бик күп әйтәм бугай, малайлар көлгәли дә кайчак. Күр әле син аны: шуннан да мыскыл ясаган бит. Гел дегет икән моның эче! Ә үзе дус, имеш!..

Мин кергәндә дәрес бара иде инде. Уйлап утырдым: нишләтергә моны? Чынлап та, сугышыргамы? Монда булмаса, урамда борынын канатсаң? Шәп булыр иде! Юк шул, кыюсыз мин, бер дә тәртип бозган юк. Аннары, унбиш яшьлек укучы башың белән башка авыл урамында башка авыл малае белән сугышып йөрү дә әллә ничек...

Тукта, тел белән, үз сүзләре белән үтерергә кирәк аны! Белсен үзенең түбән җан икәнен!.. Әллә: «Мә хатыңны, Рәмзия кире кайтарды»,— дип кенә әйтергәме? Юк, алай ярамас, Рәмзияне хурлау булыр... Ә Рәмзия үткен дә, усал да икән; укыганмы, юкмы, «төшергән» дә калдырган. «Укысыннар малайлар табып, хур итсеннәр үзләрен!» — дип уйлаган инде ул. Һәм бик дөрес иткән, шул кирәк бергәләп хат бирә торган ике тинтәккә! Ул бит мыскыл итү генә булып чыга. Сабак бу!..

Мин хәзер Рәмзиянең йөзенә күтәрелеп күз төшерергә дә оялып йөрим. Өзлексез тоткан бу «мәхәббәт бизгәге» белән болай да иза чигә идем, инде бөтенләй юкка чыктым ул кыз каршында. Соң шундый кадерле серен икенче берәүгә такылдыймы инде акыллы бәндә? Карга мин, ахмак карга! Тапканмын хат йөртер кешe!..

...Кыш шулай әкрен генә узып бара. Инде мәктәпнең зур тәрәзәләреннән сузылган кояш көлтәсе язның җылы кулы шикелле тоела, урамда казлар гаңгылдашканы ишетелә, тәнәфескә чыккач, кар атышудан туеп булмый, кергәндә боз сөңгеләре әләктереп, чуклы канфиттәй суырып йөргән булабыз. Тик минем күңел генә күтәренке түгел, балтам суга төшкәндәй йөрим. Әмма ни генә булмасын, үсмер чак барыбер үзенекен итә, кичәге хәсрәтләр бүген әкрен-әкрен таралып, күңел күгe аяза бара. Җавап тапмаган ярату да һаман үз дәвамында икән, элекке әрнетүләре берхәтле кимегәндәй тоелса да, рәхәтлеге, йөрәккә бирә торган җылысы һаман сүрелми. Миңа хәзер Рәмзиянең үзе белән сөйләшү, бер генә авыз җылы сүзен ишетү өчен зар булып йөрүдән биг-

рәк, аны бер көнне «шомырт чәчәгем» итеп күз алдыма китерү, икенче көнне «тургаем» итеп хыяллану, аның сайравын ишетеп юану мең тапкыр татлырак төсле. Юк, бәхетсез түгел мин.

Кыш уртасыннан соң миңа уналтынчы яшь китте. Мондый хисләр белән мавыгу бәлки уналтынчы яшьтәге «егет» өчен иртәрәктер дә, әмма ярата белү начармыни ул? Ярату гына микән әле бу? Ата-ананы, туган-тумачаны һәм, гомумән, җаның теләгән бөтен кешеләрне яратырга мөмкин. Ә минем өчен Рәмзия дигән кыз гына бар бу дөньяда. Димәк, бу инде сөю була түгелме соң? «Җан сөйгәнем бер генә» дип җырлыйлар ич. Әйе, сөям мин аны! Ул шундый әйбәт кыз, барлык акылым-хисләрем белән, җаным-тәнем белән сөям мин аны. Сөям, сөям!

Шулай дип бөтен дөньяга кычкырасым килә. Һәм кычкырам да. Шул ике авыл арасындагы тургайлы юлдан кайтканда кычкырам. Күкрәгемә сыймас ул бәхетле тавышымны җилләр әллә кайларга, ераклар ерагына алып китә. Кычкырам-кычкырам да җырлап җибәргән булам. Күңелдәгене әйтә торганын тапмасам, иске җырга үз сүземне кыстыргалап куям:

Ап-ак шомырт чәчәгеннән
Өзеп алдым бер сабак.
Сагыну сүзләремне сөйлим
Сезнең якларга карап...

Мин шулай яз белән көчәеп киткән сөю хыялларымда җилкенеп һәм тинтерәп йөргәндә, көтелмәгән бер хәл булып куйды. Һаман да шул без малайларның уйсыз шаярулары аркасында килеп чыкты инде бу. Төшке тәнәфестән соң мәктәпкә җыелдык, дәресләр башланырга әле байтак вакыт бар. Юаш Илдерхан белән Исмай Биков урамнан ук шаярышып кергәннәр иде, идәндә тагын әүмәкләшергә тотындылар. Әле берсе аста, әле берсе өстә. Ычкынып китәләр дә, бүлмә әйләнә куышалар, тагын бөтерешәләр, үзләре шырык-шырык көләләр, ә без аларны тагын да ныграк котырырга котыртып торабыз. Илдерхан һаман бәйләнә дә бәйләнә тегеңәр. Болай гына, уйнап кына бәйләнгән була ул, күңелендә бер төрле усаллык та юк аның. Шулай маталанганда Исмай артыграк кызып китте бугай:

— Тукта, чәнчәм ату!— дип кычкырды бу. Һәм яшен тизлегендә пинжәк кесәсеннән калай саплы карандаш пәкесен чыгарып ачты да, түбәннән китереп Илдернең кабырга астына кизәнде.

— Аллай, чукынган, чынлап чәнечтең бит! — дип кычкырды идәнгә чүккән Илдерхан.

— Чынлап булгач, чынлап! Мә тагын берне! — диде Исмай, кабат кизәнгән булып.

Тегесе читкә тайпылды.

— Шаярма, дим, чукынчык, уен-муен түгел монда, чуен-муен! — дип, аягүрә басты да, солдат шинеленнән теккән зур, салынкы җилкәле курткасын салып ташлап, күлмәк итәген күтәреп карады. Тәнендә бәләкәй генә кызыл тап күренде.

— А-я-я-яй! Каты чәнечкән икән! Инә очы белән төрткән хәтле бар! — дип көлештек без. Үзләре дә кычкырып көлделәр. Чынлап торып куркынышкан кызлар да бер почмакка өелешкәннәр иде.

— Ачуланма инде, малай, мин бит юри генә кизәнгәнием,— диде Биков.— Әз генә кызып кителгән...

Илдерхан һаман шул сабыйларча бер катлы көлүендә иде.

— Ничава-а! Туйга хәтле төзәлә ул! — дигән булды.

Шулай да алар кабат котырынмады, класс тынып калды, озакламый укытучы керде. Дәресләр көндәгечә үз агымында барып, өч сәгатьтән соң өйләргә таралыштык. Мин дә, көндәгечә җырлый-җырлый, Янсыбыма кайтып киттем.

Иртәгесен мәктәпкә килеп керсәм, безнең алтынчы классны берәм-берәм мөдир бүлмәсенә чакырталар. Ул безнең ана теле укытучыбыз Фәиз абый иде, мине дә чакыртып алды. Бүлмәдә аңардан башка тагын ике укытучы бар. Кичәге хәл буенча икән. Ни кирәге булгандыр инде моның.

— Күрдеңме?

— Күрдем.

— Ничек-ничек булды?

— Шулай-шулай булды.— Күргәнемне сөйләдем дә бирдем. Артыгы да юк, киме дә юк.

— Сез шул дәрәҗәдә аздыгыз-туздыгызмыни инде? — диде Фәиз абый.— Чәнчешүгә барып җиткәнсез ич!

Мин аптырадым да калдым авызны ачып. Ничек инде бу?..

— Юк бит, алай түгел бит,— дияргә тотындым кызу-кызу,— чәнчешү түгел бит, алар сугышмады бит, уйнаганда гына килеп чыкты бит... инә очы хәтле генә. Үзем күрдем бит...

Укытучылар минем сүзне хупламады. Мондый хәлнең бик хәтәр булуын әйтеп, мине гел куркуга төшерделәр. Кайсыдыр җүнсезе житкергән бит шуны! Кайсы лыгырдыгы икән? Хәзер мин үз сүзләрем өчен дә үкенә башладым. Ник инде, күрмәдем-белмәдем, мин китап укып утыра идем, дип кенә әйтмәскә? Барыбыз да шулай дисәк, бәлки Исмайга сүз дә булмас иде... Юк шул, ялганлый белмим шул мин. Ничек инде укытучыларың каршында ялган сөйләп торасың? Юк, тел әйләнми аңысына.

Миннән соң берәм-берәм бүтәннәр дә керде, классның берсе-бер калмады бугай. Ник шул хәтле зурдан кубардылар икән моны? Исмай, югыйсә, бер дә әшәке малай түгел ич, дәресләреннән дә начар бармый, тыңлаусыз да түгел, моңарчы тәртип бозганы да булмады бугай. Ә фортепианода ничек уйный!.. Дөрес, әзрәк тырбайчыклыгы бар барын. Андый гына безнең кайсыбызда булмый соң?..

Шулай да хәлләр бөтенләй мин көтмәгәнчә килеп чыкты. Мин аңа нык итеп «тәнбиһ» [1] ясарлар, я шелтә бирерләр дип уйлаган идем. Юк, алай гына булмады шул. Аны мәктәптән чыгарырга ясадылар...

Чыгарырга! Беребезнең дә башына сыймады бу, аңламадык. Шул гаепсез шаяру өченме? «Уеннан — уймак» та түгел бит әле бу. Шул пүчтәк, инә күзедәй төртке...

Төрткесен төртке дә... Ә класс җыелышында Фәиз абый әйтте:

— Болай уйнамыйлар. Пәке-пычак кизәнеп уйный торган уен юк! Мондый «уен» өчен Исмәгыйльне кичерсәк, икенче тапкыр пычак күтәрү һәм ачуы килгән кешесен чынлап та чәнчеп җибәрү аңа бер дә кыен булмас!..

Шулай кырыс итеп, каты итеп ышандырды ул безне. Хәтта тавышка куйды. Бөтенебез кул күтәрергә мәҗбүр булдык, тик Илдерхан гына һаман берни дә аңламаган юаш, ягымлы елмайган йөзе белән каршы кул күтәрде. Аның күзләре мөлдерәмә яшь иде...

Фәиз абыйны бик яратсам да, бу катылыгы белән килешү миңа да бик кыен булды. Кереп үзенә әйтергә тимтенеп тә карадым, булмады, йөрәк җитмәде, барыбер тыңламас дип курыктым. Ә шул ук вакытта аның сүзендә дә хаклык бар сыман тоела. Арттырганын да сизәм, хаклык та бар шикелле. Шулай ике арада тик калдым авызга су кабып. Хәер, мин гел шундый тәвәккәлсез булдым инде...

Икенче көнне иртә белән дәресләр башлангач, Исмай Биков классның ачык ишеге төбенә килеп басты, өстен чишенмәгән иде. Ике кулы белән ишекнең ике ягына тотынып, гадәтенчә, бераз шукланып торды да:

[1] Тәнбиһ — кисәтү дигән сүз иде ул чакларда.

Безне дошманнар күрәлми,
Без китәбез бу илдән,—

дип җырлап җибәрде.

Без моңа көләргә дә, җыларга да белмичә торганда, Рәмзия җәһәт кенә урыныннан кузгалып, аның каршына килде дә, берәүдән дә ящер-ми-нитми, хат чыгарып бирде. Юк, яшерми генә түгел, «Күрегез, барыгыз да күрегез!» дигәндәй итеп бирде ул Исмайга әлеге дүрт почмаклап төргән хатын!

Бу ни булды инде? Һич нәрсә аңлый алмастан катып калдым. Кичә ул да безнең белән Исмайны мәктәптән чыгарырга дип кул күтәргән иде түгелме соң?.... Шулай да аның бүген үз фикерен әйтергә көче җиткән, күрәсең. «Юк, дошманнар гына түгел, дусың да бар синең!» дигән сүзедер инде бу. Алай дисәң, Исмайга безнең класста кем генә дошман икән? Андый кеше булуын мин белмим. Әллә бер партада утырган сабакташ малаен якын итеп, жәлләп кенә шулай эшләвеме Рәмзиянең? Әллә?.. Әллә?..

Әллә ул аны яратамы?! Бу уй мине кинәт бәреп еккандай итте.

Юк, булмас ла, булмас ла!..

Ә ник булмас ла?..

Кисәк кенә күптәнге бер хәл искә төште: ул бит Рәмзияне теге чакта бишенче класстан утыргычы-ние белән күтәреп алып чыккан иде. Икесе дә чырык-чырык көлә, без дә моны күргәч көлешкән идек.

Ә Исмай шунда болай дигән иде бит әле: «Әйдә, синең белем тау хәтле. Синең урын анда түгел, синең урын бездә! Утыр минә үз яныма!..» һәм китереп утырткан да иде.

Ничек мин моны истән чыгарганмын? Әйе, болай булгач, аларның яратышулары бик мөмкин, бик тә аңлашыла бу хәл. Тик мин генә моны, үз хисләремә бикләнеп, күрми-белми йөргәнмендер, ә башкаларга бу әллә кайчан билгеледер. Әнә бит, берсенең дә исе китмәде, әз генә елмаешып кына куйдылар.

Ник булмасын, Исмайның килеш-килбәте бөтен яктан коеп куйган, класста иң күзгә бәрелеп торган малай. Аның белән Илдер дә, Миргаян да, мин дә, бүтәннәр дә алышырлык түгел, сортыбыз түбәнрәк! Аннары ул бит Рәмзия белән бер партада утыра, башта ук уйлап утырткандыр бәлки... Ә кеше, ияләшә-ияләшә, бер-берен ачыша, бер-берен табыша ич!

Әгәр алар чынлап та яратышкан булсалар, инде нишләрләр? Болай көтмәгәндә һәм болай үкенечле төстә аерылышу бик авырдыр бит ул. Җитмәсә, шундый «яманат» белән китү һәм шуны кызның да белеп калуы Исмай өчен бигрәк тә гарьлектер инде... Миңа хәзер алар икесе дә жәл тоела башлады, тик мин жәлләүдән генә берни дә үзгәрми иде шул!..

Исмай китте. Исмай китү белән генә дөнья тынмады, аралар җылынмады. Болай кеше алдында исәнләшеп, дәресләр хакында сөйләшкәләп йөрсәк тә, икәү генә туры килгәндә ләм-мим бер сүз юк! Рәмзиянең инде бәлки сөйләшәсе килми дә торгандыр, ә минем күңел дингезендә кайнаган ташкыннар берьюлы ябырылып килә дә тамак төбемә каплана, һич ни әйтә алмыйм. Авыз ачсам кинәт ургылган кайнар дулкыннар бөтен дөньяны туфан булып күмәр төсле.

Мин шулай онытылып йөргән көннәрдә минем баш очымда болытлар куера башлаганын сизми дә калдым. Исмайның мәктәптән чыгарылуын миңа сылтап, янәсе, мин Рәмзиядән көнләшеп шулай «тырышкан» итеп сөйли башлаганнар. Ул гына да түгел, кичләрнең берендә мин үз авылымда чакта җыелыш сыман нәрсә ясап, Рәмзияне тикшергәннәр. Малайлар белән хат алышкан өчен, имеш, диделәр.

Монысында да минем исем белән уйнаганнар. «Рәмзияне Мөслим

чаккан» дигән ялган таратканнар. Ис-акылларың качар! Иртән килеп укыйм да, дәресләр беткәч үк авылга кайтып китәм, берсенең дә класстан тышкы тормышы миңа мәгълүм түгел, кызыксынганым да юк, — ә шундый сүз чыккан!

Мин Рәмзияне чагам, имеш! Күңел түремдәге шомырт чәчәген! Кышкы күкләрдә дә сайрар тургаемны! Һай, бу дөнья, һай, бу алтынчы класс кичәләре! Ни дип әйтим мин аларга, ничек дип акланыйм?

Хәер, ник акланыйм? Алар каршында түгел, Рәмзия каршында да ни өчен акланыйм? Һичбер әшәкелек эшләгәнем юк ич. Күңелем саф, аяз көн шикелле якты.

Ә Рәмзия миңа хәзер кара коелып йөри, хәтта исәнләшми дә. Димәк, ул мине шундый әшәке малай дип уйлый инде...

Әнә шундый ямьсез көннәрнең берсендә Мөршидә исемле кыз кулында Рәмзиянең альбомын күреп калдым. Яз җиткәнгәме, класста хәзер альбомнарга язышу китте. Мин инде Рәмзиянең альбомын әллә кайчан сорап алып, әллә кайчан язган идем бер-ике тапкыр. Тагын язасы килде. Җайлап-юмалап дигәндәй, матур зәңгәр тышлы калын дәфтәрне Мөршидәдән алдым да, үз партама утырып, актара башладым. Китап арасында күптән үк салган бәләкәй генә бер ак күгәрчен кисентесе йөри иде, тиз генә шуны ябыштырдым да гади бер җырга әз-мәз «ремонт» ясап, язып куйдым:

Эчтем суның салкынын,
Басмый йөрәк ялкынын.
Төрле яктан сүз килсә дә,
Ышанма син, алтыным.

Җавап, әлбәттә, булмады. Хәер, альбомда язылганга берәү дә җавап бирми ич. Ул аны бәлки укымагандыр да. Түзмәдем, бер-ике көннән соң теге «кош теледәй»не язып, парта астынан гына Рәмзиянең үз кулына сондым. Аның ник шундый күңелсез булуына борчылган идем, үземчә. Теләр-теләмәс кенә алды ул аны. Һәм, озак та үтмәде, минем парта өстенә бер «ак күбәләк» килеп кунды. Үземә карамый гына җилкә аркылы төшерде ул аны. Шулай да мин ул «күбәләк»не бик сөенеп тотып алдым да кабалана-кабалана сүтеп, күз йөгерттем.

Мәлганәт, пычрак зә ялган берлә тулган безнең эч,
Бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбарәт безнең эш...—

дип язылган иде анда. Кинәт тәннәрем эсселе-суыклы булып китте. Күзалларым караңгыланды.

«Шундыймы мин? Шул тикле әшәке малаймы? Әйт әле, Рәмзия! Нинди явызлык эшләдем мин сиңа? Берәр изге хисеннән көлдемме, буй-сыныңны хурладыммы, берәр малай белән үртәдемме, берәр әйбереңне тартып алдыммы, әллә сине рәнҗетерлек берәр каты сүз әйткәнем булдымы?» дип, аягүрә басып, бөтен класс алдында сорыйсым килде. Буламы соң?.. «Тилергән икән, мескен!» дип көләрләр генә иде миннән.

Моңарчы түзә килдем, нинди авыр булса да күтәрә идем, әмма Тукайның бу сүзләре белән Рәмзия бик каты рәнҗетте мине, йөрәккә кара кан саудырды. Үзенә түгел, көн саен дәрес буена каршымда тибрәнеп торган алтын толымнарына да күз төшерәсем килми башлады...

Хәзер инде көлке тоела, ә ул чакта, егетләр, чыннан да бу минем өчен бик зур газап иде, бер гаебең юк көйгә рәхимсез җәберсетелү иде. Моннан соң ул кыз турында бөтенләй уйламаска, күңелдән бөтенләй чыгарып ташларга, хәтта каршыма елмаеп килсә дә, күз күтәреп карамаска сүз бирдем үземә. Юк ул хәзер минем өчен, юк, бөтенләй юк!..

Шулай, язның иң соклангыч бер мизгеле килеп җитте. Дөнья тулы җылы кояш, тәнне генә түгел, җаннарны да иркәли торган кояш!

Юлларда, сукмак читләрендә әле болганмаган, саф гәрәбә сулы нәни гөрләвекләр чәч толымы төсле үрелеп ага, Рәмзия толымнары төсле! Капка өсләрендәге оя чыбыкларына баскан сыерчыклар, түбә кыегына тезелешкән, ә кайберләре кызыл тәпиләрен сузып тактага кырын яткан күгәрченнәр, тирәк башларын сыгылдырырдай булып сарылган чыпчыклар, бакча талларында карга-чәүкәләр кайнаша.

Тик бары да тып-тын алар. Хәтта кыш уртасында сайраган тургай да тынып калган. Ни булган бу дөньяга, ник шауламый? Ник ул кошлар берсе дә сайрамый? Ник ул гөрләвекләр көлешмиләр?.. Әллә бар да берьюлы телсез калганмы, әллә мин саңгырауландыммы? Әллә минем кара кайгыларым колагыма кургаш булып коелдымы? Мин шул телсез дөнья эченнән, хәрәкәте булса да үле тоелган дөнья эченнән атлап барам. Дөресрәге, дәрестән соң малайлар белән калып, иртәгә кирәсе физиканы өйрәнгәч, урам кырыеннан кичке якта өйгә кайтып барышым....

Муллаларның нарат коймалы алма бакчасы турына килеп житүем булды, кинәт чыңлатып көлгән тавыш ишетелде. Бу — аның тавышы! Ул шулай матур көлә. Йа алла, мин саңгырау түгел икән ләбаса! Кошлар гына телсез калган икән. Ә ник мин саңгырау түгел? Ник ишеттем мин ул тавышны? Бер кирәге дә юк бит аның хәзер!..

Качарга теләгәндәй, йөгереп китмәкче булдым, бакча эченнән тавыш тагын ишетелде, аяклар атламас булды, күзләр койма ярыгын эзли башлады. Табылды ул ярык. Дөньямны онытып шул ярыкка сыландым.

Кары бетеп килә торган бакчада Сәхифә белән икесе йөриләр. Авыл мулласының жип-жирән һәм кырыкмыш чәчле, озын буйлы, курай сыйраклы шундый бер кызы бар иде, безнең белән укый. Ә Рәмзия һәр вакыт аның белән йөри, дуслардыр, күрәсең. Икесе дә ялан баш. Рәмзиянең толым очларында зәңгәр бант уйнаклый. Икесе дә шат йөзле, минекедәй кургаш коелмаган чырайларына. Икесе дә сөйләшәләр, көлешәләр. Әйтерсең күп еллардан соң менә әле генә күрешкәннәр. Шулай алар бакчаның мин кайтасы ягына атладылар. Мин дә атлыйм койманың бу ягыннан. Шул килеш кайтып китмәкче булып бара идем, бакчаның бу башындагы актык баганага житкәч, тагын бер карыйсы килде. Нихәтле эзләсәм дә, рәтле ярык таба алмадым, аларның теге башка борылуын гына шәйләрлек булды. Ары табарак киткәч, Рәмзия тагын бер тапкыр чыңлатып көлеп жибәрде. Өзә үзәкне шуның шулай чыңлатып көлүләре!

Акыл дигән нәрсәне бөтенләй аяк астына салып, тагын кире чаптым мин теге ярыкка. Битләрем, күзләрем белән гел сагыздай ябышып калдым коймага. Килә бу көлә-көлә нидер сөйләп. Туп-туры каршыма дигәндәй килә. Сизми, мескенкәем, минем урлап карап торуны. Берүк сизә генә күрмәсен! Сизсә, бөтен кояшлы дөнья, язгы якты дөнья, куанычлы дөнья челпәрәмә киләчәк, бар да бетәчәк!..

Шулай бу баштан әйләнеп, мин караган ярыкка таба күз төшерделәр дә, белмим, күреп алдылармы, ялт борылып түргә, йортка таба китеп бардылар. Тагын зәңгәр бантлы толымнар уйнаклады һәм кинәт тагын бер кычкырып көлде Рәмзия.

Әле генә шундый рәхәт иде, шундый татлы иде аның көлү тавышы, ә бу юлы әллә ничек, икенче төрле чыкты. Мыскыллы сыман булып ишетелде һәм йөрәккә килеп кадалды минем. Карап торуымны күргәндер дә шуңа бик тиз артка борылганнардыр. «Һаман йөри теге тинтәк», дип шулай мыскыллы көлгәндер шикелле тоелды миңа. Бәлки бер дә алай булмагандыр, мин генә тик, «шикле шикләнер, иске чикмән бөркәнер» дигәндәй, шулай юраганмындыр.

Һәрхәлдә, бу соңгы көлү баш түбәмнән бер чиләк кое суы койгандай бик тиз айнытып жибәрде мине. Инде күптән чыланып эчена су үтеп

беткән чабаталарны лыч-лыч китереп атлый-атлый, Аксыбының ак каенлы озын урамыннан җәһәт-җәһәт кенә чыгып, өйгә ычкындым. Шунда тагын гаҗәпкә калдым: әле бая гына үле тоелган бар дөнья кабат терелгән. Кошлар, гөрләвекләр яңадан телгә килгән, басу түрендәге тургайлар яңадан сайрый башлаган иде. Колаклардагы суык кургаш та эреп төшкән, күрәсең. Дөньяның бу гүзәл авазларын кабат рәхәтләнеп ишетә идем инде мин...

Белмим, язгы имтиханнар бирдекме без, белмим, майдамы, июньдәме, укулардан туктап, өйләргә таралыштык.

Рәмзия үзенең утыз биш чакрымдагы Чабышлысына кайтып китте. Мин — үзебезнең Янсыбыга. Тик моны хәзер әйтүе генә ансат, ә ул чакта бик кыен булды: без бит тәки уртак тел таба алмадык. Сөйләшү-аңлашу түгел, хәтта «исән бул», «сау бул» дигән гади генә сүзләрне дә әйтешә алмыйча аерылыштык. Белмим, чамадан тыш мин мәнесез, мин кире идемме, мин кыюсыз булдыммы, әллә ул да минем төслерәк булганмы — шул үпкәләшкән, хәтта дошманлашкан килеш, икебез-ике якка китеп бардык.

Мин, «егет малай» буларак, бөтен үпкәләремне йотып булса да, ичмаса, иң актыккы минутта каршына килеп: «Хуш, сау бул инде, Рәмзия. Ак юл сиңа!» — дип бер җылы сүз әйтсәм ни булган инде?.. Юк шул, әйтә белмәдем. Акыл да җитмәгән, тупаслык та зур булгандыр инде ул чагында...

Көзен мине Аксыбы мәктәбенә җибәрмәделәр. Ник дигәндә, шушы ел бетүгә миңа уналты тулып унҗиденче китә. Ничек инде егет башын белән җиденчедә укыган булып, җыен бала-чага арасында сөрхәнтәй шикелле буй сузанлап йөрисең. Рәмзия белән дә кабат очрашуы авыр булачак. Хәер, ул да кайдадыр башка җирдә укый, имеш. Ихтимал, ул да бәлкем минем «нурлы йөзне» кабат күрергә теләмәгәндер...

...Ә егерме беренче ел ачлыгы инде, безне төп-тамыр белән кубарып, Себер уртасына китереп ташлады. Анда уку кайгылары бер читтә калды. Бала чак, үсмер чакның зәңгәр чәчәкләре дә бик тиз коелып, кулга кәйлә-көрәк тоткан эш кешесе булып киттек.

Шунысы сәер, мин аны инде бөтенләй оныттым дип, исемә дә кертми йөргән чакта, ул кыз һичбер сәбәпсез-нисез минем күңелдә янадан үсеп чыкты. Әйе, күңел түрендә ап-ак чәчәкләргә күмелеп утыручы яшь бер шомырт булып күренә башлады ул минем күзгә. Шуны күрдем исә, кыш уртасында ашкынып сайраган тургай тавышы баш очымда гына яңгырый башлый. Ул да күренә төсле күңел күземә. Ә инде нәни кошчыкны күреп алсам, җепшек карлы язгы бакчада дөньяны чыңлатып көлгән Рәмзия үзе килеп баса каршыма. Җүләр әйтмешли, үзе бер кыз, үзе әллә ничә сурәттә күренә миңа. Әллә тилерә башладым инде, дип куям кайчакта.

Юк, бер дә тилермим, миңа фәкать рәхәт кенә бу. Элекке газаплар, хәсрәт чигеп йөрүләр дә юк. Хәер, икебез ике почмагында ич без дөньяның. Бер-беребезгә авыр сүзләр ишеттерешмибез, гайбәтче теле дә керә алмый безнең арага. Ике авыл арасындагы шикелле, моңда да гел сөйләшеп йөри башладым мин аның белән. Җиңел булып китте. Күңелгә утырган юшкыннар да юылган, йөрәктәге төерләр дә язылган иде бугай инде. Бик-бик ерактан аның ягымлы тавыш белән әйтелгән сүзе дә ишетелеп куя кебек, хәтта: «Тыныч җилләр юлдаш булсын сиңа!..» ди төсле ул. «Юату фирештәсе» дип елмаям мин.

Шулай яз килеп җитте, Себернең сыерчыксыз язы. Яраткан кошларым бит алар минем. Әллә шуларның тирәк башларында үзәкләрне өзеп сайравын ишетмәгәнгә, әллә яшь күңел ялгыз булганга, өзелепөзелеп хат язасы килә башлады Рәмзиягә.

Сызыклы дәфтәр битен урталай кисеп, озын тар кәгазьгә язарга ярата идем мин ул чакта. Бер дә арттырып әйтмим, унике кәгазьне

бер-беренә ялгап яздым, аннары икенче ягын да тутырдым, кәгазь битте, сүз бетмәде. Әйтәсе килгәннәр шул хәтле җыелган икән!

Хәер, әйтәсе килгәннәр генә микән? Бизәкләбрәк язарга теләү күбрәк булгандыр, ихтимал. Егетлек мәйданына чыккан чак бит ул! Күңелнең ташып торган чагы! Хәзер инде берсен дә ачык кына хәтерләү мөмкин түгел, шулай да анда: камышларга кача торган кыр үрдәкләре, яз саен безнең авыл болынында кунып китә торган кыр казлары, үзем әле бер генә тапкыр да күрмәгән аккошлар, кыш көне сайрый торган шул ук тургайлар, тегермән төбендә төн буе шаулаган язгы сулар, алтын балыктай уйнаклаган толымнар булганлыгы, үзем чыгарган шигырьләр язылганлыгы истә калган. Бары да бар иде, тик үпкә сүзләр генә юк иде. Гомумән, минем күңелдә Рәмзиягә карата андый хисләр сакланмый иде хәзер.

Дилбегәдән дә озын килеп чыккан бу хатны үзем ясаган конвертка «төяп» ябыштыргач, аптырап калдым, Рәмзиянең кайсы волостьтан булуын белмим икән мин. Шулай да артык баш ватмыйча: «Татарстан, Мамадыш кантоны, Чабышлы авылы», — дип яздым да салып җибәрдем.

Күп язылды мондый хатлар минем тарафтан. Күңел кычыткан саен! Тик берсенә дә җавап килмәде. Хәер, мин җавап килүен көтми дә идем. Миңа эч серләремне, беренче яшьлекнең тиле ялкыннарын ак кәгазьгә түгеп, кошлар да очып җитмәс ераклыкта калган якын кешемә юллагач, шул җитә, шул миңа рәхәтлек бирә иде...

Әмма бу гөнаһлы дөньяда берни дә мәңгелек түгел, күрәсең. Бибинур апагыз дигән бер матур килеп чыкты бит Мөслим абзагызның юл өстенә. Һәм ул аның күңел түрендәге ап-ак чәчәкле шомыртны да, хыял күгендә сайрар тургайны да, күз алдында чыңлатып көлеп торучы Рәмзияне дә әкрен-әкрен кысрыклап чыгарды. Дөресрәге, Бибинур апагызның әллә кай төшендә генә Рәмзиянең әллә кай төше белән генә охшашлык бар шикелле күренде миңа. Менә шунда инде ике тамчы бергә кушылып, Бибинур исеме белән гомерлек юлдаш булып калды. Менә шушында инде «тәмәт тәмам, билхәере вәссәләм» диярргә дә булыр иде... Һәм менә шушыннан инде:

«Үзегез уйлап карагыз, бармы ул чын сөю, юкмы ул чын сөю?»... — дип сорарга да булыр иде. Әммәдә генә ләкин, сүз бетеп җитмәгән булып чыкты. Ник дип әйткәндә, бу фани дөнья дигәннәре бикләр дә сәер нәмәрсәкәй икән! Нәкъ алтмыш кына елдан соң тотты да күрештерде ул мине Рәмзия белән. Ничек дисәгез, болай: минем төпчек кыз, Казан университетын бетергәч, шунда калды. Хәзер ике баласы бар инде. Бик чакыргач, узган ел карчык белән монда күчеп килдек. Әйтергә кирәк, шуңарчы минем Казанны күргән дә юк иде. Үзең Татарстанда туып үс, үзең шуның башкаласын да күрмә, әдәм көлкесе!

Килгән мәлләрдә сый-хөрмәттән, бала-чагадан әз генә котылдыммы — Казан урамнарын гизәргә чыгып китә торган булдым. Күрәсе килә бит үзебезнең нурлы Казанны! Әллә кайсы почмакларына хәтле барып әйләнәм. Андагы төзелеш-корылышны сөйләп тормыйм, ул инде һәркайда бер төсле.

Шулай бер көнне аргы Кабанның аргы башы артындагы Халык хуҗалыгы күргәзмәсенә барып чыктым. Карап йөри торгач, аякларга гер бәйләнә башлады. Ял итәргә утырдым. Каршыдагы эскәмиядә бер әби-ханым арбалы бала тирбәтә. Шул апага күз төште...

— Әһә, әһә!..— дип кул шапылдатып алды картлар.

— Бер дә «әһә-мәһә» түгел, просто ул әбинең әллә кай җире генә миңа таныш сыман тоелды. Белмим, мин күзәткәнгә уңайсызланыпмы, ул да миңа карап-карап куйгалый иде.

«Кем булыр икән бу?» дип баш ватам. Арабызда асфальт юл гына,

югыйсә, артык киң дә түгел. Шулай да аермачык төсмерләве кыен. Ничек якынрак барып карарга икән, дип уйлыйм.

Таптым хәйләсен, авызга тәмәке каптым да аның каршына киттем.

— Шырпыгыз юкмы, мин әйтәм, үземнекен әллә кая куйганмын...

Вәт тинтәкне, ул әбинең нинди шырпысы булсын инде? «Ата казыгыз күкәй саламы?» шушыдыр инде ул!

Ул әз генә көлемсерәгәндәй карап-карап торды да:

— Сабакташ түгелме соң сез?— дип куйды.

Мин берни дә аңламадым, бу сүз инде әллә кайчан хәтердән чыккан, хәтта искечә яңгырый.

— Исемегез Мөслим түгелме?— дип тагын сорады бу.

Шунда гына минем тай типкән баш кыймылдый башлады.

— Тукта, тукта... Рәмзия мәллә сез?— дип кычкырып җибәрдем.

Шуннан... кочаклашмадык. Кул гына бирештек.

Ул өенә кыстады мине. Якындагы кооператив йортларда гына икән квартиры. Арба бишеген икәүләп өскә меңгереп, эчкә кердек. Беләсез, мин тәмәке пошкыртмый түзә алмыйм инде, мондый очракта бигрәк тә. Ике бүлмәсен берьюлы сасытасы килмәде, кухнясына кереп утырдык. Карашып торабыз: икебезнең дә укалар коелган, дугадай зифа буйсыннарның, лимон кабыгыдай төс-битләрнең элек ничек булганлыгын күз алдына китерү дә ансат түгел хәзер. Мин җитмешне генә тутырып узган ап-ак башлы «яшь кенә егет». Ул да, әйтүе буенча, яшьти икән минем. Башының да менеке төсле икәне чәч төпләреннән сизелеп тора. Тик ул аны җирәнгә буятып җибәргән. Дәрт сүнмәгән әле, күрәсең, карчыкта! Хәер, Казан хатын-кызлары хәзер бар да җирән, бар да сары, башка төстәге чәчлеләрне вапши күрмәдем дә мин монда.

Сөйләшә торгач, алтмыш кына елга артка тәгәрәп, үсмер чакларга барып төштек...

Ышанмаган ул минем яратуга, тузан бөртеге хәтле дә ышанмаган! Флирт уйнауны да, «шомырт чәчәге» әйткән сүзләрне дә хәтерләми булып чыкты. Белмим, әллә әйтәсе килмәде, әллә «яшьлек» юшкыннары күмеп киткән... Әйе, аңа хат бирүче башка малайлар да аз булмаган. Шуңа күрә беребезгә дә ышанмаган. Өстәвенә, Исмай да: «Бүтән малайлардан хат аласы булма! Икәү генә дус булыйк»,— дип өркетеп куйган моны.

Мине бар да мыскыл итә, дип җылап, шул хурлыктан котылыр өчен үләргә теләп тә йөргән. Бу хәтле «зур кайгысын», «олы бәхетсезлеген» теге озын сыйраклы, җип-җирән Сәхифә белән генә уртаклаша торган булган. Ник дигәндә, башка кызлар: «Син егетләр белән йөрисең, әте дә, бете дә синә хат бирә!»— дип, аның күзен дә ачырмаганнар.

Шуннан соң аңа Сәхифә дусты мондый киңәш биргән: «Без,— дигән,— күселәрне пыяла ашатып үтерәбез,— дигән.— Әйдә, без дә пыяла ашыйк та үлик»,— дигән.

Рәмзия аптырап калган: «Ә син нигә үләсең?»— дип сораган. «Соң мин синең ахирәтең ич, мин дә синең өчен үләм,— дигән теге.— Аннары килеп, минe «челән» дип, «колга» дип үртиләр, бер малай да хат язмый, шул гарьлектән мин барыбер үләргә тиеш!»— дигән.

Өч тапкыр авыз тутырып, шытыр-шытыр чәйни-чәйни, пыяла ашаганнар — үлү түгел, эчләре дә авыртмаган, тик авыз эчләре уелып, тешләре генә камашып беткән. Көлә-көлә минем дә эчкә кату чыкты...

Минем Себердән язган дилбегә буе хатларның да кемнеңдер кесәсендә йөри торгач кыршылып-киселеп беткән берсен генә алган. Билгеле инде, Рәмзия минем андагы сайрауларга барыбер ышанмаган.

Укыган, үскән, укытучы булган, кияүгә чыккан, дүрт кыз үстергән, бишенчесе малай булган һәм ул аңа Мөслим дигән исем куштырган! Мин ышанмадым. Шунысы гаҗәп: мин үземнең олы кызым Рәмзия исемле булуын әйткәч, ул да ышанмады...

Моннан алтмыш кына ел элек гыйшык тота башлаган Мөслим дигән малайның «зәңгәр әкияте» менә шушы.

Бүген бардым, кичә кайттым. Биш чынаяк коймак ашап, бер тәлинкә чәй эчтем...

— Әкиятең чыннан да зәңгәр икән шул...— дип куйды берсе.

— Ул бәхетсез малайны кем генә җәлләр икән?— дигән булды икенчесе.

— Ничек соң, кухняда чәй эчкәндә, гыйшык-мишык хәлләрегезне яңадан яңартып җибәрмәдегезме алтмыш елдан соң?— дип көлештеләр аннары.

— Егетләр, кешнәшмәгез, Гөлбикә кодачагызга сүз бирелә!— диде кәмисия.

## Сыйнфый дошман

— Бар иде заманасында Зәйтүнә исемле гади генә бер кыз...— дип сөйли китте Гөлбикә ханым.

Барыбыз да шым булдык. Чөнки арабыздагы бер-ике генә бөртек кыз заты моңарчы бер дә бәхәскә катнашмый, тик кенә тыңлап утыра иде. Хатын-кыз гел шулай тартынучанрак була ич дип уйласак, алай ук түгел икән. Әнә бит, түзмәде, бер дә ялындырмастан үзе үк сүзгә кереште. Ниләр ята икән кызларның серләр тулы чыбылдыгында?.. Барыбыз да аның һәр сүзен авызыннан тартып алырдай булып тыңлый башладык.

Гөлбикәне әле әби дип тә, карчык дип тә атап булмый, бездән шактый яшь чырайлы күренә ул. Ачык йөзле, йомшак телле, кабынып китә белми торган сабыр табигатьле үзе. Шахмат белән җенләнгән көннәрдә күренә башлады ул безнең арада. «Җыен карт чыпчык арасына каян килеп кергән бу ак кошчык?» дигәндәйрәк карадык без аңа башта. Ул да безнең шикелле такта өстенә үлеп төшәргә ярата икән. Уенга кысылды бу маташа торгач. «Ну, ашыйбыз инде без моны, бер кабарга да җитмәячәк!»— дип шәбәйгәндә генә ике «мачтыр»ыбызга бер-бер артлы мат чәпәп куймасынмы апагыз! Шуннан соң гына без аның исемен сорадык.

— Былтыр кызы Гөлбикә,— дип елмайды ул.

Менә шул «Былтыр кызы» басынкы гына тавыш белән сүзгә кереште хәзер. Нәрсәләр сайрар икән?..

— Холкы-фигыле белән кече күңелле, юаш кына кыз иде Зәйтүнә,— дип дәвам итте Гөлбикә.— Төскә-биткә әллә ни кычкырып торган чибәрлеге күренми, әмма кеше куркырлык ямьсез дә түгел иде. Көлсә-елмайса, ап-ак тигез тешләреннән, сөйкемле генә балкып китә торган коңгырт күзләреннән, әз генә бөдрәләнә торган калын чәчләреннән йөзенә ягымлы бер яктылык сибелә, ә шуны күргән егетләр аны һаман күбрәк һәм озаграк көлдерергә тырыша иде.

Кайсы кыз үзендә нинди сыйфатлар барлыгын сәгатьләр буе көзге каршына басып өйрәнми? Зәйтүнә дә, өйләрендә берәү дә юк чакта, өстәл өстенә бәләкәй түгәрәк көзге куеп, башын-җилкәсен төрле якка боргалый, көлгән-елмайган була, кем беләндер сөйләшкәндәй итенә иде.

Тик аның мондый гамьсез рәхәт чаклары озакка сузылмады. Өй тулы бала-чаганың олысы булганлыктан, унсигез яше тулар-тулмастан ук эшкә урнашырга туры килде аңа. Ул еллардагы кысан тормышта ничек инде бер әтисе кулына гына карап тора алсын? Берәү дә әйтмәде, ата-анасы да тел тибрәтмәде. Үзе эзләде эшне. Аның бәхетенә, шул ел-

ны завод җирендә беренче тапкыр балалар бакчасы ачылды. Шунда мөрәббия[1] итеп куйдылар кызны.

Җәйге таңнар бик иртә яктыра, йокысы туймаган килеш тиз генә урыныннан кузгалып эшкә чабу Зәйтүнәгә бер дә җиңел булмый. Көн буе балалар белән мәш килеп, өй мәшәкатьләре дә үз өстендә булгач шактый арып-талчыгып, төн урталарыннан соң гына урынына түнүгә изрәп китә ул. Кайда ятканын да белми йоклый, хәтта төш тә керми иде аңа моңарчы...

Керми иде дә бит, ә менә беркөн төш күреп уянды Зәйтүнә. Хәер, төш дип әйтерлеге дә юк инде аның. Бөтенләй таныш булмаган ниндидер бер кеше күзенә чалынгандай булды да:

— Тор инде, Зәйтүнә, соңга кала күрмә,— дигән тавышы ишетелде. Аннары, кабат йоклап китмәсен дигән төсле, кул очы белән генә аның иңбашына кагылды һәм... шунда ук юкка да чыкты.

Әз генә озаграк ятса, әнисе шулай уята торган иде аны. Бу юлы да Зәйтүнәгә шулай тоелып, кинәт күзләрен ачты, тик әнисе бүлмәдә күренмәде. Хафаланып стенадагы калай сәгатькә карады — алтынчы ярты иде.

— Ай алла, соңга калып беткәнмен ич!—дип, урыныннан сикереп торды да идәнгә төшеп басты кыз. Буяулы идән салкынлыгы аның табан асларына йөгерде. Сабыйларныкыдай вак кына, тигез генә тезелеп киткән аяк бармакларын корыштыра төшеп, тиз-тиз оек киде. Кырып эшләнгәндәй төз, ап-ак балтырлары гади бер җеп оек эченә яшеренгәч тә үзләренең нәфис чалымнарын җуймады. «Кара, минем аяклар да бик үк ямьсез түгел икән...» дип уйларга да өлгерде әле ул.

Аннары, бәз күлмәк аркылы да беленеп торган нәзек билен турайтып, тәрәзә төбендә яткан таракка үрелде. Үзенә бик тә нечкә һәм иләмсез булып тоелган муеннарын каплап, әлеге акбәз күлмәк челтәре астыннан кыюсыз гына күренгән түгәрәк түшләре өстенә дулкын-дулкын сибелеп төшкән коңгырт-кара чәчләрен тарап үрмәкче булды кыз. Шул калын чәчләре арасыннан комод өстендәге көзгедә үзен күрүе булды, кинәт исенә төшеп, кычкырып җибәрде.

— Туктале, бүген якшәмбе түгелме соң?..

— Әйе, ял көне!

Һәм әле җылысы да чыгып бетмәгән урынына яңадан чумды ул. Керфекләренә эленеп калган йокы мамыклары һаман коелып өлгермәгән, татлы гына итеп күзләрен һаман бәйлиләр кебек иде.

— И дивана да инде мин!..— дип көлемсерәде кыз.— Үземнең ял көне икәнне дә онытканмын... Гел автоматка әйләнеп барам бугай инде...

Әнисе җылысына сыена торган песи баласы шикелле, Зәйтүнә дә үзенең татарча матур гына, җыйнак кына борынын ак җәймә челтәренә төртеп, күзләрен йомды, иртәнге урын җылысының рәхәтлеген кабат бер татымакчы булды кыз.

Тик ул теләгәнчә булып чыкмады. Әле генә күз керфекләрен бәйләп торгандай йокының йомшак ефәк күбәләкләре әллә кая гына очты да югалды. Йоклый алмады Зәйтүнә. Уңга борылды, сулга борылды, аннары чалкан ятып, башын мендәр артына ук ташлады. Калын чәчләре дә шул якка агылып төште...

Кем уятты соң әле аны? Әнисе дип, юкка гына сикереп торган икән ул. Түгел икән бит, тавышы да, җилкә башына кагылган кулы да аныкы түгел иде. Бик җылы, бик йомшак тоелса да, ир-егет кулы иде бит ул... И ходаем, комсомолка башың белән төшеңдә әллә нинди егетләр күреп ятасыңмы? Әллә шул хәтле азып-тузып барамы инде Зәйтүнә? Тәүбә, тәүбә!..

Тынгысын җуйган башын тагын чайкап куйды кыз. Каян килеп

[1] Мөрәббия — тәрбияче.

чыкты соң ул? Барын да исенә китерергә, төсмерләп карарга тырышты. Ә-ә, әйе, бакча йортының киң генә ачык верандасы бар, янгырлы көннәрдә балаларны шунда уйната Зәйтүнә. Һич аңлавы мөмкин түгел: ни өчендер шул ачык веранданың бер почмагында йоклый иде ул бүген. Инде кояшның беренче җылы нурлары битләренә төшә башлаганын сизеп: «Хәзер торам!» дип ята иде. Шул чагында кемнендер, һич тә күрмәгән-белмәгән яшь бер кешенең үзенә табан атлавын шәйләп алды. Аның киң якты маңгайлы, җете кара бөдрә чәчле булуы, ниндидер көчле карашының әз генә көлемсерәп торуы күзенә чалынды. Бу ят кешене күрүгә ничектер сискәнеп китте дә оялудан тиз генә юрганы астына качмакчы булды, шул чекерәеп көлемсери торган үткен күзләргә эләкми калырга теләде. Тик өлгермәде, аның ягымлы, йомшак тавышы ишетелде һәм шундый ук кулы Зәйтүнәнең ачык иңбашына кагылып узды. Шул секундта бөтен гәүдәсе кинәт дерт итеп китте. Күзләрен ачса, һичнинди верандада түгел, үз өйләрендә, үз караватында ятуын күрде кыз. Озак гаҗәпләнеп ятты ул. Һичкем турында уйлаганы да, һичкайчан андый егетне күргәне дә юк лабаса аның. Бармы дөньяда, юкмы андый зат?.. Каян килеп керде соң ул? Ни кирәк аңа?..

Көлеп җибәрде аннары. Тавык төшенә тары керер, кыз төшенә егет, дигәннәре шушы була микән әллә? Алай дисәң, андый «тары» бөртекләре турында уйлаганы да юк иде ич аның. Хәтта юри генә, ялгышып кына булса да.

Кайбер иптәш кызы сер итеп кенә аңа үзенең фәлән малайны өзелеп сөюе турында сөйли. Икенче берсе, фәлән егетне «үлеп яратса да», аның үзенә карамавы хакында үкенечле зар түгә. Зәйтүнә аларны шаккатып тыңлый. Тыңлый да гаҗәпкә кала: әллә нинди... сәер икән... балалар уены шикелледер, ахры, ул мәхәббәт дигәннәре...

Шулай тоела иде аңа. Ә бүген ни булды соң әле? Каян килеп керде ул Карачәч аның төшләр бакчасына?.. Нәрсә кирәк икән аңа? Әллә ул да «сөрсеп» йөриме?.. Юк ла, чын төш түгелдер бу. Чын төш җиде төн уртасында гына керә диләр ич. Ә инде әллә кайчан таң атып, сыртына кояш төшә башлагач кына күргән төшләр чеп-чи ялган була ди.

Шунда Зәйтүнә үз хәлен аңышып алды: туктале, егет дигән нәмәрсәкәең һаман кытыклый бара түгелме соң сине? Төшеңә кергән шул күләгәнең ярату билгесеме-түгелме икәнен җентекләргә керешеп киттең ич, кызый... Һәм кинәт кенә үз-үзенә боерык бирде:

— Житте сиңа, Зәйтүнә дигән тиле туташ! Тор, ятма сөрхәнтәйләнеп, төшкә хәтле ялкау симертеп, әллә ниткән чуар хыяллар белән саташып, әллә кайсы замандагы әллә кайсы гына патшаның әллә кем генә дигән кызы шикелле төшеңдә егетләр күреп, аларның кызыл чәчлеме, кәкре борынлымы, кылый күзлеме икәнен тикшереп!

— Тор, эшлексез! Ятма вакыт әрәм итеп, күргән төшләреңне суртларга бүлеп, әдәм көлдереп! Чын төш, ялган төш, имеш! Каян килгән бу хәтле белдекле, бу хәтле яңа фикерле комсомолка? Фал китабың да бардыр әле синең?.. Ач та, яткан килеш кенә юрап бак! Ә өеңнең идәнсәкеләрен әниең юып чыгарыр, сеңелләреңне мунчага әтиең алып барыр, атна буе җыелган керләреңне күрше карчыгы уар, ә син һаман шулай иркәләнеп кенә, төштә күргән егетләрең белән буш хыяллар күлендә йөзеп кенә ята бир!..

Һәм Зәйтүнә үзен шул тикле рәхимсез әрләүдән кинәт кенә көлеп җибәрде. Тавышы катырак чыкты бугай — челтәрле җәймәсе белән тиз генә авызын томалады. Әтисе теге якта булып, ишетә калса, бер дә әйбәт түгел инде бу...

Ниһаять, ул җитез генә кузгалды да идәнгә төшеп басты, оеклы аякларына чүәк элде, кызларча пөхтә, ыктымат итеп урынын җыйгач, кыска гына ефәк тасма белән чәчләрен артка төйнәде дә юынырга чыкты...

Аның ял көне шул үзе санаган эшләр белән узды да китте. Кичен клубка барырга кирәк иде, яңа спектакль әзерлиләр. Зәйтүнә сәхнәне яратмыйча ярата, аның уенын да хуп күрәләр бугай, спектакльдә шаулатып кул чабалар, хәтта «бис»кә чакырып та оялтып бетерәләр. Үзенә тапшырылган «гыйшык рольләрен» ничек шулай килештереп уйный торгандыр, үзе дә белми ул. Фәүзия исемле бер дус кызының йөрәк зарларын аңлап бетермәгәч, «Синең күңел күлендә корт уйнамый шул әле!..»— дигән иде, Зәйтүнә аны да аңлап җиткермәде.

«И дивана да инде син!»— дип китеп барды тегесе.

Алай гынамы соң әле, көннәрнең берендә Вәкил исемле күрше малае бәләкәй сеңлесе аркылы бер язу керттергән. Зәйтүнә аны-моны уйламыйча, нинди йомышы бар икән дип укып караса, кычкырып көлеп җибәрде: «Әйдә, Зәйтүнә, дус булыйк, пар сандугач кош булыйк»...— дип язган иде «егет». Кыз моны да аңлап бетермәде. Шул кәгазьнең артына ук: «Кара әле, Вәкил, без синең белән әллә кайчаннан бирле дус ич. Бер партада укып үстек, бер дә талашкан чагыбыз булмады...»— дип язды да бәләкәй кызга биреп чыгарды. Ә шуннан соң берничә көннәр узгач, Зәйтүнә клубтагы китапханәгә барды, Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр»ен сорады. Казаннан укып кайткан Мирза исемле бик үткен егет эшли иде анда.

— Була ул, Зәйтүнәкәй, син дигәндә — аяк идәндә,— дип, җәһәт кенә урыныннан кузгалды да уртадагы кызыл япмалы зур түгәрәк өстәл аркылы гына шкафка үрелде. Китапны шуннан гына алып бирмәкче иде ул. Ләкин шул чакта пышылдап кына әйтергә тырышкан эче тавыш белән кинәт кемдер кычкырып җибәрде:

— Аллай, чукынган!

Зәйтүнә моңа аптырап куйды, гаҗәпләнгән күзләрен зур итеп ачты да як-ягына каранды, тавышның каян килгәнен аңлый алмады.

— Давай, Вәкил дус, чык аннан!— диде Мирза, китапны Зәйтүнәгә алып биргәч.— Менә бит, кулыңа басылды, бармакларың сытылса нишләрсең?— һәм ул көтмәгәндә әлеге кызыл япманың бер итәген күтәрде дә өстәл астына чумәшкән Вәкилне тартып чыгарды.

— Әйттем ич мин сиңа, кермә анда дип. Шушындый матур туташлар килгәндә егет кеше качып калырмы?..

Бу сүзләрне бик чеметтергеч тавыш белән әйтте ул. Вәкил мескен, дөньяга карау түгел, җиргә тигәндәй башын да калкыта алмыйча, китапханәдән «ялт» чыгып сызды, артыннан ишек кенә шапылдап калды.

Зәйтүнәгә дә бик уңайсыз булды бу. Вәкил түгел, мондый хәлгә үзе төшкәндәй кызара башлавын сизеп, ихахайлаудан һаман туктамаган Мирзага китап өчен авыз эченнән генә рәхмәт әйтте дә тиз-тиз чыгып китте.

— Карале, Зәйтүнәкәй, тагын кил, яме! Миндә матур китаплар бик күп әле. Казаннан үзем кайтарттым. Иртәгә бик шәп кино була, билет алып куярмын!— дип такмаклый калды Мирза.

Зәйтүнә аның сүзләрен колагына да элмәде, ул шулай сайранырга ярата инде, дип кенә уйлады. Ә менә Вәкил бичарадан юл буе көлемсерәп кайтты: И җүләр сабый! Егет, имеш, дус булыйк, имеш! Ә үзе дус буласы кызыннан өстәл астына качып котылмакчы... Каян белде икән соң ул? Тәрәзәдән күрде микәнни мин килгәнне?..

Төш күрү генә Зәйтүнәнең күңеленә бер яңалык та алып килмәде. Күрде дә иртәгесенгә онытты да ул аны. Кызның бөтен эчке дөньясы, бөтен куанычы, хәтта хәсрәтләре дә көннән-көн шул нәниләр белән бәйләнә барды. Әгәр шул малайлар-кызлар көн буе тату гына, тыныч кына гөрләшеп, җылашмый-ырлашмый гына уйнасалар — бу аның бәхетле көне була. Тәрбияче булып эшләүне бик яратты Зәйтүнә. Яз килеп,

дөньялар яшәргәч, бигрәк тә рәхәт булып китте аңа. Таң иртәдән килеп, әниләреннән балаларны кабул итә дә барысын икешәрләп бер сафка тезә һәм җырлата-җырлата бакчага алып китә.

Әйдәгез, әйдә,
Бергәләп җырлыйк,
Бакчага чыгыйк,
Кошларны тыңлыйк,
Яшел чирәмдә
Тәгәрәп уйныйк...

Бу җырны да үзе чыгарды ул, көен дә ничектер үзе тапты шунда.

Бакча да аларның үзләре шикелле үк яшь иде әле. Мондагы үсмер каеннарның, беренче чәчәкләрен быел гына күрсәтә башлаган миләш, шомырт агачларының тамыр җәеп, кучкылланып китүенә ике генә ел. Завод кешеләре аны, язын шимбә өмәсе ясап, үзләре утырттылар. Үзләренең байтагысы такта баракларда гына яшәсәләр дә, тышкы дөньялары матур булуын теләделәр. Зәйтүнә үзе дә утыртышты бу агачларны. Аның шикелле бүген кызлар да, егет булып килә торган малайлар да бик күп килгән иде. Иртәдән кичкә хәтле эшләделәр. Моңарчы бер дә күрелмәгән күңелле бер бәйрәм булды ул көнне. Хәзер әнә нинди матур монда. Агач күләгәләре әле артык зур булмаса да, бөтен мәйданны ямь-яшел чирәм каплаган, тәгәрәшеп уйный балалар. Шулар белән бергә Зәйтүнә үзе дә тәгәрәп уйнар иде, бик рәхәтләнеп уйнар иде, тик оял , бакча кырыеннан үткән-сүткән кешеләрдән курка. Күрсәләр, бот чабып көләр алар — бу нинди тинтәк кыз дип китәрләр. Хәер, ул болай да көн буе уен дөньясында бит. Шул балалар белән куыша, йөгерешә, качышлы уйный, чуер ташлар җыя, күбәләк тотарга маташкан була. «Тоттык!» дигәндә генә ычкындырып җибәрә дә:

— Ах, очты бит, очты!— дип үкенгән була.

Җитезрәк малайлар юка гына, яшькелт ак канатлы күбәләкне тагын куып китәләр һәм «инде эләктердек!» дигәндә генә Зәйтүнә араларына килеп керә дә күбәләк котылып кала. Тегеләрнең сөмсерләре коела, борын мышкылдата башлыйлар.

— Ярамый шул, гөлкәйләрем, күбәләкнең канатлары бик нәзек, гәүдәсендә сөякләре бөтенләй юк, җаны шул канат төбендә генә тора, кагылдың исә, шундук чыга да китә җаны. Ә җаны чыккан күбәләк үлә, ә үлгән күбәләк оча алмый. Ә инде оча алмаган күбәләкнең нинди кызыгы бар?— дип юаткан була ул аларны. Кайбер үзсүзлерәкләре алай да киреләнсә, «Иртәгә тотарбыз, яме!» дип, бик ышандыргыч итеп вәгъдә бирә. Аннары күбәләк турындагы шигырьне укып күрсәтә. Шуннан ул шигырьне такмаклый-такмаклый өйрәнү китә.

Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп...

Бөтен шатлыгы, бөтен күңел дөньясы шул нәниләр аның. Барысын да бертигез итеп, ана яратуы белән ярата Зәйтүнә аларны. Көн буе шулар белән мавыгып, шуларны яшәргә өйрәтүдән башка бер кайгысы да юк аның.

Дөрес, кичен эштән кайткач әнисенә булышасы, суга чыгасы, плитәгә күмер кертәсе, өй тулы кече сеңелләрен дә карыйсы бар. Шулар өстенә комсомол җыелышларына чабарга, кичләрен яшьләрне ликбезда укытырга да кирәк. Шулай да иртәгесен таң тишегеннән дигәндәй тагын бакчасына килеп җитә ул.

Иртүк эшкә баручы аналар нәниләрен сәгать бишкә үк диярлек китереп җиткерәләр. Аларны кабул итеп аласы була. Кайберләренең әле күзләре дә ачылып җитмәгән, аягүрә йоклый, кайбере әнисенең кулына тотынган килеш сыгылып төшә. Андыйларның тиз генә өс ки-

емнәрен, аякларын салдырып койкага илтеп сала Зәйтүнә. Икенчеләре, чыр-чу килеп, әниләреннән аерыла алмыйча азаплана. Алары тагын да көйсезрәк, озак юатырга, юмаларга туры килә...

Әгәр бер бала ни сәбәптәндер килми калса, эштән соң аның өенә йөгерә. Авырган икән, җиде төн уртасында булса да врачмы, фельдшермы табып китерә, ул терелгәнче тынычлана алмый йөри.

Искиткеч кызык дөнья бу. Көн саен баланың аңына, холкына нинди дә булса бер үзгәлек килеп керә. Бу үзгәлекләрнең барысы да әйбәт кенә булып бетми. Текә тел, тәмсез сүз, тупас кыланыш, йодрык белән эш итәргә маташу, үзеннән көчсезрәкләрне төрлечә рәнҗетү шикелле ямьсез сыйфатлар малайларга бигрәк тә тиз иярүчән була. Мондый хәлләргә каршы Зәйтүнә минуты-сәгате белән көрәш башлый. Бала күңеле — буш бакча, ди әнисе. Чәчә белсәң, гөл үсәр, чәчә белмәсәң — чүп үсәр. Дөрес әйтә. Гөл чәчә башлаганчы ук, чүп баса башлый икән әле кайчакта ул бакчаны.

Кайбер бала өеннән үк шактый сәер холык белән килеп керә бакчага. Берәүне дә санга сукмый, теләсә кайсының уенчыгын тартып ала. Әйтсәң, киреләнә, бар да ул дигәнчә генә булсын. Капризына юл куелмаса, идән уртасына ятып озын-озакка сузып җылый башлый, юатырга теләсәң, аягы-кулы белән тыпырчынырга тотына, хәтта бәләкәй генә йодрыгын яман да каты ачулы кешедәй синең борыныңа таба сузган була...

Баштарак мондыйларның күңеленә ачкыч таба алмыйча гаҗизләнгән чаклары күп булды Зәйтүнәнең. Аптырагач, ул аларның өйләренә йөреп, ата-аналары белән якынтынрак танышырга тырышты. Балалар холкындагы шактый сәер яклар аңа шунда гына ачыла башлады.

Еракган да эзлисе түгел икән, күршедә генә Кәрим абзасы белән Кәбирә җиңгәсе бар. Бердәнбер малай үстерәләр. Бер кичне Зәйтүнә шуларга барып керсә, бик мавыгып, бик кызык итеп, бала уйнатып утыруларын күрде.

— Сук, Арсланым, әниеңнең борынына берне шалт итеп!— ди атасы.

Өч яшьлек малай, үзенең куш кашык хәтле генә йодрыгын чытырдатып йомарлый да, кашларын бик җитди генә җыерып, иреннәрен кысып, бар көченә әнисенең борынына китереп суга.

— Аллай, аллай! Арсланым мине нәә-нәә итте, э-э-э,— дип җылаган була әнисе. Аннары малаеның йодрыгын кат-кат үбеп чыга.— И үскәнем минем!— дип аркасыннан сөя. Шул ук вакытта икесе дә кычкырып көлешәләр, малай да куанып көлә.

Болай өйрәтелгән баланың бакчага килеп кергәч ниләр кыланачагын күз алдына китерү кыен түгел инде Зәйтүнәгә...

Икенче бер бала, бишектән төшүгә үк, «үз көнен үзе күрә» башлый икән. Аңа игътибар итүче дә, яхшы-яманны аерып, юнәлеш бирүче дә булмый. Бала тәрбиясе белән «маташырга» вакыт тапмый икән кайбер ата-аналар. Җыламаса шул җиткән...

Мондый кыенлыклар алдында да салпаеп калмаска өйрәнгән иде инде Зәйтүнә. Үзенең «бәләкәй» генә башы белән бик сәер уйларга бирелә ул: әгәр шушы нәниләрне ачык йөзле, кече күңелле, иптәшләренә яхшылык күрсәтә белүче, әти-әнисен олылаучы, кешеләрне яратучы, бәләкәйдән үк белемгә омтылучы итеп мәктәпкә озата алса, моннан да зур, матур бәхет бармы? Яңа дөньяның яңа буыны, киләчәктә аны тагын да матуррак итеп төзүне үз җилкәләрендә күтәрәсе яңа кешеләре, хәзердән үк шушы бакчаларда бөреләнә башламыймы икән? Әгәр шулай булса, Зәйтүнә үзенең шушы иң яраткан эшенә бөтен гомерен сарыф итәр иде. Яшәүнең бөтен мәгънәсе, бөтен күркәмлеге шунда күренә аның өчен.

Зәйтүнә дигән яшь кенә кыз үзенчә шундый җитди уйланулар, олы ниятләр белән онтылып йөргән көннәрдә көз килеп җитте. Яшь бакча-

дагы яшь агачларның әле кайчан гына ямь-яшел утырган яфракларына сыек сары гәрәбә төсе кереп, әкрен-әкрен коела башлады.

Шул көннәрдә уку яше керә торган унлап баланы, үзләренчә күңелле генә бер бәйрәм ясап, әйбәт теләкләр теләп, мәктәпкә озаттылар. Бөтен нәниләр өчен бик куанычлы көн булды ул. Барысының да йөзләре-күзләре балкыган, кызыгу хисләре эчләренә сыймый, кайсы карандаш бирә китүчеләргә, кайсы дәфтәр суза:

«Мә, ал, кирәк булыр анда сиңа»,— дип, олыларча бик җитди итеп тапшыралар.

— Киләсе көзгә мин дә барам, малай! — дип куя икенчесе. Ә кечерәкләр Зәйтүнәнең итәгенә сарылганнар да:

— Апа, апа, без кайчан барабыз инде мәптеккә? — дип, бора да бастырмыйлар аны.

Бу бәйрәмнән соң күпмедер узгач, яңаларны кабул итү башланды. Аналар, әбиләр китерә нәниләрне. Һәрбере үз сөеклесен мактап туя алмый: «Бик акыллы, бик зиһенле...»

Бу мәшәкатьле язу-сызу эшләре, һәр баланың холкы-фигыле турында сөйләшүләр төшкә хәтле сузылды. Сузылмый хәле дә юк, алар бакчада өч кенә кеше иде. Мөдирә апалары көн буена хуҗалык эшләре артыннан чаба, икенче мөрәббия Фагыйлә балаларны уйнату белән мәшгуль. Ә менә Зәйтүнәгә, «син җаваплырак карыйсың» дигән булып, яңа нәниләр кабул итүне йөкләделәр.

Инде аналар да таралып, эшләр төгәлләнеп барганда гына ишектән бала җитәкләгән олы яшьләрдәге бер хатын килеп керде. Таза гәүдәле, карчыга күзле булып күренде ул Зәйтүнәгә. Өс-башы да шактый затлы, кулларындагы йөзек-беләзекләре дә, колакларындагы алтын алкалары да уйнаклый иде аның. Шартлап ачыла торган сумкасыннан кәгазьләрен чыгарды да, дүрт-биш яшьләр тирәсендәге малае белән өстәл каршына килеп басты.

— Соңладым богай, әмән, ала күрегез инде, ятем бала,— дип тезеп китте ул ярым мишәрчәләтеп.

Зәйтүнә актык урынга малайны терки башлады.

— Исеме ничек улыгызның?

— Мәкчем,— диде хатын.— Улым түгел, оныгым — баламның баласы. Фамилиясе Акчурин,— дип өстәде.

Зәйтүнә аптырабрак калды: фамилиясенә караганда малай татар баласы булырга тиеш, ә исеме әллә керәшенчә, әллә урысча шунда...

— Шулай да дөресләбрәк әйтегез әле: баланың чын исеме ничек?— дип үтенде ул.— Иптәшләре арасына андый бозык-җимерек исем белән кереп китмәсен иде...

— Нек, вота, Максим — Мәгъсүм инде мулла кушканы!— диде хатын, шуны да белмәгән кызга исе китеп.

Кыз да көлемсерәп куйды. Малайның исем-фамилиясен язгач, төрле белешмә кәгазьләрен бер папкага теркәде дә, аны китерү һәм алып китү сәгатьләрен аңлатып, бу шәп алкалы апаны озатып җибәрде. Аннары Мәгъсүмне җитәкләп олы бүлмәгә күчте дә көнен шул «яңалар» белән уздырды. Әле нишләргә белмичә, ишек төбендәрәк өелешеп торган бу нәниләрне яшь аермаларына карап төрле төркемнәргә тараттьы. Андагы «иске» иптәшләре белән таныштырды, һәркайсына кат-кат әйтеп, бер-берләренең исемнәрен өйрәтте, дус-тату булырга өндәп, бакча тәртипләрен аңлатты.

Нәниләр, гадәттә, яңа баланы чит күреп, кыерсытырга яратучан булалар. Чыр-чу күтәрелә, кызлар почмакка поса, малайлар урталыкта мәйдан тота.

Монда, түземең җитмәсә, үзең дә бик тиз дулый башлавың мөмкин. Зәйтүнәнең бәхетенә күрәме, бу юлы әллә ни чәтерекле хәлләр күренмәде, яңаларның беренче көннәре тигез генә узып китте. Кичке биш белән җиде арасында нәниләрне өйләренә тарату тәмам булды.

Мөдирә апасы янына кереп, көнге эшләре турында кыскача гына исәп-хисап биргәннән соң Зәйтүнә үзе дә кайтырга чыкты. Көн буе умарта эчедәй гөжләп торган бакча бүлмәсеннән салкын һавага чыккач, урамнар аңа аеруча тын булып тоелды. Инде кояшның аяз күк читендә кичке кызыллыгы гына калган. Бөтен җиргә юка гына түшәлгән беренче кар өстенә чия суы йөгерткәндәй алсу нур сибелгән. Баскан саен шыгырт-шыгырт килә яңа кар. Әйтерсең Зәйтүнә белән сөйләшә ул. «Нихәл, кызкай, көн буе нәниләр белән мәш килеп талчыкмадыңмыни? Нигәдер бик җиңел атлый аякларың, әллә берәр куанычың бармы?...» — ди шикелле.

Юк, бер дә диярлек талчыкмаган икән шул. Аякларының шул хәтле җиңел атлавын үзе дә сизеп һәм гаҗәпләнеп бара, тик нинди куанычы барлыгын гына белми. Шулай да ниндидер шатлык көтә төсле аны, күңеле дә шуңа җилкенә кебек.

Аннары Зәйтүнә үз-үзеннән көлеп куя: «И сабый бала да инде син, бакчаңдагы утыз беренче сабый!.. Шатлык көтә, имеш... Менә кайтып керерсең дә, тавык та чүпләп бетермәстәй өй эшләренә чумарсың — менә сине көтә торган шатлык!..»

Чынлап та, шулай булып чыкты. Бөтен эшләрен төгәлләп, табыннар җыештырып, кече бүлмәдә сеңелләрен йокыга яткырып утларны сүндергәч, үз караватына килеп ауганда җеп өзәрлек җегәре дә калмаган иде Зәйтүнәнең. Башы мендәргә тисә, шундук изрәп китәрдәй тоелды. Тәрәзәдән төшеп килә торган ай яктысында әчке күлмәктән генә калып, сүткән калын чәчләре иңбашына таралгач, бөтен аркасы буйлап татлы бер кытык йөгерде. Ап-ак тыгыз түшләренә күз сала башлаган ай нурын күреп, кемнәндер оялгандай, тиз генә юрган астына чумды ул. Күзләрен йомды. Бөтен бәдәне рәхәт кенә язылып киткәндәй булып, җылы дулкын сара башлады аны...

Тик ул йокыга китә алмады. Әле генә шул хәтле кызыктырган татлы йокы Зәйтүнәне үз кочагына алырга ашыкмады. Уңга борылды, сулга борылды, тагын чалкан ятты. Нигәдер көйсез сыман тоела башлаган мендәрен сөзәкләп салды да, башын артка ташлады. Олы чәчләре дә шунда таба агылып төште. Шулай ятып йокыга китәргә ярата иде ул. Ләкин барыбер йокы кермәде аңа. Йомык күзләре яңадан ачылып, караңгы түшәмгә төбәлде. Урам утларыннан, ичмаса, уч төбедәй бер шәүлә кисәге дә төшмәгән ул түшәм, нихәтле төбәлеп карасаң да, һичнни күренмәслек төпсез бер диңгез булып тоелды. Зәйтүнә шул төпсез диңгезнең төбен тишәрдәй текәлеп ята торгач, нәкъ түшәм уртасында ике күз пәйда булды. Ул моңа башта артык игътибар да бирмәде, тәрәзә челтәре аша урамнан төшкән якты «тәңкәләр» дер дип кенә уйлады. Мәгәр ул тәңкәләр һаман саен ачыклана-кабына баргач, Зәйтүнә моңарчы һич кенә дә күрмәгән-белмәгән якты сер тулы, кайнар көч тулы шул күзләр аны түшәмгә таба күтәрә башлагандай тоелды. Кинәт тетрәнеп, куркынып китте ул. Тиз генә баштанаяк юрганын бөркәнде. Ләкин анда качып котылу да мөмкин түгел икән — күзләр дә юрган астына кергәннәр иде. Зәйтүнә, үз күзләрен чытырдатып йомган хәлдә, башын төрле якка чайкап карады, йөзтүбән капланды, алай тыны бетә башлагач, керпе баласыдай йомарланып ятты. Ә теге күзләр һаман янып елмаялар иде. Юк, явыз, әшәке карашлы күзләр түгел бу. Бары тик бәхет кенә, мәңге ярату гына вәгъдә иткән шикелле карый үзләре. Тик барыбер куркыныч. Кемдер, нидер аны менә хәзер үк тотып алыр кебек тоела. Ул, һаман кечерәя барган җәнлектәй бөгәрләнеп, тын да тартмый ята бирә. Ә йөрәге урыныннан кубардай булып дөп-дөп

тибә, каядыр ашкына ул йөрәк. Бөтен куркуларны онытып, бар гәүдәсен, башын-күзен томалаган шул юрганны сыдырып атып, аягүрә басарга, кулларыңны өскә сузып, шул якты һәм көчле күзләргә таба үзең барырга куша төсле. Тиле түгел диген син аны! Кыз бала була торып, ниндидер күзләр артыннан үзең чап, имеш!..

Шулай да Зәйтүнәнең болай куырылып-бөрешеп артык ятар хәле калмады. Эсселәтеп бетергән жылы юрганын ачып җибәрде дә чалкан ятты ул. Ә теге «сихерле» күзләр тагын караңгы түшәмгә менеп яна башлады. Шайтан күзләр түгел диген син аларны! Ул гынамы соң әле, кинәт ул күзләр өстендә ике туры каш, ак маңгай, кап-кара бөдрә чәч күренгәндәй булды... «Тукта, тукта, төш бит бу, төш!» — дип кычкырып җибәрә язды Зәйтүнә. «И ходаем, инде өнемдә дә төш күрә башладыммыни соң? Әллә саташам микән?» — дип уйлады ул. Теге вакытта, әллә кайчан бер күргән иде бугай бит инде ул шушы кара бөдрәле ак маңгайны, шушы күзләрне... Яңадан кабатлана микәнни соң ул төш дигәннәре?... «И тиле дә күке инде син, и җүләр дә тинтәк! Гомердә бер жылы караш күрмәгән диванадай, шул сихерле күзләргә йотылдың да калдың, эреден дә беттең!..»

Төн буе җәфаланды Зәйтүнә, төн буе йокы чырае күрмәде. Уйланды да уйланды. Үсеп буйга житкәч, шундый көлке нәрсәләр белән баш ватарга туры килүенә аптырады. Нинди җүләрлек бу?.. Ниһаять, таң беленеп килгәндә генә күңеле һәм гәүдәсе әкрен-әкрен тына төшеп, җиңелчә бер елмаю белән йокыга талды ул.

Иртәгесен сискәнеп уянды. Кемдер аңа әкрен генә тагын кагылгандай тоелды, күзләре белән әнисен эзләде, ул күренми иде. Эшенә соңга калудан куркып, тиз-тиз киенде-юынды да аннан-моннан гына тамагына капкалап, бакчасына йөгерде. Тыныч йокы күрмәгәнгәдерме, башы авыр, гәүдәсе салынкы, аяклары сүлпән атлый иде аның.

Ишектән килеп керүенә алгы бүлмәгә инде шактый җыелган нәниләр Зәйтүнәне сарып алды. Ул аларны чишендереп, һәрберсенең өс киемнәрен үз чөйләренә элдереп, кайсының чәчен, кайсының бантын рәтләп, ә юеш танаулы малайларның үз яулыклары белән борыннарын үзләреннән сөрттереп, икенче бүлмәгә озата торды.

Инде җыелып беткән балалар эчке бүлмәләрдә чыр-чу килә-килә уйный башладылар. Апалары тирәсендә өч-дүрт кызчык кына калды, аның вак-төяк эшләре бетүен көтәләр, аннары бергәләп уйныйсылары килә аның белән. Шул чакта, әлеге Мәгъсүм дигән яңа малайны житәкләп, ишектән бер яшь кеше килеп керде. Керде дә ишек төбендә терәлеп калды. Малайны чишендереп, киемнәрен үз чөенә эләргә өйрәткән арада Зәйтүнә ул кешегә сәерсенеп күз төшерде. Һәм кинәт тетрәнеп китте. Баскан җирендә кадаклангандай бөтен дөньясын онытып, Зәйтүнәгә караган да каткан иде ул кеше. Ник шул хәтле ашардай булып карый икән бу?.. «Исәнмесез!» дип эндәшкәне дә ишетелмәде бугай. Әллә урман шәүләгәне микән ул?..» — дип көлемсерәде Зәйтүнә эченнән генә.

Шул шәүләгәннән күзләрен борып, малайны тәртипкә китерде дә теге кызчыклар белән бергә эчке бүлмәгә озатты. Аннары, бу кеше тизрәк ишеккә борылса, үзе дә кереп китмәкче булып, аңа күз төшерде. Ә егет борылмады. Ашыкканы бер дә сизелми иде аның. Шул баскан урынында текәлгән килеш әз генә җемиеп тора бирә ул. Кыз үзенә текәлгән бу күзләрне кабат күргәч, коелып иңгәндәй булды: кичә төн буена түшәмнән карап аны йоклатмаган, куркыныч та, мавыктыргыч та булып үзләренә тарткан шул сихерле күзләр түгелме соң болар?.. Тез буыннары дерелдәп китүен сизде Зәйтүнә һәм тиз генә эчке бүлмәгә ашыкты.

— Туктагыз әле, — дип эндәште егет аңа әллә кайчаннан бирле таныш сыман бер тавыш белән. — Ә мин сезне төшемдә күрдем!..

Көлеп җибәрүдән Зәйтүнә үзен көчкә тыеп калды. Уен-көлке сөйләп, ихахайлап торыр урын түгел, ул эш кешесе. Тиз генә җитди төскә керде, ачулангандай, кашларын җыера төшеп, бу «шапылдык» кешегә карады.

Ә ул, һаман шул якты күзләре белән дусларча елмая биреп:

— Әйе, әйе! — диде.— Честное слово күрдем! Янытызда сезнең береннән-бере сөйкемле алты кыз балагыз уйный, җиденчесе алдыгызда утыра иде! Шунда безнең карашлар очрашты. Һәм мин, сезнең шул һуштан яздыргыч күзләрегезгә карап, баскан җиремнән кымшана алмас хәлдә калдым. Шул минутта, шул секундта ук сезгә гашыйк булдым! Йокымнан да гашыйк булып уяндым! «Дөньяда шундый матур кыз бар икән, мин аны эзләп табарга тиеш! Без кавышырбыз, җиде баласы түгел, җитмеш баласы булса да алам!» дип ант иттем. Сөенә-сөенә планнар корып яттым. Ярты ел эзләдем. Ә сез менә кайда икәнсез.

Мондый да әкәмәт әкиятне ишетүгә тыела алмый көлеп җибәргән Зәйтүнә үзе дә сизми калды. Кинәт куырылып төште: чөнки теге бүлмәләргә генә түгел, урамга, хәтта бөтен дөньяга ишетелгәндер күк тоелды аның бу тавышы. Мөдирә апасы килеп керсә?.. Ниндидер егет белән ихахайлап ята, имеш, монда мөрәббиясе. Бөтенләй әдәм көлкесе! Хурлык!

Зәйтүнәнең үз-үзенә ачуы килеп куйды. Туктале, нигә болай узындыра әле ул бу тәти егетне? Нигә аның суган әкиятенә авыз ерып тора? Юкмыни коры кыртыштай бер-ике сүз белән генә сыйлап җибәрү чарасы?..

— Карагыз әле, иптәш... сез берәр патша малае мәллә? — диде ул кинәт кырыс кына киная белән. Йөзендә дә шундый ук бер җитдилек туды.— Аларны гына бит, элекке заманнарда шулай төшләрендә кыз күреп, өннәрендә эзли-эзли бөтен дөньяны гизгәннәр, дип язалар иске китапларда... Әллә сез дә шул китапларны күбрәк укып җибәрдегезме?..

Зәйтүнә каршында әле һаман шул балкыган күзләре белән сокланып торучы егетнең бу «төртке»гә генә артык исе китмәде бугай:

— Юк, мин патша малае ук түгел түгелен,— диде ул уен-көлке сыман итеп кенә.— Мин — Акчурин, атым буладыр Баязит. Ә төштә күрүем хактыр. Ул — сез идегез һәм җиде балагыз белән! Эзләп табуыма бик шатмын, валлаһи әгәр!..

Теләсә-теләмәсә дә, Зәйтүнә барыбер тагын көлемсерәргә мәҗбүр булды. Безнең хатын-кыз халкы шулай бит инде ул, кызыклырак итеп әйткән сүзгә эреп китә. Шулай да аның ялганын тотмакчы булды:

— Туктагыз әле, ничек була соң инде бу? — диде ул егеткә туптуры караудан инде курыкмыйча. — Үзегез төштә күргән кызны эзлисез, имеш, ә үзегез бала атасы? Әнә улыгыз Мәгъсүмне бакчага китергәнсез: димәк, сез гаиләле кеше...

— Төгел,— дип куйды Баязит.— Андый бәхеткә ирешкән юк әле. Ул — минем пләмәш. Инәсе үлеп китте. Малай ятем, бездә тора...

Аларның мондый сәер сүзләре бәлкем тагын да байтакка сузылган булыр иде, тик эчке яктан Фагыйлә тавышы ишетелде:

— Зәйтүнә, малайларың якалаша!

— Хушыгыз,— диде кыз бүлмә ишегенә тотынып.— Сезнең белән суган сату әнә нишләтә. Онытыгыз ул әкиятләрегезне! — Һәм тиз генә эчке якка юнәлде.

— Хушыгыз! — дип калды егет. — Табам әле мин сезне, табам! — дип кычкырган тавышы ишетелде аның.

Ә малайлар, чынлап та, әлеге яңа Мәгъсүмне сырып алганнар иде. Менә озакламас, бөҗра тәмам кысылып җитәр дә, шул «ят ябалак»-

ның каурыйларын берәм-берәм йолкырга тотынырлар төсле күренде Зәйтүнәгә. Кыршау эчендә калган Мәгъсүм янына килеп керде дә ул, түгәрәкне киңәйтергә кушты, нәниләрнең кулларын бер-берсенә тотындырды. Бер почмакта үзләре генә керкелдәшеп яткан кызчыклар да килеп кушылды, җырлый-җырлый әйләнә башладылар. Әйләнү тукталгач, берәү дә көтмәгәндә, Мәгъсүм кулларын бөйрәкләренә таянып биергә тотынды. Апалары белән бергә барысы да кул чәбәкләп торды. Аякларын күтәрә-күтәрә, нәкъ «олыларча» итеп биеде дә, идәнгә башы белән кадалып, мәтәлчек атып җибәрде Мәгъсүм, бар белгән һөнәрен күрсәтергә тырышты, аннары аягүрә басып Зәйтүнәгә килеп сыенды. Бу юлы инде гөжләтеп кул чапылдаттылар. Шулай итеп, «ят ябалак» үзләшеп китте.

Ә Зәйтүнә апаларының хәле мөшкел иде. Ул көн буе шушы сабыйлар арасында кыштырдаса да, үзенең кай таба атлавын, ниләр эшләвен белмәгәндәй, әйле-шәйле генә йөрде. Чөнки үзе монда булса да, күңеле әллә кайларда иде аның. Сәер уйлар, чишелмәс табышмаклар дөньясында. Көч-хәл белән кичне җиткерде, эшләрен төгәлләп өенә кайтты. Ниһаять, өй мәшәкатьләреннән дә арынып, утларны сүндергәннән соң үзенең тын почмагына килеп ауды. «Уф алла, инде дөньялардыйн кичеп бер йоклыймчы!» — дип куанды ул. Баш төртергә дә өлгермәде, кыз баланың күңеленә капкан уйлар шикелле сер тулы төн килеп керде бүлмәгә. Ул аның бөтен куаныч һәм үкенечләрен, кайгы-сагышларын, бөтен уй-хыялларын тынлый һәм саклый белә торган, мендәрен чылаткан күз яшьләрен дә яшерә белә торган бердәнбер ышанычлы дусты иде.

— Бер йоклыймчы! — дип юкка гына кычкырган икән аның күңеле. Мендәргә башы тию белән үк уйлар дәрьясына батты ул. Үзенең бер дә көтелмәгәндә килеп туган иң яшерен аһ-зарларын, аны йөз төрле шик-шөбһәләргә салып, тәшвишкә төшерә, өркетә дә, җилкетә дә торган һәм очы-ахыры күренмәгән чуалчык кичерешләрен тагын шул төн дустына сөйли башлады кыз.

— И ходаем, и ходаем, ниләр генә кылаем! — дип офтанды Зәйтүнә. «Ходаем»ны әйткән саен тетрәнеп китә үзе. Чөнки кайчандыр ходай дигән затка чын күңеленнән ышанып үссә дә, комсомол аңа бик күп китаплар аркылы диннәр-аллалар юк нәрсә икәнне аңлатып биргәч, шулай ук чын күңелдән ходайсыз булып киткән иде ул. Үзенең төп юлына, изге иман итеп сайлаган ышанычына әз генә хилафлык итү дә зур гөнаһтан санала аның каршында. Андыйларны ул ике аллага табынучылар дип карый, икейөзлеләр дип уйлый иде. Ә шулай да «и ходаем» дигән ялварулы сүз еш кына ычкынгалый шул аның авызыннан. Бәлкем сүз җилеме генәдер, бәлкем кыен хәлдә калган чакларда кыз балада туа торган көчлегә сыгыну инстинкты буенча гынадыр? Бәлкем, бәлкем...

Зәйтүнә артык нечкәләп торыр хәлдә түгел иде бу төндә.

— И ходаем, — дип кабатлады ул яңадан, — бу нинди хәлләр соң бу? «Төштә күрдем, ди, җиде балаң, ди, гашыйк булдым», ди. Көлеп уләрсең, валлаһи! Әллә мин дә төштә күргәнне белгәнме? Каян белсен соң? Һичкемгә әйткәнем юк ич. Хәтта үзем дә онытып бара идем бит инде! Ә ул сөйли башлагач, тел очыма килде килүен, ярый әле, ычкындырып ташламадым. Һич кенә дә аңлап булмый, сәернең дә сәере инде бу хәл. Имештер, бер-берен бөтенләй белмәгән әллә кайдагы бер кыз белән бер егет бер-берен төшләрендә күргәннәр! Күргәннәр дә бер-берсенә гашыйк булсыннар! Белсә, бөтен дөнья егылып көләчәк! Көләчәк тә бит, ә шундый хәл булган! Әнә Баязит җиде балалы итеп үзе күргән кызны табуын әйтеп тә китте инде. Мин икән ул! Тик әз генә ялгышкан егет: җиде генә түгел, утыз балалы ич мин! Хәер,

шаярып кына сөйләгәндер ул, төшендә күргән җиде балалы «кыз»га кем гашыйк булсын ди инде? Саташып йөридер шунда...

Үзенең акылы сыймас чуалчык, кеше ышанмас сәер уйларыннан шундый уенчак фикерләр белән генә котылмакчы була Зәйтүнә. Мәгәр барып чыкмый.

— Ә син соң үзең дә шул саташкан егет белән саташасың түгелме?— дип битәрли башлый ул үзен.— Дөресен генә әйткәндә, син үзең дә гашыйк ич аңа! Теге әллә кайчангы төшеңдә билгесез бер егет күреп уянгач, ярты минутка гына булса да ниндидер бик куанычлы бер хис кичердең түгелме? Тик син аның шундук башына сугып өлгердең. Үзең дә белмәгән бер рәхимсезлек белән йөрәгеңнән йолкып алып, андый хыялый ялган кабат кузгалмасын өчен, өстенә таш бастырып куйдың. Ә күңел түреңнең иң яшерен бер почмагында әлеге татлы рәхәтлек, үзеңә дә сиздерми генә дигәндәй, кизләнеп калды түгелме? Инде килеп, кичәге төнеңдә төштә түгел, өнеңдә әллә ниткән аяусыз күзләр караңгы түшәмне тишеп сиңа текәлгәч, йөрәгең тагын җу-у итеп китте, син үзеңне кая куярга белмәс булдың! Чөнки син аларның теге чакта төшеңә кергән күзләр икәнен аңлап алдың. Төн буе изаланып чыктың, шул талган-тубал баш белән эшеңә чаптың. Һәм күп тә үтмәде, тагын шул күзләр килеп басты каршыңа. Бу юлы инде боларның җен-пәри күзе дә, азгын шайтан күзе дә түгел, ә гап-гади кешенең сәп-сәер күзләре икәне ап-ачык күренеп тора иде. Һәм иң куркынычы — кара бөдрә чәч, киң якты маңгай астындагы бу күзләрнең Баязит дигән исемле булуы, шундый да үз итеп, үзәгеңә үтләшеп каравы иде. Синең күңелдә тагын да көчлерәк зилзилә купты, аяк астында җир тетрәде. Нихәтле генә кырыс сыман булдып кыланырга маташсаң да — булмады, эредең. Шундый да эчкерсез сүзләре белән, шундый да ягымлы күзләренең җылы яңгыр сибелдергәндәй нуры белән җиңде ул сине. Эчке бүлмәгә ашыккан булып, тизрәк китүен теләдең син аның. Ул китте, ә син, кыйналып ташлангандай авыр гәүдәң, таркау уйларың, буйсынмас аякларың белән чайкала-чайкала, көчкә көн уздырып, өеңә кайттың, өеңдә дә җан тынычлыгы тапмадың. Үлеп йоклардай булып, урыныңа тәгәрәгән идең, ләкин... әнә таң атып килә, ә син әле керфек тә какмаган...

Төн буена йоклый алмады шул Зәйтүнә.

— И ходаем, мәхәббәт дигәннәре шушындый газаплы була микәнни соң ул? — дип кабат офтана-зарлана урыныннан торды. Биткүзен юып, аннан-моннан гына капкалады да эшенә йөгерде. Ә башында һаман шул ук уйлар:

— Бүген дә үзе килерер микән Мәгъсүмне, әллә әбисеме?
— Хәер, барыбер түгелмени соң?..
— Түгел шул...
— Юк белән баш ватма, оныт!.
— Килсен иде...
— Юк, килмәсен!..
— Юк, килсен...

Үзе белән шулай даулаша-бәхәсләшә, бакча йортына килеп керде. Балаларны кабул итеп бетергәндә бәләкәй малайны әбисе китерде. Зәйтүнәгә кинәт моңсу булып китте.

— И сабый! Тинтәк тә инде син! — дип эрләде ул үзен.

Ике-өч көннән соң... Зәйтүнә клуб китапханәсеннән чыгып килә иде, ишек төбендә Баязит басып торганын күрде. Уңайсызланып китте, кай яккадыр борыласы килде, шул ук мизгелдә эчендә нидер гөлт итеп кабынганын сизде. Беркая борылмыйча, раван-туры атлады. Һични булмагандай тынычлык белән аның янынннан баш иеп кенә сүзсез узып китәргә булды. Нияте барып чыкмады, егет аңа үзе эндәште.

Күптән таныш булган шул якты балкышлы елмаюы белән каршына басты да:

— Исәнмесез, Зәйтүнә,— диде һәм янынннан атлый башлады.— Сез инде бу әрсезлегем өчен гафу итегез, рөхсәтсез ияреп киттем, шулай да куып җибәрергә бик ашыкмагыз, яме? — дип өстәде ул, сабыйларча бер тавыш белән үтенгәндәй итеп.

— Йә, олан, йә! — дип үртисе килде Зәйтүнәнең аны. Тик эченнән тынды. Кыз бала алай кыю кылана аламы соң?

— Сез дә китап алырга килгән идегезме әллә? — дигән булды ул, бөтенләй сүзсез калмас өчен.

— Юк,— диде егет,— мин сезне эзләп йөрим. Бүген өченче кичем бугай инде: эштән кайтканыгызны да саклап карадым, клуб, кино ишек төпләрен, китапханә, репетиция бүлмәләрен каравылладым. Берәрсеннән килеп чыкмасмы, дим. Өч кич түгел, өч ел буе эзлим шикелле инде, шул чаклы сагындырдыгыз! Ә менә бүген бәхетле кичем икән, әбиләрчә әйтсәк, «күк капусы ачылды» һәм шуннан сез килеп чыктыгыз...

— Сез инде бигрәк...— дип кенә куйды Зәйтүнә. Бу сүзләр аңа артык елкылдаган алдавыч мәрҗәннәр шикелле тоелды.— Телгә шомарган «ухажор» егетләрчә сиптерәсез!

— Юк, мин чын күңелдән әйтәм! — диде Баязит.— Валлаһи әгәр! Мин бит уйнап сөйләшә белмим. Эчемдәге тышымда. Кызлар белән сөйләшеп, тел шомарту түгел, танышканым да юк иде...

Зәйтүнә елмаеп кына барды. «Әйтерсең мин танышкан! Мин шомарган! дип көлде ул эченнән.— Ике мокыт-бериштер инде шунда...» Аннары ул үзенең болай «җиде ят» белән бергә кичке урам буйлап кайтуына хафалана башлады. Ничек соң әле бу? Нигә ул аның иярә килүенә юл куйды? Кырт кисеп кире кагарга кирәк иде бит. Бергә үскән күрше-күлән малае да түгел, гомердә күрмәгән-белмәгән җиде ят. Таныш-белешләр очраса, нишләр?..

Ә егет сөйләнде дә сөйләнде.

— Беләсезме, Зәйтүнәкәй, үземнең сезне яратуым дөньяга сыймаслык зур булуын, изге булуын аңлатырга сүз таба алмый интегәм мин. Төннәр буе әллә нинди матур уйларга бирелеп ятам. Төштә күргәч үк башланды. Табармын, кавышырбыз. Һичкем дә булмаганча матур итеп тормыш корырбыз, мин аны, ул мине яратып, сандугачлар күк сайрашып кына яшәрбез. Күп итеп нәниләр үстерербез, укытырбыз, кеше итәрбез. Туксанга җитсәк тә мәхәббәтебез мәңге сүрелмәс безнең!.. Бик кыска итеп әйткәндә, матур уйлар дигәнем менә шундый минем.

Зәйтүнәгә бу сүзләр бик татлы тоелса да, көлеп куйды.

— Тавык әле ояга йомыркасын салмаган, ә сез аннан тәбә куырасыз түгелме, Баязит?..

— Куян әле урманда, аучы йөри урамда. Ә сез куян тиресеннән бүрек текмәк буласыз! — дип тә әйтегез инде, алайса,— дип өстәде Баязит.

Шулай атлый торгач, Зәйтүнәләрнең капка төбенә килеп җиттеләр, кыз өенә ашыкты. Сүз куешмый гына аерылыштылар. Куешмасалар да, юллары һаман очраша торды. Баязит тырышлыгы иде бу. Аның нинди дә булса түбән максат белән йөрмәгәне дә күренеп тора иде. Зәйтүнә аның киләчәк тормыш турындагы көлдергеч хыялларыннан бигрәк, бүгенге ихлас күңеленә ышана барды, ияләшә барды егеткә. Ни сәбәпледер очраша алмый калган кичләрендә хәтта күңелсезләнеп тә куйгалый иде.

Телләре дә хәзер аларның шактый ачыла төште, тартынусыз сөйләшә башладылар. Шулай да Зәйтүнә үз төшен сөйләп бирмәде, оялды. Хәер, чын комсомолка буларак, төшләргә ышанмый да инде ул. Ни

кермәс әдәм төшенә? Җыен тузга язмаганны, акылга сыймас әкәмәтләрне күреп ятасың. Әле кайчан гына Зәйтүнә төшендә үзен кәҗә сөзеп екканын күрде. Галәмәт тә усал, көчле кәҗә иде ул. Уянгач озак кына көлемсерәп ятты. Өндә булса, «Кәрим кызын кәҗә сөзеп еккан», — дип күзне дә ачырмаслар иде. Әдәм көлкесе бит... Ә ничеккә юрарга шул төшне? Яхшыгамы, ямангамы? Шатлыккамы, кайгыгамы? Төшнең киресе була, диләр. Димәк, өнендә Зәйтүнәне кәҗә сөзеп екмаячак! Шуның белән бәхетле булачак инде, янәсе...

Ниһаять, яз килеп җитте. Ә язын — кыш буе йоклаган табигатьнең күзләре яңадан ачыла башлый бит инде. Ачылган күзләрдән — көмеш сулы беренче гөрләвекләр бала тавышлы җыр белән кар өсләтеп йөгерә башлыйлар. Гөрләвекләр инешләргә барып төшкәч, бозлар ачыла. Бозлар артыннан бөреләр ачыла. Бөреләр ачылганда серләр ачыла. Изге серләр белән бергә йөрәкләр ачыла. Йөрәкләр ачылуга — сөю килә. Гомердә беренче тапкыр сөю. Иң беренче тапкыр!..

Шул язның көмеш сулы гөрләвекләре белән беренче тургайларымы, әллә сыерчыклар белән беренче кыр казларымы — Зәйтүнә белән Баязитка да сөю алып килде. Аңлаштылар! Сөйләнмәгән серләре калмады. Кая гына барсалар да, сабыйларча җитәкләшеп йөрделәр. Егермешәр яшьлек ике сабый! Ә сабыйларча эчкерсез бер-береңне яратканда дөнья шундый-шундый гүзәл икән, рәхәт икән, күпме гизсәң дә, иге-чиге күренмәстәй киң икән, юлларың бәрхет үләннәре белән түгел, бәхет гөлләре белән түшәлгән була икән.

Иртүк эшенә йөгергән Зәйтүнәне якындагы урам почмагыннан көтмәгәндә генә килеп чыга да, бакча йортына хәтле озатып куя Баязит. Кичен тагын шулай һичбер уйламаган берәр тыкрыктанмы, йә булмаса берәр койма арасыннанмы пәйда була да каршына баса. Кызыклы итеп, көлдерә белеп, кәеф күтәрә торган итеп кылана ул. Зәйтүнә һәр вакыт шат күңелле, өзлексез елмаюлы йөри хәзер. Дөньяда бәхет бар дип әйтәләр, тик ул бәхетне берәү дә күзе белән күрмәгән, кулы белән тотып карамаган ич, нинди икән ул дип уйлый Зәйтүнә. Уйлый-уйлый да, әгәр бәхет дигәннәре була торган булса, шушындыйдыр инде ул, дип куя. Тау хәтле эш башкарсаң да, ару-талуны белмисең, кулларың җитез, аякларың җиңел, көн буе күңелең җырлап йөри. Күгең кояшлы, рәхәт җылысы белән иркәли сине. Уйларың әллә нинди тылсымлы хыяллар дөньясына алып китә, ә киләчәк тормышың җәйнең бер иң матур мизгелендәге таң туып килгән чак булып күренә. Күк читләрен балкытып кабынган шул таң эченнән сандугач сайравы, тургай моңы җиргә түгелде. Син боларны газиз дустың белән икәү тыңлап куанасың. Шулдыр инде бу бәхет дигәннәре, шулдыр!..

Бу изге һәм исерткеч хисләр сәрхушлегеннән айный алмады Зәйтүнә. Хәер, айнырга теләми дә иде ул. Кемнең бәхеттән баш тартканы бар?..

Май ахырларындагы бер аулак кичтә Баязит болай диде:

— Инде бер-беребезне аңладык, таныштык, табыштык бугай. Инде «кавыштык» уйнарга кирәктер безгә, җаным.

Зәйтүнә елмаеп аңа сыенды, һичбер сүз дәшмичә күзләрен йомды. Шулай тиз килеп тә җиттеменни әле ул сәгать? Дөрес, ул аны эченнән генә көтә дә иде, шул сүзләрнең әйтелүен ишетәсе килә иде, әмма болай ук тиз булыр дип уйламаган иде. Шуңа күрә бер мизгелгә югалып калгандай булды, башы әйләнеп киткән сыман тоелды. Ниһаять, болай да зур күзләрен тагын да зуррак итеп ачты да башын егетнең сул түшенә салды. Күктә, йолдызларга төбәлде аның күзләре. Бакча тирәкләре арасыннан җемелдәшкән йолдызлар гүя аңа дусларча күз кысалар, котлап кул чәбәклиләр. «Риза бул, кул бир!» — дип пышылдыйлар иде. Зәйтүнә озак карап утырды аларга,

бик озак. Тик шуннан соң гына тыныч һәм тигез тавышы ишетелде аның.

— Мин каршы түгел түгелен... — диде ул салмак кына. — Ләкин ашыкмыйбызмы без?.. Үкенешмәбезме соңыннан?..

Мондый очракларда егетнең ни әйтәсе билгеле инде. Мең төрле вәгъдәләр бирде Баязит.

— Бар да әйбәт булыр, йөрәк маем! Бездән дә бәхетле кешеләр булмас бу дөньяда! Ата-анакаем да бик хуп күрәләр, — ди-ди тезеп китте ул.

Шактыйга сузылган бу сүз болай түгәрәкләнде: кыз да иң элек әниләре белән сөйләшә. Әгәр алар каршы килмәстәй булсалар... Зәйтүнә июль аенда ялга чыга, шул чагында клубта яңача туй ясыйлар. Заводта татар яшьләре арасында беренче тапкыр яңа туй!

Баязит башта моңа сәерсенебрәк карады, бәхәсләшеп тә алдылар.

— Муллалы, никахлы иске туй заманы узды,— дип аңлата башлады Зәйтүнә бик җитди генә.— Әмма загста язылып кайту белән генә тормыш корып җибәрү дә бик коры, кызыксыз килеп чыга ич, җаным. Ә туй ул — яшьлекнең, ике сөйгән бер булып яши башлауның күңелдә озакка кала торган матур бер бәйрәме, минемчә. Шуңа күрә яңа туй белән тормыш башлап җибәрсәк, бүтән яшьләргә дә юл күрсәтү булмас идеме?..

Килештеләр.

— Ярый, хыялый дустым, синеңчә булсын,— дип көлде Баязит.

Зәйтүнәнең моңача булган беркатлы бала күңеллелеге, кул белән сыпырып ташлагандай, әллә кая югалды хәзер. Ул олыгаеп, бик тә җитдиләнеп киткәндәй тойды үзен. Һәр эшен үлчәп, уйлап, якында башланасы яңа көннәренә бәйләп эшләргә тотынды. Көн саен диярлек комач әйберсе ала кайтып, һәртөрле кисү-тегү, чигү-каюлар башланып китте. Моңа күзе төшкән әнисе, бер кечне түгәрәк киергә өстеннән баш та күтәрмичә тамбур инәсе белән акбүзгә нин-дидер чәчәкләр төшереп утырган Зәйтүнә янына килде дә:

— Нәрсә, кызым, әллә безне ташлап китәргә җыенасыңмы? — дигән булды уйнап кына.

Кызы аңа куанычлы елмаю белән күтәрелеп карады. Зәйтүнә өчен бик кыен булган бу темага әнисенең үзе сүз кузгатуы да, эше белән кызыксынуы да аны бик тә сөендергән иде.

— Кыстыйлар бит, әни,— диде ул чигүеннән аерылмый гына.

— Шулай укмыни?

Һәм Зәйтүнә ояла-тартына гына сөйләп бирде.

Әнисе кырт кисеп каршы төшмәде, нindирәк кеше икәнлеген сораштырды. Анысына да кызыннан бик әйбәт җавап ишеткәч, әтисе белән дә сөйләшеп карарга булды. Чөнки ул олы кызының урнашыр вакытлары җитеп килүен үзе дә бик яхшы аңлый иде. Зәйтүнәсе артыннан ук бер-береннән калышмый калкып килә торган тагын өч былбылы бар бит әле аның. Бәхет-тәүфыйклары гына була күрсен берүк.

Ә берничә көннән соң әтисенең дә бу эшкә каршы килмәве билгеле булды. Хәтта ул егетнең атасын да азмы-күпме белә, имеш, әле. Болай яманатлары чыккан кешеләр түгел икән.

Зәйтүнә үзендәге сөенечле хәбәрне Баязитка да ирештерде. Җәйге кичләрнең берсендә киногa барышлый гына булса да алар егетнең ата-анасына да күренеп чыктылар. Якты йөз, тәмле сүз белән озатып калды картлар. Баязит үзе дә хәзер аңа теге вакыттагы шикелле әллә ниткән тылсымлы төшләр күреп, җиде балалы «ярын» эзләүче табышмак пәһлеван булып түгел, ә тормыштагы чын кеше, саф күңелле, олы сөюле бер егет булып күренә иде. Хәтта Зәйтүнә аңа кайчандыр үзе

күргән төшне дә сөйләп бирде, икесе дә рәхәтләнеп көлештеләр. Чынлап та, чәчләр чәчкә бәйләнгән икән безнең дип куаныштылар.

Шулай итеп, июльнең егермеләрендә клубта беренче мәртәбә комсомолча яңа туй ясаласы булды. Һәр икесе шуңа хәзерләнә башлады.

Комсомолча яңа туй... Әйтүе генә ансат! Ә нинди булып чыгар ул? Аны бит әле мондагы яшьләрдән берәүнең дә күргәне, ясап караганы юк. Хәтта Зәйтүнә белән Баязит та бу хакта ишетеп кенә, газитләрдән укымыш буенча гына белә... Туй ясаулар гел бетеп китте ич. Яңача түгел, хәтта искесен дә ясамыйлар. Култык астына төенчек кыстырган кызын ияртә дә егет, өенә алып кайта. Дингә ышанганы булса, ярты шешә белән бер табак аш куеп, берәр «салдырый карт»тан никах укыткан була. Комсомол булсалар, загска барып язылалар да — вәссәләм. Тора башлыйлар. Бер кызыгы, матурлыгы булмый. Бигрәк коры килеп чыга. Ичмаса, бер бәйләм тере чәчәк тоттыручы да булмагач, яшьлекнең «гаилә кору» дигән яңа сәхифәсен, яңа көннәрен, бергәлек тормыш юлларын ачып җибәрүнең нинди кызыгы, нинди гүзәллеге бар? «И ходаем, әдәм көлкесенә калмыйча, матур гына уздыра алсак ярар иде инде!..»

Шушы уйлар белән мавыгып йөргәндә, күрше малае аңа сүз катты. Кайчандыр «аллай!» дип кычкырган Вәкил иде бу. Зәйтүнә аны әлек тә күргәли, кинога кергәндә-чыккандамы, клуб ишек төбендәме дигәндәй күзенә чалынып уза, мәгәр эндәшми иде. Ә бүген эшеннән кайтканда, капка төпләрендә туры китереп, сүз әйтте аңа. Һәм ничек диде бит әле!

— Син үзеңнең кем белән йөргәнеңне беләсеңме? Манфактурчы буржуй малае белән буталасың ич син!..

Атлаган җиреннән шып туктап калды Зәйтүнә. Әйтерсең аның юлына кинәт кара елан аркылы төште. Тетрәнүдән чак кына егылмый калды кыз.

— Ни сөйлисең син, Вәкил? — диде ул, ыңгырашкандай тавыш белән аңа борылып.

Әмма күрше малае ишегалларына кереп бара иде инде.

— Атасы лавкасында комач сатып утырганын ничәмә рәт үзем күргәнем бар ул шома егетнең! — дигәне генә ишетелде. «Карале син аны, нинди көнчелек саклап йөртә икән эчендә, кап-кара көнчелек!..» дип уйлады кыз.

Көтелмәгән бу һөҗүмнән зиһене чуалып киткән Зәйтүнә көч-хәл белән генә тупсадан узды да, аңгы-миңге килгән бер хәлдә, үз почмагына чүмәште. Чүмәште дә, һаман түбән иелә барган башын тотып калырга теләгәндәй, ике учы белән йөзен каплады. Шулай озак кына бөкшәеп утырды ул.

Хәзер үк күршеләренә атылып кереп, Вәкилнең якасыннан аласы килде аның. «Ник син кешеләр өстенә пычрак атасың? Явыз җан икәнсең!» дип кычкырырга теләде. Тик урыныннан кымшана алмады. Алай дуамал кыланырга йөрәге җитәме соң Зәйтүнәнең?..

Туктале, дип гаҗәпләнә башлады ул аннары: ни дигән сүз соң әле бу? Манфактурчы малае, диме? Атасы кибетендә комач сата, диме? Ничек аңларга соң моны? Манфактурчылар бармыни хәзер? Ник булмасын, бер дә базар аркылы узганың юкмы, андагы такта кибетләрне күрмисеңме? Кайсында комач, кайсында кием-салым, кайсында галантерея — бетәсе түгел хәзер алар. Алайса, Баязит шундый бер нэпач малае булып чыга инде?.. Ә ул миңа: водокачкада торбалар карыйм, сулар патшасы булып эшлим, дип көлдергән иде бит... Кайсына ышанырга соң? Вәкил сүзе тик көнчелек кенәме, явыз ниятме? Әллә: «Ялгышма, үкенерсең!» дип кисәтүеме? Хәер, үкенердәй урын да юк төсле бит бер караганда... Атасы Пәҗнәк карт гел шундый да булсын,

ди, иске заман калдыгы... Ә Баязит производствода эшли ич! Без үз көнебезне үзебез күрербез...

Шулай да ул туй күлмәгенә кинәт кенә утлы күмер чәчрәгән кыз бала хәлендәрәк иде. Бер җирен учына бөгәрләп, кулын пешерә-пешерә сүндерсә, икенче урыннан көйри башлый, анысын да томаласа, өченче җирдән көек исе тарала... Аптырады Зәйтүнә. Итәгендә түгел иде бу ут, күңеленә капкан иде аның. Тиз генә өс-башын алыштырды да клубка юнәлде. Залны, бүлмәләрне әйләнде, китапханәгә кагылды, кино йортына сугылды. Бүген сүз куешмаганнар иде шул. Өенә бармакчы булган иде егетнең — кыюлыгы җитмәде. Суга төшкән чебеш хәлендә ничек килеп керсен кешегә? Сөйләшеп тә булмаячак бит әле анда...

Кире борылды. Үз капка төпләренә җитәрәк очратты ул Баязитны.

— Сине эзләп йөрим, — диде кыз сүрән генә тавыш белән.

— Ә мин — сине! — дип, култыклап алды егет. — Бер көн күрмәсәм — үлә башлыйм!

— Арттырасың... — Кызның шул ук сүрән-салкын тавышы ишетелде.

Баязит аны-моны абайламый иде әле. Сүзләре шикелле үк дәртчәнҗитез хәрәкәтләр белән ул аны икенче якка борып алып китте. Бараклар читендәге «куян каенлыгы»на килеп керделәр. Иңе-буе ун атламнан да артмаган бу каенлыкны бакча дисәң хәтере калыр дип, шулай атаганнардыр бәлки. Тар гына бер такталы бердәнбер эскәмиясе дә бар икән — шунда утырдылар.

Баязит тын алырга да өлгермәде, Зәйтүнә аны пешкәкли дә башлады.

— Син! Кем икәнеңне яшереп, мине хур итмәкче булып йөрисең икән!

— Син ни сөйлисең, бәгърем? — дип кенә әйтә алды егет. Аның урыныннан купкан күзләре тагын да олаеп, ниндидер ачы хәсрәт белән карыйлар иде кызга.

Зәйтүнәнең бөтен төс-битендә, тавышында булсын, рәхим-шәфкать заты һаман юк иде әле. Бик тә нык үпкәләгән иде ул аңа.

— Син кем малае? Ник әйтмәдең? — дип сорады ул.

Шактый эндәшми торганнан соң гына авыз ачты Баязит:

— Сон... Пәҗнәк картны кем белми инде...

Аның тавышы бик юаш чыкты. Күзләре дә, Зәйтүнәнең зиһеннәрен кайчандыр шул хәтле чуалткан күзләре дә, мескеннәрчә ялварулы карыйлар иде.

— Аның базарда такта алачыгы барлыгы да һәркемгә билгеле. Бөтен татар хатын-кызы ситсыны шуннан ала... — дип тә өстәде егет.

— Ә ситсыны аларга шул алачыкта син сатып торасың инде, ә?

— Үсмер чакта иде ул... Әллә кайчан ташладым инде...

Әмма болар берсе дә кызның хәлен җиңеләйтмәде. Ул үзенең шундый да беркатлы булып, бер̧енче елмайган егетнең кем икәнен дә рәтләп белмәстән гашыйк булуына, ә хәзер инде күңеленнән куып чыгара алмас хәлгә килүенә бик нык үкенә һәм көенә иде. Ничек куасың? Күңел түреңдәге иң кадерле, иң газиз кешеңә әйләнгән ич ул...

Әле генә үзен дәһшәтле һәм куркыткыч итеп күрсәтергә тырышкан тышкы кыяфәте дә, рәхимсез яңгыраган горур тавышы да коелып төшкәндәй булды кызның. Ничектер, ятим баладай корышып, таңгы кырауга эләккән гөл шикелле шәлберәп калды ул. Җиң эченнән яулык чыгарып күзләренә каплады. Аның тыенкы гына сулкылдавын ишеткән егет ни әйтергә дә белми утыра иде. Ә Зәйтүнәнең эчендә ут кайный, ничәмә төрле уйлар башына каба. Безнең кыз халкы мәхәббәттә ялгышуны бигрәк тә авыр кичерә бит ул. Нишләргә хәзер аңа? Гомере буе завод юлы таптаган Кәрим кызы сәүдәгәр малаена кияүгә чыга, имеш... «Байлыкка сусаган!» «Клубта яңа туй ясыйлар ди бит әле!» «Аннары мулла-хәзрәткә никах укытырлар». «Менә сиңа яңа тормыш!..»

Ишетеләчәк сүзләр шундый булып яңгырый аның колак төбендә. Үзен шулай аяусыз мәсхәрәли аның уйлары. Мәсхәрәләгән саен ешрак сулкылдый, яшьләре кайнаррак була бара Зәйтүнәнең. Баязиты аны юату сүзләре белән тынычландырмакчы була, уен-көлке мәзәкләр дә сөйләп карый, тик берсе дә кызга ишетелми аларның, ул саңгырау хәзер, әчке дөньясына бөтенләй башка төрле шау-шулар тулган!..

Кызның болай үз эченә бикләнеп дәшми утыруы егетне тәмам куркуга салды булса кирәк, ул бик нык пошыргаланып, сораулар яудыра башлады.

— Син миннән бизәрсеңме инде? Мине яратмассыңмы? Мине дошман күрерсеңме? Мине ташларсыңмы? Соң ни гаебем бар минем? Юк, канатым, ташлашмыйк без, ташлашмыйк! Мин синнән башка ничек яшәрмен?.. — Һәм ул малай, Зәйтүнәнең тез өстенә башын салып, сабыйларча үксеп җыларга тотынды. Аяныч та иде алар, көлке дә иде...

Төн уртасына хәтле дигәндәй шулай утырып, өйләренә кайтты алар. Капка төпләрендә кызның «хуш» дигән сүзе дә, биргән кулы да салкын булып чыкты...

Ә вакыт уза барды, вәгъдә көннәре якыная торды. Зәйтүнәгә, нинди генә авыр булса да, катгый бер фикергә килү кирәк иде. Бу төенне үзе генә чишә алмагач, райкомолга барып керде ул. Анда үзләре белән бергә үскән, хәтта ике-өч йорт аркылы гына күрше булган Валентин Косолапов дигән малай секретарь булып утыра иде. Татар кызлары аны Вәлеттин дип йөриләр, ә кайчакта «Косолапушка!» дип тә көлгәлиләр иде. Шундый якыннан белгән иптәше булса да, үз кайгысын туптуры гына түгәргә Зәйтүнәнең кыюлыгы җитмәде, әйләнечтән китерәк аңлатмакчы булды ул.

— Хәер-фатиха сорап килдем, Вәлеттин, — диде кыз елмаюлы чырай белән, — кияүгә чыгам. Татар яшьләре арасында беренче тапкыр яңа туй ясамакчы булабыз клубта. Ә сине, башкодабыз итеп, түребездә утыртасыбыз килә, рәхим итсәнче!..

— Бик шәп булачак бу! — диде Валентин куанып. — Молодцы. Баш бар икән үзегездә, әйбәт уйлагансыз. Мин бик риза! Давай, күрсәтик әле комсомол туеның нәрсә икәнен! — ул бик дәртсенеп, папирос кабызып җибәрде. — Күрәсең, егетең дә чижик түгелдер, синдәй кызны эләктерә белгәч, дим...

Зәйтүнә бу сүзгә оялган сыман итсә дә, көр тавыш белән көлеп җибәрде.

— Ә кемгә чыгасың? — дип сорады Валентин, тәмәке төтенен Зәйтүнәгә җибәрәсе килмичә, куллары белән читкә куып. — Кайсы ячейкада тора, исеме ничек ул лачынның?

Кыз тотлыга төште, мәгәр дәшми калу мөмкин түгеллеге ачык иде, тәвәккәләде:

— Исеме аның Баязит, фамилиясе Акчурин, — диде ул салпырак тавыш белән.

— Акчурин? — дип куйды Валентин, кинәт күтәрелгән кашларын сорау билгесенә әйләндереп. — Тукта, тукта, таныш фамилия бу, хәтерлим: без аны комсомолга алмадык, атасы мануфактурачы, базарда лавкасы да бар икән, үзе дә шунда маташа икән... Шул егетме? Син... ничек соң болай... Атаң домначы....

Зәйтүнәнең башы шактый иелгән иде.

— Менә, киңәшкә килдем... — диде ул кыенсынып кына. — Яратыштык бит...

— Нинди киңәш булуы мөмкин монда? — дип гаҗәпләнде Косолапов. — Нинди яратышу булуы мөмкин? Сыйнфый дошман ич ул!

Коелды да инде Зәйтүнә. Нәкъ ул курыккан сүзне әйтеп салды секретарь. Үзе дә шулай уйлаган иде бит ул, тик икеләнеп калуын гына җиңә алмаган иде. Хәзер дә тиз генә бирешәсе килмәде әле аның.

— Эшли бит ул, водокачкада...
— Юк, эшләми. Чыккан ул аннан.
— Без бит бик нык яратышабыз бер-беребезне, гомерлеккә дип сүз бирештек. Баязит бит яхшы егет... — Зәйтүнәнең тагын әле бик күп, бик әйбәт сүзләр әйтәсе килгән иде, мәгәр эчке кайгысыннан туган каушавы аның тел кувәсен алды, бутала башлады, башын түбән иде.
— Мәңгелек мәхәббәт беркайчан да булмаган ич, Зейтунушка,— диде Валентин, аны юатырга теләгәндәй итеп. — Янар да сүнәр. Ә еллар узгач, яңаны сөярсең, бу нэпач малаеннан шәбрәкне! Сыйнфый дошман яр була алмый! Андый мәхәббәттән — бәхет юк!
Ни дип әйтсен Зәйтүнә? Бөтен теләкләре, бөтен матур хыяллары көл булып шулай җилгә очкач, ни кылыр, ничек яшәр ул? Дөньяның бер яктысы да калмый ич болай булгач...
— Нишләргә соң инде миңа хәзер? — диде ул чарасызлыктан гаҗиз булып.
— Сиңамы? — дип сорады Валентин.— Укырга кирәк сиңа, Зейтунушка, укырга! Син бик уңган кыз, актив безнең. Чын коммунист булырга хәзерлән!
— Укырга? — диде Зәйтүнә бик тә гаҗәпләнгән кыяфәттә.— Әйе... Укырга кирәк анысы... тик хәзер түгел иде шикелле...
Тора-бара чырае ачылып киткәндәй булды аның. Чынлап та, Валентин дөрес әйтә түгелме соң?..
— Кстати, путевка да бар! — дип кызыктыра башлады аны комсомол башлыгы. — Кая диген әле — Казанга, Татрабфакка! Сезнең халыкның туган иленә. Син үзең дә шул як тумасыдыр әле. Пролетар токымыннан булсын дип сораганнар. Син ул ягың белән дә бик туры килә торган кыз. Әзерлән, озакламый китәсе!
Ул шундук, оештыру бүлегендәге Гриша дигән егетне дәшеп, чакыру кәгазен китертте дә, андагы сорауларны да үз кулы белән тутырып, райкомол пичәтен басып, Зәйтүнә кулына тоттырды.
— Иртәгә характеристика кереп алырсың, әзер булыр! — диде.
Кызның борылыр җире калмады. Сөенә дә, көенә дә, көләсе дә килә, җылыйсы да. Ә инде эченнән генә: «И ходаем, ниләр кылануым бу, ниләр генә кылануым?..» дип уф ора иде ул.
Райкомолдан чыгуга тагын шул ук уйлар кайнады аның башында. «Эшләми» ди бит... Чыккан. Нигә миңа әйтмәде икән, яшерүе мәллә?.. Сыйнфый дошман... Бик хәтәр сүз шул бу, куркыныч! «Сыйнфый дошман яр була алмый! Андый мәхәббәттән — бәхет юк», ди бит. Бигрәк каты әйтә Валентин... Хәер, бай белән ярлы аермасы электән үк килгән бит инде... Нишләргә соң? Әллә чынлап та китәсе микән? Әйе шул, иң яхшысы — китү булыр. Хәзер үк бакчага барып, мөдирә апаның эштән азат итүен сорарга кирәк. Бу кәгазьне күрсәткәч каршы килмәс... Монда калып барыбер кавышу мөмкин булмаячак, кавышкан сурәттә дә бәхет дигән нәрсә безнең тирәдә йөрмәячәк инде хәзер. Чөнки бөтен якты хыяллар көл булып очты. Үзем дә җүләр инде: ул малайның кем икәнен дә белмәстән, гыйшык дөньясына чум, имеш! Хәер, кем белә икән соң аны? Кем кемнең анкета күрсәткечләре белән танышканнан соң гына сөя башлый икән? Шунысы гаҗәп: атасы кылган эшкә баласы да җаваплы микәнни соң? Шул хәтле әйбәт, әдәпле һәм чын күңелле егетне сыйнфый дошман баласы булыр дип кем уйлый алсын? Хәерле булсын, киләчәктә сабак булыр... Баязитка һични белдермичә, хәтта аны бөтенләй күрмичә, тиз арада китеп барырга кирәктер инде. Төнге поезд белән. Шунсыз булмас... Әгәр күрешсәк — аерылыша алмаячакбыз. Аны ташлап китү көчемнән килмәячәк минем. Кая киткәнне белмәве яхшы — артымнан килер... И дөнья! Ничекләр түзәрмен икән?..

Таныш-белешләрдән дә һичкем күрмәсен. Бу хакта әнигә дә бер-ике сүз белән генә аңлатып, һичкемгә һични сөйләмәвен үтенергә кирәк. Әтигә соңыннан, мин киткәч кенә әйтер. Ярый әле, яңа туй турында кешеләргә алдан белдермәгән идек, юкса, менә хәзер егылып көләрләр иде... Сүз дигәнең — терекөмеш диләр. Бер тамчы булып төшсә, ун тамчы булып чәчри, имеш. Кеше күңеләре колак төбендә чыңлый башлаганчы, качып котылуың — мең хәер. Бу укырга китү җае — бик тә яхшы булды әле, рәхмәт Валентинга, каян уйлап тапты, ничек ашыктыра белде!..

Балалар бакчасына шул уйлар белән тинтерәнгән хәлдә килеп керде Зәйтүнә. Эше озакка сузылмады. Мөдирә апасы аның укырга китүен бик хуп күрде.

— Үс, Зәйтүнәкәй, укы! — диде.

Тик үзе тәрбияли торган нәниләрдән аерылу гына кыен булды кызга. Һәммәсенең башыннан сыйпап чыкты, сөйдә, елмайды һәм, җылап җибәрмәс өчен, ашыгып ишеккә ташланды. Барлык көчен шул нарасыйларга багышлап, төрле-төрле матур чәчәкләр үстерүче бакчачыдай, алардан үзе белгәнчә һәйбәт кешеләр үстерү дәрте белән яши иде бит ул. Ә язмышның беренче ачы җилләре үк аны әнә ничек сөрлектереп ташлады. Яшьлекнең мәхәббәт дигән давылына каршы торыр әмәле дә юк...

Өйгә кайткач, әнисенә шул ниятләрен ипләп кенә аңлатырга тырышты.

— Райкомол миңа путевка бирде әле, әни, укырга китәргә кушалар, — дип башлады. — Уйлап-уйлап карадым да үзем дә каршы килмәдем, китәргә булдым. Яшь чакта укып калырга кирәк. Ә кияүгә чыгу — качмас әле...

Әнисе, әлбәттә, һични аңламады. Күзләрен очлайтып, кызына текәлде. Бик сынаулы караш иде бу. Беркайчан да алдау-йолдауны, егетҗиләнбелән шаяру-шуклануны белмәгән бу акыллы кызы ни сөйли аның? Әле күптәнме генә чигү-тегүләр белән утырганда йөрәк серләрен ачып ни сөйләгән иде дә, бүген ни сөйли?

— Бу ниткән керделе-чыктылы сүз тагы? — диде ул шактый кырыс тавыш белән. — Бала-чага уены кормакчы буласың мәллә?

— И әнием!..— Зәйтүнә аны биленнән кочаклап алды да күкрәгенә сыенды, күзләрен күрсәтмәс өчен башын түбән иде. Кайнар тамчылар үз беләгенә төшеп, кинәт яндырып алгандай булды. — Ялгыштым мин... Ашыкканмын...

Һәм ул үз хәлен сак кына сүзләр белән аңлатып бирде. Борчылмаска кушты, бар да әйбәт булыр, диде. Бу хакта берәүгә дә берни белдермәвен, хәтта әтисенә дә соңыннан гына әйтүен үтенде, ә Баязит сорап килсә, Чиләбедәге туган апасына китте әле ул, дип җавап бирерсең диде...

Иртәгесен райкомолдан характеристика кәгазен һәм бакчадан тиган хезмәт хакын алып кайтты да үзе белән аласы барлык әйберләрен чемоданга тутырып куйды. Әнисе пешергән юл азыкларын җиңелчә генә ак чыбык кәрзингә урнаштырып, өстен марля белән бәйләде. Бар да әзер, хәтта юл киемен дә киенгән иде ул...

Рәшәткә капкасы төбендә ирләр тавышы ишетелде. Кыз йөрәге моны шундук сизеп алды.Әнисен чыгарды да үзе чоланга кереп бикләнде.

Капка төбендә, әлбәттә, Баязит иде. Ул инде ике-өч көннән бирле кич саен бу капка төбен таптый, тик эчкә узып керергә генә базынмый. Һәм Зәйтүнәне күрә алмыйча кайтып китә иде. Бүген дә ул тамак кыргалап торды да, ниһаять, «Хуҗалар өйдә микә-эн?» — дип, аваз салырга мәҗбүр булды. Мәгәр бик сәер килеп чыкты. Әйтерсең ул Зәйтүнәне түгел, аның әнисен эзләп килгән. Каршына атлаган Сәҗидә апаны күрүгә исәнләшү кирәклеген дә искәрмичә:

— Зәйтүнә авырый мәллә? — диде кабаланып.

Ана кеше, ул мескеннең хәлен бик яхшы аңласа да, кызы сүзеннән чыкмады, өйрәтелгәнчә ялган җавап бирде.

— Ике-өч көннән дә калмый кайтыр ул, йомыш белән генә киткән иде, — дип егетне юатырга тырышты.

Баязит нидер әйтергә теләгәндәй байтак кына таптанып торганнан соң юаш кына: «Хушыгыз, алайса»,— диде дә китеп барды.

Әнисе кергәч Зәйтүнә чоланнан чыкты, берни дә сорамады, әнисенең тирги башлавыннан куркып, вак-төяк эш белән мавыккан булды. Ана кеше актык минутларда бала күңелен яраламаска сабырлык тапты. Шул төнне Зәйтүнә үзе артыннан «куа» килгән Маһи сеңлесен ияртте дә дүрт чакрымдагы вокзалга чыкты. Иртәрәк китеп калуым хәерле, дип юатты ул үзен. Баязит белән кабат очрашса, аерылыша алмаячагын аңлый иде кыз. Ә болай әле җиңелрәк, укулар башланганчы Казан белән дә танышыр, бәләкәй чакта киткәннән бирле күрмәгән туган авылына да кайтып килер. Бар да әйбәт булыр...

... Зәйтүнә Казанда инде хәзер. Бөтенләй яңа бер дөньяда! Әле тәүлек кенә элек мең төрле пошынулар эчендә Уралдагы металлургия заводыннан төнлә «качып» киткән кыз, монда килеп төшкәч, ул пошынулардан берхәтле бушанып калгандай булды, иркенрәк бер сулыш алды...

Уку йортларының монда шундый күп булуына исе китеп, Казан урамнарын гизгәндә Болак буендагы зур бер таш бина ишегендә «Педагогия техникумы» дигән язу күрде Зәйтүнә. Һәм тукталып калды. Бирегә килгәннән бирле аны бер сорау борчый башлаган иде: «Кем булырмын икән мин ул рабфакны бетергәч? Нинди һөнәр кешесе?..»

Үзе белмәгән эшкә артык кызыкмый иде ул. Врач та, юрист та аның өчен түгел кебек иде. Ишектәге бу язу кызның шул соравын кабат исенә төшерде һәм нindидер ачыклык бирмәсме, дигән өмет уятты. Димәк, бу йорттан укытучылар чыга... Син тормышта беренче адымыңны нәниләр тәрбияләүдән башладың, шулар дөньясында үзеңне бәхетле саный идең... Шулай булгач, чыкма син шул җанлы чәчәкләр дөньясыннан. Укытучы бул. Мәктәп булсын хәзер синең бакчаң!..

Шушы уйлары таш бина баскычыннан өскә күтәрде аны. Авыр, калын ишекләрне ачып эчкә узды ул. Сораштыра торгач, кирәкле кешесен дә тапты, язуларын күрсәтте.

— Менә шушылар белән педагогия техникумына керә аламмы мин? — дип сорады.

Аның каршында чигәләренә һәм мыекларына чал йөгергән, бөтен килеш-килбәтенә укытучылык кыяфәте сеңгән бер кеше басып тора иде.

— Аласың, гөлкәем, бик тә аласың, — диде ул балаларны сөендерә торган тавышы белән.— Язуларың әйбәт — рабочий класстан икән. Комсомол биргән характеристикаң да шәп. Җидене бетергән булуың да бик хуп! Ник рабфакка кермисең соң?

Зәйтүнә өчен бик кыен сорау иде бу. Ничек җавап бирсә дә мактану шикелле тоелыр иде.

— Без ишле семья булып үстек, балаларга ияләнгәнмен, — дип кенә куйды ул...

Укый башлавына өч ай тулганда гына өйләренә беренче хатын язды Зәйтүнә. Конверт тышында да, хат ахырында да адресын күрсәтмәде, фәкать Маһи сеңлесенә язган аерым кәгазьдә генә бар иде. Һичкемгә бирмәскә, күрсәтмәскә, телдән дә әйтмәскә кушып язды. Хәер, бу хакта ул аңа төнге поездга утырып киткән чакта ук җитәрлек кисәтүләр ясап, колагына киртләп дигәндәй калдырган иде...

Җавап хаты озак көттермәде. Өй эчендәгеләрдән бәйнә-бәйнә сәламнәр күндереп, исән-сау яшәүләрен белдергәннән соң Маһи үз сүзләренә

кучкән: «Үләм инде бу Баязит абый белән, — дигән ул. — Син киткәннән бирле чистый теш төпләремә төште бит! Көн саен, кайсы гына урамнан йөрсәң дә, әллә каян гына каршыма килеп чыга да: «Кайда ул, кая качты ул? Ник качты?» — дип җелекләремә тия. «Белмим» дигәнгә ышанмый, үпкәли, миннән дә бигрәк сиңа күп ачы сүзе. «Качты, алдакчы икән... Яратам дигән сүзләре чеп-чи ялган булган икән...» — ди. Аны тыңлап торулары бик авыр, күңел түзми, җыласы килә. Кара әле, апа, ник сез шулай газап чигәсез? Ниләр булды сезгә?..»

Зәйтүнә җиңелчә генә елмаерга тели. Юк, әллә ни булмады, газап чигүләр дә күренми... Тик ялгышу гына булган, яшьлек ялгышуы. Аны гына җиңеп чыгарга мөмкин булыр!.. Үпкән-кочкан җилгә очкан дигән сүз дә бар бит әле. Тиле яшьлектә андый мавыгулар булмыймыни?

Шулай да ул хәзер үзен олыгаеп, акылга утыра барган, җилкенчәк мавыгуларны узып килә торган кызга саный. Укуындамы, комсомол эшендәме, йөреш-торышындамы булсын — җитди кыланырга, уйлап эш итәргә тырыша. Ленин көннәрендә партия сафына да кабул иттеләр аны. Утлы тәнкыйтьне күбрәк ярата торган курсташлары ул җыелышта җылы сүзләр әйтте. Үзе өчен генә яшәми, иптәшләрен дә кайгырта белә, диделәр. Җитди бәхәсләр барганда принципиаль позициядә нык тора, Ленин комсомолына лаек булган шикелле, Ленин партиясенә дә лаеклы иптәш, дип өстәделәр. Зәйтүнәнең мөлдерәмә булып күңеле тулды, җылыйсы килде. Белмиләр алар минем сай кыз икәнемне... Алдыйм бугай мин үз иптәшләремне, дип борчылды ул.

«Юк, ышанмагыз, мин бөтенләй тилемсә кыз! Әллә ниткән җүләр төшләр күреп, сыйнфый дошман малаена гыйшык тотып йөргән дивана мин!» — дип тә әйтәсе килде аның җыелышка.

Әйтмәде. Алай дисәң тиле-тинтәкнең дә теге ягында булачаксың ич син! Кем ышансын сиңа? Башы зәгыйфьләнгән икән бу мескеннең дип бөтенләй Казаннан ук куарлар!.. Шулай тыйды үзен. Партиягә кергәндә «мәхәббәт мәсьәләсе» каралмавын белми иде шул ул.

Ә төн урталарыннан соң, бүлмәдәге иптәш кызлары йоклап беткәч, алардан гына түгел, хәтта үзеннән дә яшереп дигәндәй, тагын кайнар яшь сыкты Зәйтүнә. Нинди дер татлы да, ачы да шикелле иде бу җылау. Шул якты нур балкыта торган күзле Баязитны сагыну иде ул яшьләрдә. Күпмегә хәтле барыр бу сагышлар, кайчанга хәтле сузылыр?..

Хисләрен караңгы куышта томалап, күңелен суык ташка бәйләп, күзләренә кара пәрдә корып дигәндәй кыш уздырды, язны житкерде кыз. Җәйге каникулда әниләре янына кайтса, шул Баязит белән очрашудан куркып, Казанда калды. Элек тәрбияче булуы ярап куйды тагы, монда да шундый эш табылды аңа, мехкомбинатның балалар бакчасына урнашты. Җәйге айларын шундагы нәниләр белән Идел буендагы лагерьда уздырды. Күңелле булды, күз яшьләрен исәпләмәгәндә рәхәт булды аңа...

Рәхәтен рәхәт булды, ә күңеленең әллә кай җире барыбер китек иде. Ялгыз иде ул. Үз-үзенне таш капчыкка бикләгәндәй яшәү дә җиңел түгел икән. Нигә бикләнә соң ул? Кемгә турылыклы булырга тырыша?.. Югыйсә, дәрестәшләре арасында әйбәт-әйбәт кенә егетләр азмы? Шундый якты, шундый җылы итеп елмаймыйлармы? Шундый ягымлы сүзләр әйтеп, аның күңелен табарга тырышмыйлармы? Ник танышмый ул алар белән? Ник берсенә дә якты караш бүләк итми? Ник сайламый үзенә берсен чын дус итеп? Ә шундый дус бик тә кирәк ич аңа! Бик тә кирәк! Шундый дус булса, үткән яралар тизрәк йомылмас идемени? Ялгыз башың һаман моңаеп йөрүләр кимемәс идемени?

Юк шул, булдыра алмады Зәйтүнә. Бик яхшы дуслары булса да, ярату дигән нәрсә уянмады аның күңелендә, уянмады...

Калган еллары да шулай бер төрлерәк узды Зәйтүнәнең. Башкалардан алга да чыкмады, артка да калмады кыз. Бәгырен ярапап узган

элеге аерылышу вакыйгасе дә һаман ерагая, күк томаннар эченә күмелә бара кебек, ә күңеле элекке хисләрдән әкрен-әкрен айный бара шикелле иде. Баязит дигән малай сурәте дә җаны-тәне һәм сихерле күзләре булган тере кеше түгел, ә теге әллә кайчангы бер төндә искәртмәстән төшенә кергән ярым-йорты бер шәүлә генә булып калды бугай инде...

Шулай актык елның актыккы имтихан көннәре дә килеп җитте. Тәүлек буе диярлек баш та калкытмый укулар, чышын-пышын ятлаулар, конспект чәйнәүләр, язның иң матур мизгелендә, ичмаса, бер рәхәтләнеп сандугач сайравын да тыңлый алмый калган төннәр башланды. Студентның йөрәк маен суыра торган ул көннәр дә, ниһаять, узды. Белемнәренә генә түгел, шпаргалкаларына да атланып «сират күперен» кичкәннәр диплом алу шатлыгын һәм кая билгеләнү билгесезлеген кичерәләр иде хәзер.

Ата-аналары бик чакырса да, Зәйтүнә анда кайтмаска, кая җибәрсәләр — шунда китәргә ниятләнә. Кайтса, иске яраларының кабат ачылып китүеннән һаман шикләнә иде әле ул... Һәм сыйнфый дошман малае белән тормыш кору мөмкин түгеллеген тагын да ачыграк аңлый иде хәзер. Аның күз алдында күпме мулла, сәүдәгәр, кулак балаларын техникумнан сөрделәр!

Диплом тапшыру, эшкә юллама бирү һәм саубуллашу кичәсе ул чактагы Мәдәният йортында уздырылды. Сәхнә генә түгел, тамаша залы да, фойэлар да шушы бәйрәмгә хас лозунг, плакатлар, котлау сүзләре һәм тере чәчәкләр белән бизәлгән иде. Әйбәт нотыклар, изге теләкләр күп булды. Аннары теге карт укытучы кыяфәтендәге директор урталыкка басып, аерым исемнәрне әйтә-әйтә, дипломнар тапшыра башлады.

— Зәйтүнә Кәримова! — диде ул берничә исемнән соң. — Уралдан, эшче кызы. Беренче дәрәҗә диплом. Эшкә билгеләнүе — Мамадыш каласына. Әйбәт укуыгыз өчен рәхмәт! Хәерле юл, тырыш хезмәт! Залны гөрләтеп кул чаптылар.

Зәйтүнәнең, абына-сөртенә дигәндәй, сәхнәгә менеп, бирелгән кәгазьләрен алып, калтыравыкка әйләнгән кулы белән директорның кулын кысып һәм авыз эченнән генә рәхмәт сүзе мыдырдап, залга кире төшкәнче җан тирләре чыкты. Нигә шул хәтле каушады ул? Гомерендә мондый хәл беренче мәртәбә һәм шундый зур җирдә булгангамы? Хәер, ул моңа җавап табарлык хәлдә түгел иде...

Ниһаять, барлык дипломнар тапшырылып, халык эченә мәгърифәт таратырга китүче яңа көчләргә тагын бер кат хәерле юл теләгәннән соң тәнәфес игълан ителде, аннары концерт-кичә булачак иде. Студент халкы дәррәү кубып, залдан агыла башлады. Шул агым эчендә Зәйтүнә дә бар иде. Артык бөркүлектән һавага чыкмакчы булып, уңдагы ишеккә борылыйм дигәндә, аның сул беләгенә җиңелчә генә кемдер кагылды. Әйләнеп караса — егылып китә язды кыз. Аның каршында, сагыш тулы күзләрен моңсу гына җемелдәткән хәлдә, Баязит басып тора иде. «Өрәге мәллә бу аның, күземә күренә мәллә?» дип уйлады кыз. Һәм аннары гына көч-хәл белән зиһенен җыеп әйтте:

— Нихәл, Баязит... Нишләп йөрү?..

Искә-оска кермәгән бу очрашудан аның эченә курку төште, хәтта корышып киткәндәй булды. Тиз генә, бик тиз генә агым эченә кабат кереп югаласы килде аның, мәңгегә югаласы!..

Сулдагы буфет ишеге котылгыч бер урын булып күренде кызга — шунда ташланды ул.

— Ярый әле... Ә нишләп йөрүне син сорама, мин әйтмим инде...— дигәне ишетелде артыннан кергән егетнең.— Башыңа төшкәч, башмакчы гына түгел, качкын эзләүче дә буласың икән...

Иң почмактагы бәләкәй генә бер түгәрәк өстәл артына сыенды аптыраган кыз. Тыны беткәндәй тоелгач, нәни яулыгы белән битләрен җилпи башлады. Баязит тиз генә салкын лимонад белән тагынниләрдер күтәреп килде. Ләкин Зәйтүнә боларны аңлар хәлдә түгел иде. Ничек аңласын соң! Инде күпме еллар узды, юллар суынды, эзләр өзелде, хисләр киселде, бар да онытылды дип торганда!.. Бу нинди саташу соң бу?.. Ник бу стеналарны давыл кубарып атмый, ник Зәйтүнәне тузан итеп очырмый ул моннан?..

Аптыраган-йөдәгән күзләре нииндидер билгесез бер ноктада туңып калган төсле аның. Чамадан тыш каушаган куллары белән кармалана торгач, яулыгын табып, тагын битләренә җилпи башлады. Гүяки тын алу мөмкин булмаган бөркүлектән гаҗиз иде ул. Аның бу хәлен аңлаган Баязит шешәдәге салкынча лимонадны стаканнарга салды, тынны ачып җибәрү өчен берсенең эченә ике бөртек сары «витамин»га охшаш борчак төшерде, алар лимонадны күбекләндереп, тиз арада эреп тә беттеләр.

— Әйдә, — диде егет, — бу пирожный кисәген капкалыйк та, аннары салкынча лимонад эчеп җибәрербез. Озакламый, концерт та башланыр ич...

Кызлар татлыны яратучан булса да, Зәйтүнә пирожныйга кагылмады, кибегүен басарга теләп, күбекле суны бертоташтан эчеп җибәрде. Рәхәтләнеп киткәндәй булып, тыны-көне ачыла төште, хәтта елмаенкырап куйды. Аннары, кызыгып киткәндәй, бер пирожный да ашады.

— Сине, сине эзләп килдем мин! — диде егет. — Җиде кат күккә менеп, җиде кат җир астына төшеп булса да табармын дип ант иттем һәм таптым!

Өстән кыңгырау тавышы ишетелде. Буфеттагы кешеләр ишеккә тыгылдылар. Алар чыгып бетүгә Баязит белән Зәйтүнә дә кузгалды.

Кинәт таш идән чайкалып китте кебек. Зәйтүнәнең күз алдында исәп-хисапсыз очкыннар уйнады, ә тәрәзәләр, буфет киштәләре, ишекләр, кырын-ярын килеп, туктаусыз әйләнә башлады. Кызның бая сораган давылы инде купкан иде, һәм дөнья, диңгез уртасында калган ялгыз каек шикелле, айкалды-чайкалды да, нииндидер ташка сугылып аска капланды... Аңын җуюдан урындыгына сыгылып төшкән Зәйтүнә каршында коточкыч курку баскан Баязит нишләргә белми аптырап калды.

— Ни булды соң? Ни булды шулай кисәк кенә? — дип пышылдый иде ул. Аннары башын күтәреп, куркынган күзләрен тирә-якка йөртте дә ачыргаланып ишеккә ташланды. — Ярдәм, ашыгыч ярдәм! — дип, вахтер янындагы телефонга килеп тотынды...

Зәйтүнә күзләрен ачканда үзен ак бер бүлмәдә күрде. Мондагы бөтен нәрсә дә актан иде. Үзенең больница койкасында ятуын аңлады ул. Сул тәрәзәгә түбәнтен генә сузылып кояш төшкән. Шул кояшлы пыялага каен яфраклары кагылып уйный. Ботак очларында тулып бүрткән яшел әкәйләр суыра торган баллы канфит булып күренәләр. Авызыннан сулар килер. Бала чакта шул әкәйләрне өзәр өчен югарыга үрелеп яшь каеннарны сыга торгач, күлмәк җиңнәрең ертылып, бит-күзләрең тырналып бетә иде бит...

Җиңелчә җил белән каен яфраклары пыялага кагылып һаман җилферди, тәрәзә артына килеп нидер сөйли төсле. Ә кояш кичке түгелдер, ахры, шәүләсе һаман текәләнә, нуры һаман җетеләнә бара. Зәйтүнә урыныннан кузгалып, тәрәзәгә килмәкче, тупсасына таянып тышка карамакчы, хәтта ачып та җибәрмәкче булган иде. Барып чыкмады. Торып аякларын идәнгә суза башлауга йөрәге каты дереләп һәм чәнчеп

китте, бөтен гәүдәсе хәлсезләнде, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә башлады. Теләр-теләмәстән мендәренә кире ауды ул.

Ни булды икән аңа? Көтмәгәндә китереп тота торган нинди чир икән бу? Андый төрле өянәге-фәләне дә юк иде бит аның... Уйлары белән күпме эзләнсә дә, бу хәлнең сәбәбен таба алмады ул. Әллә пирожный ашавыннан булдымы? Хәер, бер дә андый шикле күренмәде ич. Начар булса, Баязитка да зыяны тияр иде ләбаса...

Баязитка?..

Кара, нишләп ул күренми икән? Минем хәлне күргәндер ич ул... Хәер, бәлки аны да больниска салганнардыр?.. Әллә кул селтәдеме? Нигә, үзең бик теләгәч, селтәр дә шул... И сантый да инде мин! Үзем аннан качам, үзем килүен телим. Балалар эгоизмы дигәне түгел микән бу?..

Өлкән яшьләрдәге бер ханым күренде ишектә. Аның бөтен җире, крахмаллаган шикелле, шыштырдап торган ак иде. Кулындагы термометр һәм ниндидер даруларга караганда, дежур сестра булырга тиеш.

— Әһә, димәк, терелә башладык! — дип елмайды ул Зәйтүнәнең ачык күзләренә карап. — Юкса, куркыта язган идегез. Мин инде ике тәүлектән бирле керәм яныгызга, ә сез һаман күз ачарга теләмисез. Әйтерсең әнә шул якты кояшлы матур дөньядан бөтенләй бизгәнсез...

Зәйтүнә дә елмаерга теләде, чыраена җылы яктылык йөгергәнен үзе дә сизгәндәй булды.

Сестра термометрын селеккәләп аның кайнар култык астына тыкты. Терекөмешле пыяла салкыны кызның бөтен тәненә йөгерде, рәхәт бер чиркәнчек алу тойды ул. Аннары сестра ниндидер дару эчерде аңа. Тын гына ятарга кушып, күрше бүлмәгә юнәлде.

«... Бөтенләй бизгәнсез... Якты кояшлы... матур дөньядан» дип ятты эченнән Зәйтүнә. Сәер бу сестра. Улмы соң дөньядан бизәр кеше? Ни өчен?.. Ничә ел укып, шундый диплом алып, әле дөньяны яңа башлыйм дип кенә торганда... Юк, башына да килгәне юк Зәйтүнәнең андый уй! Якты дөньядан туючылар булуына ышанмый да ул. Андыйлар була калса, бик тә бәхетсез бәндәләрдер алар...

Сестра әйләнеп керде, Зәйтүнәдәге термометрны алып карады.

— Ә температурагыз һаман төшми, — диде, кашларын җитдиләндереп, — ошамый бу миңа!

Кыз гаепле кешенекедәй тавыш белән генә сорап куйды.

— Нәрсә белән авырыйм соң мин, сестра?..

— Ә сез үзегез белмисез дәмени?.. — диде сестра, ышанмаган сыман итеп. — Ничек инде ул алай?

— Юк шул, белмим шул...

Өлкән яшьләрдәге бу ханым, әйтимме-юкмы дигәндәй, икеләнеп калды.

— Анализ күрсәтүенә караганда — сез агулангансыз. Шуннан артыгын мин белмим... Озакламый, врач керер, ул сезнең белән сөйләшер һәм аңлатып бирер...

Зәйтүнәнең күзләре көтелмәгәнчә бик зур булып ачылды, төсе качты, иреннәре күгәрде.

— Мин?.. Агуланганмын?.. Кем... Ничек...— дип кенә әйтә алды ул хәлсез тавыш белән. Әле генә зур булып ачылган куркынулы күзләр яңадан йомылды. — Э-эһ, — дип ыңгырашты ул һәм аңын җуйды.

...Кызның күзләре икенче тапкыр ачылганда аның аяк очындарак Баязит утырганы күренде. Җилкәсенә ак халат салынган, төсе-бите йончыган, күзләренең мае беткәндәй тоныгып, яңаклары суырылып калган. Кыска бер вакытта Зәйтүнә күңеле кызганып куйды аны, тик шул ук мизгелдә йөзен читкә чөерде ул, күзләре ярым йомык хәлгә килде. «Ник килгән?.. Ник йөри?!»

Инде ничәмә сәгатьләр буена Зәйтүнәнең йомык керфекләренә, ап-ак хәлсез чыраена карап утырган егет кинәт кенә аның күз яктылары күренүгә сабыйларча сөенеп тә өлгермәде, «күк капусы» яңадан ябылды һәм башы сулга чөерелде.

— Зәйтүнә... Зәйтүнә... — дип эндәште егет җан тавышы белән пышылдап кына. — Хәлләрең ничек... бик авыр түгелме... терелэсеңме инде?..

Җавап булмады. Әйтерсең Зәйтүнә бу ялваруның берсен дә ишетмәде.

Байтак тын утырганнан соң егет тагын дәште аңа.

— Әллә нәрсә булды сиңа, Зәйтүнә... Әйбәт кенә сөйләшеп утырдык... Инде концертка керәбез дигәндә генә... Мин бик куркып калдым, бөтенләй зиһеннәрем чуалып китте... «Ашыгыч ярдәм» машинасына мине алмадылар... «Төн-көн үзем кизү торам, үзем карыйм» дигән идем, алмадылар...

Кыз боларның һәммәсен дә ишетеп ята, тик берсенә дә ышанмый, акланырга маташа дип уйлый иде. Каны каткан иде аның. Агулануын белгәннән соң шулай булды ул.

Ә егет, һаман аңа елыша төшеп, бөтен койкасы, юрганнары-ние белән кочып алырдай булып, үзенең йөрәк сагышын һаман түгелдерә бирде.

— Әйтми китүеңә үпкәләмәдем... Шулай кирәклеген күңелемнән кай җиредер әйтеп бирде... Пәжнәк картны «Сандугач атавына» озаттылар... Инәй бик жәл... Никтер миңа тимәделәр... Эштә булганга микән... Син киткәч кердем... Сиңа әйтәсе сөенечләрем бар иде... Югары разрядлы слесарь мин хәзер... Эшче сыйныфка берегеп үсәм... Хәзер инде яңача туй ясарга да була.

Зәйтүнәгә боларны тыңларга мәҗбүр булып яту бик тә авыр булды, юри кыланган шикелле килеп чыга иде. Аның тыны кысыла, йөрәге көйсезләнә башлады, хәле китте. Ирексездән күзләрен ачып, «су!» диде.

Егет, аның телгә килүенә бик тә куана-куана, су салып эчерде.

— Йа алла, синең бер кәлимә сүзеңне ишетер көнем дә булыр икән! — дип елмайды.

Кызның чыраена яктылык иңмәде, күзләре кабат йомылды, Баязит тагын хафага төште. Ни кылырга белмичә, ишекле-түрле йөрергә тотынды.

— Ни булды соң сиңа, ниләр генә булды? — дип өзгәләнде ул.

Зәйтүнә, ниһаять, тәвәккәлләргә булды. Үпкәсе чиксез иде аның Баязит аңа икейөзле булып тоелды. Өзәргә, бер чабуда өзәргә!

— Син кит моннан... — диде Зәйтүнә бөтен көчен җыеп. — Беркайчан да күренмә, юлыма чыкма...

Егетнең өстенә кинәт бозлы су койгандай булды, һични аңлый алмаудан гаҗиз калды.

— Ни сөйлисең, Зәйтүнәкәй, бу ни дигән сүз?! Шул сыйнфый дошман булганым өчен генәме, бүтән гаебем дә бармы?..

— Сабыйлар булып кыланмыйк, — диде Зәйтүнә, шактый зәһәр көлемсерәгәндәй итеп. — Сыйнфый дошман булу — бик пүчтәк нәрсәмени ул?.. «Ни булды?» дип кат-кат сорап маташуың да бик сәер яңгырый. Ә соң ни булганын синнән дә яхшы белгән әдәм бармы?..

— Зәйтүнә, ник син мине шул тикле җәберлисең? Синең каршыңда сөттән ак, судан пакь мин! Һичбер гаебем юк!

Кыз аны хәлсез иреннәре белән үчекләгәндәй тагын көлемсерәп куйды.

— Үзеңә бармаган кызга агу эчерсәң дәме?

Баязитның кайчандыр балкып янган төссез күзләре урыннарыннан купкандай булып өскә сикерде, чәчләре үрә торгандай булды.

— Әстәгыфирулла! — дип куйды ул, карчыкларча итеп. — Ничек телең бара? Авызыңнан җил алсын бу сүзне. Ник агу эчерим ди мин сиңа? Аллам сакласын!.. Ул бит, ул бит... сөйдергеч даруы гына иде... Аптыраганнан-йөдәгәннән генә... Сине һич кенә дә югалтасым килмәгәнгә... Бер карт әби-врач ясап бирде, кулы шифалы дип, бөтен кеше йөри аңа. Үзең дә беләсеңдер, Маргарита әби...

— Әтекәйләрем! «Сөйдергеч даруы»на да ышанасыңмыни әле син, Баязит? Ай-яй, бигрәк тә заманнан артта калгансың икән. Әйтәм җирле аны, миңа эчергән суыңнан, анализ күрсәтүенә караганда тигәнәк мае, тилебәрән орлыгы һәм дәрмана белән мышьяк чыккан. Шәп «врач» икән ул әбиең! Кеше үтерүдән дә курыкмый. Эх, Баязи-ит!.. Булды... Аңлаштык... Хуш... — диде Зәйтүнә салкын тавыш белән. Аннары бөтенләй икенче ягына борылып ятты. Куе кара керфекләре кайнар күзләренә сарылды. Егетнең ирләрчә тыенкы үксүен аңлады кыз. Аннары әкрен генә ишек ябылганы ишетелде.

... Уникс тәүлек тулганда Зәйтүнә терелеп чыкты.

— Ярый, бәхетегез бар икән, — диде дәвалаган врач, — яшьлегегез җинде. Юкса, хәлегез шактый мөшкел иде... Алгы юлыгызда ялгышмаска тырышыгыз инде... Кыенлыктан чыгуның юлларын һәр вакыт табарга мөмкин... Хушыгыз, уңыш телим...

Зәйтүнә бу хәлгә төшүенең төп сәбәбен күпме генә сорасалар да әйтмәгән, дөресрәге, әйтергә оялган иде. Ничек инде: «Егетем сөйдергеч даруы эчергән», дип, авыз күтәреп сөйләмәк кирәк, көлке ич. Шуңа күрә аны үзе агуланган дип уйладылар. Врачның соңгы сүзләре дә шуңа ишарә булуына эче пошып, аңа күп-күп рәхмәтләр укыды да, алмага килгән иптәшләре белән тизрәк тулай торакка юнәлде...

Җәйге ялын әниләре янында уздыргач, яңа урынга килеп эшли башлады ул. Әше кыен түгел, элек балаларны уенга, җырга өйрәтсә, хәзер ул аларны укырга-язарга өйрәтә. Аларны җитәкләп китаплар дөньясына, фән бакчасына алып керә. Мәктәбе аның яр буе урамда, класслары Нократ иделенә караган. Буш минутларында тәрәзә каршына килеп баса да, шул киңлекләргә төбәлә аның күзләре.

Ага да ага сулар. Туктау юк, тыну юк... Уралып, сарылып ага сулар... Кеше гомере дә шулай бугай. Агыла да кагыла... Әйләнеч эзләрдән, тар бормалардан, хәтәр кыялардан ыргылып, мавыктыргыч матур юл эзли кеше. Һәм: «Инде таптым, инде кояшны тотып алдым!» дигәндә генә, ут кубәләге шикелле, янып җиргә төшә... Әйе, агымсулар туктамый, һаман бер үзәнлектән әйләнеп-тулганып ага бирә, ага бирә. Ә кеше ашыга, ялгыша... һич көтмәгәндә, уйламаганда бәгырен ут чорнап ала, йөрәге көл булып кала. Бөтен хыяллары, бөтен якты хисләре тузан булып күкләргә оча... Әйе, ялгыша кеше. Ялгыша кыз бала...

Сулар шулай ага бирде, еллар шулай уза бирде. Кайчандыр Зәйтүнә татыган бөтен якты хисләр, сөю куанычлары, аны хафага салган кайнар көенечләр, ялгышу үкенечләре — барысы да, барысы да бик күптән, инде бала чакта ук күргән нарасый бер төш шикелле, зәңгәр томан эченә күмелеп, мәңге булмагандай, күңеленнән юылып бара инде. Калын чәчләренең чигәсенә сибелә башлаган көмеш суы да, мөгаллимәлек төсе сеңгән тын-тымызык чырае да шуны сөйли кебек. Язгы сулар ачылгач, Нократ аръягындагы болыннарда төн кунып китә торган кыр казлары гаңгылдашуы да, ара-тирә генә ишетелеп калган аккош тавышлары да җилкетми инде аны. Шул язмышына буйсынып, бары тик балалар белән генә куанып яшәүче Зәйтүнә иде ул хәзер. Шундый язларның берендә аның тар гына, бәләкәй генә булмасена күрше тирәдә яшәүче Хәмдия апа дигән хатын килеп керде.

— Исәнме, Зәйтүнә, — диде ул. — Менә сиңа бер әманәт алып кайттым әле...

Өстенә бер сүз дә язылмаган гади бер конверт бирде. Зәйтүнә аны кулына алгач, гаҗәпләнгән бер хәлдә карап тора башлады. Хәмдия апасы тагын сөйләп китте.

— Өфе ягына барганием, Шафран дигән җирләренә. Анда минем олы кызым эшли. Систра булып авыру-сырхауларны карый. Үпкә белән җатучылар икән. Шунда сине белгән бер кеше бар, имеш, көн саен сораштыра, имеш, кызымнан. Мин килгәнне ишеткәч, аңа шушы канвиртны биргән, зинһар тапшыра күрсен әнкәң, дигән. Әманәткә хыянәт булмасын дип, тизрәк кертеп чыгыйм дидем. Хәзергә хуш, алайса...

Хатын чыгып та китте, кыз рәхмәт әйтергә дә онытты бугай. Шул әманәт дигәнне тоткан килеш, баскан җирендә тораташ булып калды. Ниндидер эчке бер куркыну билән алган иде аны. Конвертны әйләндергәләп карады. Ачты. Хат иске хәрефләр белән язылган иде. Таныш почеркны күрүгә йөрәге жу-у итеп китте, хат тоткан бармаклары калтыранды, андагы юллар чайкала, сикерешә кебек иде. Шулай да күз йөгертте.

«Гаҗәп, нигә үлмим икән мин?.. — дип башланган иде ул. — Бу дөньяга минем ни кирәгем бар? Аның да миңа кирәге юк. Әллә кайчан кабергә хөкем ителгән бәндә! Ә шулай да үлеп булмый. Ни яшәтә икән мине? Белмим. Бер өметем дә калмады, югыйсә. Үпкәләр ертык та тишек. Корт мыжгый аларда. Сагыш кортлары. Нигә тизрәк кимереп бетерми ул комсыз кортлар мине? Менә тагын яз. Язгы бозлар алып китә диләр миндәйләрне... Әй, сөенер идем бозлар белән агып китсәм!.. Ә күңелдә тинтәк бер теләк: ичмаса, төшемдә генә һәм бер генә тапкыр күрсәм дә шуны, үлем чүп кенә булып калыр иде, дим. Ә син кермисең дә кермисең төшләремә... Бүтән бер үкенечем дә калмас иде... Күпкә китте... Хуш... Бәхил бул!.. Бәхетле яшә, якты яшә!.. Баязит.»

Актык юлларны укыганда Зәйтүнәнең күзләре хәрефләрне таный алмый башлады. Алар ничектер җәелеп, су өстендәге вак дулкындай биешәләр иде. Көч-хәл белән тәрәзә янакларына килеп тотынды ул. Түбәндәге Нократ ташуы да ярсып айкала, ярдагы көймәләрне әзеп китәрдәй чайкый кебек күренде. Җил чыккан икән, монда да тынгылык беткән... «Ник ярсына бу дөнья?.. Аңа ни булган инде?»..— дип уйлады Зәйтүнә.

... Май аенда башлангыч классларда укулар тәгалләнде. Әлеге хаттан соң бөтенләй боегып, моңсуланып калган кызның уйлары һаман бер тирәдә әйләнә иде хәзер. Ниһаять, мәктәп эшләре бетүгә ул уйлар тәвәккәл бер хәрәкәткә әйләнде.

Соңга калган аккош сыман, бозлар эрчелгәч килгән беренче пароход белән китеп барды ул. «Кирәк, кирәк, кирәк!» — дип типте аның йөрәге. «Юкса, мәрхәмәтсезлек булачак!..» Соколкада Уфа пароходына күчеп утырды. Шафраннан түгел, Салават тирәсендәге таш карьер төбәгеннән барып тапты ул аны. Тешләре әллә кайчан коелудан әби авызлы булып беткән, болай да юка гәүдәсе бөтенләй кечерәеп калган бик борынгы бер әбинең бәләкәй генә өе сәкесендә ята иде егет. Әби белән исәнләшкәннән соң Зәйтүнә аның аяк очына килеп басты. Күзләре йомык иде — йоклыймы, хәле шулай авырмы... Йөзләре сулган, саргайган, ябыккан. Кайчандыр балкып, яшьлек һәм тазалык ташып торган Баязитның бу дип уйлавы да кыен иде хәзер...

— Үпкә зәхмәтенең катысы эләккән балага, — диде әби берхәтле танышып алгач. — Кәҗә сөте дә күп эчердем, кымыздан да өзгәнем юк, үләннәр белән дә дару итәм, әммәдәки мантымый балакай... Аның ичкеме дә калмады хәзер, инәсе ягыннан бер мин — чыбык очы... Белмим инде, аптыраган, ниндәен генә духтырларга күрсәтәсе инде тагы...

Зәйтүнәгә бу сүзләр ерактан гына ишетелгән кебек. Баскан җиреннән купмыйча, күзләре белән һаман сырхауга текәлгән ул. Уйлары әллә ничә-әллә ничә төрле, чуалчык...

Ник монда килде инде ул? Аны шушы хәлдә күрер өченме? Йөрәк ялкыны күпме еллар буена эчкә, тирәнгә куылса да, күпме суык сулар сибелсә дә, һаман сүнмәгән-сүрелмәгән булуымы? Баязитның шул актык хатын укуга да ул ялкынның кабат «гөлт» итеп өскә калкуы мәҗбүр иттеме? Вөҗдан-намус кушуы, кешелек бурычы җитәкләп китердеме? — берсенә дә анык кына җавабы юк иде кызның. Шушы сәгатьтән алып нишләргә тиешлеген, беренче хәрәкәтне ничек ясарга кирәклеген дә белмәде ул. Хәзер үк, шушы минутта ук, Баязитны самолетка утыртып Уфага яки Казанга, анда булмаса Мәскәүгә очырып, иң яхшы профессорларга күрсәтергә, алар кушкан клиникага салып дәваларга, аннары илнең иң яхшы санаториена җибәрергә теләде ул. Фантазиянең көчлесе һәм татлысы иде бу, үзе дә көлемсерәгәндәй итеп алды. Күз ачып йомганчы килеп җитә торган андый самолетлар да, алар кунаклардай аэродром да юк иде бу тирәләрдә. Монда тик Урал итәгеннән таш чыгаралар, яңа шәһәр кормакчы булалар иде.

Егетнең кипшенгән иреннәрен ялмап, башын боруы, шунда күзләре дә әз генә ачылып китүе чынлыкка кайтарды Зәйтүнәне. Шул ярым ачык нурсыз күзләре белән байтак карап ятканнан соң гына танып алды булса кирәк, елмаерга теләде егет.

— Килдеңмени?.. — дигән хәлсез сүзе ишетелде.

Зәйтүнә аның янына утырды. Күкрәгенә кочып, бөтен җан түреннән чыккан юату сүзләре әйтәсе, «терелтәм мин сине, терелтәм!» дип кайнар вәгъдәләр бирәсе килде аның. Тик берсен дә әйтә алмады, егетнең күзләре яңадан йомылган иде.

— Ни хәлләрең бар соң?.. — дип кенә сорады ул әкрен тавыш белән.

Әби карчык аңа бер чокыр су китереп бирде. Зәйтүнә авыруның башын беләгенә салып, су эчерде. Яулыгы белән йөзендәге һәм муеннарындагы салкын тирен сөртте. Баязитның күзләре кабат ачылмады да диярлек. Мендәрен рәтләп яңадан яткыргач, әйтә куйды:

— Минингит башланган диләр миндә. Кох таякчыклары кан белән баш миенә менә, имеш...

Ни дип әйтергә дә белмәде Зәйтүнә. Күзләрен томалап килгән яшьне кире йоту өчен бик күп көч кирәк булды аңа.

Әби кеше инде бу кызның кем икәнен, кайлардан һәм нигә килүен аңлый башлаган иде. «Шәфкать фирештәсе» дип атады ул аны эченнән. Чәй әзерләп эчерде. Юк-бар сораулар биреп йөдәтмәде.

— Тукталган җирең булмаса, үз кунагыбыз бул, урын табармын, — диде.

Өй алдында бәләкәй генә тәрәзәле такта чоланы бар икән, шуны күрсәтте. Эчендә тар гына караватт кисәге дә күренде.

— Җәйлек өчен менә дигән почмак, — дигән булды. — Ирәндек түбәләренә чыгып йөрерсең, арт табарак инеш тә, болыннар да бар,— дип өстәде.

Зәйтүнә, бу әйбәт карчыкка рәхмәт укып, шунда калды. Хастаның хәлен, әлбәттә, берничек тә яхшырта алмады ул, яхшыртудан узган да иде инде. Могҗиза юк шул бу дөньяда... Әби әзерләгән үлән төнәтмәләрен, аптека даруларын эчерде. Көн саен диярлек карьердагы фельдшерны алып килде, аның киңәшләрен үтәде. Хәтта кантон күләмендә атаклы карт врач Терегуловны да китертеп карады. Мәгәр бу бәхетсез өйгә өмет яктылыгы иңмәде.

— Хәзергә медицина көчсез шул әле, — диде карт. — Әгәр кешенең үз организмы җиңеп чыга алмаса, кох таякчыкларын тәмам бетерә торган дару табылмаган әле. Бөтен өмет — киләчәктә. Без аны табарга тиеш!..

Юату сүзләре күтәренке иде. Тик егетнең хәле генә көннән-көн мөшкелләнә барды. Унбиш тәүлек буена көн-төн аның янында утырды Зәйтүнә. Әбине артык борчымас өчен бөтен мәшәкатьләрне үзе күтәрде. Йокысыз төннәрдән күз алмаларына кан савып, башы авырайды, йөзләре сулыгып-суырылып калды. Ул килгәннән бирле Баязитның рәтләп сөйләшә алыр хәле булмады, төннәрен еш кына саташып, бәйләнешсез пышылдаган сүзләрне тыңлап утыру бигрәк тә авыр иде. «Еракка, еракка, икенче бер матур җиргә качыйк без аннан. Туйны да шунда ясарбыз...» — дип пышылдады ул бер төнне. Икенче бер кичтә: «Ә синең туй күлмәгең бик матур булган, аккош, тик канатларың гына сыймый бит анда...» — дип куйды.

Тора-бара егетнең ул сүзләре дә бөтенләй аңлаешсызга әйләнде. Ниндидер куе томан эченнән генә ишетелгән кебек иде. Үпкәләп, рәнҗеп китмиме ул аңа, бәхиллеге бармы, аңлыймы ул Зәйтүнәнең хәлен?.. Ниһаять, ул бөтенләй телдән калып, ыңгыраша гына башлады. Су эчерде Зәйтүнә, дару эчерде, аларның яртысы да керми иде авызына. Ашатканда да шул ук хәл: берәр кашык йота да, ютәле кубып, башын читкә ташлый.

... Актык төн килде. Җәйге таң беленеп, тәрәзәләр аксылланып килә иде. Баязит тагын бик каты буылып йөткерә башлады. Зәйтүнә аны бәләгенә салуга авызыннан гөрләп кан китте һәм агарып сүнгән күзләре бер генә мизгелгә ачылды да кире йомылды. Беләктәге башы кинәт авырайгандай булып, артка каерылып китте. Тирән итеп суларга теләгәндәй авызы ачылды, түше калкынды. Мәгәр сулыш алганы сизелмәде һәм коры сөяккә әйләнгән гәүдә хәрәкәтсез калды.

Кычкырып җибәрде Зәйтүнә. Әбигә эндәшергә теләгән иде ул. Карчык та йокламаган, күрәсең. Шундук хаста янына килде. Маңгаен, битен-күзен сыйпаштырып карады, кул-аякларына кагылды.

— Боз кук, — дип куйды ул, башка сүз таба алмагандай итеп. — Хуш, балакай, урының оҗмахта булсын...

Ә Зәйтүнә әйтер сүз дә тапмады. Сүз әйтерлек хәлдә дә түгел иде ул. Аңы, уйлары, хисләре, барлык дөньясы авыр бер томан эчендә, күз алмаларын сарган элпә аркылы бөтен нәрсә җәелеп, үз төсен җуеп күренә иде аңа. Мәет каршына баскан да ул, мәңгелеккә шикелле хәрәкәтсез калган. Йөрәге, җаны, бөтен бәдәне сызлый аның, кыса, авыртыра, чәнчешә. Нәрсә бу? Югалту сагышымы, үкенү газапларымы? Кайчан ялгышты ул — сөя башлагандамы, сөюеннән — гомерлек бәхетеннән ваз кичкәндәме?..

Юк, мондый әрнеткеч сораулар белән күпме генә баш ватма, җан тынычлыгы бирердәй җавап табу барыбер мөмкин түгел. Ниндидер төн күләгәсенекедәй җансыз хәрәкәтләр белән атлап урамга чыкты Зәйтүнә. Сөзәк тау башларыннан калкып килгән кояш белән очрашты ул. Кемнеңдер (әнисенең бугай) йомшак җылы кулы битләрен сыйпагандай итте. Якында гына сыман күренгән әнисенекедәй шул кояшны кочаклап җылыйсы килде аның. Ялгыз иде ул...

Артыннан әби карчык күренде.

— Күргән-белгән кешеләр табып, кабер казыту кирәк булыр инде, кызым, — диде.

Зәйтүнә башы белән генә «әйе» дигәнне аңлатты. Кая барырга белмәгәндәй, хәлсез адымнар белән анда-санда салынган йортлар арасына юнәлде әби.

Байтактан соң Зәйтүнә өйгә керде. Тагын мәет каршына килеп басты, гүя аның ни дә булса әйтүен көтте. Аннары, исенә килгәндәй булып, башын калкытты да алачык эченә күз салды. Соңгы юлга озатканда кирәк буласы әйберләр турында уйлый башлады ул...

Туганны төрәләр, үлгәнне күмәләр, дигән сүз бар бугай. Баязитны да соңгы юлга хәстәрләп җиткерделәр. Зиратлары ике чакрымдагы та-

тар авылында икән, төштән соң зур кара ат җигелгән мәет арбасы килде. Кәфенләп кабыкка салынгач, егетне шуңа урнаштырдылар. Аның баш очына әбине, аяк очына Зәйтүнәне утырттылар.

Мондый чакта була торган авыр һәм тантаналы тынлык эчендә ат юлга кузгалды... Юл буена Зәйтүнә кая китеп барганын аңлый алмастай бер хәлдә булды. Яшь бер кешенең гомер юлы болай кинәт киселеп калуына һәм үзенең бу мажараларына һич тә ышанасы килми иде аның. Болар берсе дә чын түгелдер, Баязит юри генә, аны куркытыр өчен генә шундый шуклык уйлап тапкандыр кебек тоела иде. Тора-бара бу хисләр дә узып югалды. Зәйтүнәнең бөтен эчке дөньясы ниндидер моңсу һәм горур тынлык белән тулды. Кайгыдан сыгылып төшмичә, гәүдәсен туры тоткан хәлдә, Баязитның йомык күзләренә, аксылсары кәгазь төсле чыраена карап барды ул.

«Икебез дә яшь идек, җүләр идек,— дип сөйли башлады Зәйтүнә аңа күңеленнән. — Төшләр күреп йөргән булдык, яратыштык... Ә кавышулар насыйп булмаган икән... Минем качып киткән булуларны гафу ит инде син, Баязит... Булмады бит... Арабызга тау үсте... «Сак-Сок»ларның шундые да була икән безнең заманда. Хәер, электән үк шулай килгән ич... Тигезсезләр кайчан бәхетле булган соң?.. Кичер инде, яме... Бәхил бул...»

Атның җай гына барышы белән гәүдәсе әз-мәз селкенгәләп киткән Баязит авызыннан да ниндидер бик әкрен генә пышылдау ишетелгән сыман тоелды. Зәйтүнә бөтен игътибарын җигеп, күз-колакларын алгарак сузгандай итте. Әби карчык белән күчергә карап алды. Аларга һични ишетелми иде, ахры. Ә Зәйтүнәгә исә өзек-өзек сүзләр тагын да аермачык ишетелә төшкәндәй булды:

— «Юк, Зәйтүнәкәй... мин... бәхетле... Актык... минутларымда... сине... күреп... калдым... Рәхмәт... килүең... өчен... Мин... уйлаганнан да... гүзәлрәк... иптәш... булып... чыктың... син... Онытма... яме...»

Мәетне кабергә төшереп күмә башладылар. Боларның берсен дә аңлар-абайлар хәлдә булмаган Зәйтүнә ниндидер үле хәрәкәтләр белән генә ике кушуч балчык салды кабергә.

— Хуш... — дип пышылдады әкрен генә.

Астан чыгарылган кызыл балчык, бәләкәй генә таучык булып, кабер өстенә калкынды. Күмүчеләр кайтып китте. Икәве генә калган кыз белән карчык кабер читендәге яшел чирәмдә бик озак тын гына гамь чигеп утырды. Алар өйләренә юнәлгәндә кояш кызарып бара иде инде. Хәле мөшкелләнеп киткән әбине Зәйтүнә җитәкләп алды...

Җәй буена шунда калды ул. Бу авыр хатирәле, кайгы-хәсрәтле урыннан ни өчен тиз генә китә алмавын үзе дә аңламый, җавап та таба алмый иде Зәйтүнә. Ниһаять, август ахыры якынлашты. Мәктәбенә кайтырга кирәктер инде... Гади генә агач рәшәткәләрдән корылып, яшькелт-зәңгәргә буялган чардуган өстенә беләкләрен куйды ул. Чирәм кәс белән бөркәлгән кабер өсте үлән чәчелгән җир шикелле тоташ яшеллек белән күмелеп килүенә сөенде. Кәс почмаклары арасыннан калкынган миләүшә чәчәкләре дә, соң утыртылуларына карамастан, корымады, күрәсең, яшеллеккә үз төсләрен өстәп, хозурлык бирәләр. Баязитның аяк очларына килеп баскан нәни миләш тә тере. Беренче чәчәкләрен киләсе елга күрсәтер инде ул... Нинди булыр икән? Әчкелтем хуш исен саклармы? Сөю сагышы шундый татлы да, ачы да була, имеш... Тагын бер килеп карамыйча булмас инде...

Тагын бер...

Тагын бер...

Тагын бер...

Ел саен Зәйтүнәнең шул сүзләре кабатлана торды. Алдагы килүен-

дә борынгы әби дә күренми иде инде. Дим буендагы кызының кызына киткән, имеш, диделәр. Ел саен ул барыбер ерак юллардан шунда килеп, шул чәчәкле кабердә яткан кешенең баш очына утырган килеш күңел серләре белән уртаклашканнан соң, тагын да ераклардагы карт әнисе янына китә торган булды.

Шулай сәяхәт итә торгач, әле кичә генә сыман балкыган яшь чаклары узып та киткән булып чыкты Зәйтүнәнең.

— И-и, гомерләр, күрми дә калдым бит... — дип гаҗәпләнде ул...

... Гөлбикәбез тукталды. Гәүдәсен турайтып, башын калкытты. Каршыдагы фонтан суларының киң генә сай табактан мөлдереп түбәнгә сибелүен күзәтә шикелле ул. Бу сәер хикәяне тыңлаучылар әле һаман тып-тын утыра иде. Ниһаять, теле һәр вакыт кычытып тора торган Шалтыр Шакирыбыз (шул теле тиктормаслыгы өчен үзебез куштык бу исемне) сорый куйды:

— Нижәли гомер буена шулай кияүгә чыкмый яшәден, аппагым?

— Туктале, — диде Гөлбикә кинәт сискәнеп. — Саташтың мәллә? Мин бит Зәйтүнә дидем. Үзебезнең күрше кызы Зәйтүнә хакында сөйләдем!..

— И Гөлбикә гөлкәем! — дип көлде Шакир. — Беләбез ич инде, кызлар һәркайчан тыйнак була, эч серләрен «мин» дип түкмиләр, кыр казлары исеменнән генә сөйләргә яраталар.

— Гел шыр тиле инде син, дияр иде берәү булса, име, Шакир кордаш, ярый әле, мин алай ук дип әйтмим... — дип көлде Гөлбикә рәхәтләнеп.

Аның һәр вакыт ниндидер моңсу карашлы күзләре очкынланып киткәндәй булды, ирен почмакларына нечкә генә җеп эзләре төште, матур булып чаларган калын чәчләре балкып киткән сыман булды.

Барыбыз да аңа кушылып көлештек бу юлы. Аннары уйга калдык...

Уйга калган килеш өйләргә таралышкан идек. Шуннан соңгы көннәрдә, өзек-төтек кенә итеп яуса да, яңгырлар сөендереп алды безне. Яңгыр булгач, җыелышырга да туры килмәде, чыгабыз да бер-икебез, кулларны каш өстенә куеп, күккә карыйбыз. Карыйбыз да, очы-кырые ачылырдай күренмәгәч, таралышабыз. Бүген шимбә. Бүген менә алай түгел. Иртән явып узганнан соң күк битләре «Зөләйха» сабын белән юынган кызлар йөзе шикелле чип-чиста, зәп-зәңгәр, чалт аяз булып китте. Күзне күктән аласы килми, өстән очкын коела башлагач кына түбән төшерәсең. Аннары беравыкка дөм караңгы булып кала күз алдың...

Ярар, тәмәкеләрне кабыздык та, бакчаның саф һавасын литрләп исни-исни, үзебезнең эшкә тотындык.

*(Ахыры бар.)*

## Сажидә Сөләйманова

### Сер алдым

Икенче кат килдем бу дөньяга...
Көн утырды. Буран басылды.
Дусның кадере артты. Дошманның да
асыл йөзе, шөкер, ачылды.

Ачыкланды төсләр! Хисләр кискен.
Әмма акыл инде өстенрәк.
Җиргә мәңгелеккә килгән кебек
яшәп калсын көнчел мескеннәр.

Якты көннән алар бер китсәләр,
белеп торам, кире кайталмас.
Очрашасы килә йөзләр-йөзгә
сезнең белән, «яшь һәм ят алмаш!»

Һәм әйтәсе: яшәү — иң чын бәхет.
Үтә кырыс, үтә нәзберек.
Күз дә тия бик тиз, сүз дә тия —
бәхет күпне сорый, аз биреп.

Нәфес сузсаң, бөтенләйгә кача —
эзлә! Эзәрлекләү — әсирлек.
Безнең яшәү — илгә бәхет кошын
очырып җибәрүгә әзерлек.

Очышларның ул иң хәвефлесе,—
төпкә тартса заман чоңгылы,
гәүдәң белән бергә хатирәң дә
илдән китә түгелме соң ул?

Канатсызны күккә чөймик әле,
егылалар, үрчи сукбайлык...
Борылдым да кинәт йөзләр-йөзгә,
өзеләсен сизеп сукмакның —

очканында күрдем бәхет кошын,
канатларның көчен сынадым;
кемнәр эзләр, кемнәр эзәрлекләр —
киләчәктән шулай сер алдым.

## Җиргә күчә

...Җилдә шаулый урман:
— Җир мәңгелек!
Күзгә карый күлләр:
— Күр безне!..
Ярдан чыга дәрья:
— Җир гөнаһлы...
Таштан чыга чишмә:
— Җир изге!

Изгеләре, гөнаһлысы белән
фани дөнья җирдә гаугалы.
Изге булып кала соңгы теләк,
гөнаһларны җуеп, дауларны.

Ак өметләр бодай булып шыта...
Әрнүләрне тирән күмгәннәр,
буразнада, ындыр табагында,
эш өстендә егылып үлгәннәр.

— Бай булыгыз! — диеп киткән алар,
бушка әйтелмәгән васыять,—
таш астында, тирән сандыкларда
ата-баба җыйган бай зиннәт.

Гасыр төпләрендә әллә шулай
саклаганнар янгын, яңгырдан?
Туган илнең иминлеген яклап
яу кырында алар җан биргән.

— Дус булыгыз! — диеп киткән алар,
аманәтләр түгел коры сүз.
Дуслык юлы сузыла илдән-илгә —
киләчәккә тоткан юлыбыз.

Уттан алып, суга салсак та бит,
җиргә күчә күңел җылыбыз.
Изге теләк илгә без юллыйбыз:
— Сау булыгыз, тату булыгыз!

Кабатлыйлар таулар:
— Бай булыгыз!
Күзгә карый күлләр:
— Күр безне!

Ярга кага дәрья:
— Җир гөнаһлы...
Җырлап ага чишмә:
— Җир изге!

## Боз акканда, атлар чапканда

Идел ярларында гөрләвекләр,
Идел талларында ал бөре.
Боз кузгатып, җил тузгытып җилә
табигатьнең акбүз апреле.

Акбүз ат өстендә чая чапкын —
төшләремдә күргән хыялым,
җилфердәтеп чаба җитен ялын,
боз җиленнән кинәт уянып.

Ага бозлар, гөрли яз туйлары.
Җан эшеме, әллә дан эше —
актарылган хисләр ярышуы —
яшәешнең тиңсез табышы.

Бозлар аккан, атлар чапкан чакта
читтәрәк тор, акыл, үр саклап.
Ат чабышы, җыр тавышы тынгач,
соңгы хөкем синдә, аксакал.

Синең хөкем кырыс, дәвамлырак.
Бу бүген дә шулай, элек тә —
кайчак гаскәрләрнең һәм илләрнең
язмышларын мизгел хәл итә.

Фидакарьләр, фанатиклар җиңә,
таң калдырып дөнья хачларын —
амбразура каплый йөрәкләре,
дарга менә фидаи башлары.

Тантаналар һәм хаталар белән
йөрәкләрнең уртак язмышы.
Җырга салган Чулман-Идел ягым,
синең даның — минем җан эше.

Актарылган хисләр язмышына
син ваемсыз икән, и акыл,
боз аккан да, атлар чапкан чакта
мин йөрәгем белән мөстәкыйль.

●

Бүлдералмаса юл басып,
үтералмаса дар асып,
гайбәт — дошманның
иң соңгы чарасы.

Ул сазлыкта да батмасаң,
горур җаныңны сакласаң,
мактау — дошманның
иң соңгы җәтмәсе.

Башың һаман әйләнмәсә,
телең һаман бәйләнмәсә,
дуслык — дошманның
иң соңгы хәйләсе.

## Айлыбикә...

Тукталам да төнге күккә карыйм:
Хәйран сызылып төшкән Ай кашы.
Читтән генә безне күзәтәмсең,
мәшәкатьле Җирнең юлдашы?

Мәңге шулай нурлы, мәңге серле,
үз сагышың белән ялгызсың.
Әйләнәсең һаман Җир тирәли,
үкендерә мәллә ялгышың?

Утларында янып киткәнсең дә,
сайлап Җирнең биек сәхнәсен,
салкын булса да бит ташламыйсың
мәңгелекнең зәңгәр сәхрәсен.

Җирең сине сагынып сәлам юллый,
тугрылык ул ике яктан да.
Чиләкләрең тулы, Айлыбикә,
Син карама инде ятларга.

Сагышланган, сагынган чакларда,
и бердәнбер ялгыз сердәшем!..
Утларыннан китеп, мин дә гизәм
зәңгәр төннең салкын сәхрәсен.

●

Бөреләнә, караладыр
җир шомырт сөрмәсендә.
Алланадыр, балланадыр
алмасы, хөрмәсендә.

Тамганмы кояш тамчысы —
җиләкле аланнары.
Баллыдан туйсаң, ачысы —
миләше, баланнары.

Дөньяның түгәрәклеге —
бөрлегән мөлдерәве.
Түм-түгәрәк җир өстендә
кеше ник сөрлегәдер?

... Көтмиләр айлар, тәүлекләр,
көн туа да эш куа.
Бер очын тапсаң тормышның,
тәгәрәп бара дөнья,—

кемне кагып, кемне танып...
Җир — күзләр сөрмәсендә.
Җиркәем, җирсүләр серен
җанымнан сөрмәсеннәр.

1977

## Фәния Чанышева

### Әнкәй килә минем каршыма

Ак яулыклы, ап-ак күлмәк кигән...
Яшел ялан буйлап, каршыма
Әнкәй килә... Сабый чактагыдай,
Кочагына аның ашыгам.

Мин йөгерәм! Әнкәй нигә өнсез?
Танымыймы әллә баласын?
Күкрәгемне өткән уйларымны
Килә тизрәк әйтеп каласым:

— Кайтып ничек әйбәт эшләгәнсең,
Син бит бераү генә — әнкәбез!
Бу гомерне инде белеп кенә,
Үкенмәслек итеп яшәрбез.

Учакларда утны сүндермәбез,
Кабатланыр бишек җырыбыз,
Күңел бушаганчы сөйләшербез,
Эш бетмәс ул — куеп торырбыз.

Бала өчен җаның фида булып,
Тынгы белмәгәнен кулларның
Сөйләшербез оныкларның ничек
Балаңнан да газиз булганын.

Син дә шулай безне югалттыңмы?
Сагындыңмы? Ничек хәлкәең?..
Күңелем төеннәрен чишеп җибәр —
Бер генә сүз әйтче, әнкәем!

Яшел ялан буйлап китеп барды...
Эндәшмәде, хәтта күрмәде —
Кабер каеннары арасында
Бер җилфердәп калды күлмәге.

### Таудан карап

Читтән караганда: тау башына
Канат җәйгәнмени чал болыт!
Ата-бабалардан калган сүз бар:
«Тауга карап булмый тау булып».

Шушы сүзләр төште хәтеремә
Тау үренә менеп барганда.

Әзер сукмаклардан үрләсәм дә,
Буыннарым шактый талганнар.

Өстәл өсте кебек тирә-ягым:
Чиксез кырлар яшьлек төсендә,
Борма юллар, көзге күлләр — бар да
Зәңгәр томан пәрдә эчендә.

Кояш чагу монда, җилләр үткер,
Һавалары татлы, ширбәтле.
...Тауга карап тау булмавың мәгълүм,
Түбәләрне күрү гыйбрәтле.

## Калкан булыр идем

Яньп көлгә калган хисләр
Кабынмыйдыр кабат.
Алда — һаман алданулар,
Үткәннәрдә — сабак.

Яхшы, яман, ак, карадан
Күптән араланган.
Сиңа төбәлгән уклардан
Җаным яраланган.

Хаталардан, хафалардан
Саклап калыр өчен,
Калкан булыр идем сиңа,
Әгәр җитсә көчем.

## Дөрес икән

Көзгә каршы ерак юлга чыктым.
Мул һәм тулы калды табыннар.
Үпкәләгән кебек, каеннарым
Саргаешып озатып калдылар.

Әйтте гүя алар: «Бездән башка
Чит якларга күңелең ятмас ул.
Гүзәллекләр бәлки күрерсең дә,
Безнең тугрылыкны тапмассың.

Көзен саргайсак та, язлар җитсә,
Исертәбез бөре исеннән.
Без түгелме җаныбыздан бүлеп
Суыбызны сиңа эчергән?

Югалтулары да читләп үтми...
Табигать ул — ничек итәсең.
Ә син безне иң кайгылы чакта,
Авыр чакта ташлап китәсең.»

...Күрдем җете төсләр, сихри кичләр,
Чагыштырыйм дисәм, җаем бар.
Кайтып киләм сезне өзелеп сагынып,
Дөрес уйлагансыз, каеннар!

Җәүдәт Кәлимуллин

# ЕГЕТ БУЛСАҢ — ДАНЫҢ КИТСЕН...



Кичке концерт тапшыралар иде.

Радиодан бик ягымлы көй агыла. Нәгыйм Харисламович, келәм ябылган кәнәфине урыныннан күчереп, бу минутларда үзен бөтенләе белән әсир иткән бәләкәй генә тартма-радиоалгычның каршысына ук килеп утырды.

Гөлсем Сөләйманова җырлый иде:

Иртә дә томан, кич тә томан,
Томан кырауларны эретә.
Әй, югалттым сөгать лә чылбырым,
Күрмәдеңме, сары ла былбылым?

Күпме генә ишетсә дә, бу көйне һич тыңлап туймый Нәгыйм. Кайгы килгәндә, гүя ул шуны уртаклаша, шатлыгы булса — аны бүлешә сыман бу җыр. Иң тирән кичерешләрен әйтеп бирә шикелле.

Шакирҗан бабай да күңеле нечкәргән минутларда шушы җырны көйли торган булган, диләр. Тик ул аның сүзләрен үзгәртеп, үз калыбына салып җырлаган, имеш. Һәм моңа нәкъ менә Нәгыйм Харисламович сәбәпче булуын тәгаенлыйлар. Төзүче исә үзе бу хакта еллар узгач кына белде.

Озын-озак юллар үтеп, ниһаять, үз иясенә килеп ирешкән кадерле бүләк кебек булды ул.

... Мәскәүдән бөтен участок белән Зәй ГРЭСы төзелешенә китәргә дигән хәбәр алынды. Павловск ГЭСын төзү кешеләрне тәмам йончыткан, яраткан җирең белән аерылганда була торган нечкә хисләргә урын калдырмаган кебек иде. Алай ук түгел икән әле. «Башкортстаныңнан, ГЭСыңнан китәбез» дигәч, Вазилның борыны салынды:

— Үзең диңгез яса да, рәхәтен күрмичә кинәт китеп бар, имеш.

Егетләргә шул гына кирәк — Агыйдел буйларында ишетелерлек итеп көләләр алар:

— Калдырыйк без аны, җәмәгать, туйганчы су коенсын, балык тотсын. Балык шулпасы әзер дип телеграмма суккач та кайтырбыз.

— Диңгез дип инәләсең син, Вазил,— диде бригадир мөмкин кадәр сабырлык белән, — ГРЭС дигәч тә, ул да бит сусыз ком чүлендә утырмаячак. Анда да, мондый ук булмаса да, диңгез ясалачак. Ә менә бу ГЭСның су саклагычы билгән мәйданны, суының тирәнлеген беләсеңме?

— Белмәскә...
— Я, әйтеп кара әле.
— Әби ысулы белән—аршынлапмы, әллә бабай хисаплаганчамы?
— Бусы ни дигән сүз тагын?
— Ну, әби — искечә, бабай яңача исәпли иде безнең — икесенеке дә дөп-дөрес була иде.
— Килештек, яңача әйт, алайса.
— Бу су саклагычның мәйданы — 120 квадрат километр, озынлыгы — 150, иң киң җире — 2 километр. Суның уртача тирәнлеге — 11,8 метр, — дип сөйләп китте Вазил, класс тактасы янына чыгарылган укучы кебек ашыга-ашыга.
— Ва-зи-иил! — дип шау-гөр килделәр егетләр, — кара, ничек шартлата — чикләвек ватамыни?!.
— Шулай кирәк, Вазил, — диде бригадир, бу күңелле әңгәмәгә йомгак ясагандай, — синдәй егетләр белән без әле бик күп ГЭСлар төзербез. Зәй ГРЭСы да иң зур җылылык электр станциясе була. Ул елына 2,4 миллион киловатт электр энергиясе эшләп чыгарачак, ГРЭС янында яңа поселок салыначак.
— Су, су, мине шунысы кызыксындыра, бусын онытгыгыз бугай, бригадир,— диде Вазил, күзләрен челт-челт йомгалап.
— Әйе, су бит әле. Онытылган икән шул, Вазил, ГРЭСның үз күле була. Аның өслеге 16,7 квадрат километр мәйданны биләргә тиеш. Салкын душ ятучылар булса — Зәй елгасы агып ята, ул гына җитмәсә, Кама бар...

Күрше республикадагы башка төзелештә эшләргә җыенып чыгып китәр алдыннан булган бу әңгәмәдә Нәгыйм үзе ни дә булса әйтеп катнашмады. Мәгәр күңеле белән шушы гәпне тирән кичереп, төзүчеләр әйткәнне үзенә сеңдерә барды. Әмма Вазилның сүзләре беркатлы, төче булып тоелды аңа. «Шулай да аны да аңларга кирәк», дип уйлады ул...
Вазил Башкортстандагы Павловск ГЭСы төзелешендә беренче казык кагылган көннән бирле эшләгән. Ә Нәгыймнең бирегәге хезмәт стажы бер ел да түгел иде әле. Шулай булса да, күңеле төзелештәге иптәшләренә олы рәхмәт хисләре белән тулы икән. Ул да, Вазил шикелле үк, шушы хакта ихлас йөрәктән сөйли алган булыр иде. Тик әлеге минутларда ул бөтенләе белән алда торачак зур бурыч — Зәй ГРЭСы төзелеше белән бәйле вакыйгалар әсирлегендә калган иде. Аның да үзе башлаган яңа төзелештә беренче казыкны кагасы килә.
Әмма тагын соңгарган булып чыкты ул...
Зәй ГРЭСында эшнең нуль циклы төгәлләнеп килә иде инде. Алай да, өлешенә тигән көмешкә ул вакытында өлгерде. Монтаж циклы башланган гына иде.
Бөтенсоюз комсомол удар төзелеше яшьләрне илебезнең иң ерак почмакларыннан үзенә магнит кебек тартты. Комсомолец Нәгыйм Әгъләмов эшләгән бригадада күп иде андый энтузиастлар. Шулай тырышып эшләп йөргәндә, бер көнне төшке аштан соң бригадир Галимулла абыйсы Нәгыймне читкәрәк чакырып алды да:
— Без саубуллашыр көннәр җитте бугай, Нәгыйм, син үзең берәр нәрсә сизмисеңме? — диде.
— Уң күз кабагымның тартканы юк әле, Галимулла абый, шәт андый-мондый каза булмастыр, әбиләр әйтмешли, — диде Нәгыйм елмаеп. — Инде участогыбызны башка җиргә күчерәләр дисәгез генә...
— Күчермиләр, — диде бригадир, чигәсендә бармакларын йөрткәләп, — күрәсең бит: мондагы эшнең дә очы-кырые күренми әле,

ләкин сине минем бригададан алачаклар, туган. Бик карышып караган идем дә — барып чыкмады. «Нинди объектта эшләгәнегезне кабат исегезгә төшерәбез: бу — Бөтенсоюз комсомол удар төзелеше. Димәк, аның җисеме дә исеменә туры килергә тиеш. Без производство командирлары постына яшьләрне кыюрак тәкъдим итәргә тиешбез», диделәр анда, ике уйларга урын калдырмадылар.

— Моның миңа ни кагылышы бар икән соң, Галимулла абый?

— Бик бар, Нәгыйм, участокта яңа бригада оешачак — комсомол-яшьләр бригадасы. Бригадиры син булачаксың. Әллә риза түгелме?

— Түгел шул. Миңа бу коллективта эшләү дә бик ошый! Тагын ни... нинди бригадир чыксын ди миннән. Барыгыз, Галимулла абый, әйтегез — аңлатыгыз җитәкчеләргә.

— Син мине аңламадың, — диде бригадир кеткелдәп, — бик барыр идем дә, көлкегә каласым килми: «Сез, Галимулла Сәмигулович, төшкә кадәр «барам» дип, төштән соң «калам» диебрәк фикер йөртәсез», дисәләр, нишләрмен?

— Болай булгач, сез «саткан» булып чыгасыз инде мине, Галимулла абый. Үзегездән җибәрәсегез килеп тора икән...

— Сөенергә генә кирәк, Нәгыйм, миңа да бик күңелле. Минем бригадада шундый кешеләр тәрбияләнгән икән — ник горурланмаска! Әйдә, карышма, белгән кадәр мин дә ярдәм итәрмен, оядан очарга күптән вакыт сиңа...

Галимулла абыйсының соңгы сүзләре аның оядан беренче мәртәбә очкан чакларын хәтерләтте... Авылдашы Исхар белән бергә кузгалганнар иде алар юлга...

— Я, Исхар, авылыбыз белән саубуллашыйк инде, үпкәләп калмасын.

— Калса, әллә бик сагыныпрлыгы бармы Олы Шадының. Салам башлы йортлары белән төшкә кереп йөдәтсә генә инде, Нәгыйм.

— Минем бабай «туган туфрак суытмый» дип әйтергә яраткан. Шәт кире әйләнеп кайтырга туры килер.

— Кайтмаска булсын иде монда.

— Син инде бигрәк тә...

Авылны чыгуга зур урман башлана. Нәгыйм белән Исхар шул урман авызына җиткәч туктап калдылар. Нindидер серле көч туктатты диярсең. Элек алай булганы юк иде. Өйдән чыгуга ук чалбар балакларын сызганып куялар да, әлдертәләр иде шушы якка. Бер кызган мәлгә аның аргы башына хәтле үк йөгерәләр иде. Урманда рәхәт: кошлар сайрый, җиләк исе сулыш юлын кытыклый, тар юлдан узганда биткә, шап-шоп итеп, чикләвек агачы яфраклары сугылып кала.

Ләкин бүген Нәгыйм белән Исхар кулында каен тузыннан ясалган тырыс та, юкә суя торган пәке дә юк. Алар урынына аркада юл капчыклары. Капчыклар дигәнебез хуҗалары җилкәсен байтак кисәрләр әле — барасы җир карап күренерлек кенә түгел.

— Сау бул, Олы Шады, ачуланып калма безгә...

— Юк, болай ярамый. Шулай чыгып китәләрмени туган җирдән, авыл гыйбады булмыйк инде.

— Чит илгә китмибез ләбаса — ул тикле кәнфитләнергә...

— Нишлик соң, алайса? Мин андый нәрсәне белмим.

— Беләсе дә түгел. Шушы юан имән янына басыйк та, күзләребез талганчы авылга карап торыйк, аннан кулларыбыз белән имәнне сыйпарбыз. Авылыбыз да, урманыбыз да безгә рәнҗеп калмаслар...

Бу — Башкортстан АССР, Мишкә районы, Олы Шады авылыннан ике гражданның Уфага — фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбенә китеп баруы иде диясе килә дә, аз гына хата булачак икән. Исхарга ул чакта уналты яшь тулган булса да, Нәгыйм унбиштә генә иде. Әлегә ул балигъ булмаган кеше хөкемендә генә йөри ала иде.

Сугыштан соңгы еллар, ФЗӨ сүзе кайберәүләр күңеленә хәтта шом сала торган чак иде...

Нәгыйм белән Исхарның үз туган авылларыннан, шулай шартын йоласын китереп, кутәренке күңел белән ФЗӨ мәктәбенә китеп баруларына килгәндә, эшләр болайрак тора. Нәгыймнәр гаиләсендә дә, Исхарларда да сигезәр бала үсә иде. Нәгыймнең өйрәнчек булып китүе, крестьянча исәпләсәң, бер кашыкка «ял» бирү дигән сүз ул.

Шулай да Нәгыймнәр юлга чыгасы көнне Харислам абыйның күңеле сүрән иде. Кайгыра идеме этисе, икеләнәме — Нәгыйм белә алмады. Әтисенең өйдән чыгып киткәндә әйткән сүзләре исә бүген дә күңел түрендә: «Сагынам-нитәм дип кире кайтырлык булсаң — китеп тә йөрмә, улым!» Күршеләрдән берәү: «Харислам, син алай бик каты бәрелмә, бала гына бит әле, юксынган чаклары булыр»,— димәсә, аргы очта берәү гармун сузып җибәреп, кемдер аңа кушылмаса, Нәгыймгә бөтенләй күңелсез булган булыр иде ул чакта:

> Агыйделкәйләргә аулар салдым,
> Табаннарга түгел лә, сазанга;
> Егет тә генә булсаң, даның китсен,
> Уфаларга түгел лә, Казанга...

— Солдатлар, йоклап калмагыз, Чиләбегә җитәбез! — Сырган чалбар кигән проводник апа ирләрдәй калын тавыш белән вагонга хәбәр салды.

— Күрегез, минем җанкай күксел алкалар җибәреп утыра, тотенли чибәркәем!.. Чыннан да, Чиләбе бу, егетләр,— диде, гимнастерка төймәләрен ычкындырып, бил каешын кулына тоткан солдат. Аннан соң сикереп урыныннан торды, проводник апасын этеп ега язды.

— Син, нәрсә, минем белән сугышмакчы буласыңмы әллә, өскә очып киләсең,— диде проводник.

— Кая инде ул сезнең белән сугышу, я, бер үбеп алыйм әле үзегезне. Җанкайны сагынып кайтып киләбез әле без. Сезне дә менә бик яраттык.

«Бер үбеп алыйм әле үзегезне» дигәч, проводник апаның карашында елмаю балкып киткән иде китүен дә, «җанкай» турында ишеткәч, күзләре усал карый башлады.

— Җанкайларыгыз янына ашыгыгыз,— диде ул, куллары белән вагон ишегенә таба ишарәләп.— Тизрәк төшегез, бушатыгыз вагонны!

Солдатлар төшеп калдылар. Нәгыйм дә. Поезд китеп барды.

— Сынландырып сөйләү харап итә инде мине,— диде теге солдат, изүен каптыра-каптыра.— Армиядә дә эләккәли иде шуның аркасында. Соң, мин бит элек үзем эшләп киткән металлургия заводын «җанкай» дип искә алган идем. Чиләбе металлургия заводына эшкә кайтам, диюем иде, югыйсә.

— Кеше төсле сөйләшүгә ни җитә?

— Синең белән оятка калып бетәрсең,— дип шаулаштылар егетләр.

Чита якларында Совет Армиясендә хезмәт иткәндә Нәгыймгә дә төшенә Уфа шәһәре, аның үз куллары белән калкыткан матур йортлары еш керә иде. Тагын шул шәһәрдә эшләргә җыена иде дә, армия-

дән кайтасы елында апасы белән җизнәсеннән хатлар бик ешаеп киттеләр шул. «Бик сагындым, Нәгыйм, туп-туры безгә кайт», «Мин дә сине көтәм, кайниш... Апаң, җизнәң», дип язалар иде алар Чиләбедән. Һәм ул шунда кайтты да.

Урамнарда чат саен игълан эленгән иде. Кайсын гына диярлек карасаң да, бер үк сүздән башланалар: «Коксохиммонтаж» оешмасына... Теге солдат «җанкай» дип атаган металлургия заводын да шушы төзелеш оешмасы киңәйтә икән. Ә бу эш Нәгыймгә ят иде.

— Зарар юк, Миша дәдәй тиз өйрәтер,— диделәр аңа кадрлар бүлегендә.— Аюны да биергә өйрәтә белә ул.

Аннары күтәрелеп бер көлделәр. «Китереп тыктылар мине кара урманга,— дип гасабиланды Нәгыйм. Эченнән генә апасы белән җизнәсен әрләде.— Ни дип шулар сүзен тыңладым соң әле. Уфада да ташчылар бер дә урамда аунап ятмыйлар ич. Ә монда аларның поты бер тиен икән...»

— Син курыкма,— дип каршылады аны Миша дәдәй.— Тәртип булыр, барысы да рәтләнер.

Бу сүзләр дә йөрәккә барып кадалдылар. «Әләкләргә дә өлгергәннәр икән инде,— дип уйлады Нәгыйм кадрлар бүлеген тагын бер кат искә алып.— Беренче көннән үк «куркак» мөһере сугылгач...»

Армия сафларыннан кайткан егетләр Миша дәдәй карамагында барысы егерме кеше булып чыкты. Остаз аларны ай буена монтаж эшләренә өйрәтте, кирәк дип тапкан күләмдә үзенең тормыш юлы белән таныштырды. Сокланып тыңлады аны Нәгыйм. Миша дәдәй бик яшьли үк заводта эшли башлаган, дистәдән артык һөнәр үзләштергән, сугыш вакытында илебезнең Көнчыгышына эвакуацияләнгән заводларны сафка кертүдә аның өлеше зур булган, бик күп кешеләрне үз һөнәренә өйрәткән.

...Бер ай дигәндә егерме егетнең унбише мөстәкыйль рәвештә эшли ала иде инде. Ә бишесенә төенчекләрен җыйнарга туры килде.

— Кибәк оча, көшел кала,— дия иде Миша дәдәй андыйларны озатканда.

Озак эшләргә туры килмәде Нәгыймгә Чиләбедә: әнисе авылдан хат артыннан хат яудырды: «Әтиең дөнья куйганын беләсең, инде үземнең дә сәламәтлегем начар, энеләреңә дә күз-колак булучы юк. Уфа якларына кайта алмассыңмы, улым?» дип яза иде ул. Киңәшкә дип Нәгыйм башта Миша дәдәсе янына барды. Карт эшче уйлап-уйлап торды да:

— Ана гозере — ил гозере ул, туган, — диде. Аннары өстәде: — Бик кызганыч, син монда да бик кирәк идең бит.

...Атна-ун көн үткәнче үк Миша дәдәй Нәгыймнән телеграмма алды. Егет үзенең остазына Новоуфимскида слесарь булып урнашуы турында хәбәр иткән иде.

Тора-бара Нәгыймгә бригадир вазифасын да йөкләделәр.

Аннан соң Павловск ГЭСы төзелеше, инде менә ул Зәйдә...

Бригадир постына Нәгыйм Әгъләмовны тәкъдим итүләре белән остазлар ялгышмадылар. Иң читен хәлләрдән дә бик оста чыга белгән салкын канлы, җиде кат үлчәп, бер кисә торган, түгәрәк йөзендә зәңгәр күзләре ялтырап торган уртача буйлы бу егет җитәкчелегендәге 12 кешелек комсомол-яшьләр бригадасына төзелештә танылып өлгерү өчен атна-ун көн генә кирәк булды. Кай арада алар шулай оешып киттеләр дә, борчаны да дагалый ала торган Тула сулагае дәрәҗәсенә җиттеләр диярсең! Шушы кечкенә генә коллектив вәкилләре ГРЭС плотинасын монтажладылар, станциянең стеналарын күтәрделәр, ма-

шина-мазар кирә алмаган урында кул белән җир казыдылар, бетон салдылар... Алар кулыннан килмәгән эш юк кебек иде бирәдә.

... Смена тәмамланырга биш минутлап вакыт калган иде. Прораб, авыр резин итекләре белән төзелеш мәйданындагы канаулар аша сикерә-сикерә, Нәгыйм каршысына килеп басты. Башта, сәхнәдәге тылсымчы артист кебек, бригадирның күзенә озак кына карап торды. Аннан, гадәттәгечә, тирә-юньне шаулатып көлеп җибәрде дә:

— Гали үз эшендә, Вәли үз эшендәме, егетләр? — дип сорады.

— Галигә дә, Вәлигә дә әлеге бер шөгыль — кулда көрәк уйнату, — диде Нәгыйм кырыс кына. — Эшләр көрәккә калса, сезнең белән безнең борчак пешмәячәк, иптәш прораб. Егетләр монтаж эшенә атлыгып торалар. Европаны таң калдырырга тиешле төзелеш мәйданында көрәкне ялга чыгарырга кирәк дип исәплиләр.

— Аңлыйм. — Прораб рәсмирәк булырга тырышты. Чөнки дарының коры икәнен чамалый иде ул. Төзелештә дан алган бригаданы көрәккә таяндыру өчен мактамыйлар. Ләкин ул көннәрдә бүтәнчә чара юк иде.

ГРЭСта монтажланырга тиешле блоклар, Вавилон хәрабәләре төсле, төзелеш мәйданына чәчелгәннәр. Кырыгар тонна блокларны күтәрергә тиешле кранның хәле дә шул блоклар язмышыннан артык түгел: саны-санга аерылган килеш җирдә ята. Анысын дөрес җыю юлын күрсәтергә тиешле завод вәкилен дүрт күз белән көтәләр — әлегә күренми.

— Сезнең янга килүемнең сәбәбе дә шул иде, — прораб аклана иде бугай. — Кранны җыю эшенә үзебезгә тотынырга кирәк. Җитәкчеләр белән уйлаштык-киңәштек тә, бу эшне сезнең бригадага йөкләргә булдык...

Нәгыйм, бер кочак кәгазь күтәреп, өенә кайтып китте. Бу — 40 тонна йөк күтәрә торган кранның техник документациясе иде. Төне буе укып чыкты бригадир. Аңлашылмаган, моңарчы колагы ишетмәгән әйберләр күп иде анда.

Ләкин чигенергә дә урын юк иде.

... Бу көнне Нәгыйм яхшы хәтерли. Кран авыр блокны, бала уенчыгыдай, һавага күтәрде. Төзелеш мәйданчыгына бихисап кеше җыелган иде. Җәяүләп тә, ат җигеп тә килгәннәр: картлар-карчыклар, бала-чагалар...

— Я хода, кырык тонна әйбер күтәрә диген шушыны...

— Бу безнең кырык йортлы Таш Чишмә авылын эһ тә итми күтәрә ала инде, алайса....

— Эх, шушы кран белән мунчаны бакча башына күчертеп куясы иде, әттәгенәсе...

Халык гаҗәпләнә, шаулаша, куана.

Мәзәк хәлләр дә булмый калмаган икән... Кырык тонналы йөкне күккә күтәрә ала торган кранның дөньяда булуын, аның инде Зәй ГРЭСы төзелешенә кайтарылганын ишеткән Шакирҗан атлы карт белән Заман исемле абзый үз авылларында бәхәсләшеп киткәннәр ди. Карт бу хәлнең булуына ышанмаган, тегесе исә киресен раслаган.

— Отсаң — чылбырлы кесә сәгатем синеке булыр, — дигән үз сүзендә нык торучы карт.

— Ярар, — дигән Заман абзый, — оттырсам, бер бакча бәрәңгеңне берүзем казып алып бирермен.

Килгәннәр ди болар җитәкләшеп ГРЭС төзелешенә, торалар ди карап. Кран ифрат авыр блокны җирдән бер сантиметрга аерырга өлгергәнче үк Шакирҗан бабай чылбырлы сәгатеннән колак каккан ди. Бабай егет икән — оттыру ачысыннан җебеп төшмәгән:

Әй, югалттым ла сәгать чылбырын,
Тик күрмимдер бу эшнең һич хурын...

— дип, горурланып урам буйлап җырлап кайткан диләр.

Менә ни өчен «Сәгать чылбыры» җырын Нәгыйм Харисламович аеруча үз итә.

... Зәй ГРЭСы төзелешендә Нәгыйм Әгъләмов мәхәббәтен тапты: ул бирегә кранчы чибәр кыз Хафизә белән гаилә корып җибәрде. Инде ике уллары үсә. Тагын бер хатирә — Зәйдә ул Коммунистлар партиясе сафларына кабул ителде.

Ул төзегән Павловск һәм Зәй электр станцияләре күптән коммунизмга эшли. Ә Нәгыйм Харисламович аннан соң Түбән Кама, Чаллы төзелешләрен күтәреште. Төзелешләр аның үзен дә күтәрделәр. Ул — Социалистик Хезмәт Герое булды.

...Еллар су кебек агып торганнар икән. 45 яшьлек кешегә, чигә чәчләренә кырау төшерү бик үк килешеп бетмәсә дә, узган гомер эзен яшерергә мөмкин түгел инде. Зәйдә дөньяга аваз салган улы Рим да унынчы класска күчте. Егет булып җитте — ата-ана канаты астыннан чыгып бара.

... Ял көне иде. Нәгыйм Харисламович кече улы Риф белән урамда йөреп керергә чыкты. Риф та инде алтынчы классны тәмамлады, абыйсы кебек буйга тартып, егет булып килә. Шулай да балалыгы бөтен әле аның. Сабый чагындагыча, әтисе кулыннан бер дә ычкынмый.

Кама елгасы ягына борылдылар. Биткә яз һавасы килеп бәрелде, баш очыннан кыр казлары очып узды.

— Тиздән боз да кузгалыр инде, әти.

— Озакламас шул, улым.

— Бу казлар кая очалар икән?

— Туган якларына.

— Кайда соң ул як?..

— Аналары, оя корып, балаларын кайда чыгарган булсалар, алар өчен туган як шул була инде, улым.

— Ә-ә-ә-ә, — ди Риф, сернең шулай бик тиз чишелүенә сөенеп, — мин тагын...

Ә үзе һаман да әтисенә табарак елыша.

Уң якта иске Чаллының әле сүтелергә өлгермәгән агач йортлары күзгә чалынды, ишегалдында казлар каңгылдавы, әтәч кычкыруы ишетелде.

Яз гүзәллеге, табигать хозурлыгы.

Йөрәкне юксыну хисе чәнчеп узды. «Язларын безнең Олы Шады авылы да шундый була иде, мин дә шулай әтигә ияреп кыр казларын күзәтергә дип болынлыкка чыга идем бит...» Әти кеше туктап калды, улы аны алга әйдәде, ләкин олы кешене кузгатырга аның көче җитми иде...

Хыял канатлары КамАЗ батырын Башкортстан якларына алып китте...

... Харислам абзыйның дөнья куйганына өченче дистә китте инде. Әгәр исән булса, шушы кояшлы яз көнендә күкрәгендә Герой алтын медале балкытып кайтып кергән Нәгыйм улын күргәч, нишләр иде икән ул? Башта, мөгаен: «Рәхмәт, улым, рәхмәт! Әгъләмовлар нәселенә тап төшермәдең, сиңа миннән гомерлек хәер-фатиха», — дип әйтер иде. Шуннан, чал сакалын сыпыргалап, түр башындагы урындыкка килеп утырыр да, туган авылында укытучы булып эшләүче Фәргать улын үз янына чакырып, болай дияр иде:

— Герой абыең кайтты, улым. Бирскидан укытучы апаң Фәүзия-

не, Түбән Камадан электросварщик Данир баламны, монтажчы Фәрит улымны, Уфадан монтажчылар бригадиры Нәсих акыллымны телеграмма сугып авылга кайтар. Начальниклары җибәрми калмас, үтенеп сорасалар, карышмаслар...

Семья түгәрәкләнгәч, Харислам карт Алтын медальнең тарихын сөйләтер иде, әлбәттә. Нәгыймгә үзенең хезмәт юлына кабат әйләнеп кайтырга туры килер иде.

— Шулайрак булды инде хәлләр, — дип дәвам итәр иде ул, сүз очын Зәй ГРЭСында эшләү чорыннан соңгы көннәргә ялгап китеп, — Түбән Кама шәһәренә күчкәч тә эшне су корылмасы булдырудан башладык. Красный Ключта бик зур водозабор төзедек, тагын җылылык электр станциясе, искиткеч зур химкомбинат (беләсез, аңа дөньяда тиңнәр юк), аннан килеп шин заводы...

— Аларда минем дә өлеш бар. Оныта күрмәгез. — Бу Данир. Ул мыек астыннан гына елмая.

— Мине кая куясыз? Пропискам минем дә Түбән Камада бит. — Бусы — Фәрит тавышы.

— Билгеле инде, сезсез ул дөнья — сансыз. Мин дә бит «төзедек» дип сөйлим—игътибар белән тыңлагыз, энекәшләр.

— И-и-и, улымны ашатмыйлар да инде ашым кайнар чагында, тәлинкәңә сузыл, улым, сүз бетми ул.

— Карчык, дәшмә, бүлдермә сөйләгәндә, болар сиңа мунча әмәлләү генә түгел — заман корылмасы диләр аны.

— Хәзер, әни, мин тәмамлыйм. Ну, 1969 елда инде без КамАЗ җирендә идек. Монда торак йортлар комбинаты, зур бетон заводы, зур эстакада төзедек. Тиз кирәк дигәч, бик кызу тотылды. Шуннан пресс-рам заводына күчеп килдек, арматуралар куйдык, автозавод корпусын монтажладык, шәһәр өчен базар да төзеп бирдек. Без, солдатлар шикелле, кая кушсалар — шунда барабыз.

... Әти, аягым туңа, кайтыйк инде, тиздән телевизордан хоккей күрсәтә башлаячаклар, — диде Риф көпшәк карда уйнап туйгач. — Әни дә безне югалткандыр...

Улының бу сүзләре аны татлы уйларыннан айнытып җибәрде.

Алар ашыга-ашыга кайтып киттеләр.

Безнең хоккейчылар дөнья чемпионатында чираттагы уенны ул көнне оттырдылар. Риф, ашарга да онытып, телевизордан аерыла алмады. Әтисе дә ара-тирә уенга күз салгалады. Безнең капкага шайба кергән саен Риф куырылып кила, иреннәрен тешли: тагын керттерделәр, пас бирә белмиләр безнекеләр, дошман капкасы алдында куркып калалар, ә тренерлар нәрсә карый, йөзләрендә борчылуның әсәре дә юк, ичмасам, алыштырырга кирәк аларны, дип уен кырындагы хәлгә үзенчә бәя бирә барды. Бәясе болай бөтенләй үк буш булмаска тиеш. Риф үзе дә балаларның «Факел» командасында капка саклый. Ә «Факел»ның Татарстан чемпионы дигән исеме бар.

«Тренерны алыштырырга кирәк». Кара нинди кызу канлы малай дип уйлап куйды Нәгыйм Харисламович, һәм күңелендә аның әле күптән түгел генә булган бер вакыйга яңарды...

Соңгы айларда аларның гидромонтаж участогы бөтенләе белән Түбән Кама ГЭСы төзелешенә күчте. Ветеран эшче аңлый иде: ГЭС никадәр тизрәк сафка басса — КамАЗ куәте дә шул чаклы тизрәк артачак. Ләкин...

Ләкин соңгы вакытларда ГЭС плотинасы өчен блоклар көннән-көн азрак китерелә башлады. Кайбер блокларда арматура шәрәләнеп күренеп тора, икенчеләренең исә бетоны чәрдәкләнгән була. Бригадирның шуңа җаны әрни иде. Ә арматура участогында кайберәүләр: каккалап-суккалап булса да утыртырлар әле, диләр икән. Соңыннан

мондый башбаштаклыкның нигезе дә ачыкланды. Участокта тәртип какшаган, прогул ясау, станнан төшкән блокларны «юу» кебек алама гадәтләр тамырлана башлаган булган.

Җитәкчеләр Нәгыйм Харисламовичка арматура участогына бригадир булып күчәргә тәкъдим иттеләр, бу фикернең һәрьяклап уйланылган булуын әйттеләр.

Яңа эшкә ул тиз генә ризалашмады. Юк, эштән курыкмый ул, шулай да күчүнең бер читенлеге бар кебек иде: сине яңа коллективта дөрес аңларлармы, Герой булуына ишарәләп: «Әйдә, кылансын егет, җете кызыл тиз уңа ул», дип уйламаслармы?

Тик буласы эш барыбер булмый калмады. Ул арматурачыларга бригадир булып килде.

— Узган айда сез безгә 43 блок бирергә тиеш идегез, инде чираттагы ай уртасы җиткән, әзер блоклар һаман нибары 38 генә әле. Нишлибез, графикны тиешле эш сәгатьләрендә үтибезме, әллә төнгә калабызмы? — диде Нәгыйм Харисламович, бригаданы кабул итеп алгач та.

— Төнлә эшләтергә закон юк, куркытмагыз безне, бригадир иптәш.

— Сезгә генә ярамады инде, Герой булдым дигәч тә, ник ул чаклы һәрнәрсәдән гаеп табасыз, сыйфат та сыйфат дисез, рабочий классны премиядән калдырырга чамалыйсыз.

— Син минә сыйфат турында сүз каттың, — диде яңа бригадир,— менә бусы ошый, бу — егетләрчә сөйләшү. Инде фикеремне аңлагансыз икән — тагын бер тапкыр исегезгә төшереп үтим: ГЭС ул, егетләр, завод бинасы түгел. Ул тулысынча су астында кала. Без төзи торган плотинада энә очы чаклы гына шәрә металл кала икән, еллар узу белән суда күгәрә-күгәрә ул зураерга, ГЭСның бер участогында зур авария китереп чыгарырга мөмкин...

Аннан соң бригадир бүгеннән башлап бригаданың дүртәр кешелек звеноларга бүленүе турында әйтте, ял көннәрендә буш вакытны үткәрү буенча да кызыклы гына фикерләре булуын искәртте. «Матур итеп яшәргә дә, эшләргә дә мөмкин, егетләр, — диде ул сүзен тәмамлап. — Моның өчен һәркемнең үз вөҗданы алдында хисап бирүе генә кирәк».

Бер ай да узмады, бригада узган айдан калган бурычны «кайтарды» гына түгел — өстәмә бер блок та җыйды...

Ул «Гидромонтаж» трестының Зәй участогы партия комитетына килгәндә, төшке аш вакыты булып, партком секретаре урынында юк иде. Ләкин секретарь тиз килде.

— Гафу, Нәгыйм Харисламович, гафу...

— Зарар юк, мин бит юри төш вакытына килдем. Парткомда кешеләр азрак булыр дип уйлап. Аннан сезнең дә вакытны аласы килмәде.

— Яхшы кешеләр өчен вакыт кызганыч түгел ул, Харисламович...

Икесе дә көлеп куйды.

— Менә монда бераз тырнаштыргалаган идем мин, карап чыксагыз икән.

— Рәхим итегез.

Партком секретаре тышына известь оны ягылган яшел папканы кулына алды һәм аны алдына ачып салды. Укый барган саен аның йөзендә канәгать елмаюдан туган сызыкчалар арта иде...

Бу — РСФСРның атказанган төзүчесе, Социалистик Хезмәт Герое Нәгыйм Харисламович Әгъләмовның үзе эшләгән арматура участогында хезмәт нәтиҗәлелеген күтәрү буенча тәкъдим итәсе план-фикерләр сөземтәсе иде.

## А. Литвин,

тарих фәннәре докторы

# РЕВОЛЮЦИЯ СОЛДАТЫ

Табигый хәлдер: кайбер вакыйгалар еллар үтә торган саен кешеләр хәтерендә тоныклана бара. Хәлбуки, бу кешелек тарихында Бөек Октябрь социалистик революциясе булачак урын алган бөек вакыйгаларга кагылмый. Киресенчә, еракта кала барган ул заманнарга, ул вакыйгаларны хәрәкәткә китергән шәхесләр тормышына кешеләрнең ихтирамы һәм игътибары арта. Бөек Октябрьның 60 еллыгы тантанасы көннәрендә тагын бер кат без моның шаһитлары булдык.

Сафлары сирәгәя барса да, безнең арада әле Октябрьда булган бөек вакыйгаларның каһарманнары яши. Шул каһарманнар рәтендә партия ветераны, Совет Армиясе эшлеклесе генерал Якуб Җиһангир улы Чанышев та бар. Быел Совет Армиясенең 60 еллыгы язында генерал-лейтенант Я. Чанышевка 85 яшь тулды. Партия, революция, Совет Армиясе солдаты Я. Чанышев бүген дә ил эшенә, халык эшенә бөтен барлыгы белән бирелеп хезмәт күрсәтеп яши.

... Якуб агадан үзе турында сөйләтү шактый зур түземлелек сорый торган эш ул. Совет власте өчен көрәшнең бөтен авырлыгын күтәргән, социализм төзешкән һәм шул казанышларны Бөек Ватан сугышы елларында саклап кала алган өлкән буын язмышы — аның язмышы... Ярлылыкта узган бала чак, ятимнәр йорты, Казанда татар укытучылар мәктәбендә уку, аннан, 1913 елның сентябрендә патша армиясенә алынганчы, мөгаллимлек итү... Өч ел фронтта була Якуб. Окопларда артиллерия батареясына хезмәткә килгән Путилов заводы эшчеләреннән ул илдә революцион вакыйгалар куеруын белә. 1917 елның январенда прапорщиклыкка укырга Казанга курсларга җибәрелгәч, ул турыдан-туры революцион эшкә бирелә. Казанда, 1917 елның 15 мартында Я. Җ. Чанышев большевиклар партиясенә кабул ителә. Аның партиядәш остазлары В. А. Тихомирнов, Г. Ш. Ольконицкий, К. Я. Якубов кебек күренекле ленинчы революционерлар була. Әмма аңа иң көчле тәэсир ясаган кеше — Мулланур Вахитов. «Безнең арада, татар большевиклары арасында, — дип искә ала Я. Җ. Чанышев, — Мулланур Вахитов иң укымышлы кеше, марксизмны һәм дөнья әдәбиятын белгән эшлекле, политик мәсьәләләрдә иң зирәк һәм тәҗрибәле җитәкче, өстәвенә, ышандырырлык һәм рәхимсез логик фикерләү сәнгате белән дошманнарының өнен ала торган оста оратор һәм курку белмәс трибун иде».

Якуб Җиһангирович бу вакытта вакыйгаларның эчендә кайнап яши: РСДРП(б)ның Казан комитеты каршындагы хәрби оешма әгъ-

засы буларак, гарнизон солдатларын революция ягына тарту буенча актив эш алып бара. Аны эшчеләр җыелышларында еш күрергә мөмкин була. Мулланур Вахитов һәм башка татар большевиклары белән берлектә, ул милләтчеләрнең халыкка каршы эшләрен фаш итүдә, илебездә милли мәсьәләне большевиклар программасы нигезендә хәл итүне яклап агитация алып баруда катнаша.

240 нчы полк комитеты әгъзасы большевик-прапорщик Я. Җ. Чанышев 1917 елның сентябрендә Мөселман хәрби комитеты составына кертелә. Ул, Казан Советы карарын үтәп, Казанда патша монархиясе символы — ике башлы бөркетне Сөембикә манарасыннан төшерүдә катнаша. Шул чакта ук, сентябрь аенда, Я. Чанышев тулысынча революция ягына күчкән 240 нчы полкның батальон командиры итеп билгеләнә.

1917 елның октябрь көннәрендә Якуб Җиһангир улы, Казан урамнарында юнкерларга каршы сугышучылар сафында торып, татар роталарын һөҗүмгә алып керә, шәһәрдә кораллы восстание күтәрү буенча прапорщик-большевик Н. Е. Ершов җитәкчелегендәге революцион штаб члены була.

Ул чактагы баш күтәргән халык белән тулы шәһәр урамнары, 25—26 нчы октябрьда шәһәр биналарында кызыл әләмнәр җилфердәгәне, Н. Ершов, К. Грасис, Г. Ольkеницкий иптәшләрнең элекке губернатор сарае трибунасыннан халыкны тарихи җиңү белән котлаганнары, Г. Ольkеницкий Петроградта Совет власте җиңүе турындагы телеграмманы укыгач, халыкның бу хәбәрне «ура!» тавышлары белән алкышлавы революция ветераны Якуб Чанышевның хәтереннән һич җуелмас.

Казанда Совет власте җиңгәч, Я. Җ. Чанышев Революцион штаб әгъзасы була. Штаб шәһәр һәм губерна хезмәт ияләренә: «Авыр көрәш көннәре артта калды. Революцион гаскәрләр җиңде. Шушы җиңү белән власть тулы вәкаләтле органнар — Эшче, солдат һәм крестьян депутатлары йөзендә халыкның үз кулына тапшырылды... Бүгеннән башлап халык үз тормышын үзе иҗат итәчәк, үз язмышын үзе хәл кылачак»,— дип мөрәҗәгать итә.

Аннары Я. Җ. Чанышев Казан хәрби округы комиссарларының берсе итеп сайлана. Ул Кызыл Армиянең беренче отрядларын төзүдә, юнкер училищеларын таратып, кызыл командирлар курсларын ачуда, милләтче буржуаз оешмалар белән көрәштә катнаша. Комиссарлар Советының башка әгъзалары белән берлектә, ул да 1917 елның 2 декабрендә солдатларны контрреволюция белән хәлиткеч көрәшкә чакырган 109 нчы номерлы боерыкка кул куя. Шушы елның ахырында Я. Чанышев Казан отрядлары белән Оренбург ягына барып чыга, анда Дутовның ак казаклары белән сугышларда катнаша.

1918 елның 8 январенда Казанда мөселман сугышчыларның 2 нче съезды ачыла. Ул ике айга якын дәвам итә. Губерна советы председателе Я. Шейнкман, С. Сәедгалиев, К. Якубов, Г. Касыймов кебек большевиклар белән берлектә, Чанышев «Идел-Урал штаты» оештырырга, Советларга каршы көрәшер өчен милли армия төзергә, Казан советы һәм шул совет каршындагы Мөселман комиссариаты депутатларын кулга алырга өметләнгән шурачыларга каршы көрәшә. Казан большевиклары тәкъдиме буенча ул съездда беренче булып чыгыш ясый, Совет власте белән бергәләп эшләргә, контрреволюциягә каршы рәхимсез сугыш алып барырга өнди. Аның чыгышы шурачыларның ачуын кабарта, ә татар солдатларының исә көчле алкышларына күмелә. 1918 елның февраль-март айларында Казанда татар буржуазиясенең «Болак арты республикасы» төзергә маташуы бетерелә, хәрби һәм милли шура кебек контрреволюцион оешмаларның эше туктатыла.

1918 елның язында гражданнар сугышы башланып, Урта Иделдә дә сугыш давылы куба: ак чехлар корпусы баш күтәрә, кулаклар активлаша, Самарада властьны уң эсерлар үз кулларына ала. Казанга һәм Сембергә һөҗүмнәр башлана. Бу чорда Комиссарлар советы йомышы белән Я. Чанышев фронтта еш була. Шулай бер чыгуында ул аклар кулына эләгә, аны Уфа төрмәсенә ябалар. 1918 елның 31 декабрендә Кызыл гаскәрләр тарафыннан азат ителгәч, Я. Чанышев Уфа шәһәре коменданты булып тора. 1919 елның гыйнварында яңа оештырылган гаскәри частьлар өчен корал табыштырырга Мәскәүгә килгәч, ул беренче тапкыр Владимир Ильич Ленинны күрү һәм тыңлау бәхетенә ирешә.

1919 елның мартында илнең көнчыгышында тагын зур куркыныч туа: адмирал Колчак гаскәрләре Идел ярларына якынлаша, Мәскәүгә ыргыла. Көнчыгыш фронт яңадан революция, республика язмышы хәл ителәчәк фронтка әйләнә. Шул чакта Казанда һәм башка шәһәрләрдә Кызыл Армиянең эре милли часте — 1 нче Идел буе укчы татар бригадасы оеша башлый. Бригада командиры итеп Ю. Ибраһимов, комиссары итеп Ш. Усманов билгеләнә. Я. Чанышев башта батарея, аннары артиллерия дивизионы белән командалык итә, соңрак шушы данлы частьның хәрби комиссары була. 1919 елның маенда бригада Көнчыгыш фронтның Көньяк группасы составында Колчакның акгвардияче армияләрен тар-мар иткән хәлиткеч сугышларда катнаша. Шул көннәрдә 1 нче татар полкы сугышчыларының партиянең Казан губерна комитетына җибәргән телеграммасы архивта саклана. «Хәлиткеч сугышка чыгар алдыннан 1 нче татар укчы полкы хезмәт ияләренең азатлыгы өчен барлык көрәшчеләргә сәлам юллый һәм Кызыл байрак астында акгвардияче шайкаларга каршы үзенең соңгы сыйнфый сугышчысына кадәр көрәшәчәгенә һәм яу кырыннан җиңеләп кайтмаячагына ышандыра...» — дип язалар татар сугышчылары. Бу телеграмма — аларның югары революцион аңы һәм сугышчан ныклыгының дәлиле.

Бригада составында Я. Җ. Чанышевның артиллерия батареясе Урал елгасын кичкәндәге каты сугышларда катнаша, аның тупчылары Колчак атлыларының байтак атакаларын кире кага.

1919 елның августында М. В. Фрунзе командалыгында Төркестан фронты төзелгәч, татар бригадасы шул фронт гаскәрләре белән берлектә кан койгыч сугышларда катнаша, Орск, Актүбә, Тимер шәһәрләрен, бик күп авылларны Колчак бандаларыннан азат итә.

Якуб Җиһангир улы Чанышев ул елларда партия һәм Совет дәүләтенең М. В. Фрунзе, В. В. Куйбышев, Ш. З. Элиава кебек күренекле эшлеклеләре кул астында хезмәт итәргә туры килүе белән горурлана, Ю. Ибраһимов, Ш. Усманов, Б. Белоусов, Х. Мәүлетов, Г. Касыймов кебек сугышчан иптәшләрен зур ихтирам белән искә ала.

Сугышчан юл аннары Төркестаннан Фирганәгә сузыла. Бу вакытта Я. Җ. Чанышев бригаданың хәрби комиссары була. Җирле партия-совет оешмалары белән киңәшеп, ул берьюлы күп төрле мәсьәләләрне хәл итүгә көч куя: ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруда катнаша, басмачыларга каршы көрәшне оештыра, көнкүрешне җайлау мәсьәләләре белән шөгыльләнә.

1920 елның 1 апрелендә татар бригадасы үзенең оешуына бер ел тулуны билгеләп үтә. Төркестан фронты Реввоенсоветы әгъзасы В. В. Куйбышев, бригаданың сугышчан эшчәнлеген югары бәяләп, аңа менә нинди котлау сүзләре белән мөрәҗәгать итә: «Кызылармияче иптәшләр, бригаданың командирлар составы һәм политработниклары Оренбург далаларында Колчак авантюрасын юкка чыгару өчен барган байтак рәхимсез сугышларда үзләренең фидакарьлеген һәм дисциплиналы булуын раслый алдылар һәм Фирганәнең ярлы халкы-

на чын кызылармиячеләргә хас мөнәсәбәт күрсәтеп, Фирганә фронтын ябарга мөмкинлек тудырдылар».

Бригада белән бергә шушы данлы сугышчан юлны командир һәм хәрби комиссар Якуб Чанышев та үтте, В. Куйбышевның тәбрик сүзләре аңа да багышланган иде.

Сентябрь башында Бохара фронты ачыла. Бригаданың шунда җибәрелгән ике полк сугышчылары борынгы шәһәр стеналары янында үзләрен сүнмәс-сулмас данга күмделәр. Я. Чанышевка әлеге сугышларда катнашырга туры килми — бу вакытта ул Бакуда Көнчыгыш халыклары съездында булып кала. Бүгенге карт генерал үзенең истәлекләрендә бригада сугышчыларының Бохара өчен бәрелешләрдә каһарманлыкларына сокланып яза, шул сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен икенче тапкыр Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән полк командиры Х. Мәүлетов белән горурлануын белдерә.

Бохарадан соң Җидесуда бригада сугышчылары ак казаклар белән көрәшә һәм халык арасында агарту эшләре алып бара. 1921 елның мартында партиянең 10 нчы съезды делегаты Я. Җ. Чанышев В. И. Ленинны тыңлый. Бригадага кайткач, хәрби комиссар сугышчан көрәштәшләренә революция юлбашчысының сүзләрен җиткерә, яңа экономик политикага күчүнең мөһим эш булуын аңлата, милли мәсьәлә буенча һәм партиянең ярдәмлеге турында съезд карарларын төшендерә.

Татар бригадасының бик күп сугышчылары һәм командирлары гражданнар сугышында күрсәткән каһарманлыклары өчен РСФСР һәм Урта Азия республикалары орденнары белән бүләкләнә. Я. Җ. Чанышев Сугышчан Кызыл Байрак орденына һәм Үзбәкстанның Кызыл Байрак орденына лаек була. Ул — Әндиҗан шәһәренең почетлы гражданины.

Гражданнар сугышы җиңүле тәмамлангач, Я. Чанышев өчен уку һәм хәрби хезмәт еллары башлана. Эшче-крестьян Кызыл Армиясе академиясен тәмамлап, 1925 елда ул 1 нче Казан укчы дивизиясе командиры итеп билгеләнә һәм 1932 елга хәтле шул эшен башкара. Казанда чагында ул республиканың җәмәгать тормышында актив катнаша: партия өлкә комитеты бюросы члены, Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының Президиумы члены итеп, партиянең 14 нче һәм 16 нчы съездларына хәлиткеч тавыш белән делегат булып сайлана.

1932—34 нче елларда яңадан уку, аннары—Төркестан хәрби округында хезмәт итү, илебезнең көньяк чикләрен саклау. Аннары — Кызыл Армиянең М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби академиясендә курслар начальнигы эшен башкару.

Якуб Чанышев Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәү өчен сугышларда катнаша, Сталинград янында каты яралана. 1943 елның сентябреннән ул — Кызыл Байраклы Брест укчы корпусы командиры. Аның җитәкчелегендәге гаскәрләр Белоруссиядә, Польшада, Одерны кичкәндә һәм Берлин өчен сугышларда катнашалар. Сугыш алып бару осталыгы һәм шәхси батырлыгы өчен Я. Җ. Чанышев хөкүмәтебезнең бик күп бүләкләренә лаек була.

Якуб Җиһангир улы Чанышев кырык биш ел гомерен хәрби сафларда уздыра. Революция солдаты данлыклы совет генералы булып җитлегә. Революция казанышларының иминлеге хакына хәрби хезмәтләре һәм шәхси каһарманлыгы өчен илебезнең һәм тугандаш социалистик илләрнең егерме биш ордены һәм медале белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышыннан соң Я. Җ. Чанышев Генеральный штабның Хәрби академиясендә укыта.

Отставкага чыккач та генерал-лейтенант Я. Җ. Чанышев күп кырлы җәмәгать эше алып бара: ул гражданнар һәм Бөек Ватан сугы-

шы ветераннары комитетында, совет-поляк дуслыгы җәмгыятендә актив эшли.

Якуб Җиһангирович Казанда бик еш була, бирөдә ул ветераннар белән очраша, яшьләргә В. И. Ленин турында, Совет власте өчен сугышлар хакында сөйли, яңа тормыш төзүче гүзәл кешеләрне яшь буынга үрнәк итеп күтәрә.

Бөек Октябрьның 60 еллыгы тантанасы көннәрендә, партия һәм революция ветераннары белән берлектә, Якуб Җиһангирович Чанышев КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневка мөрәҗәгать итеп, үзләренең, өлкән буын коммунистларының, киләчәктә дә бөтен көчләрен, белем һәм тәҗрибәләрен Ватаныбыз файдасына, коммунизм тантанасы хакына бирәчәкләрен белдерде. КПСС һәм социалистик революция ветераннарының мөрәҗәгатенә җавап хатында Леонид Ильич Брежнев: «Сез, өлкән буын коммунистлары, Октябрь революциясендә актив катнашкан кешеләр, аның җиңүе, Совет властен урнаштыру хакына мөмкин булганның барысын да эшләдегез, социализм һәм коммунизм төзүчеләрнең алгы сафларында бардыгыз, революция казанышларын дошманнардан нык саклдыгыз. Шушы данлы юлның барлык этапларында Сез Ленинның бөек эшенә чиксез бирелгәнлек үрнәге күрсәттегез», — дип язды («Правда», 1 ноябрь, 1977 ел).

Якуб Җиһангир улы Чанышевның революция, Совет власте, Ватаныбыз хакына хезмәтләре шундый югары бәягә лаеклы.

# «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**Шәмси Хамматов,**
«Социалистик Татарстан» газетасы редакторы,
тарих фәннәре кандидаты

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Социалистик Татарстан» газетасының элгәре, башлангычы булган «Эш» газетасының беренче саны Бөек Октябрь социалистик революциясенең беренче язында — 1918 елның 12 мартында басыла. Башта ук исеменә игътибар итегез әле. Аның туганы — «Советская Татария» газетасының элгәре Казан большевикларының «Рабочий» газетасы 1917 елның язында ук чыга башлый. «Рабочий» һәм «Эш» — исемнәрендә һәм эчтәлекләрендә нинди тирән бердәмлек!

Беренче санында «Эш» газетасы революцион эшчеләр, хезмәтчел крестьяннар һәм солдат массаларын революциянең эчке һәм тышкы дошманнарына каршы, царизм һәм империалистик сугыш калдырган артталыкка, ачлыкка, җимереклеккә каршы көрәшкә берләштерү өчен дөньяга килгәнлеген игълан итте. Совет дәүләтенең иҗади характеры турында Ленин фикерен чагылдырып, газета беренче санында ук: безнең максат — эшчеләрнең һәм иң ярлы крестьяннарның яшь дәүләтен, халык өчен яулап алынган тынычлыкны саклау, нормаль тормыш урнаштыру һәм яңа тормыш өчен кирәк булганнарның бөтенесен тудыру, дип язды.

«Эш» газетасы укучыларны хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы В. И. Ленинның докладлары һәм чыгышлары белән таныштырып баруны беренче чираттагы бурычы итеп саный. Беренче саннарында ук ул В. И. Ленинның Советларның IV чираттан тыш съездында Брест договорын ратификацияләү турындагы докладын һәм 1918 елның 12 мартында эшче, крестьян һәм кызылармеецларның Мәскәү советында ясаган чыгышын урнаштыра.

Мәгълүм булганча, 1918 елның 17 январь декреты нигезендә шул ук елның февралендә эшче, солдат һәм крестьян депутатларының Казан советы янында Мөселман эшләре комиссариаты төзелде. Комиссариатка Казан большевиклары оешмасының күренекле эшлеклеләре — Сәхипгәрәй Сәидгалиев, Камил Якубов, Хәсән Урманов һәм башкалар җитәкчелек иттеләр. «Эш» газетасы, шушы комиссариат органы буларак, Казан партия оешмасы җитәкчелегендә эшләде. Газетаның редколлегиясенә күренекле революционер һәм журналист Хәсән Урманов җитәкчелек итте. Редколлегия составына шулай ук Вәли Шәфигуллин, Камал Каспронскийлар да кертелгән иде.

Колчак оккупациясе көннәрендә, 1919 елның 1 маенда, «Эш» редакциясе хезмәткәрләре, Көнчыгыш фронтның Икенче армиясе Реввоенсоветы политбүлеге органы булган «Кызыл көрәшче» газетасын чыгару максаты белән, фронтовиклар белән берләшәләр.

Большевиклар партиясенең Казан комитеты карары нигезендә, «Эш» газетасы 1919 елның 18 маеннан 1920 елның июленә кадәр яңадан үз исеме белән басыла. 1918—1920 нче елларда чыккан беренче большевистик татарча газета эчтәлеге ягыннан төрле һәм бик бай була. Бу газетаның барлыгы 418 саны чыга.

Әйе, хәзерге «Социалистик Татарстан» газетасының данлы тарихы әнә шулай башланып китә.

1918—1978 нче еллар. 60 еллык газета тегелмәсе. Шушы еллар эчендә газетаның 17 400 дән артык саны чыгарылды. Ул — Татарстан хезмәт ияләренең алтмыш еллык тормышын, аларның тырыш хезмәтен, данлы көрәшен, уй һәм өметләрен колачлаган елъязма, данлы чорыбыз елъязмасы. Ул — Идел буе һәм Уралда гына түгел, бәлки бөтен илебездәге иң өлкән һәм күп тарала торган милли газеталарның берсе. Аның тиражы хәзер 178 мең данә.

Бүген без 60 еллыгын билгеләп үтә торган «Эш» — «Социалистик Татарстан» газетасы һәм әдәбият мәсьәләләре темасы: газетаның әдәби тарихы, әдәбиятның партиялелеге өчен көрәш юлы — галимнәрнең, әдәбият белгечләренең, тарихчыларның, журналистларның җитди игътибарын җәлеп итәрдәй зур тема ул.

Бу мәкаләдә газетаның егерменче-илленче елларда әдәбият вәкилләре белән тыгыз элемтәдә торып ничек эшләвенә махсус рәвештә тукталынмый, бәлки ул аның шуннан соңгы еллардагы әдәби тарихына бер караш буларак тәкъдим ителә [1].

Газета үзенең беренче саннарыннан ук әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен киң яктырта, үз тирәсенә әдәби көчләрне туплый, әдәби процесска партия политикасыннан чыгып принципиаль юнәлеш һәм бәя бирә килә. Егерменче елларда ук газета, партиянең Татарстан өлкә комитеты җитәкчелегендә, әдәбият-сәнгать проблемаларын яктыртуда зур тәҗрибә туплады. Шул елларда туып, инде газета эшчәнлегендә сынау узган формалар һәм алымнар хәзер дә «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе коллективы тарафыннан партиябез әдәбият-сәнгать алдына куйган бурычларны үтәүдә тагын да үстерелеп һәм баетылып файдаланыла.

«Социалистик Татарстан» редакциясе, Татарстан Язучылар союзы идарәсе белән берлектә, әдәбият-сәнгать проблемаларын газета битләрендә бергәләп күтәрү, бу эшкә танылган язучылар һәм публицистларны тарту, иҗади командировкалар бирү чараларын күрде. Газета битләрендә әдипләрнең очерклары, юлъязмалары, публицистик мәкаләләре, повесть-романнардан өзекләр ешрак күренә башлады. Милли газеталар арасында беренчеләрдән булып атнага бер тапкыр әдәбият-сәнгать сәхифәсен биреп бару гамәлгә кертелде.

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу, Совет властеның һәм Татарстан АССРның 50 еллыклары уңае белән әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең иҗат активлыгы тагын да артты. Газетада иҗади союзларның җитәкчеләре, күренекле язучылар юбилейларга хәзерлек чорындагы эшчәнлекләре турында мәкаләләр белән чыктылар. Бөек Октябрьның 50 еллыгына хәзерлек чорында «Илһамыбыз синдә, Октябрь» дигән рубрика алып барылды. Ленин юбилеена хәзерләнгән вакытта «Аның образы — мәңгелек илһам чыганагы» дигән махсус рубрика ачылды. Анда республика иҗат оешмалары җитәкчеләре, язучылар мәкаләләр, публицистик язмалар, Ленин турындагы яңа әсәрләре белән әледән-әле чыгышлар ясадылар. «Ленин һәм китап», «Ленин образы — халык иҗатында», «Тугандаш республикалар шагыйрьләре Ленин турында» дигән тематик сәхифәләр чыгарылды. «Ленин укулары» дигән махсус рубрика астында В. И. Ленинның идея-эстетик карашлары, балалар әдәбиятында, драматургиядә, М. Горький, В. Маяковский иҗатында юлбашчы образының чагылышы турында мәкаләләр бирелде. Газета редакциясе һәм Язучылар союзының поэзия секциясе белән берлектә, Ленин һәм Татарстан юбилейларына багышлап газета битендә ике елдан артык алып барылган «Шигъри сабан туй»да республикабызның һәм тугандаш халыклар шагыйрьләренең иң яхшы әсәрләре басылды. Сүз уңаенда шушыны ассызымлап әйтик, башка милләт шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итүдә безнең каләм осталарыбыз бик актив эшлиләр.

---

[1] Мәкалә кыскартып урнаштырыла.

Халык хуҗалыгының, милли культураның төрле тармакларында ирешелгән казанышларны күрсәткән махсус саннар чыгарылды. Аларда шулай ук язучылар публицистик мәкаләләре, очерк-язмалары, шигырьләре белән актив катнаштылар. «Социалистик Татарстан» редакциясе тугандаш культураларның чәчәк атуын, интернациональ элементларның ныгуын күрсәтү максаты белән өлкә яки республика газеталарының берләштерелгән саннарын чыгаруны башлап оештыручы булды. Идел буе һәм Урал автономияле республикалары газеталарының үз республикаларында культура революциясе темасына багышлап «Октябрьда туган культура» дигән баш астында 1967 елның 26 октябрендә чыгарылган берләштерелгән санын «Правда» газетасы уңай билгеләп үтте [1]. Бу санда күренекле әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең Ленинга, партиягә, туган илгә, элек артта калган халыкларның культурасын үстерүдә бөек рус культурасының ярдәмен күрсәтүгә багышланган публицистик мәкаләләре, әдәби әсәрләре басылды. Башкортстанның халык шагыйре С. Кудаш ул санда халыкларның уртак уе турында болай әйтте: «... Үзен тудырып үстергән һәм кешеләргә тиңдәш иткән атаанасына бөтен гомере буена бурычлы икәнлеген тирән аңлаган тотнаклы балалар сымак, — дип язды шагыйрь, — безнең татар һәм башкорт, чуваш һәм мари, удмурт һәм мордва халыклары да үзләренең бүгенге бәхетле язмышлары өчен Бөек Октябрь революциясенә һәм шул тарихи үзгәрешне барлыкка китерү белән җитәкчелек иткән Ленин партиясенә мәңге бурычлы икәнлекләрен бөтен йөрәкләре белән аңлыйлар».

Газета төрле милләтләр арасында культура байлыклары алмашуда, тәҗрибә уртаклашуда, аерым халыкларның рухи җимешләрен гомуми байлык итүдә арадашчы хезмәтен үти. Анда А. Пушкин, Л. Толстой, Т. Шевченко, М. Горький, Д. Фурманов, М. Шолохов, Н. Тихонов, М. Кәрим, С. Кудаш, Ч. Айтматов, Э. Межелайтис һәм башкаларның иҗатлары турында мәкаләләр, тугандаш язучыларның әсәрләрен күрергә мөмкин. Соңгы елларда Ш. Руставели, А. Навои, Т. Шевченко, А. Герцен, А. Чехов, И. Тургенев, К. Федин, А. Корнейчук, С. Вургун һәм башка бик күп әдипләрнең еллыкларына махсус саннар, сәхифәләр, подборкалар һәм мәкаләләр багышланды, аларның әсәрләре киң пропагандаланды. Кагыйдә буларак, ул материалларны оештыруга редакция язучыларны актив туплый.

1966 һәм 1967 нче елларда татар әдәбияты корифейлары Г. Тукай, М. Җәлил, Г. Ибраһимовлар, 1970 һәм 1971 нче елларда һ. Такташ һәм композитор С. Сәйдәшев юбилейлары киң билгеләп узылды.

... Бу урында газетаның тарихына мөрәҗәгать итеп, шунысын әйтеп китәргә кирәк.

«Эш» газетасының актив авторлары арасында Камил Якуб, Хәсән Урманов, Вәли Шәфигуллин, Садыйк Әхмәтов, Шәһит Әхмәдиев, Каюм Саттаров, Исмәгыйль Губанов, Ибраһим Кули, Нурмөхәммәт Галиев, Габдрахман Кәрам, Мостафа Сөбхи, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, С. Сөнчәләй, Фатих Сәйфи, М. Дулат-Али, Фәтхи Бурнаш, Сәгыйть Фәйзуллин һ. б. бик күп татар большевиклары, совет работниклары, язучылар һәм журналистлар була. Ул Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов, Бари Рәхмәт, Мансур Крымовларның әдип булып үсеп китүләренә юл ачты.

Атаклы әдибебез Галиәсгар Камал «Эш» газетасының тернәкләнеп үсеп китүенә иң зур өлеш кертүчеләрнең берсе була. Ул — революциягә кадәр үк демократик журналистика эшчәнлегендә актив катнашкан, халыкара мәйданга чыккан, чит илдә хәбәрче булып йөргән журналист. Балкан сугышы вакытында аны татар матбугатының махсус хәбәрчесе сыйфатында Төркиягә җибәрәләр. Совет газетасында аның бай тәҗрибәсе бик тә ярап куя.

«Эш» газетасының дәвамы булган «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан», «Кызыл Татарстан» газеталарында төрле елларда татар совет культурасы һәм әдәбиятының күренекле эшлеклеләре Фәтхи Бурнаш, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти редактор булып эшлиләр.

Ул еллар матбугатын Галимҗан Ибраһимовтан башка күз алдына китереп булмый. Октябрьдан соң чыга башлаган барлык газеталарга да әдип якыннан булышлык

[1] «Правда» газетасы, 30 октябрь, 1967 ел.

күрсәтә. 1922 елның маенда партия өлкә комитеты аңа «Татарстан» газетасына шефлык итү эшен тапшыра.

Галимҗан Ибраһимов Октябрьга кадәрге милли матбугат һәм журналистиканың алдынгы традицияләрен иҗади рәвештә файдаланырга омтыла, дәүләт эшлеклесе һәм язучы буларак, ул демократик интеллигенция вәкилләрен кыю рәвештә үзенә ияртә, өлкән буын татар язучыларын һәм журналистларын газета тирәсенә туплый. Г. Ибраһимов эшче һәм крестьяннар арасыннан чыккан яшь каләм ияләренең иҗат үсешен аталарча күзәтеп тора, аларга шифалы йогынты ясый, яшьләрдән журналист кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә. Матбугатта эшче һәм авыл хәбәрчеләре хәрәкәтен җәелдерүдә дә Г. Ибраһимов якыннан катнаша, моны редакция эшенең иң мөһим юнәлеше дип саный.

Тынгысыз каләм иясе Г. Ибраһимов республика газетасы битләрендә татар культурасы, әдәбияты һәм сәнгате мәсьәләләренә багышлап күп мәкаләләр белән чыгыш ясый. Газета социалистик реализм принципларын урнаштыру өчен җәелдерелгән әдәби-эстетик көрәшнең алгы сызыгында була.

Г. Ибраһимовның публицист буларак активлыгын күрсәткән бер сан китерик: 1922—1925 нче елларда гына аның имзасы белән 50 гә якын әсәр басылып чыга. Г. Ибраһимовның матбугат органнарында оештыру һәм аерым алганда республика газетасына шефлык итү эшчәнлеге әдипнең үзенең идея-рухи үсешендә дә уңай чагылыш таба.

Г. Ибраһимов үз эшчәнлегенең һәр өлкәсендә марксизм-ленинизм идеяләрен армый-талмый пропагандалый, интернационализм байрагын югары тота. 1928 елның мартында әдипнең әдәби иҗат һәм иҗтимагый политик эшчәнлегенә егерме ел тулу уңае белән алган котлауларга җавап рәвешендә «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясенә җибәргән телеграммасында бу хакта аеруча ачык әйтелгән: «Мин, — ди Г. Ибраһимов, — пролетариат революциясенең солдатымын. Бөтен үткән тормышым мине моңа хәзерләде. Үземне үстергән, тарихы, теле туган булган татар халкымның гына түгел, дөньядагы барлык изелгән милләтләрнең, сыйныфларның иҗтимагый азатлыклары, пролетариат байрагы астында, ленинизм нигезләрендә көрәшкәндә генә мөмкин дип эшләүчеләрдәнмен. Мин эшче-крестьян халкына кирәкле әйберләр биргән булсам, аның сәбәпләре минем шәхси талантымнан гына түгел, бәлки революциячә массага бәйләнгән булуымда, бигрәк тә тарихның бердәнбер иҗади юлбашчысы принципларыннан булган марксизм методларының биргән куәтләрендә, күрсәткән юлларында». «Социалистик Татарстан» газетасының 60 еллыгын билгеләп үткән бу көннәрдә без әлеге сүзләрнең тирән мәгънәсен тагын да ачыграк тоябыз.

1928—1930 нчы елларда «Кызыл Татарстан»да культура бүлеге мөдире булып Гадел Кутуй эшли. Аның материаллары номер саен диярлек күренә. Ул репортажлар, очерклар, зарисовкалар яза, театр тәнкыйтьчесе, фельетончы буларак танyла. Матбугат аны кыска, төгәл язарга, вакыйгаларга көн кадагында торган бурычлар күзлегеннән карап бәя бирергә өйрәтә. Г. Кутуйның вакытлы матбугатта 500 ләп материалы басыла. Ул иҗат юлының беренче көненнән соңгы сулышына чаклы халыкка журналист буларак та хезмәт итә...

«Кызыл Татарстан» газетасының утызынчы елларда, аннан алдагы чорда да үз битләрендә актив катнашкан шагыйрь-публицистлар Һ. Такташ һәм М. Җәлил белән элемтәсенә аеруча тукталасы килә.

Бу елларда чыккан журналлар, бигрәк тә «Кызыл Татарстан» газетасы эшчәнлегендә актив катнашуы, редакция белән еш аралашуы, анда күренекле әдипләр Г. Камал, Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти кебек публицистлар, шагыйрьләр иҗатын күрүе, белүе, иҗади атмосферада кайнавы Һ. Такташның дөньяга карашын киңәйтә. Матбугат аны Коммунистлар партиясе, Ленин идеяләре рухында тәрбияли.

Һ. Такташның политик характердагы шигырьләре, поэмалары, иҗади командировкада булып кайткач язган публицистик мәкаләләре беренче чиратта «Кызыл Татарстан» газетасында басыла. Аның «Гасырлар һәм минутлар» исемле поэмасының кичәдә җәмәгатьчелек алдында укылуы турында газетада хәбәр бирелә. «Һади Такташ иптәшнең «Гасырлар һәм минутлар»ыннан Ленин үлгән атнасындагы картиналарны ачып күрсәткән шигырьләре белән чыгуы кичәгә аерым рух, тәэсир бирде», — диелә анда.

Шагыйрьнең «Никахсызлар», «Син дә ул инде», «Бүгенге матурлык», «Москва — Лондон сөйләшә», «Җырым сиңа булсын», «Лорд Чемберленга...», «Үтеп барышлый» кебек бик күп шигырьләре беренче башлап «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә басылды. Ул үз шигырьләрендә көрәшчеләрне, яңа тормыш төзүчеләрне данлый, иҗади хезмәт батырларына мәдхия җырлый, империалистларның мәкерле уйларын фаш итә.

Һ. Такташ газета аша укучыларына үзенең иҗат планнарын сөйли, «Киләчәккә хатлар»ының төп идеясен аңлата. «Хәзерге вакытта мин «Киләчәккә хатлар» әсәре өстендә эшлим. Аларда мин киләчәк буыннарга безнең яңа тормыш-көнкүреш, яңа кеше өчен алып барган көрәшебезне тасвирларга тырышам», — дип яза шагыйрь.

1930 нчы ел. Газета ул елларда әдәби битләрне «Матур әдәбият фронты» дигән рубрика астында биргән. Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасыннан өзек шушы рубрика белән иң элек «Кызыл Татарстан»да басыла. Ул әдәби тормышта зур вакыйга була, социализм төзүчеләргә шигъри гимн булып яңгырый.

Һ. Такташның матбугатка, аеруча «Кызыл Татарстан»га олы ихтирамы газетаның 2000 нче саны (1927 ел) чыгу уңае белән язылган «Онытылган тәбрик» шигырендә сурәтләнә.

**Ике меңне тутыргансың, «Кызыл Татарстан».**
**Ә мин**
**Бүген генә аны ишеттем,**
**Дөнья куып, бәгърем, йөри-йөри,**
**Тәбрикләргә сине кичектем!**
**Сәлам булсын сиңа!**
**Ак битләрең**
**Тыгыз юллар белән каралсын,**
**Һәрбер битең тарих булып калсын!**
**Исемең эшче илдә дан алсын.**

**Айга күптән инде миллион тулган,**
**Ә ул үзе аны оныткан,**
**Бүген саташкан ай, кыш дип белеп,**
**Төн уздырган күктә толыптан.**
**Ай кебек син ялгыз читтә калма,**
**Битләреңә**
**Миллионнарның бәйлә йөрәген,**
**Миллион күзләр синең биттә йөрсен,**
**Шушы минем сиңа теләгем!**

«Һәрбер битең тарих булып калсын!», «Миллион күзләр синең биттә йөрсен». Һ. Такташның бу сүзләре безне, журналистларны, халыктан, эшче-авыл хәбәрчеләреннән, әдипләрдән аерылмагыз, хәзерге заман кешеләре турында күбрәк языгыз, дип васыятьли-нәсыйхәтли кебек.

Үзен шагыйрь генә түгел, ә тулы хокуклы журналист та дип санаган Муса Җәлилнең вакытлы матбугат белән бәйләнеше, газета-журналлар редакцияләрендәге эшчәнлеге Һ. Такташныкына бик охшаш. Шагыйрь 1922 елның көзендә әдәби Казанга килә. «Үземнең шигырь көчемә нык ышану мине Казанга канатландырды... — ди ул.— Анда язучылар белән күрештем. Укырга инде вакыт соң иде. Мин «Татарстан» газетасы редакциясенә кучереп язучы булып кердем».

Муса Җәлил имзасы «Татарстан» газетасында 1923 елда күренә башлый һәм бу иҗади дуслык шагыйрь Бөек Ватан сугышы фронтына киткәнче дәвам итә.

«Кызыл Татарстан» газетасына үзенең олы ихтирамын М. Җәлил 1940 елда газетаның юбилее уңае белән шаяру төсендә язылган шигырендә әйтеп биргән:

**Каләм батырлары, алдынгылар**
**Утыралар табын түрендә,**

Стаканда ташкан сыра төсле,
Куанычлар ташый күңелдә...
Чәчәк итеп сибәм табынызга
Котлау сүзләремнең бәйләмен,
Котлы булсын, «Кызыл Татарстан»,
Данлыклы һәм матур бәйрәмең.

... Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты М. Җәлилнең тууына 60 ел якынлашкан көннәрдә «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе, шагыйрьнең шәхесе һәм иҗаты турында фикерләрен язып җибәрүне үтенеп, илебезнең күренекле культура эшлеклеләренә мөрәҗәгать итте. Нәтиҗәдә газетада рус әдибе Н. Тихонов, әзербәйҗан язучысы М. Ибраһимов, украин әдибе О. Гончар, калмык шагыйре Д. Кугультинов, кыргыз язучысы Ч. Айтматов, үзбәк шагыйре Г. Голәм, белорус әдибе П. Бровка, литвалы шагыйрь Э. Межелайтис, башкорт әдибе М. Кәрим h. б. үз фикерләре белән уртаклаштылар.

Язучыларны матбугатка җәлеп итүдә әдәбият-сәнгать сәхифәләре зур роль уйный. Кайбер әдипләр андый сәхифәләргә атап әсәрләр язалар, иң яхшы иҗат җимешләрен шушы махсус битләрдә урнаштыруны үтенәләр. Соңгы вакытта бу сәхифәләр тематик итеп чыгарыла башлады. Мәсәлән, эшчеләр, нефтьчеләр, химиклар, авыл эшчәннәренә багышлап махсус сәхифәләр чыгарылды. Балалар әдәбиятына, юморсатирага аталган сәхифәләр дә дөнья күрде. Сәхифәләрне шулай максатчан оештыру иҗат интеллигенциясенең игътибарын мөһим мәсьәләләргә юнәлдерә, социаль заказлар үтәргә күнектерә.

Язучыларны матбугатка тартуда соңгы вакытта туган тагын бер яңалыкка — «Түгәрәк өстәл янында сөйләшү» оештыруга тукталыйк. Әдәбиятның теге яки бу актуаль мәсьәләсе, күләмле әсәрләр турында матбугатта сүз әйткәнче, башта редакциянең «Түгәрәк өстәле» янында әдәбият белгечләрен, язучыларны, тәнкыйтьчеләрне җыеп фикер алышу уздырыла. «Түгәрәк өстәл» янында эстрада һәм җыр жанрларының бүгенге хәле, Н. Фәттахның «Этил суы ака торур» дигән әсәре буенча шундый сөйләшүләр булды. Алдан шулай сөйләшү теге яки бу мәсьәләне тирәнрәк яктыртырга мөмкинлек бирә, субъективлыкка юл калдырмый.

«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе «летучкалар»га язучыларны, тәнкыйтьчеләрне чакыруны гадәткә кертте. Шундый «летучкалар»да И. Гази, Г. Бәширов, галимнәр Н. Гыйззәтуллин, Х. Курбатов, Б. Мифтахов, Г. Ахунҗанов, В. Хаков, К. Сабиров һәм башкалар газетада әдәбият мәсьәләләренең яктыртылышы, теле турында төпле фикерләр белән чыктылар.

Әдәбиятның өлгергән мәсьәләләрен хәл итүдә иҗат союзларының съездлары, конференцияләре һәм пленумнары, әдәби ел йомгагына багышланган җыелышлар сизелерлек роль уйный. Шул вакыйгаларга хәзерлеккә һәм аларның барышын яктыртуга газета зур игътибар бирә. Андый чакта күренекле язучылар, әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр чыгышлар ясыйлар. Шул рәвешле, җәмәгатьчелекнең игътибары актуаль проблемаларга туплана, аларны хәл итү юллары билгеләнә.

Татарстан язучыларының 1968 елда уздырылган VII съезды алдыннан, мәсәлән, газета-журналларда әдәбиятыбызның бүгенге хәле, аның бурычлары турында зур сөйләшү булды. Шул уңай белән «Социалистик Татарстан» газетасында Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Х. Хәйри, С. Рафиков, Г. Ахунов, А. Әхмәдуллин, Р. Фәйзуллин һәм башкаларның чыгышлары дөнья күрде. Әдәбиятыбызның үсүе, әдипнең халык, партия, чор алдындагы җаваплылыгы, яшь көчләр тәрбияләү, әдәби осталык турындагы бу чыгышлар язучыларның үзләренә дә, әдәбиятның үсешенә дә нәтиҗәле йогынты ясады.

Татарстанда әдәби ел йомгакларына багышлап фикер алышу уздыру кебек матур традиция күптән яши. Вакытлы матбугат әлеге җыелышларда әйтелгән фикерләрне киң катлау укучыларга җиткерә, язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең фикерләре белән киң җәмәгатьчелекне таныштыра. Язучылар союзының басма органы — «Казан утлары» журналы эшчәнлеге дә системалы төстә тикшерелә. «Социалистик Татарстан» мондый мөмкинлекләрне дә игътибардан читтә калдырмый.

Әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең иҗат активлыгын күтәрүдә Г. Тукай исемендәге республика һәм М. Җәлил исемендәге комсомол премияләре булдыру зур әһәмияткә

ия. Газета бу премияләргә тәкъдим ителгән әсәрләрне пропагандалау, алар хакында җәмәгатьчелек фикере туплау буенча шактый эш башкара.

Әдәбиятның актуаль мәсьәләләре тирәсенә җәмәгатьчелек фикерен туплау, шул проблемаларны чишү юлларын билгеләү максаты белән «Социалистик Татарстан» үз битләрендә иҗади дискуссияләр оештыра.

1961 елда газета хәзерге заман татар драматургиясе һәм театр сәнгатенең торышы турында дискуссия үткәрде. Бу сөйләшүне «Драматург һәм режиссер» исемле мәкаләсе белән Г. Кашшаф башлап җибәрде. Аннары И. Нуруллин, Х. Кумысников, М. Әмир, Х. Вахит, Н. Дәүли, М. Гәйнуллин, Х. Уразиков, Г. Ильясов һәм башка язучылар, драматурглар, театр тәнкыйтьчеләре, әдәбият белгечләре чыгыш ясадылар.

Шул ук елның азагында хәзерге проза турында дискуссия башланды. Аны Ибраһим Гази «Чикләвекләребез төшле булсын» дигән мәкаләсе белән ачып җибәрде. Дискуссиядә Ә. Еники, И. Нуруллин, Р. Мостафин һ. б. әдипләр катнашты. Бу чыгышларда бүгенге прозабызның торышы, үсеш перспективалары, яңа кеше тәрбияләүдәге уңыш һәм кимчелекләр ачыклыртылды.

Татар поэзиясендә Г. Тукай һәм М. Җәлил традицияләренә багышланган сөйләшүне башлар алдыннан редакция, Язучылар союзы идарәсе белән берлектә, бер төркем әдәбият эшлеклеләрен җыеп киңәшмә уздырды. Анда танылган шагыйрьләр, прозаиклар, тәнкыйтьчеләр иҗади сөйләшүнең максатын, юнәлешен, тематикасын, авторлар даирәсен билгеләделәр. Шуннан соң дискуссиянең махсус планы төзелде, авторларга заказлар бирелде.

1965 елның 26 сентябрь санында газета «Тукай, Җәлил традицияләре һәм хәзерге татар поэзиясе» дигән темага сөйләшү башлап җибәрде. Ул тәнкыйтьче Флүн Мусинның «Аларга турылыклымы без?» дигән мәкаләсе белән ачылды. «Тукай иҗаты йөзендә поэзиядә критик реализм иң югары үсешкә ирешсә, Җәлил иҗаты социалистик реализм методының җиңүле адымын чагылдырды», дип язды автор һәм бүгенге шагыйрьләрнең бу традицияне ничек дәвам иттерүләре турында сөйләде. Мәкалә азагында редакциядән: «Әдәбият корифейларыбызның традицияләре шагыйрьләребез тарафыннан ничек үстерелә һәм баетыла, бу юлда нинди уңышларыбыз һәм кимчелекләребез бар? Хәзерге поэзиябездә сезне нинди мәсьәләләр борчый һәм дулкынландыра? Тәнкыйтьчеләрдән, шагыйрьләрдән, язучылардан һәм әдәбият сөючеләрдән әнә шул хакта проблемалар куелган мәкаләләр көтәбез...» дип мөрәҗәгать ителгән иде.

Елдан артык дәвам иткән бу сөйләшүдә күп кенә тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләр катнашты.

Фикер уртаклашуларның барышы редакция «летучкалары»нда, редакцион коллегия, Язучылар союзының тәнкыйтьчеләр секциясе утырышларында тикшерелеп торды. Ахырдан редакция һәм Язучылар союзы идарәсе әдәби җәмәгатьчелекнең зур җыелышын уздырдылар. Газета, иҗади дискуссиягә йомгак рәвешендә, филология фәннәре кандидаты Н. Юзеевның «Традицияләр дәвам итә, байый һәм яңара» исемле зур мәкаләсен урнаштырды. Шулай фикерләшүләр әдәби хәрәкәтне җанландыруда, әдәби фикерне үстерүдә, аеруча матбугатка язучыларны, әдәбият белгечләрен тартуда мөһим роль уйнады.

Газетада урын алган рецензияләр, китап күзәтүләр, әдәбият мәсьәләләренә караган мәкаләләр, дискуссия материаллары һәр язучының эшчәнлегенә дә, тулаем алганда әдәби хәрәкәтнең бөтен үсешенә дә йогынты ясый. «Безнең махсус әдәбият һәм сәнгать газетабыз юк,— дип яза күренекле язучыбыз Г. Әпсәләмов.— Әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез исә, мәгълүм булганча, зур, бай, тарихы ераклардан килә. Менә шул әдәбиятны, шул сәнгатьне «Социалистик Татарстан» илле ел буена һаман игътибар үзәгендә тотып килде... Иң авыр чакларда да аңа үзенең битләрендә урын бирде, язучылар анда кадерле кунак булдылар. Хәер, кунак дип дөрес әйтми торганмындыр, язучылар газетаның аерылмас эшчеләре, материал кирәк булса, алар төн йокламый язалар».

«Социалистик Татарстан»да бик күп язучылар катнаша. Шулар арасыннан күптәнге әдәби хезмәткәребез Фатих Хөсни аерылып тора. Аңа газетада эшләү тормыш белән бергә атларга, совет кешеләренең уй-хисләрен тирәнтен өйрәнергә ярдәм

итте. Аның публицистик чыгышлары, хикәяләре, рецензияләре, репликалары укучыларда һәр вакыт олы кызыксыну уята, борчыларга яки шатланырга мәҗбүр итә. Ф. Хәсни газетада озак еллар эшләү үзенең әдип булып үсүенә ярдәм иткәнен рухланып искә ала. Газетаның 60 еллыгы алдыннан «Истә калган кайбер сәхифәләр» дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: «Җыеп алганда, мин вакытлы матбугатта — журнал һәм газета редакцияләрендә барлыгы егерме биш ел эшләдем. Шуның егерме елы «Кызыл Татарстан», хәзерге «Социалистик Татарстан» редакциясендә. Вазифам ягыннан гел бер дәрәҗәдә — үсмәдем дә, кечерәймәдем дә, гел әдәби сотрудник. Бу хезмәт миңа бик күп нәрсә бирде. Әгәр мин, язучы буларак, игътибарга лаеклы кайбер әсәрләр тудырган икәнмен һәм яшем 70 кә җиткәнче чишмәнең әлегә корыганы юк икән, моның нигезендә, башлыча, ике чыганак ята: беренчедән, яшем уналтыга җиткәнче гел авылда, халык арасында, табигать кочагында эш белән кайнап үсүем. Икенчедән, озак еллар буена газетада эшләвем. Әйтәсе дә юк, газетада, бигрәк тә әдәби сотрудник булып эшләү уен түгел ул. Анда син гел тормыш материалы, фактлар дөньясында гизәсең. Редакция бүлмәләрендә утырып эшләгәндә дә, кулыңа блокнот тотып авылдан-авылга, районнан-районга чапканда да...»

Газета Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм штыгы белән дә, каләме белән дә фашизмга каршы кыю көрәшкән әдипләрнең иҗатына, алар турындагы яңа материалларга һаман саен зур урын бирә. Язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның «Моабит дәфтәренең сере» дигән мәкаләсе газета укучыларыбызда зур кызыксыну уятты. Автор бу мәкаләсендә М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» туган илгә ничек, нинди юллар белән кайтканын күрсәтә.

М. Җәлилнең «Бәрәңге турында» дигән поэма-кульъязмасы архивта табылып, беренче тапкыр шулай ук «Социалистик Татарстан»да басылды.

Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрь һәм журналист Рәхим Саттарга багышлап газета махсус сәхифә бирде. Сәхифә Рәхим Саттарның:

**һәр сулышым, барлык көчем,**
**Синең өчен, Туган илем, синең өчен!**

дигән шигъри юллары белән ачыла.

Бирелә Барлас Камаловның «Җәлилче батыр», Рафаэль Мостафинның «Президент» доносы» дигән мәкаләләре, шагыйрьнең яшьләр газетасында эшләгән елларда төшкән фоторәсеме басылды. «Тоткынлыкта» дип исемләнгән кульъязма җыентыгының бер бите бирелде.

Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең 70 еллык юбилее алдыннан махсус рубрика белән газетада бик күп материаллар басылды. 1976 елның 12 февралендә махсус сәхифә бирелде. Ул Р. Мостафинның «Утта чыныккан яшьлек» мәкаләсе белән ачыла. «Халык иҗатына тугрылык», «Фикер чишмәсе» исемле мәкаләләре белән Илбарис Надиров, Нәгыйм Ибраһимов, филология фәннәре докторы Вахит Хаков чыгыш ясый. Нәби Дәүли «Берлинда окоп» дигән шигырен бастыра. Ә М. Җәлилгә 70 ел тулган көнне, 1976 елның 13 февралендә, «Социалистик Татарстан»ның махсус саны чыкты. Ул КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеевның «Батырлыкка әверелгән гомер» исемле мәкаләсе белән ачылды. «Моннан 70 ел элек, — дип язды Ф. Ә. Табеев, — атаклы совет шагыйре, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тормыш юлы башланды. «Моабит дәфтәрләре» авторының каһарман язмышы хәзер бөтен дөньяга билгеле. Аның исеме ныклык, кыюлык символына, батырлыгы халыкка, партиягә, социалистик Ватаныбызга фидакарь хезмәт итүнең якты үрнәгенә әверелде. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежнев совет кешесенең сынмас ихтыяры һәм ныклыгы символы булган Бөек Ватан сугышы геройлары арасында шагыйрь Муса Җәлил исемен дә атады».

Махсус санда шулай ук Михаил Луконин, башкорт шагыйре Гыйлемдар Рамазанов, Сибгат Хәким, Роберт Бикмөхәммәтов, музыка белгече Клара Таҗиева һ. б. чыгыш ясады.

14 март, 1976 ел. Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булу уңае белән әдәби сәхифә дөнья күрде.

Газета әдәби мирасны пропагандалауга зур әһәмият бирә. 1976 елның 2 май санында Г. Тукайның 90 еллык юбилее уңае белән чыккан «Мәңгелек мирас» дигән мәкалә — шуның бер дәлиле. Мәкалә авторы — Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре Ш. Абилов халык шагыйре Г. Тукай иҗатын башка халыклар әдәбиятына нисбәтән анализлый, аның интернациональ рухлы шагыйрь булуын дәлилли.

КПСС Үзәк Комитетының 1972 ел башындагы «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карарыннан соң редакция шулай ук шактый эш башкарды һәм башкара. Күренекле әдипләрне «Түгәрәк өстәл» янына җыеп, әдәби тәнкыйтьнең актуаль проблемалары турында махсус сөйләшү уздырылды. Анда катнашучылар республикабыз әдәби хәрәкәтендә тәнкыйтьнең торышына анализ ясадылар, аның методологиясен һәм теориясен үстерү, теоретик һәм идея-эстетик тирәнлегенә ирешү юллары турында фикер алыштылар. Соңыннан бу сөйләшү газета сәхифәсендә урын алды һәм күтәрелгән проблемалар хакында «Әдәбият-сәнгать хәрәкәтенең алгы сызыгына» дигән рубрика белән фикер алышу үткәрелде. Ике елдан соң газета, бу мәсьәләләргә яңадан кайтып, аларның ничек хәл ителүен күрсәтте.

Аерым әдипләр иҗатына анализ ясалган мәкаләләр, яңа чыккан китапларга рецензияләр бирү газетада системалы рәвештә алып барыла. Мәсәлән, М. Горький исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе һәм Г. Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким иҗатын анализлаган «Шагыйрь дөньясы» исемле мәкаләне күрсәтергә мөмкин. Мәкаләнең авторы Әхсән Баянов өлкән каләмдәшенең Татарстан китап нәшриятында басылган бер томлыгына анализ ясый, бу китапның «татар совет культурасы хәтерендә аның үсеш дәрәҗәсен күрсәтә торган вакыйга булып калачагы» турында яза.

Әдәбият-сәнгатебез үзе туктаусыз үсештә булган кебек, бу үсешне яктырту формалары да хәрәкәттә. Культураның совет кешеләрен коммунистик тәрбияләүдәге роле үсә һәм аның совет кешеләре тормышына, аларның иҗади хезмәтенә тәэсире көчәя бара. Әдәбият-сәнгать белән производство арасындагы бәйләнеш ныгый. Шуның ачык мисалы буларак, газетада әдәбият-сәнгать әһелләренең үзара һәм производство алдынгылары белән «Түгәрәк өстәл» янында әңгәмә, бәхәс, диспут рәвешендәге очрашуларын күрсәтеп үтәсе килә. Биредә җитди проблемалар хакында эшлекле, иҗади сөйләшүләр була һәм алар газета битләрендә урын ала.

Чаллы һәм автозавод комплексы төзелә башлауга ук газета «Илһамыбыз — КамАЗ төзелешенә» дигән рубрика ачып җибәрде. Бу рубрика астында язучылар, художниклар, композиторлар иң яхшы әсәрләре белән катнаштылар, КамАЗ төзүче батырларга йөрәктән чыккан кайнар сүзләрен әйттеләр. Г. Бәширов, Н. Җиһанов, Г. Әпсәләмов, Г. Минский, А. Шамов, Х. Туфан һәм башка бик күпләр газета битләрендә чыгыш ясады. Матбугат органнары, «Социалистик Татарстан», идеология учреждениеләре һәм оешмалары КамАЗ төзелешенә шефлык эшен җәелдерделәр, ул газета битләрендә киң яктыртылды. Редакция заказы буенча Чаллыда урта һәм яшь буын язучылар иҗади командировкада булдылар. Нәтиҗәдә, газета битләре кызыклы очерклар, шигъри репортажлар белән баеды.

«Иҗат оешмалары — автозавод төзелешенә» дигән махсус сәхифә игътибарга лаеклы. Анда иҗат союзлары җитәкчеләре З. Нури, Х. Якупов белән әңгәмәләрдә язучылар, рәссамнар алдында торган бурычлар турында сөйләнә. Газета мондый сәхифә һәм подборкаларны ай, квартал саен биреп бара.

Республика язучылары, композиторлары, художниклары КамАЗ төзүчеләрнең образларын роман, очеркларда, повестьларда, полотноларда иҗат итteләр. Укучылар М. Хәсәнов, Г. Минский, мәрхүм С. Рафиков, Ә. Баян, Э. Касыймов, Б. Камалов, М. Хәбибуллин әсәрләреннән өзекләр белән таныштылар, рәссамнарның иҗатын карап бара алдылар. 1971 һәм 1974 нче елларда КПСС өлкә комитетының культура бүлеге җитәкчелегендә республиканың әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре КамАЗда булдылар. Эшчеләр, төзүчеләр белән мондый очрашулар турында махсус сәхифәләр чыкты.

Шулай итеп, Татарстан җирендә, Яр Чаллы шәһәрендә илебезнең иң бөек гигантларыннан берсе — автомобиль заводы төзелә башлау, аңа шефлык итү газетабыз

битләрендә Камада хезмәт батырлыгын мактаган, данлаган публицистиканы, вакытлы матбугат жанрларын активлаштырды, әдипләрне тормышка, производствога, әдәби әсәрләр геройларына бик нык якынлаштырды. Партиянең XXV съезды трибунасыннан КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев Совет иленең барлык коллективларына, безнең сугышчан партия матбугатына, радио һәм телевидениегә бу куәтле индустриаль комплексны төзүдә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ихлас күңелдән рәхмәт әйтте. («Правда» газетасы, 29 февраль, 1976 ел.)

Әдәбиятның һәм сәнгатьнең яңа алмашы мәсьәләсе — яшьләр иҗаты соңгы елларда газетада киң чагылыш тапты. 1973 елның октябрендә КПСС өлкә комитеты республикабыз яшь иҗат көчләренә багышлап берләштерелгән пленум үткәрде. Пленумга әзерлек барганда газетабызда әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең проблемалы мәкаләләре бирелеп барылды. Пленум ачылган көндә махсус номер чыкты.

1976 елның 21 октябрендә газетабызда КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карары басылды. Шул нигездә КПСС өлкә комитеты да 1976 елның ноябрендә махсус карар кабул итте. Анда республикабыз яшь иҗат көчләренең сан һәм сыйфат ягыннан үсә баруы әйтелә. Яшьләр Татарстанда хәзер художество интеллигенциясенең өчтән бер өлешен тәшкил итә. Аларның шактые рухи байлыклар тудыруда инде актив катнашалар.

Яшьләр — «Социалистик Татарстан»ның да хөрмәтле авторлары. Атна саен чыгып килә торган әдәбият-сәнгать сәхифәләрендә яшьләр иҗатына, аларның иҗатын тикшерүгә багышланган мәкаләләргә зур урын бирелә. И. Низамов, З. Насыйбуллин, М. Газизов, Р. Вәлиев, С. Шәрипова, К. Сибгатуллин, Ә. Гаффаров, Л. Хәйретдинова кебек яшь авторларның беренче әсәрләре безнең газетада басылды. Болар — соңгы берничә елдагы кайбер исемнәр генә.

Соңгы вакытларда гына И. Юзеевның яшь талантлар турында кайгыртып язылган «Әдәбиятның киләчәге» дигән мәкаләсе һәм Чаллы, һәм Әлмәт яшь иҗат көчләре әсәрләреннән торган сәхифә укучыларда кызыксыну уятты.

Зур төзелеш барган урыннарда әдәби берләшмәләр, түгәрәкләр эшли. Язучыларның Әлмәт бүлеге, Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск әдәби берләшмәләрендәге яшь талантларның әсәрләре даими күренгәләп тора. Алар газетага шул яклардагы хезмәт сулышын алып киләләр. «Яшьләр иҗаты» дигән рубрика берничә еллар газетабыз сәхифәләрен бизәп килә. «Аның беренче китабы» дигән рубрика кызыклы алып барылган иде. Аны киләчәктә тагын да җанландырасы бар. Соңгы вакытларда «Яшь талантларга — кайгыртучанлык, таләпчәнлек», «Иҗат җимешләре» кебек рубрикалар активлашты. Беренче рубрика белән проблемалы материаллар бирелсә, икенчесендә яшь артистлар, художниклар, композиторлар турында, аларның иҗаты хакында сөйләнә.

Яшь иҗат көчләренең яңа китапларын, әсәрләрен аксакаллардан, өлкәнрәк язучылардан рецензияләтеп газета дөрес эшли дип уйлыйбыз. Соңгы елларда унлап шундый кызыклы мәкалә дөнья күрде. Г. Әпсәләмовның «Мин уйланам», М. Әмирнең «Карап-карап торам да» кебек мәкаләләре әдәби җәмәгатьчелектә кызыксыну уятты.

Бөек Октябрьның 60 еллыгы, һәр өлкәдәге кебек, газета эшчәнлегендә, аерым алганда әдәбият-сәнгать тормышын яктыртуда үз төсмерен тапты, моңа үзенең ачык буяуларын салды. 1977 елның башыннан бирле әдәбият-сәнгать сәхифәләрендәге материаллар юбилейга багышланды. «Октябрь тудырган культура» дигән махсус сан чыгарылды.

Газета редакциясе коммунизм идеалларына бирелгән, бай рухлы замандашыбыз турындагы очеркларга, публицистик мәкаләләргә ачык конкурс игълан итте. «Безнең заман кешесе» рубрикасы белән барган бу конкурста йөздән артык язучы, журналист, хәбәрче катнашты. Очерк геройлары — төрле һөнәр ияләре, төрле характердагы кешеләр, әмма барысын да революцион рух, коммунизм идеалларына, героик традицияләргә тугрылылык берләштерә.

Газетада Октябрь темасын яктыртуның тагын бер кызыклы формасы файдаланылды. «Иҗатымда — Октябрь» рубрикасында күренекле әдипләребез, артистларыбыз һәм башка сәнгать кешеләре чыгыш ясады. СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров, язучы һәм драматург Риза Ишморат, Мөхәммәт Садри, Госман Бакир, Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир чыгышларын газета укучыларыбыз яратып кабул итте.

Утызынчы еллар дәвамында «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә эшләгән Әхмәт Исхак, шагыйрь һәм журналист буларак, беренче чыныгуны шушында алды. Редакциядә эшләү аңа бик әйбәт тормыш мәктәбе, политик чыныгу мәктәбе булды. «Социалистик Татарстан»ның 1977 ел, 30 октябрь санында «Давыллы чор буйлап» исемле мәкаләсендә Әхмәт Исхак горурланып болай ди: «Күбрәк мин Ленин, Октябрь, гражданнар сугышы, комсомол-яшьләрнең фидакарь эшләре темаларын эченә алган публицистик шигырьләр яздым».

Әхмәт Исхак, Бөек Ватан сугышыннан соң «Кызыл Татарстан»да эшләгән шагыйрь Нури Арсланов белән бергә, Совет Социалистик Республикалар Союзы Дәүләт Гимнын татар теленә тәрҗемә иттеләр. «Социалистик Татарстан» редакциясе коллективы алар белән хаклы рәвештә горурлана. «һәм, ниһаять, миңа гомерлек җан азыгы биргән һәм иҗатымда чикләнмәгән юллар ачкан Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллык тарихи юбилеена якынлашкан һәм дөньяда иң демократик яңа Конституция проектын бөтен халык дәртләнеп өйрәнгән һәм тикшергән соңгы көннәрдә якын дустым шагыйрь Нури Арсланов белән бергәләп, Совет Социалистик Республикалар Союзының Дәүләт Гимнын ана телебезгә тәрҗемә итү бәхетенә ирештем»,— дип язды Ә. Исхак.

Шунысы куанычлы, әдәбият эшлекләләре газетаның әдәбият-сәнгатьне үстерүгә керткән хезмәтен таныйлар, аңа рәхмәт әйтәләр. Филология фәннәре докторы, элек редакциядә эшләгән тәнкыйтьче Хәмит Ярми газетаны «күптәнге тәрбиячем» дип бәяли. «Кызыл Татарстан»да эшләгән Гомәр Бәширов: «Миңа күп вакытны авылда уздырырга, очерк һәм мәкаләләр язу өчен үз вакытының алдынгы кешеләре белән эш итәргә, аларның хезмәтендәге һәм тормышларындагы яңа сыйфатларны күрә һәм яза белергә, авыл хуҗалыгы күмәкләшү уңае белән килеп туган зур тарихи үзгәрешләрнең уртасында кайнарга туры килде, соңыннан, язучы булып киткәч, әдәби әсәрләр язганда болар миңа бик кирәк булып чыктылар. Газетада эшләү мине күп нәрсәгә өйрәтте, гомергә онытылмастай кадерле истәлек булып калды», — ди.

«Социалистик Татарстан» битләрендә әдәбият һәм сәнгать проблемаларына игътибарның шактый зур булуын тугандаш республикаларның язучылары да билгеләп үтәләр. Казакъ язучысы, академик, 1920 елдан КПСС члены Сабит Мукановның газетабыз исеменә язган бер хатында менә шундый юллар бар: «Мин үземне татар вакытлы матбугатының, шул исәптән «Социалистик Татарстан» газетасының тарихы белән таныш кешеләрнең берсе дип саныйм. Мин аларны даими диярлек укып бардым һәм алардан үземә күп кенә файдалы нәрсәләр алдым... «Социалистик Татарстан» татар культурасы, бигрәк тә матур әдәбият тарихын өйрәнү белән яхшы шөгыльләнә. Моны — Габдулла Тукайның һәм Галимҗан Ибраһимовның 80 еллык юбилейларына багышланган саннары ачык күрсәтә. Алар икесе дә минем онытылмас остазларым. Аларның тормышын һәм эшчәнлеген дөрес яктырткан өчен «Социалистик Татарстан» газетасына чиксез рәхмәт» [1].

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте әдәбият-сәнгать, культура казанышларыннан һәр совет кешесенең файдалануы турында өзлексез кайгырталар. Бу хокук СССР Конституциясендә беркетелгән, аның 46 һәм 47 статьяларында: «Ватан һәм дөнья культурасы хәзинәләреннән һәркемнең файдалана алуы белән, культура-агарту учреждениеләрен үстерү һәм ил территориясендә тигез урнаштыру белән, телевидение һәм радионы, китап чыгару эшен һәм вакытлы матбугатны, түләүсез китапханәләр челтәрен үстерү, чит ил дәүләтләре белән культура алмашуын киңәйтү...», «әдәбият һәм сәнгатьне үстерү белән тәэмин ителә», — диелгән. Партиябезнең, дәүләтебезнең культура мәсьәләләренә мондый олы игътибары иҗат интеллигенциясен яңа уңышларга рухландыра.

1977 елның 19 октябрендә Мәскәүдә Зур Кремль сараенда иҗат союзлары идарәләренең берләштерелгән пленумы булды. Ул Бөек Октябрь социалистик револю-

[1] «Социалистик Татарстан», 4 апрель, 1968 ел.

циясенең 60 еллыгына багышланган иде. Анда танылган язучылар, кинематографистлар, художниклар, театр эшлеклеләре, композиторлар, архитекторлар, журналистлар, партия работниклары катнашты. Татарстаннан да иҗат союзлары вәкилләре, әдәбият, сәнгать, журналистика эшлеклеләре Г. Ахунов, Н. Җиһанов, Р. Җиһаншина, Х. Якупов, Ш. Хамматов, М. Яруллин, А. Монасыйпов, Е. Лисин һәм башкалар булды. Без, ул тантаналы җыелышта катнашучылар, Ватаныбызга, Коммунистлар партиясенә йөрәкләребез партия, халык белән бергә тибә дип белдердек. Берләштерелгән пленум исеменнән КПСС Үзәк Комитетына хат кабул ителде. Анда Коммунистлар партиясенә мәхәббәт бөркеп торган шундый юллар бар: «Партия иҗат интеллигенциясенә күрсәтә торган зур ышаныч безне — язучылар һәм композиторларны, журналистлар һәм архитекторларны, художниклар, кинематографистлар, театр эшлеклеләрен — бөек коммунизм эшенә тагын да максатчанрак, фидакарьрәк хезмәт итәргә рухландыра.

Безнең берләшкән пленумыбыз юбилейга хәзерлек һәм яңа Конституцияне кабул итү нәтиҗәсендә туган илһам һәм күтәренкелек шартларында үтте. Совет иҗат интеллигенциясе, халыктан аерылгысыз буларак, һәр вакыт Бөек Октябрь байрагына турылыклы булды, һәр вакыт Ленин партиясе белән бергә барды. Күп милләтле әдәбият һәм сәнгатьнең 60 ел эчендә төрле буын осталары тудырган иң яхшы әсәрләре халкыбызның рухи тормышына аерылмас өлеш булып керде»[1].

Бөек Октябрь кояшы астында үзенең 60 ел дәверендә «Социалистик Татарстан», илебезнең барлык матбугаты кебек, олы, данлы юл үтте. Аның партиябез җитәкчелегендә әдәбиятыбыз, сәнгатебез, культурабыз үсешенә керткән өлеше чорыбызның онытылмас елъязмасы булып калыр. Үз гомерендә алты төрле исем белән чыккан бу газета һәр вакыт тормыш, халык белән бергә атлады һәм атлый, партиябез, Ленин, Октябрь идеяләренә тугрылыклы булып кала, хезмәт ияләрен яңа җиңүләргә өнди яши.

[1] «Литературная газета», 26 октябрь, 1977 ел.

## Клара Булатова

### Яз, газиз углым...

УКЫТУЧЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Яз, газиз углым, кара тактаңны сыз
акбур белән.

Г. Тукай.

Яз, газиз углым, кара
Тактаңны сыз акбур белән,
Әмма, зинһар, кагыла күрмә
Журналларга бу кул белән.

Кай арада өлгердең соң
Буялырга ал-зәңгәргә?
Ник тиясең минем дәфтәр
Карый торган каләмнәргә?

Китапларга ник тиясең,
Дәфтәрләрне ник аласың?
Бер апаңның диктантына
Әкәм-төкәм ясагансың.

Аңа ни дип аңлатыйм мин
Бу сурәтнең чыганагын?
Дәрестә бит сөйләп булмый
Балаңның тик тормаганын...

Мә үзеңнең дәфтәреңне,
Теге якка, әнә, кер дә
Яз, газиз углым, әмма тик
Бу өстәлгә тия күрмә!

Укучылар дәфтәренә
Кагылма син, тыңла әле:
Бар, газиз углым, булмаса
Бабаң белән уйна әле.

...Яз, газиз углым, тик мена
Бу тирэдэн кит эле син.
Аңламыйсың, и нэнием,
Бик бэлэкэй бит эле син.

Бераз үскэч, аңлый төшкэч,
Тыңларсың бит гел сүземне?
Кил эле, улым, «үчти-үчти»
Итим эле бер үзеңне!

Кил эле, улым!

●

«Хэллэрең ничек?» — дидең син,
Чын күңелдэн сорадың.
«Әйбэт!» — дидем, чын дөресен
Сөйлэмэдем, чыдадым.

«Хэллэрең ничек?» — дидең син,
Белэсең дэ килгэндер.
Минем хэлне белим дисэң,
Кара чыклы гөлгэ бер.

Минем хэлне кем дэ эйтмэс,
Җил дэ эйтмэс, гөл эйтер.
Гөл дэ эйтмэс... тик үзенең
Яшьле таҗын күрсэтер.

## Нәҗип Мадьяров

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

•

Давыл белән ярсып килгән болыт
Күгебезгә килеп кунаклады.
Яшеннәрнең утлы кылычыннан
Төн пәрдәсе меңгә туракланды.

Игеннәрем исән калды микән?..
Хәвеф-хәтәр инде ераккланды.
Таң атканчы дәвам итәр, ахры,
Йөрәгемдә яшен уйнаклавы.

•

Тагын йөрим менә кыш илендә,
Тагын калды бер көз артымда.
Сизә йөрәк, инде ерак түгел —
Өр-яңа яз балкый каршымда.

Елмая ул чәчәкләре белән
Кар-буранлы айлар аркылы.
Уйда йөзгән күңелләрне кайчак
Җылыта шулай кышның салкыны.

•

Үткәннәргә карыйм, үткәннәргә,
Көенеп түгел, сөенә-сөенә.
Сикәлтәләр аша үтелгән юл
Хәзер тигез булып күренә.

Иң хозуры, ахры, шунысыдыр:
Уйчанланып, бераз моңаеп,
Сугыш елларының азагында
Безнең яшьлек тора елмаеп.

●

Очраттым мин киң тормышны
Гел тәр итеп аңлаучыны;
Кеп-кечкенә моң-зарны да
Таудай итеп шаулаучыны.

Һәм юлыктым зары булып
Зарланмаучы кешеләргә;
Кешелекне күбрәк күрә
Алдым аның ишеләрдә.

●

Горизонттан кояш
Сүрән генә көлә.
Каеннарга январь
Ак челтәрләр элә.

Күрәсеңме, алар
Ничек матурайган!
Бар да солдатлардай
Киенгәннәр пардан.

Карап туйгысыз бит
Бу мәңгелек мода!
Әйтерсең лә кышның
Күргәзмәсе монда.

●

Өр-яңа моңы тургайның
Түгелә өстән аска.
Тирбәлә алмас кебек кыр
Нигәдер шуннан башка.

Шушы җир, әйе, шушы җир
Хисләрне алды биләп.
Йөгерә аяз уйларым
Башаклар илен иңләп.

●

Балкый Идел июнь кояшына
Якты йөзен куеп.
Акчарлаклар оча дулкын җилен
Уеп-уеп-уеп.

Хисләремне дулкыннарга кушып
Мин дә торам ярда.
Алда — Идел. Агылып керә аның
Сулмас яме җанга.

●

Балкый чәчәк күз яуларың алып,
Хуш ис бөркеп бөтен тирәгә.
Итәгендә үскән үләннәргә
Аннан да бит төшә күләгә.

●

Алмалары коелып бетте көзнең,
Ә миләшләр әле шул килеш.
Ерагайган кояш нуры белән
Янып тора алар туң килеш.

Шау алмалы җәйге иртәләрдә
Сокланмадык никтер аларга.
Ә хәзер күр: ничек матур балкый
Ут тәлгәшләр эленеп таңнарга!

●

Тиргә, орыш, кисәт яки
Каты шелтә бир аңа,
Иммунитеты көчәйде,
Берсен дә сукмый санга.

●

Астан өскә генә карый
Кеше башта.
«Күтәрсәләр» — киресенчә:
Өстән аска.

●

Каргаларны әләкләргә баргач,
Әйтеп калды тик өч сүз генә:
Кереп китте бөркет авызына
Әләге дә, чыпчык үзе дә.

●

Явыз уйлар тулган күңелдә шәп
Фикер ничек тусын?!
Ташлык җирдәй ич ул. Андый төштә
Иген ничек уңсын!

●

«Үсәләр бит кояш астында,
Ни кызык бар инде аларга!» —
Аландагы чәчәкләрне күргәч,
Шулай дигән, имеш, абага.

## Флера Гыйззәтуллина

•

Болыннарда атлар утлый,
Атлылар дөнья гизә.
Чытыр арбага төялеп
Авылдан киттек без дә.

Киттек. Белдек:
Күрәчәкләр
Киләчәккә юл ача...
Җил исте, тегермән тартты,
Зыр-зыр килде куласа.
— Дөнья ул куласа,— диләр
Көчсезләр, юл уңмаса...
Без әле: «Тормыш авыр»,— дип,
Зарланмадык моңача.

Як-якка таралышсак та,
Калмадык юлда туктап.
Чорларга сыртлап төйисе
Шатлыкларыбыз уртак.

•

Ничә җиңсә тузды беләгемдә,
Бу кырларны ничә урадым.
Әнкәемнән мирас — ай урагым:
Бодай чәчтем, бодай урамын.

Әткәемнән мирас — таң җилләре
Җиңсәләрдән күчә җиңнәргә...
Өйрәндек без яшьли саф алтынга
Көннең һәр минутын тиңнәргә.

Өйрәндек без чәчү орлыкларын
Күз нурыдай күреп сакларга.
Булды газиз туган туфрагымны
Дошман таптап йөргән чаклар да!

Булды, бөртекләрне бөртекләдек,
Теләп көзен икмәк уңганын...
Заман рухы миндә, үз илемдә
Эшсезлекне белмәс кулларым.

Һәм һичкайчан үз кыйммәтен җуймас
Кырда үзләштергән һөнәрем.
Ризыкларым буйларыма сеңгән,
Күкрәгемдә көчем-егәрем.

## Кырларда ай нуры...

Кырларда ай нуры. Сагышын, шатлыгын
Ал җаның теләгән кадәрле.
Кыш туган җырымны әткәйгә багышлыйм:
Кыш килде кайгылы хәбәре...

Җәй туган җырымны әнкәйгә багышлыйм:
Әнкәем җәй аен яраткан...
Җәйләрдә төн кыска: көлтәдән куышта
Күземне йомганчы таң аткан.

Яз туган җырларым — гөлчәчәк бәйләме —
Әткәйгә, әнкәйгә тигездән!
Җырларым тынмаса, мин алар исеменә
Мәңге дә кара тап тигезмәм.

## Тегү җыры

Энә тотсам, ишетелә шигырь көне...
Каләм тотсам, ишетелә тегү көне.
Шигыремне күңелемә ятлап алдым,
Келтер-келтер көйгә салдым тегүемне.

Асыл кием, асыл шигырь кирәк булса,
Рәхим итсен кыз-киленчәк, егет-җилән!
Ярәшелгән сылу кызга парча-бизәк! —
Түшләренә чәчәк чигәм, мәрҗән сибәм.

Һай, якасы! Әллә күктән ай төшкәнме?
Җиңнәр җилдә җилфер-җилфер очар гына.
Ак күлмәге керләнгәнче, кияү егет,
Фәрештәңне күтәреп ал кочагыңа.

●

Түгел лә мин бөек чор өстеннән
Коштай очар егет...
Ә шулай да җырлар канатында
Чорлар кочам кебек.

Түгел лә мин
Чукмар йодрыклы,
Хәр холыклы ир-ат...
Ә шулай да сер сынатканым юк
Җиңел хезмәт сорап.

**Нәбирә Гыйматдинова**

*Һаман эзлим... Тик әдәбиятта барып туктарлык нокта, урталык юк икән. Урталык — һәлакәт. Туган җирем — республикабызның Аксубай районы, Карасу авылы. Мәктәптән соң Иваново шәһәрендә тукучы, аннан соң Казанда торак йортлар төзелешендә буяучы булып эшләдем.*

*Хәзер университетның тарих-филология факультетында укыйм.*

# СУ ХИКӘЯТЕ

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

ХИКӘЯ

— Кайчан кавышырбыз соң, Айнан?
— Йөзүдән кайткач, тагын алты ай, Рәфинә.
— Безне нәрсә аера, Айнан?
— Су, Рәфинә.
— Су? Сумы?!
— Су.



Су! Су-у-у-у!
Мин Идел ярыннан шашып йөгерәм. Күз кабакларым елаудан шешенгән. Карашыма диңгез чалына. Нәкъ пыяла сыман. Тип-тигез. Тып-тын. Каты итеп баса-баса, шул пыяла өстеннән барам. Ул күтәралмый, сына, ватыла ишелә...

Мине «ашыгыч ярдәм» машинасы белән шәһәр больницасына алып китәләр.

— Су!—дим. Иренемә кайсыдыр су тигезә. Бер хәрәкәт. Сулы стакан чәлперәмә килеп ватыла.

— Су бирмәгез, аңа су ярамый, — ди ак халатлы ир.

Караватымны иңгә кочаклап үксим. Үксүемә кушылып, миңа табан су ага...

— Айнан! Казанкага зур су тулган. Су-у-у!

— Әйдә, Кремльдән карыйбыз. Өстән тагын да матур күренә ул.

— Әйдә, Айнан.

Без ак ныгытмага табан йөгерәбез. Кремль стеналарына басканда мин Айнанга карыйм да:



— Тарих истәлеген таптыйбыз, ярамый бит, — дим.

— Алайса, яр буена төшик, — ди ул, кулы белән ак ташларны сыпырып.

— Күпергә керик!

— Мин — баш имәс кыз — Айнанны үз иркемдә тоткандай кыланам. Ярый, ул килешә. Кирелегем аңа тансык бугай. Бер елдан соң күрештек. Безгә очрашу өчен, берберебезне сөю өчен, сөелер өчен нибары өч көн бирелгән.

Аның беренче көне — Казанка буе. Әнә, күпер астыннан көймә йөзеп үтә. Кыз белән егет. Кара ничек утыралар. Күз карашлары бер-берсендә. Ә минем Айнаным янәшәмдә. Мин аның җылысын тоям. Ул җилкәмнән коча да, киң су өстенә карый. Су да зәңгәр, Айнанның күзләре дә.

— Айнан, су гел шулай зәңгәрме?

— Көндезен зәңгәр, кояш баеганда кызгылт.

— Син кайсында йөзәсең?

— Икесендә дә, Рәфинә.

— Синең пароходың да әнә шундый акмы?

Мин дулкыннарга сыенып очкан акчарлакларга ымлыйм.

— Ак, гел ак.

— Диңгез дә Казанка кебек тынычмы?

— Диңгез түгел, океан. Җил-давыл вакытында ул убырлы карчыкка охшый. Дулкын өстендә бии теплоход. Хәтта палубага су тула.

— Су?

— Су, Рәфинә.

... Битләрем, муеннарым манма су. Хәтерем сулымы әллә? Юк, бу күз яшьләрем икән. Кайсыдыр йомшак кулы белән маңгаема кагыла.

— Ач күзеңне.

— Ачалмыйм бит.

— Син ач.

— Ачам.

Сыек яктылык. Инде кич җиткән. Палатаның зур тәрәзәсеннән уч хәтле зур-зур яфраклар карый. Тупыл агачы пыялага сыенган.

— Сары яфраклар кертегез әле, апа.

— Мин апаң түгел, ә синең яшьтәшең, Рәфинә.

— Син кем?

— Шәфкать туташы. Яфраклар дисеңме?

— Әйе, исемеңне дә белмим.

— Асылъяр.

Бераздан Асылъяр баш очыма яфраклар кертеп куя. Борынны кытыклап көз исе аңкый.

— Көзне яратасың, ахрысы, Рәфинә.

Бу йомшак тавышны эзләп башымны күтәрәм.

— Торма, ят, — ди кыз, өстемә ярым иелеп.

Йөзенә әйтерсең учлап-учлап сипкел сипкән Асылъяр мине елма-

ерга мәҗбүр итә. Бигрәк сөйкемле икән үзе. Әллә ул тапларны энә белән кадап чыкканнар микән?

— Асылъяр, сипкелләрең бик матур, әйеме?

— Әй, Рәфинә, түгел шул. Юсаң да бетми. Кислота белән бер яндырырмын әле.

— Бит матурлыгы нәрсә ул, җан матурлыгы кирәк.

Тәрәзә пыялаларында көз күзе — сары яфраклар. Әллә ничә күз. Залдан тамашачылар карый диярсең. Мине күзлиләр кебек сарыкайлар, гөнаһсызлар.

— Синең балаң булыр, Рәфинә...

Ә мәрхәмәтсез җил аларны очыртып җиргә ташламакчы.

— Балаң булыр, Рәфинә.

— Ә? Нәрсә?

— Балаң...

Йөзләгән кырмыска тәнем буйлап үтә. Сары яфраклар, сез дәштегезме моны?

— Рәфинә, шатлык...

— Кемгә шатлык, Асылъяр?

— Синең балаң булу.

— Әтисезме?

Күз кабакларым авыраеп ябылмакчы.

— Күзеңне йомма, — дип ялвара Асылъяр. — Рәфинә, йомма! — Һәм ул инәлеп елый башлый.

— Больницада озак тотарлармы?

Кыз халат җиңе белән күзен сөртә.

— Нервыларың какшаган бит, берәр ай дәваланырсың әле. Курыкма, ялгыз калдырмам. Яныңда мин, гел мин булырмын.

— Рәхмәт, Асылъяр. Ә хәзер ярты гына сәгатькә ялгыз калыйм. Миңа үткәнемә кайтырга кирәк. Анда — Айнан.

— Ул сиңа зарарлы.

— Үтенәм.

Асылъяр аяк очларына гына басып палатадан чыгып китә...

— Айнан.

— Әү, Рәфинәү.

— Ашыкмадыкмы? Мин... Бала....

— Ышанмыйсың. Иртәгә үк язылышабыз, әйдә!

— Ышанам, кадерлем.

— Алайса?

— Я, бу хакта сөйләшмик.

Төн караңгылыгы безне үз кочагына ала. Салкын су җиле исә. Шыбыр-шыбыр иткән Идел камышлары йөрәкне шомландыра.

— Куркам, Айнан.

— Кер куеныма. Күкрәгемә тенә сула.

— Айнан... шул тиклем... яратам бит үзеңне. Бер карауда ошаткан идем. Хәтерлисеңме?

Айнан мине күкрәгенә кысканнан-кыса бара. Тупасланган, яргаланган бармаклары чәчемне аралый. И сихри дә төн инде соң бу, аерылу төне.

— Хәтерлисеңме? Безнең бригадага теплоходта йөзү өчен путевкалар бирелгән иде. Казан — Әстерхан маршруты. Кызларга ияреп мин дә сәяхәткә чыккан идем. Кичләрен палубага матрослар чыга, гармун уйныйлар, бииләр. Без дә аларга кушылабыз. Кинәт каршыма берсе килә.

— Биикме, сылу? — ди.

— Кирәкми, кирәкми, — дим. Егет яндырып иренемнән үбә.

— Тиңсезем, — ди ул колагыма пышылдап. — Мәхәббәтем.

— Я, үзем дәвам итәм, — дип кушыла Айнан. — Күрәм, кыз оя-

ла, тартына, күзләрен яшерә. Кайдан сез дигәч, төзелештән, буяучы ди. Ә куллары йоп-йомшак, разве төзүче кулы нәфис була инде, әкәмәт, дип уйлыйм.

— Арттырма, лыгырдык. Кит, калганын үзем сөйлим. Тыңла. Егет оста бии икән, аягы-аякка йокмый. Үзе бармакларымны гел учына җыя.

— Алардан хуш ис килә иде, шуңа бит ул, тиңсезем.

— Лыгырдык.

— Мәхәббәтем.

— Айнан! — Караңгылык аша егетнең күзләренә текәләм. — Ул чактагы кебек нигә бирелә генә, үзебезнең Иделдә генә йөзмисең соң? Аерылмас идек.

— Түз, Рәфинә. Тагын алты ай.

— Сагынуга түзә алмам шул.

Менә хәтернең соңгы кадры. Мине участок начальнигы чакырта. Яныңа капитан килгән, ди. Тугыз катлы подъездны бер итеп аска томырылам. Айнан кайткан, Айнан! Күрешергә нибары ике-өч секунд!

— Айнан! Ай... син кем?

Чал чәчле капитан иелгән башын күтәрә... Ул миңа карый.

— Ни бар? Кайда ул? — дим.

Капитанның кырыс йөзендәге җыерчыклар дулкынланып куя.

— Син Рәфинә, димәк?

— Ә Айнан?

— Айнанның синнән бүтән кадерле кешесе юк иде. Ул әти-әнисез тәрбияләнгән, беләсең.

— Соң, соң, иптәш капитан, шуннан?

— Айнан Галимов көчле штурм вакытында... һәлак булды...

— Алдыйсыз! Алдакчы!..

— Океан мәрхәмәтсез кылана. Егетнең гәүдәсен дә таба алмадык...

— Айнан... Айнан... Су... Су-у-у-! — Яр буеннан йөгерәм. Идел өсте — тигез пыяла...

— Тотмагыз. Җибәрегез!

— Рәфинә! — Асылъяр килеп җитә.— Әйттем бит. Сиңа күп уйлау куркыныч.

— Куркыныч? Бала чакта миңа әнием, ялгызлык иң куркынычы, дия иде. Аннан адәм баласы тилерә, шаша икән.

Чал чәчле капитаннан атна саен хат алам. Шул кадәр ерак аралардан хатлар тиз килә. Ак биткә сырланган тигез хәрефләрдә — җылы сүзләр. Әле җавап язылмаган. Вакыт тарлыгы. Кичә төзелешкә бер ханым елап килгән. Безнең идарә төзүчеләре брак биргәннәр икән. Бүлмә стеналары төртке-төртке булып куба башлаган. Ә тиздән кемеш туй ди. Үтенә, ялвара ханым, зинһар төзәтегез ди.

Төзелеш прорабы Кадыйровка хәлне аңлаттым.

— Ул подъездга расход тотылган, өстәмә нәрәд бирә алмыйм,— ди. — Стена «ата» икән, лаборатория гаепле. Измәдә известь сүнмәгән.

— Измәне кабул иткәндә сиңа кисәткәннәр ич.

— Бригадир Галимова! Сиңа мине тәнкыйтьләр өчен тагын егерме ел тир түгәргә кирәк әле. Әнә эштән соң калып үзең эшлә!

Кадыйров күпләрнең канына тоз салучы. Ул мине дә мыскыллап ишектән озатты. Гарьләнүемнән ярылырга җитешеп тулай торакка кайттым. Иртәгә ял көне. Бәлки бригада кызларын җыя алырмын. Көне буе кайнашсак, эшнең чиреге бетәр иде.

Бару-бармау мәсьәләсе бик тиз хәл ителә. Берәүләр каршы, икенчеләр изге теләктә. И дөнья! Кемең генә юк синең. Җан бирәсең, йөрәк бирәсең. Миләренә акыл саласың. Кешеләрне тигез яратмаудан кайчан туктарсың.

— Акча түләрме ханым? — ди Рәмзия. Мал корты. Кешене бәхетле итүне дә кәгазь кисәгенә алыштырып буламы икәнни?

— Бер машина акча китереп аударсалар, нишләр идең, Рәмзия?

— Эчең янганнан сорыйсыңмы? Акчаң җитмәгәнгә бит син тулай торакта ятасың. Улыңны да туар-тумас балалар йортына илтеп тыкмас идең.

Үзеңне аклау яки исбатлау кыен. Син арифметик мәсьәлә түгел. Тик Рәмзиядә эшем юк, миңа Рәмзиясез дә дөнья бар.

Аның сүзләре генә йөрәккә ук сыман кадала. Әле ярый, йөрәк дигәне күкрәк эченә яшеренгән. Ачык ятса, һәркем серенә кереп, ә Рәмзиядәйләр көлеп узар иде.

Авыр минутымда сыеныр кешем — әнием кирәк хәзер. Ул да еракта. Тормыш каршылыкларына очрый-кыйнала килеп, аны оныта язганмын. Хатларым сирәгәйгәч нәрсә уйлый икән. Бабам ясаган кабаны куеп йон эрлидер, бичара. Эш арасында җырлыйдыр да елыйдыр. «Ходай ялгызлыкка дучар итмәсен», дигәнен күп мәртәбәләр ишеттем. И әни, әни. Кичер кызыңны!

«Кайт, кызым. Улың авылда иркендә үсәр. Болын күк өй, ашарга-эчәргә иркен, нигә таш калада каңгырып ятасың. Әллә шул гынамы бәхетең? Мин-анаң авыл башыннан чит туфракка бер адым атламаган, ә барыбер бәхетле. Монда эшләр дә байтак. Мәктәп төзергә таш кайтарткаңнар. Төзү кайда да бер бит, кызым».

Калалар төзим дип хыялланганымны беләсең, әни. Килсәң, мин сине Горки ягына алып барыр идем дә, кул кочем кергән өйләрне санап күрсәтер идем. Анда, әрекмәнле далада биек-биек яңа өйләр калыкты. Аларга соклану, төзүче икәнеңне тою — бәхетем бит, әни.

«... Кала өйләре биек буладыр. Егылып төшеп имгәнерсең. Чыпта кызы җиткергән хәбәрдән дә инәлеп калган идем».

Әни, Чыпта кызы күпертеп сөйләгән ләбаса. Лифтта менгәндә, ток бетеп, без чүт әйләнеп төшмәдек. Прораблар, электриклар йөгереп килде. Акт төзеп маташтылар да, әзне җуйдылар.

Барсын да хатка язарга мөмкинме соң? Бүгенге аяныч хәлне дә сиңа җиткерә алмам. Кичер. Кызларым ишек шакыйлар. Җыеныргa вакыт.

Беренче кар аклыгын җир танымый. Аклыкны күз карашы һавадан ук тотып ала. Калкып чыккан йортлар да үсүе белән түгел, сыйфаты белән таныла. Түшәмнәр, стеналар төсен күңел якын итсә, ул йөрәк өшеткеч ямьсез буяулы булмаса, төзүче тыныч яши. Алдагы төзелешләрне хыялында яңарта, салават күперендәге яшел, сары төсләрне шыксыз, шәрә стеналарга күчереп карый. Ә мин... Битарафмы? Кадыйров ишегеннән тәрткәләп диярлек озатканга, «аткан» стеналарга тап чыкканга, эшемнән нәфрәтләнәм, көям. Алдагы көннәрем, нәкъ шушы стена кебек бозылып, миңа нибары уңышсызлык, кара төсләр алып килер сыман.

«Төзелештән кач», ди эчтәге шайтан. Качмыйм, дим аңа. Бу хакта уйламыйм да. Мин әле хыялланырга тиеш! Кадыйровлар, төрле браклар юлымда киртә түгел. Гомер кулыма тотмаган, хат язганда да тәртелгән каләм алып газитка бу турыда мәкалә язып җибәрәм. Үзебезнең объектка килеп тикшерүләрен үтенүдән кала мохтаҗ нәрсәм юк. Тик хәбәрчеләр бераз соңгарак калып килләләр. Без тишекләрне ямап, бүлмәләрне буяп бетерәбез. Сыек зәңгәр төс аяз күк йөзен, әле һаман да хәтеремнән китми азаплаткан Айнан күзләрен хәтерләтә.

Тик кара болытлар агылганда күктәге зәңгәрлек төссезләнә, бутала башлый. Ә минем Айнаным үлемгә чын, үзгәрмәс күзләре белән карагандыр. Аларда үкенеч тә, шомлану да булмагандыр. Бәлки ул... соңгы сулышында минем исемемне кабатлагандыр. Я, Рәфинә... Уйлама бу хакта, уйлама!

Квартира хуҗасы ашыга-ашыга табын әзерли. Бу минутларда аңардан да бәхетлерәк кеше юктыр, мөгаен. Берсекөнгә көмеш туй бәйрәме. Ире кибетләргә йөгерә. Безне кыстап диярлек кичке ашка калдыралар. Түгәрәк өстәлне китек итәсебез килми, кызлар белән ризалашабыз.

Киткәндә алар безне ирле-хатынлы озата чыгалар. Ханым подъезд төбендә кыенсынып кына мине чакырып ала, күзләрендә мөлдерәмә яшь. Рәхмәтен ничек тә аңлата алмаганын тоеп, аның җилкәсеннән кочам.

— Бигрәк булган бит үзең, балам. Тиңең бармы соң?

— Тиңсез, парсыз кыз буламыни соң, бар, бар, — дим. Чырык-чырык көлгән улым тавышы, йөрәк тибеше мине өч итә. Өчәүләп яшибез икән, өчәүләп! Үзем, мәхәббәтем, балам! Нигә кичегеп аңлыйм моны.

Уйлардан арынырга теләп, кызлар арасына керәм. Без җәяү генә кайтырга сүз куешабыз. Киче җылы, тыныч. Җан рәхәте. Аяк астында кояш кыздыруыннан кипшенгән яфраклар кыштырдый. Нәкъ баш өстебездә ай тәгәри.

— Ә бит күзләр җитте, күзләр, — ди Фәния. Ул үзе дә күзгә охшаган. Чәчләре, керфек-кашлары сары төстә.

— Моңсуланмасана, — дип әләктереп ала Нурфия. — Әйдәгез, кызлар, айны Кремль түбәсенә эләбез!

Чал Кремль башындагы сәгать, безне кисәткәндәй, тугыз мәртәбә суга. Диң-диң, дың-дың... Патша заманыннан калган чаң кагалармыни. Әйтерсең мин Сөембикә заманында басып торам. Чү, кызларым да зур капка алдында тавыш-тынсыз гына басып калалар. Ул да булмый, гүзәл сыныннан нур чәчеп Сөембикә каршыбызга килә... Мин аны ачык күрәм!

— И Сөембикә, моңыңнан гаскәриләр елаганы дөресме?

— Тарих алдамас, и кыз күрке!

— Кызлар, кыз-з-ла-ар! — Уйларымны чәлпәрәмә китереп Нурфия кычкыра. — Җе-ен!

Төркем чыр-чу килеп ныгытма буенча йөгерә. Көчкә сулу алып Казанка ярына төшәбез.

— Кызлар! Җилкәнле көймә!

— Кызлар, пар акчарлак!

— Су өстендә Ханбикә шәүләсе!

Иртәгә безнең эшкә барасы бар. Кызлар аны оныталар, гамьсез кыланалар. Яшьлек! Миндә дә узып та узалмаган яшьлек, кайнарлык, шаяру — боларга нәрсә тиң?

— ... Айнан, су гел зәңгәрме?

— Көндезен зәңгәр, кояш баеганда кызгылт.

— Син кайсында йөзәсең?

— Икесендә дә.

Уй пәрдәсен ертып шалтыр-шылтыр трамвайлар уза, машина тавышыннан колак тона. Ә Казанка тыныч. Төнен йоклый микән? Әллә давыл көтеп сагайганмы? Их, су, телсез су. Син тыныч. Минем күңелем генә давыллы чагыңа охшаган. Иртәгә Кадыйров чакыртып алыр, исемен газиттә күрмәгәндер дисеңме? Кыяфәтен алдан ук беләм. Маңгае җыерылган, төпсез күзләре акайган.

— Во-о-о-н кабинеттан! В-о-он!

Бөке кебек атылганыңны көт тә тор. Чыкмыйм, диярмен, сүнмәгән известь кабул итмә, диярмен.

— Кайтыйк, кызлар!

— Төн озын әле, өлгерербез, Рәфинә, — диешәләр кызлар. Ләкин калмыйча артымнан ияләр.

Казанка, чал Кремль безне озатып кала. Ә алда озын-озын тукталышлар.

Буяучы — чегән кебек ул, ай саен урын алыштыра. Йөк машинасына чиләген, кисмәген, эскәмияләрен, пумалаларын төягән кызлар өс-башлары белән дә чегәннән ким түгел. Кат-кат яулык бәйләп, сырма киеп салкынны каршылыйсы да, озатасы да бар бит.

Бүген безнең бригаданы яңа йортка күчерделәр. Башлыклар тызбыз йөренә, телефоннар шалтырый, димәк, эшне кыска срокта башкарырга. Тәҗрибәм шулай, ди.

— Котыпка җыендыгызмы әллә?

Борылып карасам, алдымда күзләрен чекерәйтеп бер егет басып тора. Җавап кайтарырга өлгермим, прораб будкасының тәрәзәсеннән башын тыгып Кадыйров кычкырып ала.

— Кер, бирегә Галимова, син дә, энем. Вәт, Галимова,— хәзер ул миңа тигәнәк кебек ябышачак, — икенче этаж сиңа бирелә. Катлам сырмаңны салып ат та, җиң сызганып эшкә кереш. Ике атнадан соң нәрәд ябам.

Нәрәд ябам... Бу — буяу эшен ике атнада тәмамлыйсың дигән сүз.

— Кыстати, синең кул астыңа яшь кадр бирелә. Иптәш Наганов Илдус. Эшкә өйрәт!

— Буяугамы? — Егет күзләрен тозсызландырып миңа карап тора, елмая да баш селки. — Авыр, пычрак эш, — дим.

— Акча әллә нишләтә, — ди ул исе китмичә, гүя эчендәген ярып сала.

Аны будкабызга алып китәм. Кызлар ир-ат кулына тиенүдән шатланышып ур-ра кычкыралар. Әзрәк тыйнаклык та саклый белмиләр, юньсезкәйләр. Шатлыкларын үзләреннән кала берәү дә аңламас. Әйе, аңламас. Төзелешнең башыннан ахырына кадәр алар авырлык күтәреп килә. Китерелгән буяуларны бушату дисеңме, носилка тотырып измәсен, известен ташу дисеңме, барысы да кызлар кулында. Кайчакта кисмәкләр балта белән каерылып суксаң да ачылмый. Ә бит бу кызлар ана буласы кешеләр. Бәлки аларга авыр эштән качу хәерледер? Тискәре уйлар кызларымның шат авазларына күмелеп кала. Будканы аударырлык итеп көләләр. Ничектер миңа буяучының шатлана белүеннән башка йортлар төзелмәс, матурлык тумас кебек. Төзүче халкы нечкәлекне тоймый, күңеле катылыкта, диләр. Бик ялгышалар. Мин шушы будканы урам буенча этеп йөртер идем. Ишетсеннәр, күрсеннәр. Әнә нинди алар минем шаян кызларым! Шымаеп калуымны күргәч, алар дәррәү көлүдән туктыйлар.

— Әйдә, бригадир, әмереңне бир, — ди эш дигәндә җанын аткан Фәүзия. — Стеналарга төсле күлмәк кидерә башлыйк.

Әлегә каты шкуркалар тоттырып, аларны стеналар чистартырга җибәрәм. Үзем Фәүзия белән буяу складына юнәләм. Безне трестта «акыллы» дип даны киткән, Кадыйровның беренче сердәше Әсмәрия түти каршы ала.

— Әнә, рәт-рәт бучка, кирәк төсне сайлап алыгыз, — ди ул, иң читтә яткан буяу савытларына төртеп. Үзенең менәргә исәбе күренми, мичкәдәй гәүдәсе артка өстеридер, күрәсең. Тик кирәк төс-буяуны таба алмыйбыз. Куе зәңгәре кымшанмыйча бер читтә ауный.

— Сезнең бетмәгән тагын, — дип акыл сата Әсмәрия түти. — Тотыгыз да сылагыз. Үзегез торасы йорт түгел лә.

— Сыларбыз, ак буяу бирсәң.

— Нәмәгә ул?

— Нәмәгәме? — Фәүзия куе зәңгәр буяуны кулына буйый да, Әсмәрия түтинең борын төбенә куя. — Шуңа бермә-бер өстәргә. Безгә сыек төс кирәк. Караңгы якка кара килешми.

— Акны тәрәзәләргә генә тотарга дигән күрсәтмә бар, — ди склад мөдире.

— Күрсәтмә? Ух, корт Кадыйров, — дип тузына Фәүзия һәм сиздермичә генә күз кыса.

— Чү, берүк башлыкларга тел тидермә, кызый.

— Алай гынамы, тотып буармын да.

Без көлә-көлә складтан чыгып китәбез.

Төшкә хәтле кирәкле төсләр сайлап алына. Кадыйровның койрыгы куырыла, тизрәк йортны тапшырасы бар. Әсмәрия түтигә ни соралган булса, шуны бирергә куша.

Минем иң яраткан эшем — төс табу.

Күз алдымда салават күпере. Күк бизәгеннән өч төс сайлап алырга тиешмен.

Сары, яшел, зәңгәр...

Калган ал, кызыл төсләр кеше өчен зарарлы. Андый стеналар булмый да. Бу — буяучы законымы?..

Кызлар фуфайкалары артына төрле исем язып тутырганнар.

Кайчакта җитдилекләре юкка чыга да, балалар кебек шаяралар. Алар белән зур эшкә алынасыңны тоеп, пошаманга төшәсең. Бу — минутлык кына ялгышу. Теләсә нинди каршылыкларны да җиңә белүче кызлар икәнен беләм, югыйсә.

Мин бригаданы икегә бүләм. Бер өлеше залларны эшкәртергә, икенчеләре йортның тышын акларга тотыначак. Соңгысы катлаулы операция. Известь куиылган сыекча панельгә тигез ятарга тиеш. Аннан да җаваплырак чәрсә — лифт үзе. Дөрес идарә итү осталыгы сорала. Техника буенча җаваплы кеше итеп Илдусны билгелим. Ни әйтсәң дә, ир кулы каты, нык була.

Бригадирның эш бүлүе бер көнгә генә түгел, атналар, хәтта айлар буена планлаштырылырга тиеш. Моны миңа остазым Гамир абый өйрәтеп калдырды. Гамир абый... Тормыш шау-шуы белән мин аны бөтенләй онытканмын лабаса. Ул хәзер КамАЗда. Иң җаваплы участокларның берсен җитәкли диләр. Аның да хәтереннән Рәфинә исеме җуелып беткәндер инде. Миндәй кызлар хәзер йөзләр, меңнәр бит.

— Рәфинә-ү-ү! — күтәрелеп карасам, югарыдан кызлар кул болгыйлар. — Тигезме, кара-а-а!

Насос көпшәсендә ут сыман бөркелгән известь панельгә тигез генә төшеп бара.

— Шулай дәвам итегез, кызлар, — дим, куанып.

Кич өйгә кайтсам, өстәлдә хат. Капитан яза.

«Исәнме, сеңелем Раиса!

Бу араларда хатың сирәк килә. Айрат турында да тулысынча язмыйсың. Үсәме яшь капитан?

Үзеңнең хәлләрең ничек? Җәйгә ял итәргә безгә килерсең. Алдан ук вәгъдә биреп куй. Мария Сергеевна Айратны бәлки безгә китерер, ди. Бу сүзләрне авыр кабул итмә. Курыкма, Раиса, без аны үстерербез, әтисенә лаек капитан булыр.

Сиңа күптән бер киңәш бирәсем килә. Яраларым төзәлер дисәң, су өстенә чык. Аның өчен кичке курслар тәмамларга кирәк. Барысыннан да әйбәте — радист һөнәредер. Радио мәктәбе Казанның ДОСААФ комитеты каршында икән. Син ничек уйлыйсың, Раиса?..»

Искиткеч... Мин ничек уйлыйм... Су мине чакыра. «... Кил, кил, Рәфинә. Киләчәгең — ачык диңгез».

Капитанга җавап язарга утырам. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз. Ә мин егетләрдән киммени?!



Караңгы төн. Иләмсез буран котыра — карны аяк астыннан гына себереп ала да йөзгә китереп каплый. Даладан җәяү атлыйм. Дала дигәнең Горки ягы. Әле бит нибары унлап кына йорт төзелгән. Казан белән ике араны тоташтыру өчен күпме көч куярга кирәк. Бер ай элек алты йөз кеше торырлык яңа өй тапшырдык. Бригада кызы Фәүзиябезгә шуннан бүлмә дә бирделәр. Шатлыгы-бәхете белән булсын, рәхәтен күрсен.

Яңа нигезгә изге теләкләр белән кайтырга чыктым. Юлы таныш, соңгы айларда бирегә безнең бригада буяу эшләренә күчте. Хәзер мин үзебезнең тапшырыласы йорт янынннан узып барам. Кинәт сыңар тәрәзәдәге тоныкут мине өркетеп җибәрә. Кичә сүндермичә калдырдым микәнни? Югыйсә, яктылыгы җитми дигәч, иң зур лампочканы элгән идек. Әллә... Андый хәлләр булгалады. Ишеккә ачкыч ятрапмы, ватыпмы керәләр дә, булган әйберләрне алып чыгып китәләр. Тузанлы киемнәр күп очракта читкә ташлана. Ә буяулар... Мин сыек яктылык сирпелгән тәрәзәгә табан йөгерәм. Тик подъезд ишеге тышкы яктан бикле, аркылы кадаклаган такталар да үз урынында. Каравылчы Шәех абзый аны эш сәгате башланыр алдыннан гына каерып ата.

Нишлим? Шомлы караңгылыктан йөрәгем дөп-дөп тибә, уйда: буяулар, буяулар! Складтан ташып куйган бер мичкә лак җанымны ашый. Нәрсә дип бүлмәгә күчерәсе иттем икән? Иртән килербез дә эшкә тотынырбыз, склад арасында йөреп вакыт узмас дигән идем. Аякларыма үрмәләгән салкыннан арынырга теләп, сикерә башлыйм. Тоныкут та, үртәгән сыман, минем белән сикерә... Юкка шомланам төсле. Сүндерергә онытып киткәнмендер. Тик зәгыйфь янмаска тиеш бит! Әллә ток көче кимеде микән?

Тынычланып кайту ягына борылам. Көчле буран артымнан озата баргандай җуылдап ала, пальто чабуларымны алга каера. Буранга ачу итеп каршы басам. Һәм... атлавымнан шып туктыйм. Сыңар тәрәзәдәге ут сүнгән! Ут! Ут! Такталар, йозак... Бикле ишек алдады. Әнә шыгырдап ачыла... ачыла... Аһ, бу кем?

— Карак, тукта! — дим мин аны танып, йөгерүдән тыным кысыла. Төнге кунакның юлына аркылы төшәм. Ул кулын күтәрә. Башымда пидер чыңлап үтүен ачык тоям. Буран тына...

Сихри тынлык арасыннан су ага. Су түгел бу, кан, Җирдән күтәрелмәкче булам. Көч җитми...

—Айнан...

— Түз, Рәфинә, түз! Мәхәббәтең сиңа көч бирсен.

— Син бүгенгем дә, киләсе көнем дә түгел, Айнан. Димәк, көч бирерлек сөю дә юк.

... Керфекләрем карга кадала. Хәтеремне чуалтмаска, адымны җуймаска тырыштым. Ачык изүемнән кереп, гәүдәмә су сарыла.

— Сезне әле озак илтергә туры килер, — ди ниндидер ят тавыш һәм кемдер мине җирдән алып биек-биеккә күтәрә.

Гүя бишеккә салалар...

Әкрен генә тирбәлә башлыйм. Бала чакка кайту шушы микән әллә...

— Тукталышка кадәр шактый әле, бирешмәгез.

Хәтер бер томалана да, яңадан ачыла. Үземне кемдер күтәреп

баруын инде ачык аңлыйм. Тик башымның үтереп авыртуы һәрнәрсәне тоюдан туктата.

Күз алдымда теге ут бии... Әле сүрән, әле якты. Ул да булмый, миңа табан кул күтәрелә... Йодрыгымны җыеп кысам. Учымда әллә нәрсә... Тимер кисәге күк. Кыскан саен елыйсы килү басыла...

— Айна-а-а-н! Сагынуга ничек түзәләр?

— Дөнья кысса.

— Ничек?

— Кайгы-хәсрәт, тормыш мәшәкате сагынуларны оныттыра.

— Алайса, син дә мине онытырсың. Океан давылы, уку, практика... Юк, минем сагыш алардан мең өстен. Сагынуны тик авырту җиңә. Яралансаң, төзәлү хакында гына уйлыйсың...

Бүген минем тән яралы, алай да сине сагынам, Айнан.

Сине сагынам... сине... сине...

Мин озак яшәрмен. Ике үлеп, ике терелгәнне үлем ала алмый диләр. Өченчесе — картаю көненә. Ашын ашап, суын эчкәч, дөньядан китүнең куркынычы юк. Сиңа алмашка яңалар килер, син эшли алмас эшләрне алар эшләр.

Төзелешкә кайтуыма атнадан артык. Көн саен диярлек участок милициясенә чакырталар. Имеш, мин кул күтәрүче хулиганны танырга тиеш идем. Әйе, мин аны таныдым. Ул Илдус иде. Тик бу адәм буяуны алмыйча ташлап качкан. Әгәр лак урланган булса, белмим, түзмәс идем, ул дияр идем. Билгесез сугышта күсәкнең башы миңа төште. Ә аңа? Аңа — аннан да зуррагы. Намус! Вөҗдан! Ул бит күзләремә туры карый алмыйча интекте дә, төзелештән китеп барды. Үтерсә бәлки алай җәфаланмаган булыр иде. Тик үлем мине җиңмәде. Мин яшим. Элеккечә стеналарны «дәвалыйм», матурлык эзлим. Билгеле, Илдус ул төнне мине танымадылар дип уйлагандыр. Әйдә, шатлансын. Адәм өчен бу да шатлык икән, шатлансын.

Кара төннең яман хатирәсе арасында төш сыман бер изге урын бар. Мине коткаручы кешене эзлим. Теге чакта, авыртудан, коткаручының гимнастерка төймәсен өзгәнмен. Төймә учымда калган. Андыйны Айнан формасында күрә идем.

Кем син, әй, билгесез егет? Хәрбиме? Казанда яшәүчеме? Кем син? Хәтта исемеңне дә калдырмыйча киткәнсең. «Сер» дәфтәремдә сиңа багышланган әллә ничә шигырь дә бар. Син минем алдыма Айнан образы булып, кыю лачын булып киләсең... Кем син? Дин сөременә күмелгән кыз булсам, алла тарафыннан җибәрелгән изге дияр идем. Кем син? Тере кеше ләбаса! Очратмам микән? Очратмамдыр. Казан зур. Җир тулы мәрхәмәтле кешеләр. Эзләсәм дә, синдәйләр күптер.

Ләкин мин синең белән бүген башлап исәнләшергә уйлыйм.

Исәнме, кеше! Чибәрме син, әллә түгелме? Барыбер күңелең матур, исәнме! Исәнме, кеше!

Таң белән уянып мин эшкә ашыгам. Кар ява. Аклык ява... Исәнме кеше! Бәлки син дә томан ерып, кар хакында уйлана-уйлана каядыр ашыгасыңдыр. Исәнме, кеше!

Их, адәм баласының үткәне булмаса, хәсрәте кимер, шатлыгы артыр иде. Айнан! Юк, юк... Айнан, син үткәнем...

Ә син бүгенгем, иртәгәсем. Исәнме, кеше! Киләчәк нинди гүзәл! Татлы хыяллар белән шуны бизисең дә, көтеп яшисең. Көтүнең аерым сәгате дә, ае да, елы да билгеле түгел. Шуңа да бит ул хыял! Киләчәк! Хыялымда мин Кеше белән очрашырга телим.

— Исәнме, Рәфинә, — дияр ул. Үзе гел Айнанга охшаган булыр. Җитен чәчләр, зәңгәр күзләр...

— Сәлам, Кеше, — дияр йөрәк.

— Килдеңме?
— Килдем.
— Уз! Күңелем түренә.
— Узам.
Керфекләремә очып-очып кар куна. Шәлем дә акланган. Карга күмелеп автобус тукталышына җитәм. Кызлар шаулашып өс-башымны кагалар. Тик Рәмзия генә бер читтә басып кала. Аның боек күз карашы, керфек очларына эленеп калган яшь бөртекләре сагаерга мәҗбүр итә. Өч ай элек ул Казан егетенә кияүгә чыккан иде. Ир дигәне беренче атналарда ук эчә, тавыш чыгара башлаган. Балага узганын белгәч, бөтенләй куна йөри, кайтмый икән.
— Рәмзия, карашың сүрән, нәрсә булды? — дим. Яшь хатын башын читкә борып ахылдап ала. Ул арада автобус та килеп туктый. Рәмзиянең җиңеннән эләктереп ишеккә ташланам. Без арткы утыргычларга барып утырабыз.
Кызлар, гадәт буенча, бер тыннан җыр башлыйлар.

Кыр казлары, кыр казлары
Кайтыр микән язларга?
Бер сөюдән күпме газап,
Күпме сагыш кызларга.

— Сөйләрлек сүз дә юк инде. — Рәмзия иренен тешли. — Ялгыштым, Рәфинә, ялгыштым. Гомергә көтәргә иде миңа.
— Нәрсәне? — Мин аңламыйм.
Яшь хатын иелеп миңа карый.
— Мәхәббәтне, — ди ул газапланып.
Автобус тәрәзәсенә кар сылана. Сикәлтәле урыннарда кызларның җыры киселеп-киселеп китә.

Бер сөюдән күпме га-а-а...
К-ү-ү-ү... а-а-а... кызларга.

Никадәр үзгәргән Рәмзия. Усал телле кыз. Тормыш шулай баса микәнни?
— Нәсел төбебез белән ике өйләнгән, ике кияүгә чыкканбыз. Язмыш мине генә читләтер дисеңме?
— Алай бозма җаныңны.
— Әй, Рәфинә, Рәфинә, нишлим соң? Кыз баланы ир-ат кына бәхетле итә бит.
— Ялгыш фикер.
— Сер бирмисең син.
Карның тизлеге кими төшә. Ачыла башлаган тәрәзә пыяласы аша тугыз катлы йортларны күрәм. Кызларның да тавышлары салмаграк яңгырый. Кинәт автобус эчендә ыңгырашуга охшашлы әрнүле аваз ишетелә.
— Көтәсе калга-а-ан! — Рәмзия сулыгып-сулыгып елый...
Сөйгәнеңне еллар буе көтүе дә авыр, сөеп яр югалту да авыр, аннан да битәр мәхәббәтең булмау авыр икән.
Рәмзияне юатмыйм. Бирелә сүзләр көчсез. Хәзер күңелне нечкәлеккә дә бирәсе килми. Нечкәрү — артка чигенү ул. Ә безне алда эш көтә. Моны барыбыз да бер төрле аңлый.
Автобус туктауга кызлар җиргә сибеләләр. Әллә ничә пар аяк, кар өстенә эз сала-сала, яңа йортка якынлаша. Бәһадир краннар, элмәкләрен җилдә чайкый-чайкый, сәламләп каршылыйлар. Тәрәзә пыялалары бәсләнеп туңганнар да чекерәеп карыйлар.
Үзем барам, үзем керәсе «кладовка» дигән шул нәрсәне каһәрлим. Батареяләргә җылылык бирмәделәр, өс киемен алыштырырга чирканып, һәр көнне зарлана кызларым. Кадыйровка очраган саен тукый торам. Складка мичләр кайтаргач, берне бирәбез дигән иде. Мичнең

башы-ахыры күренми. Кадыйров трестка шалтыратса, мөгаен, җылылык бирүдән баш тартмаслар иде. Мин, будка ачкычын кызларга сузып, Кадыйров «оясына» керәм. «Оя» дигән кушаматны буяучыларның үткен телләләре таккан. Аю сыман көне буе шунда утырып чыга Кадыйров. Халык белми әйтмәс шул.

Ишекне ачуга, битемә пар бәрелә. Будка эче җылы, өс киемеңне дә салып ташларга мөмкин. Гаҗәпләнүемә каршы, Кадыйров ялгыз түгел, качкан Илдус та аның каршында утыра. Керүемнән тартынып, егет кызарып китә. Һәм тиз генә урындыгын миңа табан этә. Кайчан әле шундый әдәпкә өйрәнгән ул? Теге вакыйгадан соң мәллә?

— Узмыйм әле, йомыш белән идем,— дим баш тартып.

— Ни бар, Галимова?

— Җылылык хакында.

Кадыйров тыңламас борын сүземне бүлдерә:

— Ун градус салкынга да бирешәсез, сеңелкәем, ай-һай.

— Стеналарга буяу ябышмый — бу бер, икенчесе — кеше сәламәтлеге. Сез ике нәрсә белән шаярасыз.

— «Чаян» ярдәм итмәс, сеңелем. Выше кит.

— Югары? Юк, юк, без түбәннән менәргә күнеккән. Сез, иптәш Кадыйров, кичкә кадәр җылылык мәсьәләсен хәл итәсез. Әә аңа чаклы бригада эшләмәячәк.

— Күрсәтермен, вон ясармын төзелештән! — Кадыйров, урыныннан ярым кубып, бүртенә-бүртенә кычкыра.

Ул да түгел, «Рәфинә»! дип, Илдус артымнан ишеккә ташлана. Урамга чыккач, мин егетнең елаудан шешенгән күз кабакларына игътибар итәм. Ләкин сорамыйм. Ниндидер көч тыеп кала.

— Рәфинә... Син кичер мине.

— Бригаданы ташлавың өченме? Буяу эшен яратмыйсың икән, китеп ялгышмагансың. Димәк, һөнәрең ул түгел.

— Кичер... — Ул иелеп бер уч кар ала да маңгаена каплый. — Кара төн бөтен тәнемне үләксә күсесе сыман кимерә. Ул чакта... мин... мин... суктым.

— Беләм, — дип кычкырганымны сизми дә калдым.

— Беләсең?! — Илдус шытырдатып беләгемнән эләктерә. — Беләсең?.. Алайса, нигә милициягә хәбәр итмәдең?

— Дөньядан кер эзлисем килми иде.

Илдус тагын маңгаен кар белән ышкый. Эрегән су битенә агып төшә бара.

— Әниемне җирләдем,— ди ул, теш арасыннан сүзләр кысып чыгаргандай. — Кинәт җир читен табасым да аска — упкынга атыласым килде. Һәм шунда син барын искә төшердем. Бары син генә аңлый алыр идең. Буяу урлавым өчен тик үзем генә гаепле. Коткыга бирелмәскә иде...

— Җитәр,— тамагыма таш тыгыла.— Сөйләмә. Узган эшкә салават. Үткәннәргә кайтырга яратмыйм. Инде тынычлап китә аласың.

— Тыңла! Тыңла! — Илдус карлыгып бер-ике мәртәбә кычкырып куя. — Син бит бу кабахәтлекнең акча өчен эшләнгәнен белмисең. Миңа акча вәгъдә итәләр!

— Җитте, Илдус. Бар, кит.

— Китмим. Мин яңадан төзелешкә, бригадама кайтам. Күзем ачылды, Рәфинә. Намусым ачылды... Китмим, бел.

Радио мәктәбенә кичке сменага йөрим. Кайткан саен көндәлек дәфтәремә нәни генә яңалык теркәлә.

*17 февраль.* Танышу көне. Өйрәтүчебез Григорий Алексеевич Навалов дигән егет. Татарча да шәп кенә сукалый. Үзе усал, җаны тоташ боз диярсең. Бер дә елмаймый.

*18 февраль.* Эштән шул кадәр арып кайткан идем, тиз генә капкалап радио мәктәбенә йөгердем. Соңга калганмын. Дәрес башланган иде инде. Григорий Алексеевич ымлап утырырга кушты. Морзе әлифбасын өйрәнә башладык. Кызык: «м» хәрефен нибары ике буй сызык аңлата. Әле катлаулысы алда, ди өйрәтүчебез.

*19 февраль.* Улым авырган. Эштә дә, мәктәптә дә була алмадым. Беренче мәртәбә Айрат миңа апа дип дәште. Җаным әрни.

*20 февраль.* Көне буе Айрат янында утырдым. Баламның хәле яхшыра. Нарасый тамчы гына авырса да, ана йөрәге телгәләнә шул. Йончыган хәлдә мәктәпкә килдем. Әзерләнергә йөрүчеләр юк, Григорий Алексеевич ялгызы приборлар арасында йөренә иде.

— Килдеңме? — диде ул дустанә елмаеп. — Ә кичә нишләдең?

— Онытканмын, — дип алдашам.

— Икенчеләй калдырма. Я, алдагы дәресләрне кабатлыйк.

Теләп башкарган эш яхшы эшләнә бит ул. Радио мәктәбенә мине берәү дә өстерәп китермәде, ялынмады. Минем хыялымда ерак океаннар киңлеге, ак пароход иде. Шуңа күрә хыялымдагы көннәрне якынлаштыру өчен, тырыша-тырыша морзе хәрефләрен ятладым.

— Рәфинә. Синең йөз чалымың миңа таныш.

Елмаеп куям. Бер-берсен хәтерләткән кешеләр азмыни.

— Кызык, дөньяда охшаш өч кеше була диләр бит, Григорий Алексеевич.

— Бәлки шулайдыр.

*10 март.* Әллә атып бәрим микән? Тапшыруга әллә кайдан дулкын-көй агылып керә. Янам, пешәм. Төгәл тапшыруны тотарга тырышам.

— Үзеңне кулга ал, Рәфинә, — диде Григорий Алексеевич. — Дулкыннарны рәтлә. Радист чыдамлы булырга тиеш. Я әле.

Һәм ул үзе минем урынга утырды. Әллә нәрсә, бу егеткә ихтирамым көннән-көн үсә бара. Ул радио мәктәбенә йөри, җәйгә ерак йөзүгә китәчәк икән. Киткәнче безне тәмам радистлык серләренә төшендереп калдырмакчы ди. Үз авызыннан ишеттермәсә дә, кайберәүләр шулай диләр. Хактыр, күрәсең. Шул тиклем кыска срокка алынуына кара инде аның.

*11 март.* Минем тормышымны сихри көй тулыландыра. Ул көйне ишетәм. Яратам. Бераз моңсу, билгеле. Күңелне әрнү айкый. Бер минутка гомернең кыл урталай өзелүен тоясың. Кулымда бояу пумаласы. Стеналарга бизәк төшерә барган саен, ул көй дә чәчәк булып ташка төшә бара кебек. Кичә озак итеп бер пластинка әйләндергән идем. Бәлки шуның зәхмәтедер, белмим. Гомер болай да көй агылышына буталып узадыр төсле. Кайчагында мин ваемсызлардан көнләшәм. Миндәй нечкә билле дә, сагыш өртелгән күзле дә түгел бит алар. Битараф җаннар, көнләшәм сездән! Көнләшәм, тик озакка түгел. Мәңге көй агылышлы тормыш кирәк миңа. Шунсыз яши белмәс, яшәүнең тәмен татымас идем.

— Рәфинә. Соң инде... Кайтырга кирәк.

— Әйе, әйе. — Мин трубканы куям. Уйларыма чумып, тапшыруны бөтенләй кабул итмәвемнән бит очларыма кадәр кызара, оялам. Әллә боларны Григорий Алексеевич күрми дисеңме? Бөтенесе дә таралышып беткәннәр икән инде. Вакыт та соң. Кремль башындагы сәгать теле унберне күрсәтә. Тәрәзәгә сыланып кар ява. Быел кыш бигрәк явымлы булды. Иртәгә урамда учак ягып келәй әзерлисе бар. Мондый явым комачауламас микән?

— Синең һөнәрең төзүче бит әле, — ди Григорий Алексеевич. Әйтерсең карның яуганын ул да килештерми, эшкә тоткарлык киләчәгенә борчыла.

— Төзүче-буяучы мин.
— Дөресме, буяучылар зәңгәр төсне артык яратып буйыйлар ди.
— Кайдан ишеттегез?
— Зәңгәр төс — гашыйклар төсе, имеш.
Җавап табалмадым. Бу әйтү бер миңа гына кагылган төсле иде. Сүзсез генә киенеп урамга чыктык.
— Кайтырга еракмы сиңа, Рәфинә?
— Гагарин тукталышына кадәр.
— Минем син яшәгән якларны күрәсем килә.
— Ә сез үзегез кайсы районда торасыз?
— Яңа Горки ягында.
— Чынмы? — Чынмы дигән төсле куанышып кар бөртекләре битемә куна. — Без төзегән микрорайон лабаса.
— Чын.
Григорий Алексеевич кар йомарлап миңа ыргыта. Бүген әллә ничек кырыс укытучыга бөтенләй охшамаган ул. Нинди ягымлы итеп елмая, көлә. Шатлыгы арткан диярсең.
— Мөмкинме, иртәгә син эшләгән участокка киләм, Рәфинә.
— Рөхсәтем юк, юк! — Мин куркып кычкырам. Буяулы, зур размерлы комбинезоннан аңа күренәсем килми.
— Рөхсәт ит инде, иптәш Галимова, — дип, укытучым беләгемнән эләктерә. — Ерактан гына эшегезне карармын.
— Анда бик пычрак, — дип котылмакчы булам. — Тузан оча. Аннан төзүчеләрнең теле сезгә ошамаска мөмкин.
Ә үзем эчтән генә сөенеп куям. Әле берәүнең дә эшем белән болай якыннан танышасы килмәгән иде. Григорий Алексеевич — беренчесе. Йөрәкне икенче нәрсә чеметтерепме, авырттырыпмы үтә. Айнан нигә һөнәрем хакында бер мәртәбә дә кызыксынмады икән? Аңа барыбер идеме? Әллә бөтенесен дә сөю күмеп, айнык сорауларга урын калдырмадымы?
— Килерсез, Григорий Алексеевич.
— Миңа рәхмәт, дустым.
Вагоннарын шалтыратып трамвай туктый. Мин күперне күрмим дә. Казанка өстеннән очабыз төсле.
— Синең йөзең таныш миңа, Рәфинә,— ди Григорий Алексеевич, үзе текәлеп-текәлеп күзләремә карый. — Тик ул кызның бите кар катыш кан белән укмашкан иде.
Дерелдәп куйдым.
— Кыз туктаусыз кемнедер чакыра, ниндидер аңлаешсыз сүзләр әйтә иде.
— Григорий Алексеевич! Төймә иясе!
Трамвайда булган бар халык безнең якка борылды. Мин аның киң күкрәгенә капландым да такмаклап елый башладым.
— Нигә ул чакта исемеңне дә әйтеп калдырмадың. — Миңа «сез»дән сингә күчү иң гади нәрсә кебек иде. — Кулымда өзелеп калган төймәң генә...
— Ул чакта мин синең өчен борчылсам да, артык кайгырмадым. Исән каласыңа иманым камил иде. — Григорий Алексеевич шуып төшкән шәлемне рәтли, ә куллары җиңелчә генә калтырый. — Менә табыштык та инде. Син миңа иң якын кешеңә дәшкәндәй Гриша диң!
*12 март.* Кеше яңадан кайчан туа? Кеше, кеше, кеше... Мин сиңа мәдхия укыйм. Кеше миңа икенче тормыш бүләк итте. Рәхмәт, Кеше!
— Үзгәрдең, Рәфинә, — диләр кызлар.
— Улым әни дип әйтте, шуңадыр, кызлар.
— Айрат күптән әни ди инде, Рәфинә. Синең икенче шатлыгың бар.
— Мин Кеше очраттым, белегез, алайса.

— Кеше?! — Кызлар төрле яктан гаҗәпләнеп сорыйлар. Аһ, тилекәйләр, алар мине гашыйк булган дип уйлыйлар бит. Әнә, грунт та салмаган шәрә стенага «Рәфинә плюс» дип язарга да өлгергәннәр. Шаян Фәүзия янымда бөтерелә.

— Әйт инде, кем ул?

— Гриша.

Плюс янәшәсендә Гриша исеме куелып, ике исем тигезләнә дә мәхәббәткә әверелә.

Кичкә табан көтелгән кунак килеп җитә.

— Хәерле көн, Рәфинә.

— Хәерле көн, Кеше.

— Нигә Кеше дисең?

— Белмим.

Бернәрсәне дә бу кадәр тиз хәл иткәнем юк иде әле. Без Гриша белән йөзүгә бергә китәргә сүз куешабыз. Яшерәсе калмый, мәхәббәт икебезне дә якынайта. Тик арада әйтелмәс сүзләр кала. Мин Гришага Айнан хакында да, балам турында да әйтмим. Ишетүгә кинәт ташлап китәр төсле тоела.

Соңгы көннәрдә башым түнә. Бөтенесе дә чишелгән кебек, югыйсә. Айрат балалар бакчасында кала, трест начальнигы гаризамны кире какмый, эштән азат итеlә дип кул куя. Әмма кыен. Ташлавымны кызлар ничек авыр кичерәләр. Берәү дә шаяртмый, җырламый. Әллә нигә эштә Илдус та күренми. Рәмзия аңардан хат кисәге тапшырган иде. Ул да кесәмдә укылмаган килеш ята.

Әбәткә утырышабыз. Исе аңкып торган буяулы кладовка, чиләкләр, пумалалар, хушыгыз, хушыгыз. Хушыгыз, кызлар! Мин эчемнән генә хушлаша башлыйм. Кызларым алып килгән ризыкларын алларына җәеп теләр-теләмәс кенә ашыйлар.

Авырлыкларны бергәләп җиңгән кызларым, сабыр холыклы дусларым, нәрсә дияргә сезгә? «Китмә...» Сезнең бердәнбер ялваруыгыз шул. Ләкин мин ерак йөзүдән калмаска тиеш. Кулымда — радист таныклыгы, йөрәгемдә — Гриша.

Аптыраудан гаҗиз калгандай Илдус язуын укыйм. Укыйм, кычкырып укыйм. Кызлар иелгән башларын күтәреп тыңлыйлар.

«Син киткәч, бригадада ни кала, Рәфинә? Минем тормышым кителә. Ләкин мин сиңа бәхет телим. Соңгы тапкыр күрә алмам һәм төзелешкә дә кайтмам, ахры. Бу записканы укыганда мин милициядә булырмын. Ә син хаклыкны ахыргача белеп кит. Теге кара төнгә кайтыйк. Беркөнне иптәш Кадыйров мине аулакка чакырды. «Синең Рәфинәгә карашың ничек?» ди. Дөресен әйткәндә, сине әллә ни өнәп бетерми идем. Кырыс идең, таләпчән идең, серле идең. «Начар», дип әйтеп ташламыйммы. Кадыйров шуны гына көткәндәй балкып китте. «Кара әле, — ди бу. — Сүз беркетеп шушы кызны төпкә утыртыйк әле». «Ничек?» дим. Башлыкларның кул астындагыларны ничек төп башына утыртуларын күргәнем юк иде әле. Кызыксынуымнан «Әйдәгез!» дип тагын шапырынып алдым. «Синең ышанычлы малай икәнеңне сразы сизгән идем, маладис, энем, — ди Кадыйров. — Тыңла, — ди. — Рәфинә бүген складтан ике мичкә лак алып будкасына ташыта. Син төнлә килеп шуны юк итәсең. Я, ераккарак илтеп түгәсең дә, мичкәсен елгага ташлыйсың. Я, машина яллап, төяп кит. Тик кеше-мазарга юлыкма. Ачкыч бирермен. Шуны төшен: мондый ачкыч Рәфинәдә дә, миндә генә. Так что, лакны шул кыз гына урлаган дияргә сәбәп бар. Хезмәтең өчен — акча!»

Акчага күзем кызды. Акча туза, ә вөҗдан... Вөҗдан мине милициягә илтәчәк. Хуш. Илдус.»

Ак кәгазьгә тигез итеп язылган хәрефләр күз алдымда биешә. Нишләдең син, Илдус? Нишләдең? Төрмәгә башыңны тыктыңмы? Юк, монда син түгел, Кадыйров гаепле.

— Кызлар! — урынымнан сикереп торам. — Кадыйров гаепле!

— Дөрес!

— Якасыннан тотып милициягә илтик!

— Әйдәгез! — Кызлар төрле яктан шаулашырга керешәләр. — Әйдәгез аның «оясына».

— Ашыкмагыз, үзем, үзем...

— Китәсең бит, — Рәмзия сызланып әйтеп куйды.

— Китмим... Калам... Кеше язмышы хәл ителгәндә китә алмыйм.

... Йөрәгемне канатып елга портына төшәм. Күпме газап, күпме әйтелмәгән сүз... Барысы да үземдә калыр микәнни?

— Рәфинә!

Халык төркеме арасыннан берәү исемемне атый. Бу — Гриша. Аңа табан йөгерергә дә, эндәшергә көчем җитми. Җанымны чамасыз авырлык биләгән. Нишлим мин? Яратам лабаса! Гриша — минем кабат яңарган мәхәббәтем. Ул Айнан дәвамы, Айнан дәвамы!

— Рәфинә, ике буш кулыңны селтәп киләсең. Кайда әйберләрең?

Их, тилекәй. Син аерылуны белмисең, кисәтеп кычкырасың. Ичмасам, соңгы минутларда күземә кара да мине аңла. Аерылабыз бит... Моны телдән җиткерә алмам, ахрысы. Гриша кулымнан тотып читкә алып китә.

— Кайда әйберләрең? — ди ул кабат. Тавышында куркыну, хәвеф.

— Юк алар, мин...

— Тыңла: хәзер үк әйберләреңне җыйнап килеп җитәсең!

Гриша белән озак итеп бер-беребезгә карашып торабыз.

— Китәргә мөмкин түгел,— дим пышылдап.— Анда, еракта шәүләм генә йөриячәк бит.

Егет авырттырып кулымны кыса. Язмыш никадәр рәхимсез, Гриша, никадәр рәхимсез! Өзеп-өзеп теплоход кычкырта. Бер гудок, ике гудок, өч...

— Калдырмыйм үземнән!

— Ай, Гриша, Гриша. Артык яратышып бер-беребезне аңламаганбыз бит...

— Мин барыбер сине аңлармын. Аңлармын, аңлармын!

... Офык читендә нәни генә бер нокта — теплоход. Йөгерек дулкыннар аны һаман саен еракка-еракка куа төсле. Улым Айратны үз яныма алдырырга кирәк, бүлмә бирәбез дип ышандырганнар иде. Илдус язмышы да минем кулда. Аны коткарырга кирәк.

Мин шуларны уйлап тынычлангандай булам. Тик күңелем юатуларга буйсынмыйча әкрен генә елый... Ә күңел елаклыгын күпләр вакытлыча диләр. Дөрес микән?

# ҖЫР ЯЗАЛАР ЧАЛЛЫ КЫЗЛАРЫ

Һөнәрләре буенча алар төзүчеләр, тәрбиячеләр, пешекчеләр, сәламәтлек саклау хезмәткәрләре. Туган җирләре — Татарстан һәм Башкортстан авыллары. Тынгы белмәс кызларны көн саен могҗизалар туыя торган Чаллы җире, КамАЗ төзелеше үзенә тартып китергән. Яңа җиргә алар зур өметләр, якты хыяллар белән килгәннәр. Кайнар хисләр тормышны ямьләндерә, хезмәтне җырга сала. Мәхәббәт белән үрелеп шәһәр үсә, яңа гаилә, яңа буын туа. Бәхетле кеше генә бәхетле тормыш төзи ала.

**Җырламыйча ничек түзим,**
**Ургыла яшәү көчем.**
**Дөньяга яңа җыр өстим**
**Яраткан кешем өчен.**

Бу сүзләрнең авторы — моң һәм оптимизм белән сугарылган шигырьләре укучыларга байтактан таныш Сәлимә Шәрипова. Сәлимә башлап җибәргән яңа Чаллы җырын күпләр күтәреп алды.

**Җыр языйм дип илләр гизмим,**
**Ул бит һәр чак минем белән,—**

ди дөньяның ямен сокланучы Рәйсә Фахразиева.

Гүзәл табигатьле Арча якларыннан килгән Фирая Хәлиуллина ялгыз минутларында туган авылы белән сөйләшә:

**Канаты ныгыган коштай**
**Текә яр өсләрендә —**
**Еракта йөргән кыз балаң**
**Төшәме исләреңә!**

Гигант төзелеш көн саен батырлык, көн саен сабырлык сорый, ихтыяр көчен сыный. Башкортстан кызы Венера Хәбибрахманова тормышның каршылыклы якларын күңеленнән кичерә:

**Әллә язмышымны сыный —**
**Гел шаярта шул ак болыт;**
**Кайчакта йолдыз күрсәтеп,**
**Ә кайчак яшергән булып...**

Яңа җирдә бәхетен тапкан Тәнзилә Сәгыйтова бөтен дөньяга ишетелерлек итеп аваз сала:

**Көннәрем, минутларым да**
**Гел сөенеч, гел рәхәт.**
**Ятка түгел, үпемгә дә**
**Бирмим сине, мәхәббәт!**

Чаллы кызлары. Чая, эшчән, уйчан кызлар... Укучыларны бүген бишесе белән таныштырабыз. Аларны мәшһүр КамАЗ очраштырды, шигърияткә мәхәббәт дуслаштырды. Кызлар «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә йөриләр. Яшь әдәбиятчыларның эшенә танылган язучы Эдуард Касыймов ярдәм итә. Монда шагыйрь Мәхмүт Газизов чыныгу алды. Казан дәүләт университетын бетереп төзелеш романтикасына чумган Равил Вәлиевнең КамАЗ очерклары, беренче повесте башлап «Ләйсән»леләргә укылды. Яшь тәнкыйтьче Равил Лотфуллин — берләшмәнең хәзерге җитәкчесе — кызларның яңа шигырьләрен үз кулы белән күчереп Әлмәткә җибәреп тора, язучыларны әледән-әле берләшмә утырышына чакырып ала.

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА.

## Сәлимә Шәрипова

### Игенче

Басу өсте дулкын-дулкын,
Колач салып йөзәрлек.
Нурга чумган башаклары
Бар дөньяны бизәрлек.

Дулкыннар ярып үтәсең
Комбайнда, әй, егет!
Таң зәңгәр чаршавын ачып
Ал яулык болгый кебек.

Йокыдан уянган тургай,
Егетне күрү белән,
Шатлыгыннан җырлый-җырлый
Җиде кат күккә менгән.

Тургай җырларын бар галәм
Күтәреп ала төсле:
«Бодай диңгезе ясаган
Игенче егет көчле!
Игенче егет көчле!»

●

Йөрәк — серләр тулы сандык,
Ачар ачкыч тап кына.
Төймә кадәрле шатлыгын
Дөя иткән чак була.

Йөрәк — серләр тулы сандык,
Бикләре мең кат була.
Дөньяга сыймас кайгысы
Учка сыйган чак була.

## Фирая Хәлиуллина

### Туган җирем

Ак каендай үскән җирем
Хыялым, төшләремдә.
Давылдагы чәчкә сыман
Киң дала өсләрендә.

Канаты ныгыган коштай
Текә яр өсләрендә —

Еракта йөргән кыз балаң
Төшәме исләреңә?

Далалар, җилләр куенында
Син, минем туган ягым.
Кадереңне назыңнан башка
Күпме түзәрмен тагын.

## Син көттеңме?

Ромашкалар юлларыңда дәштеләрме
Ярата да, яратмый дип күзләр кысып?
Серләштеме ак каеннар җил көенә
Сагынудан бер-береңнең иңен кочып.

Мин җил идем көй көйләүче яр буенда,
Чәчләреңне назлый-назлый сыйпап үттем.
Еракларга дәшеп барыр юлларыңда
Хыял сыман офыкларга таба киттем.

# Рәйсә Фахразиева

## Авылымда икмәк исе

Урамнарга килеп керсәм,
Яңа пешкән икмәк исе:
Игенченең куйган көче,
Кешеләрнең уртак хисе —
Яңа пешкән икмәк исе.

Авылыма кайтып керсәм,
Яңа пешкән икмәк исе.
Туган якның айлы киче,
Сабый чакның татлы төше —
Бар да сиңа бәйләнгән бит,
Яңа пешкән икмәк исе —
Авылымның күмәк көче.

## Җырларым аша беләм

Җыр язайым дип эзләмимен,
Җыр ул үзе мине эзли.
Синең зәңгәр күзең булып,
Күңелемнең күлен күзли.

Яши алмыйм тыныч кына
Качып китеп җырларымнан.
Әнкәм булып дәшә ул җыр
Сабый чагым елларыннан.

Җыр языйм дип илләр гизмим.
Ул бит һәрчак минем белән.
Икмәк тәмен, дөнья ямен
Мин җырларым аша беләм.

## Кыңгыраулар көен тыңладым...

Кыңгыраулар көен тыңладым мин,
Сагышлана төшеп чак кына.
Кыңгыраулар үскән туган ягым,
Күңел һаман сиңа ашкына.

Кыңгыраулар көен тыңладым мин,
Зәңгәр бер моң күмде тирәмне.
Кыңгыраулар үскән, туган ягым,
Тугайларың яшел чирәмле.

Кыңгыраулар көен тыңладым мин,
Көйләрендә нинди тирән моң!
Кыңгыраулар әллә сагыну булып
Җырларыма күчте микән соң?

Кыңгыраулар, зәңгәр кыңгыраулар...
Хисләремдә назлыйм үзләрен.
Кыңгыраулар — минем туган якта
Торып калган күңел күзләрем.

# Венера Хәбибрахманова

## Җилләр иссә

Сезнең яктан җилләр иссә,
Сизә җилкән.
Җилсез җилкән — синсез үткән
Көннәр, иркәм.

Булам җилкән, язгы назлы
Җилләр булсаң.
Җилдә җилкән — канатлы кош,
Оча белсәң.

Алга карап омтылуым
Бары синнән.
Уйга калып онытылуым —
Иркәм, синнән.

Җилләр иссә, җилкән ярсып,
Әй, җилкенә.
Йөрәгемне җилкендергән
Җил — син генә.

## Өметләр өзелмәсен

Үзәкләр өзелгәндә дә
Булган өчен түземле,
Өзелмәс өметем итеп
Санар идем үзеңне.

Зәңгәр күл өстендә йолдыз
Шәүләсе уйный чумып.
Мин — тирән күл, син янасың
Өмет йолдызым булып.

Өмет авазы син булсаң,
Кайтавазы мин булам.
Синең җырыңны кабатлап
Җиргә моң булып тулам.

Яра салдың йөрәгемә
Һәм беләм төзәлмәсен.
Үзәгем өзелсә түзәм,
Өметләр өзелмәсен.

●

Кешеләргә тиз һәм төз йөрергә
Тимер юллар җирдә салганнар.
Ул чак җиргә сеңгән каннар, җаннар
Шпаллар сыман сафта калганнар.

Гасырларга юллар салган чакта
Сазлык, урман, чүлләр үтелгән.
Тау-таш ярып үткән авыр юлдан
Тигезлеккә килеп җителгән.

Шомлы еллар авырлыгын җиңеп
Сынау үткән юллар сынмыйлар.
Илләр генә түгел, җирләр тетри,
Җил-давыллар һаман тынмыйлар.

Әзер юлдан гомер вагонында
Җырлар җырлап үтеп барабыз.
Юл буенда һаман сазлыклар бар,
Текә ярлар, таулар — карагыз!

Кул сузарга теләк, юл сузарга —
Йөрәкләрдә койган корыч нык.
Континентлар буйлап юллар уза,
Поездлары: «Дуслык!», «Тынычлык!»

## Тәнзилә Сәгыйтова

### Осталар өй сала

Авылда тагын бер яңалык!
Шуңармы, урамда ямь арткан:
Осталар яңа йорт күтәрә,
Өр-яңа нигезгә, нараттан.

Апрельнең кояшы куанып
Уйнаклый балталар йөзендә —
Әйтерсең бүгенге өмәгә
Дәшкәннәр кояшның үзен дә.

«Тук та тук»... Мускуллар биешә,
Ялтырый чык кунган яңаклар.
Киртәгә утырып, дәртләнеп
Өмәне күзәтә чал картлар.

— Әй, нигез боткасы китердем!
— Ай, энем, үскәнем, мең яшә!
Бәләкәй малайлар шау килеп
Өй саен тәлинкә өләшә.

Йөзендә үзгә гамь — ир гаме.
Дөнья бу — яшәргә өйрәтә!
Яшь егет ял иткән арада
Уйланып тәмәке көйрәтә.

Яшь кенә булса да, егетнең
Йөреше, сөйләше килешле.
Төп йортта энесе житеште,
Ул оя корырга тиешле.

Авылда шатлыклы яңарыш!
Урамда матурлык, ямь арткан:
Осталар яңа йорт күтәрә
Өр-яңа нигезгә, нараттан.

### Тамчы

Кышларның үз матурлыгы —
Өянкем гел бәс кенә.
Ябалак кар ява жиргә
Теләр-теләмәс кенә.

Учым суздым — бизәк-бизәк
Кар бөртекләре кунды.
Сокланырга өлгермәдем —
Эреде, тамчы булды.

— Исәнме, тамчы бөртегем,
Шаяным, яз кисәгем.
Апрель диеп белдең бугай,
Йөгерергә исәбең.

Учымда — яз, язымда — син,
Бу мизгелем — сәгадәт.
Сизми калдым: шаян тамчым
Төште... Китте тәгәрәп...

Кыш әле. Бу җир өстенә
Иренеп кенә кар ява.
Көтә беләм: һәр фасылда
Сагынуыма бар дәва.

## Учак

Юлым җуеп, җаным өшеп,
Каңгырып йөргән чакта,
Юлыктым ялкын биетеп,
Җырлап янган учакка.

Кемнәр яккан — кызыксынмыйм,
Бар уем — җылынырга,
Ышанып бу ят учакка
Сабыйдай сыенырга.

«Ут ул, урар да көл итәр».
Беләм, бу да хакыйкать.
Нишлим, күшеккән җаныма
Ут сулышы мең сихәт.

Булса булыр икән яну
Кемдер яккан язларда!..
Инде көз, ә ялкыныннан
Көнләшә йолдызлар да.

Ә асылда, үзәгендә
Дөрли икән мең яра.
Ут оныта, кичерә белми —
Яралары өр-яңа.

Бу төзәлмәс яраларга
Ничек соң орынырга?
Теләмим учак кырында
Бары тик җылынырга.

Владислав Лукъянов

# ХАЛЫК ҖЫРЫ — ТӘРБИЯ ЧАРАСЫ

Яшь буынга, бигрәк тә мәктәп яшендәге балаларга, эстетик тәрбия бирү мәсьәләсе коммунистик тәрбиянең мөһим бер өлеше буларак алга куела. Кешеләрнең рухи дөньясын баетуда музыканың нинди зур роль уйнавы яхшы билгеле, һәм безнең җәмгыятебез шартларында ул чыннан да нәкъ шундый максатларга хезмәт итә, һәркем өчен файдаланырга мөмкин булган уртак хәзинәгә әверелә. Илебезнең күп төбәкләрендә, аерым алганда, Балтик буе республикаларында, шулай ук Болгария, ГДР, Венгрия һәм башка социалистик илләрдә тупланган олы тәҗрибә күрсәтүенчә, һәр милләтнең музыкаль-эстетик тәрбия системасы нигезендә халык җыры культурасы ята. Татар халык музыкасы һәм җырына килсәк, әле Габдулла Тукай ук, аның тәрбияви әһәмиятенә югары бәя биреп, «халык җырлары безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирас» булуын әйткән. «Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырлар сөймәкемнән,—дип яза Г. Тукай, — миндә туган телебезне сөю тугды.» «Халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгесе» булган җырларны «дикъкать белән укылса, халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын барчасын күреп буладыр», — ди шагыйрь. Халык җырының әнә шундый кыйммәтле хасиятләре аңарда бөтен бер милләтнең рухи энергиясе, иҗат куәте тупланган булуыннан килә.

Әлбәттә, актуальлек, бүгенге эстетик ихтыяҗлар күзлегеннән караганда, халык җыры мирасындагы һәр нәрсә дә бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле дип әйтеп булмый. Җыр хәзинәсен тема һәм эчтәлек ягыннан алып карыйк. Туган җир һәм табигать, туган тел турындагы җырлар, мәхәббәт җырлары, уенбию җырлары халык арасында яратып җырлана. Һәм шул ук вакытта татар халкының авыр үткәне, газаплы көнкүреше белән бәйле җырларның бүгенге яшьләр аудиториясендә уңыш казана алуы бик икеле. Патша хезмәтенә китүче рекрутлар яисә байдан алданган ярлы кызы турындагы җырлар тематик эчтәлекләре белән хәзерге тыңлаучыга эстетик канәгатьлелек хисе бирә алмыйлар. Шул ук вакытта иске җырларның көй-моңы, элеккечә үк, беркемне дә битараф калдырмый. Мәсәлән, «Зиләйлүк» көе, җырчы тарафыннан башкарылса да, уен коралында уйналса да, самими саф моңы белән күңелләрне әсир итә. Көйнең мелодик байлыгы аның текст эчтәлегеннән өстен чыга. Бүгенге тамашачы һәм тыңлаучы өчен «Зиләйлүк» көе туган җирне, табигатьне ихлас күңел белән сөю хисе булып яңгырый. Шушындый бер генә җыр аша да күп нәрсәгә төшенергә, күңел тетрәве кичереп, туган җиреңне, халкыңны сөю хисен татырга мөмкин. Чөнки син ул моңда үзең туып үскән шушы изге туфракта гомер кичкән ничә буын кешеләренең хис-тойгыларын ишетәсең, күңелеңдә аларның хисләре белән уртаклык тоясың. Халык көйләренең төрле буын кешеләре күңелендә якты хисләр уятырлык әнә шундый кодрәте хакында академик Б. Асафьев болай дип язган иде: «Көйләр төрле тормыш күренешләренең һәм тойгыларының символлары булып әвереләләр. Һәм алар, күп буыннарның күңел кыллары аша үтә-үтә һәм тәэсир итү

куәте һәм сәләте сынала-сынала, кристаллашып житкән гажәп тотрыклы авазлар бердәмлегенә әвереләләр».

Мәгълүм булуынча, музыка җәмгыятьтә өч төрдә — житди «академик» музыка, күңел ачу музыкасы һәм музыкаль фольклор рәвешләрендә яши. Аларның үтемлелеге, аңлаешлылык дәрәҗәсе бер үк түгел. Яшьләрнең, беренче чиратта, күңел ачу, бию музыкасы белән кызыксынуы табигый күренеш. Җиңел музыка яшүсмерләр өчен кайчак музыка сәнгатен үзләштерүнең бердәнбер формасы булып кала. Бу урында композитор Д. Кабалевский сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Күңел ачу, әгәр ул бердәнбер рухи ихтыяҗга әйләнсә, котылгысыз рәвештә күңел туклыгына илтә, хисләрне тупасландыра һәм ахыр чиктә барлык эстетик идеаллар һәм сәләтләрне һәлак итүгә китерә. Әнә шул рәвешчә чын сәнгатьнең бөек казанышларын актив һәм иҗади үзләштерергә сәләтсез, сәнгать әсәрендәге олы фикерләрне дә, тирән хисләрне дә кабул итми торган, эстетик яктан бозык тип формалаша. Күңел ачарга! Нинди юллар белән булса да фәкать күңел ачарга! — аның эстетик дөньясы шуның белән чикләнә».

Моңа өстәп, шуны әйтергә кирәк: күңел ачу музыкасы диңгезендә көнлек модага ияреп язылган, кешене чынлап мавыктыра алмый торган әсәрләр зур урын алып тора. Җиңел музыка исеме белән кайчак эстрададан, эфирдан, киноэкраннан зәвыксыз һәм иләмсез музыка яңгырый. һәм үз зәвыгын тәрбияләргә өлгермәгән яшь кешегә шушы болганчык агымда дөрес юнәлеш табу җиңел түгел. Шул ук вакытта ул әле житди профессиональ музыканы аңлауга да әзер булмый. Мондый шартларда музыкаль фольклор яшьләрне музыкаль-эстетик тәрбияләүнең нигезенә салынырга тиеш. Беренчедән, интонация һәм образлар корылышы ягыннан халык җыры мәктәп укучылары өчен үтемле дә, җиңел дә. Икенчедән, халык җырларының иң зур күпчелеге — югары художестволылыкның чын үрнәкләре, яшь башкаручы һәм тыңлаучыларның музыкаль тоем һәм зәвыгын үстерүдә алардан бер дә шикләнмичә файдаланырга мөмкин. Музыкаль фольклор житди музыканы аңларга һәм җиңел музыка жанрында яхшыны яманнан дөрес аерырга һәм өйрәнүгә хезмәт итә ала.

Әмма тәрбия эшендә халык җырларының яшәеш рәвеше революциягә кадәрге чор белән чагыштырганда инде шактый нык үзгәрүен онытмаска кирәк. Әгәр элек яшь буын халык җырларын нигездә гаилә эчендә үзләштергән булса, хәзер бу рольне радио, телевидение, магнитофон язмалары үти. Җырларны ул мәктәптә һәм театрларда, культура сарайларында һәм бәйрәмнәрдә ишетә. Җырны профессиональ җырчылар да һәм һәвәскәр артистлар да башкара. Халык җыры профессиональ композиторлар иҗатында да файдаланыла, опера һәм балет спектакльләрендә, симфоник концертларда яңгырый.

Татар милли музыкаль фольклорының яшәеш шартлары үзгәрү житди тикшеренүләр таләп итә торган тема. Аны социологик планда өйрәнү музыка педагогикасына фольклорны эстетик тәрбия максатларында нәтиҗәле файдалану юлларын һәм формаларын табарга ярдәм итәчәк. Барыннан да элек мәктәп балаларының халык җырын белү дәрәҗәсен тикшерү кызыклы. Чыннан да, мәктәп балалары халык җырларын һәм музыкасын хәзер ничек үзләштерәләр һәм алар нинди чыганаклардан нәтиҗәле файдаланалар?

Шушы максат белән Казан дәүләт консерваториясенең хор белән дирижерлык итү кафедрасы Казан, Әлмәт, Лениногорск шәһәрләре һәм Азнакай, Баулы, Мөслим, Сарман районнары мәктәпләрендә сигезенче-унынчы класс укучыларыннан анкета тутырттырды. Анкетада татар халык җырлары хәзинәсеннән кырык җыр күрсәтелгән иде. Аларның егермесе революциягә кадәрге, ә икенче яртысы революциядән соңгы чорга карый. Укучылар теге яки бу җырны белү дәрәҗәләрен «яхшы», «канәгатьләнерлек», «начар» билгеләре белән бәяләргә тиеш булдылар. Алынган мәгълүматларны анализлаганнан соң менә нәрсәләр ачыкланды: укучылар «яхшы беләм» дигән җырлар арасында беренче урында «Туган тел» җыры тора. Калган тугыз әсәр белү дәрәҗәсе буенча менә болай тезелә: «Ай, былбылым», «Пар ат», «Әпипә», «Көзге ачы җилләрдә», «Галиябану», «Каз канаты», «Сарман», «Кара урман», «Матур булсын». Тагын унбер җырны укучылар «канәгатьләнерлек» дәрәҗәдә беләбез дип саныйлар. Болар арасында «Комсомолка Нәфисә», «Әллүки», «Тәфтиләү», «Фазыл чишмәсе», бишек җыры «Әлли-бәлли», «Җизнәкәй» һ. б. бар. Калган унтугыз җырны укучылар начар хәтерлиләр яисә таныш ук түгелләр. Ул әсәрләр арасында «Сибелә чәчәк», «Таң атканда», «Зиләй-

лук», «Дисанә», «Уел», «Һаваларда йолдыз», «Ком бураны» кебек җәүһәрләр бар.

Гомумән алганда, мәктәп укучылары халык җырларын канәгатьләнерлек дәрәҗәдә беләләр дип әйтеп булса да, аларның совет чорында туган җырларны йомшаграк белүе күренә.

Тикшерү күрсәтүенчә, радио һәм телевидение — хәзерге балалар өчен җырлар белән танышуның төп чыганагы. Мәктәп, клублар һәм гаилә бу җәһәттән тиешле роль уйнамый.

Анкетадагы кырык җырның тик өчесе мәктәптә, берсе гаиләдә өйрәтелгән. Шушындый тикшеренүдән үк инде халык җырының яшәеш шартлары чорга нисбәтле рәвештә бик нык үзгәргән дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Эшне башлар алдыннан без шәһәр балалары белән чагыштырганда авыл һәм районнарда яшәүчеләр халык җырын яхшырак белергә тиеш дип уйлый идек, чөнки авылда халык җыры һәм музыкасы традицияләрен саклау өчен шартлар күбрәк. Әмма чынлыкта халык җырын белү дәрәҗәсе шәһәрдә һич тә түбәнрәк булмавы күренде. Җыеп әйткәндә исә, мәктәп укучыларының милли җыр хәзинәсен үзләштерү дәрәҗәсе шактый йомшак икәнен таныырга туры килә. Укучының җырны башкара алу-алмавы турындагы сорауга уңай җавапларның аз булуы борчый. Хәтта «Туган тел», «Ай, былбылым», «Пар ат», «Әнипә», «Каз канаты», «Матур булсын» кебек җырларны да балаларның (саналу тәртибендә) җитмеш, илле сигез, утыз җиде, утыз өч, егерме биш, унсигез проценты гына җырлый ала. «Кара урман» җыры укучыларның күбесенә яхшы таныш булса да, аны һәр йөз яшүсмернең җидесе генә әйбәт белә. Шул рәвешчә, укучыларның иң күп өлеше җырны таный, ә җырларлык кадәр белми. Бу һич тә очраклы хәл түгел, чөнки яшьләрнең халык җыры белән танышуы пассив формада бара. Беренче карашка ничек кенә гаҗәп тоелмасын, радио һәм телевидение тапшырулары, музыкаль театрлар, магнитофон язмалары булу фольклорның көнкүрештә тоткан актив ролен йомшартуга алып килә. Халык җырын үзләштерү, башкаруга караганда, күбрәк әзер язманы тыңлыйлар. Фольклор көнкүрешкә турыдан-туры хезмәт итүдән бигрәк эстетик ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен файдаланыла. Хәер, хәзерге көндә җыр мирасы әнә шул ягы белән, яшьләрне тәрбияләүдә халык җыры һәм музыкасының эстетик роле үсүе белән әһәмиятле дә. Халык музыкасын өйрәнү һәм үзләштерү нинди формада һәм ничек оештырылырга тиеш соң? Ни генә димә, бу бурычны урта мәктәпләр катнашыннан башка хәл итеп булмавы үзеннән-үзе аңлашыла. Әйе, укучыларга музыкаль тәрбия бирүдә урта мәктәпләр җитди урын алырга тиеш. Тәҗрибә күрсәтүенчә, радио һәм телевидениенең роле нинди генә зур булмасын, югары зәвыклы актив тыңлаучыны тәрбияләүдә аларның мөмкинлекләре чикле. Б. Асафьевның язуынча, «моның өчен тыңлаучыда башкаручы инстинктын уятырга кирәк». «Хорда катнашу музыкаль аңны һәм кабул итү сәләтен тиз үстерү мөмкинлекләре бирә», — дип яза ул.

Мәктәпләрдә кече күләмле оркестрлар һәм хор коллективлары оештыру, аларда татар халык җырларын өйрәнү һәм башкару яшьләрне тәрбияләүдә бик әһәмиятле чара булыр иде. Мәктәптә актив рәвештә үзләштерелгән күнекмәләр кешедә гомер буена кала. Татар мәктәпләрендә бүген өйрәнелә торган «Туган тел» һәм «Пар ат» җырлары әнә шуның матур мисаллары дип әйтергә кирәк. Әмма бу җырлар әлегә ... әдәбият дәресләрендә өйрәнелә. Кызганычка каршы, музыка һәм җыр дәресләре халыкның җыр хәзинәсен җитди төстә үзләштерү бурычын хәл итми әле.

Музыкаль фольклорны өйрәнүдә укучыларны профессиональ композиторлар иҗаты белән таныштыру да мөһим рольне уйный. Беренче чиратта, әлбәттә, композиторлар тарафыннан хор өчен эшкәртелгән халык җырлары күз алдында тотылырга тиеш. Опера-симфония жанрындагы һәм кече күләмле күп кенә инструменталь әсәрләрнең нигезендә шулай ук халык көйләре ята. Алар белән таныштыра бару яшьләрне җитди музыкага якынайтуда ярдәм итә ала.

Шулай итеп, мәктәп укучыларына һәм яшүсмерләргә музыкаль тәрбия бирүдә халык җырының үзәк урынны алырга тиешлеге аңлашылса кирәк. Яшьләрнең идея-эстетик карашларын формалаштыруда, үз халкының профессиональ музыкасын, бөтендөнья музыка культурасы әсәрләрен үзләштерүгә хәзерләүдә халык музыка иҗатын өйрәнү зарури бер баскыч булып кала.

Ленар Җамалетдинов

# ЭНҖЕ ЧӘЧТЕМ, ЭНҖЕ ҖЫЙДЫМ...

ФОЛЬКЛОРЧЫ ЯЗМАЛАРЫ

Татар халык әкиятләре җыентыкларының иң тулысы һәм абруйлысы булып саналган ике томлык фәнни басмага (I том — 1946 ел, II том — 1956 ел) күз салсак, әкият яздыручылар арасында бер генә хатын-кыз фамилиясен дә очратмабыз. Ләкин бу әле бездә хатын-кыз әкиятчеләр юк диган сүз түгел. Соңгы еллардагы фольклор экспедицияләреннән күренгәнчә, хәзерге әкиятчеләрнең өчтән берен хатын-кызлар тәшкил итә. Биредә мин әнә шуларның берсе — оста әкиятче Миңҗамал әби Гулова турында сөйләргә телим.

Ике һәм аннан артык әкият белгән кешеләрне без, фольклорчылар, әкиятче дибез. Хәзерге вакытта әкият сөйләү гадәте бетеп барганлыктан, әкиятчеләр дә сирәк очрый. Алар әкият сакланган төбәкләрдә дә, гадәттә, авылга уртача бер кеше генә туры килә. Хәлбуки, шундыйлар арасында кайвакыт зур осталар очрый. Оста әкиятче — ул матур һәм җиңел тел белән кемендә унлап әкият сөйләгән кеше.

Кама Тамагы районында унҗиде әкият сөйләгән Хәбибулла Хәйруллин белән очрашкач, мин, бу яңалыкны халыкка да мәгълүм итү теләге белән, аның турында «Социалистик Татарстан» газетасында кыска гына бер мәкалә бастырган идем. Шуннан соң озак та үтми, редакция аша Лениногорский районының Мөэмин-Каратай авылыннан бер хат килеп төште. «Мин, Миңҗамал Гулова, — диелгән хатта, — күп әкиятләр беләм, Хәбибулла ага белән ярышырга телим».

Әбинең хаты шактый кыю язылган. Танылган әкиятчене ярышка чакыра икән — димәк, аңарда әкиятләр унҗиде генә түгелдер. Шулай да ачыкларга кирәк. Сорашып, әбигә хат яздым. Җавап озак көттермәде. Бу юлы ул, әчтәлекләреннән чыгып, әкиятләрнең исемнәрен язып җибәргән. Чыннан да әби «буш булмаска» тиеш.

Шуннан соң СССР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының 1976 елгы экспедиция планына «Лениногорский районы» диган сүзләр язылды, сәфәрнең «май азагы-июнь башы» дип, вакыты да күрсәтелде.

Беркадәр вакыттан соң Миңҗамал әбидән тагын бар хат килде. «Улым, — диган әби, — син берүк чебиләр чыккан вакытта килә күрмә, андый чакта керәстияннең әкият сөйләшергә вакыты булмый».

Хат уйга калдырды. Фәннәр академиясе планы һәм... чебиләр! Нишләмәк кирәк, сәфәр уңышлы булсын, әкиятләр күп язылсын дисәң, алар белән дә исәпләшергә туры килә.

Юлга июньнең 20 сеннән соң чыктым. Лениногорский район советы башкарма комитетындагы иптәшләр (Рөстәм Вильданов, Гакил Вәлетдинов) әкияткә әкият итеп кенә караучылар түгел икән. Фольклорыбызның үзенчәлекле культура байлыгы икәнен, аның гаять үтемле тәрбия чарасы булуын тирән аңлаўлары сизелеп тора. Алар, изге ният белән йөрүемә канәгатьләнү белдереп, эштә уңышлар теләделәр. Гакил иптәш хәтта Мөэмин-Каратайга машина белән илтеп үк куйды.

Авыл калкулыклар арасындагы бер үзәнлектә утыра. Тирә-ягы урман. Тау өстеннән караганда йортлар уч төбендәге кебек күренә. Шул йортларда күпне күргән, җитмешәр, сиксәншәр язны каршылаган кешеләр яши. Бәлки әле өлкәнрәкләре дә бардыр. Ә аларның хәтерләрендә син эзли торган хәзинә яшеренгән. Нәкъ әкияттәгечә! Бу хәзинә матди нәрсә түгел, аны күреп тә, тотып карап та булмый. Киләсе буыннарга калдыру өчен, аны, һичшиксез, матди хәлгә әверелдерергә — ягъни магнитофон тасмасына һәм кәгазьгә язарга кирәк. Халык та бит амбарга кергән ашлыкны гына ризык дип саный.

Фольклор һәр кешедә дә булмый. Әкиятчеләр, әйткәнебезчә, аеруча аз. Аларны да, халык әкиятче икәнен белмәгәнлектән, эзләп табуы җиңел түгел. Моның өчен авылдагы барлык карт һәм карчыклар белән очрашып чыгарга туры килә. Табылгач, аның телен ачу бәхетенә ирешергә һәм, ниһаять, аңардагы материалларны төкмичәчми язып алырга кирәк.

Мөэмин-Каратайда 170 хуҗалык булуын белгән идем. Әнә ул 170 йорт минем күз алдымда. Шуларның кайсындадыр 74 яшьлек Миңҗамал әби яши.

Менә без аның белән ничәнче көн инде бергә утырабыз. Әби үзенең сихри әкиятләрен сөйли, мин тыңлыйм, ара-тирә кайбер кирәкле нәрсәләрне язып куям, магнитофон тасмасы берөзлексез ага да ага.

Очрашасы кешеңне әлегә кадәр беркайчан да күрмәгән булсаң, иң элек күңелдә аның хыялый портреты пәйда була. Дөрес, күзаллау һәр вакытта да чынбарлыкка туры килми. Ләкин Миңҗамал әби, ни өчендер, минем күз алдыма тормыштагыча, нәкъ менә шушы кыяфәттә килгән иде: какча гәүдә, еллар төрле-төрле юнәлештә ерганаклар сызып калдырган озынчарак мөлаем йөз, җылылык сирпелеп торган сөйкемле күзләр... Табигате — тыныч, хәрәкәте — җыйнак, сүзе — ягымлы. Әллә барлык әкиятчеләр дә шундый буламы икән? Чөнки күпме сәфәр йөреп, алар арасында бер генә дорфа кешене дә очратканым булмады.

Әби, җитен чәчләрен яшергәндәй итеп, ара-тирә яулыгын төзәткәләп ала да, тәмам онытылып, сөйли дә сөйли. Мин аны көнгә дүрт сәгатьтән дә артык эшләтмәскә тырышам, талчыкмасын, кәефе гел әйбәт булсын иде, дим. Бу очракта «аз булсын, яхшы булсын» дигән принцип белән эшләү хәерле. Инде чын остага юлыккансың икән, ашыкма, вакытыңны кызганма.

Гаҗәп хәл: сигезенче дистәне ваклаучы әби ару-талуны белми икән. Әкиятләр берсе артыннан икенчесе агылып кына тора. Аларның да ниндиләре генә әле! «Мөлтәки» дигән беренче әкияте үк игътибарны җәлеп итә. Бу әсәрнең «Җилбикә», «Хөрхөр», «Мөлтәл» дигән вариантлары безгә билгеле иде инде. Димәк, болардан тыш «Мөлтәки» дигәне дә бар икән әле. Янә халык арасында киң таралган һәм дистәләп язмасы булган «Үги кыз» әкиятенең дә яңа варианты барлыкка килде. Әкиятләрнең иң күренеклеләрен әби сөйләвендә колхоз радиосы аша да тапшырдык.

Сихри әкиятләр биредәге сихри табигатькә ярашып, аның белән бергә кушылып, бер бөтен булып киткәндәй тоела. Әйе, монда барысы да әкияттәге кебек шул. Бигрәк тә таулары. Аларның һәркайсының исеме бар: Миңҗамал әби тәрәзәсеннән күренеп торганы «Каршы тау» дип атала, аннан соң «Кәҗә тавы», «Түгәрәк тау», «Әсән тавы», «Бәшир тавы», «Юачалы тау»... Аларның һәркайсының легендасы яки риваяте бар. Таулардагы урманнар да төрлечә исемләнгән: «Бөркет кулы урманы», «Юачалы урманы», «Иманлек борыны», «Чаукалык»... Урман эчендәге матур аланнар (биредә



*Миңҗамал әби оныгы Флера белән.*

«аклан» диләр), тау итәкләрендәге болыннар күңелгә аерым рәхәтлек бирәләр. Кыргый җәнлек-җанварлар да шактый монда: пошилар (биредә — «моши»), тау кәҗәләре, сыркалар, бүреләр... Инде таулардан агып чыга торган чишмәләрне бу төбәкнең бизәге дияргә мөмкин. Аларның кайберләрен елга дип тә йөртәләр. Исемнәре генә дә ни тора: «Күлле чишмә», «Ямщиклар елгасы», «Аугалак», «Кара бия», «Шобагалы», «Рәхмәнкол бабай чишмәсе»... «Зирекле» һәм «Кирәмәт» сулары торбалар буйлап авылга килгән. Бу якларда минераль сулы чишмәләр дә бар. Мөэмин-Каратайдан өч километр ераклыкта шундый шифалы чишмәсе, сихәтле ләме булган урында атаклы Бәкер курорты урнашкан.

Мөэмин-Каратайда гомер иткән бер бабай: «Без җәннәттә яшибез икән», — диде. Бу сүзләр белән килешергә туры килә. Ул күптән түгел Төркмәнстанга кунакка барып кайткан һәм үзенең гомер буе яшәгән җирен яңадан «ачкан». Шулай шул: үзеңне, үз туган җиреңне ныграк аңлау өчен, кайчак читкә чыгып кайтырга да кирәктер.

Әнә шундый тышкы гүзәллекнең, матди байлыкның эчке гүзәллек, рухи байлык белән бәйләнеше тыгыз булса кирәк. Ләкин рухи хәзинәгә игелекле мөнәсәбәт, аны ярату, хөрмәт итү булмаганда, кеше барыбер буш булып кала. Кайвакыт шул бушлыкны аклау өчен сәбәп эзләп, тормышның авыр булганлыгын искә төшерергә яратучылар да очрый. «Нужаны күп күрдек шул, әкият сөйләшү кайгысы булмады», — диләр андыйлар. Ә ул нужаны кем генә күрмәгән соң? Аларча фикер йөртсәң, әкиятне бүгенгә кадәр яшәтүчеләр кайгы-хәсрәтсез кешеләр булып чыга. Бу алай түгел, әлбәттә. Безнең оста әкиятчеләребез тормышның ачысын-төчесен җитәрлек татыган кешеләр. Шул исәптән Миңҗамал әби дә. Аның авыр тормышта, күп нужа чигеп үскәнлегенә бөтен авыл халкы шаһит.

Миңҗамал әби 1902 елда дөньяга килгән. Туган ае да, көне дә мәгълүм түгел. «Син, кызым, шомырт пешкәндә тудың», — дия торган булган аның әнисе Литафәт. Әтисе Вәлиулла авылның иң ярлы кешеләреннән була. Кечкенә генә өч тәрәзәле иске йорт, ике кәҗә — бөтен дәүләт әнә шуннан гыйбарәт. Җитмәсә, берничә елдан соң Вәлиулла абзый, авырып, гүр иясе дә булып куя. Кечкенә Миңҗамал әнисе белән генә кала. Кечкенә димәктән, кыз чыннан да бик кечкенә һәм зәгыйфь була. «Юклык галәмәтеннәндер инде, мин итсез-нисез туганмын,— дип искә ала Миңҗамал әби үзе турында.— Әни мине кеше булыр димәгән».

Ләкин шушы чандыр кыз укуга бик һәвәс булып чыга. Абыстайга сабакка йөрүче кызлардан өйрәнеп, биш яшендә инде ул яхшы гына укый башлый һәм беркөнне, тугыз яшьлек күрше кызына ияреп, үзе дә абыстайга бара. Бу көнне аңарда үз-үзенә ышаныч тагын да ныгый: баксаң, зур үк кызлар «кәлиматен»не иҗекләп кенә укыйлар икән ләбаса, ә кайберәүләре бөтенләй дә укый алмый.

Миңҗамалның әнисе тукмак хәтле генә кызының сабакка йөрү теләгенә каршы килми — аны үз ирегенә куя. «Үзем «бу кәгазьгә нәрсә язылган икән?», «бу китап нәрсә турында икән?» дип, әрнеп гомер иттем, инде, кызым, син дә минем кебек надан булма», — ди ул.

Кызчык, башкалар кебек үк, көнгә ике мәртәбә абыстайга йөри. Иртәнге сабак таң беленгәч үк башлана. Төшке сабак дигәненең вакытын билгеләү өчен, абыстай песи күзенә карарга кушып җибәрә. Песинең күз карасы нечкә генә сызык булып калгач, кызлар абыстай өенә янә җыелалар. Бу юлы инде дәрес кечкә кадәр дәвам итә.

Абыстайга ике ел йөргәннән соң, Миңҗамал дүрт ел дәвамында мулладан сабак ала. Һәм шуның белән аның «мәктәп» еллары тәмамлана да. Йортта ир кеше булмаганга, бөтен авырлык әнисе белән аның җилкәсенә төшә. Яшь кыз тормышны җигелеп тарта башлый. Ләкин белемгә сусау кимеми кызда. Үзе киндер эрли, ә каба төбендә — китабы. Эрли дә, бер үк вакытта укый да.

Кичләрен әнисе кызына әкиятләр сөйли. Миңҗамалның күңелендә бөтенләй яңа, сихерле бер дөнья ачыла. Әкиятләрне ул йотылып тыңлый. Матур да алар, шул ук вакытта куркыныч та.

Менә, әти-әниләре кунакка киткәч, өйдә үзләре генә калган җиде кыз янына кеше ашаучы убырлы карчык юнәлә. Җитмәсә, юлда мөнәҗәт әйтә-әйтә атлый:

**Каптыр-коптыр итәрем,**
**Кабык күпер кичәрем,**
**Бер өйдәге җиде кызның**
**Җидесен дә йотарым.**

Миңҗамалның тәненә салкын йөгерә, эче чымырдап китә. Аның күз алдында куркыныч, шыксыз йөзле карчык пәйда була. Әнә карчык, юл тузанын туздырып, эре-эре атлап бара, мөнәҗәтен әйтә-әйтә, туп-туры Миңҗамалга таба килә. Кызчык, куырылып, аякларын итәге астына яшерә, күзләрен чытырдатып йома, ләкин барыбер тыңлый.

Әнисе ягыннан туган тиешле Зөфәр һәм Сабит абзыйларын да аптыратып бетерә кыз: «Әкият сөйлә дә әкият сөйлә!» Нишләсеннәр, сөйлиләр абзыйлары. Бигрәк тә Сабит абзыйсы әкияткә маһир кеше була. Миңҗамал әби үзе сөйләгән әкиятләрнең кайсыларын кемнән ишеткән булуын бүген дә бик яхшы хәтерли. Төлке белән сандугач, бүре балаларын укыткан төлке, кәҗә тәкәсенә атланып сугышка барган таз малай, төрле суратка керүче әби турындагы әкиятләрне әнә шул Сабит абзыйсы сөйләгән булган.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Миңҗамал, авыл буенча хат язып йөреп, өенә дә кайтып керми. Яраталар аның язуын. Чөнки кыз «тагын нәрсә языйм» дип, яздыручының әйткәнен генә көтеп тормый, үзе белеп яза, хәтта аны янында да тотмый, «бар, эшеңне эшлә» дип җибәрә торган була. Хәрефләрне көчкә-көчкә генә куя алган кайбер ярым надан солдатларның фронттан килгән хатларын уку аеруча кыенга туры килә. Ләкин Миңҗамал барыбер укый. Хәрефләрне ничек дөрес язарга һәм ике сүз арасында буш урын калдырырга кирәклеген аңлатып, сугышчыларга үзе дә хатлар яза.

Янә дә күп сулар ага, яңадан-яңа вакыйгалар чыга. Октябрь революциясе, гражданнар сугышы... Инде Миңҗамал да буй җиткергән кызлардан санала, аңа төрле яктан яучылар килә башлый. Ләкин ничек килсәләр, шулай борылып та китәләр. «Инәйне ташламыйм дигән шәфкатем бар күңелемдә, беркемгә дә кияүгә чыкмыйм», — ди кыз, катгый итеп.

Менә Мөэмин-Каратайга укытучы булып Гыйльметдин исемле яшь кенә егет килә. Авылның хәлле кешеләре аңа үзләренең кызларын димлиләр. Ләкин Гыйльметдин:

«Миңа бай кызы түгел, ә укымышлы кыз кирәк»,— ди һәм Миңҗамалга өйләнергә теләге булуын белдерә. Сабит абзыйсы да: «Гыйльметдингә бар син, сеңелем,— ди,— минә тиздән өйләнермен дә әниеңне үзем тәрбияләрмен».

Әмма бәхет насыйп булмаган икән: күрше авылдан сәнәкчеләр килеп, Гыйльметдинне чанага салып алып китәләр дә чәнчеп үтерәләр. Ул гына түгел, Сабит абзыйсы да шулар кулыннан ук һәлак була, бары тик истәлеге булып аның җырлары гына кала. «Сабит абзыемның ике җырын гомерем буе күңелемдә сакладым»,— ди Миңҗамал әби һәм аларны көйләп тә күрсәтте. Бу борынгы җырларның берсендә түбәндәге юллар бар:

**Сәхра капкасының төпләрендә**
**Әлванский җимешләр ашадым;**
**Зифа буйларымны бер күрсәтеп,**
**Гомерлеккә хәсрәтләр ясадым.**

Миңҗамал үзенең киләчәк язмышын Харис исемле егет белән бәйли. Гаилә корганнан соң, тормыш мәшәкатьләре тагын да арта. Бер-бер артлы дүрт бала дөньяга килә. Ә еллар һаман да авыр булып кала.

Колхоз төзелгәндә Миңҗамал гаризаны беренче булып бирә һәм кая кушсалар шунда эшли: яшелчә үстерә, кирпеч суга, урман кисә, дуңгыз карый, сабан сөрә, колхозның беренче савымчысы була. Кайда эшләсә дә сынатмый, гел ударница исемен йөртә.

— Бүләккә бер елны бозау, икенче елны сарык бирделәр,— ди әби. — Шулай итеп, сыерлы да булдык, сарыклар да үрчеде, эшләп кеше үлми икән. Ни булса, барысын да колхоз бирде миңа.

Саулыгы какшаса да, Ватан сугышы елларында ясле балаларын тәрбияләгән ул. Шуның өстенә өйдә кул хезмәте белән шөгыльләнгән — бик матур паласлар суккан. Авылда аның паласы булмаган йортлар сирәктер. Күрше авылларда күпме тагын! Авыр елларда чабатаны да үзе үргән Миңҗамал әби. Хәзер дә әле ул кул кушырып утырырга теләми: өй җыештыра, гөлләр үстерә, аш-су әзерли, кош-корт тәрбияли — хуҗалыкта эш бетәмени!

Әби әкиятләрне дә, тормыш хәлләрен дә матур итеп, образлы итеп сөйли. Аны тыңлау — җан рәхәте. Әкияттәге диалогларны биргәндә, ул тәмам «рольгә керә» һәм персонажларның һәркайсы «үз тавышы» белән сөйли башлый.

Миңҗамал әби әкиятләрендәге бетемнәр дә без күнеккән традицион бетемнәрдән аерылып тора. Мәсәлән, кайбер әкиятләр болай тәмамлана: «Болар матур гына гомер итеп, максуды морадларына ирешеп, дөньядан үтеп киткәннәр ди... Кичә барып, бүген кайттым, дуга белән печән чаптым».

Мин сорый куйдым:

— Нишләп болар дөньядан китәләр соң? Әкиятләр, гадәттә, «болар әле дә булса рәхәтләнеп яшиләр» дип бетә ич!

Бу турыда әбинең үз фикере бар икән:

— Кешеләр борын-борын заманнан бирле яши алмыйлар,— диде ул. — Ә мин сөйләгән әкиятләр барысы да борын заманда булган хәлләр турында.

Чираттагы әкиятне сөйләп бетергәч, әби җитез генә урамга чыгып китте дә озакламый сөйләнә-сөйләнә килеп тә керде:

— Быел казлар белән бик җәфаландым, улым. Ике ала бәбкә чыккан иде. Шуларны ата каз минеке түгел дип талый гына бит. Атасы талагач, анасы да талый. Каз җәмгыяте бик кызык ул: төсне аера, калганына башы җитми. Бер көнне шулай балачагага ышанып калдырган идем, шул арада берсен тәки талап үтергән бит. Шуннан соң ата казның аягына озын бау тагып җибәрдем. Аза башласа, коймага бәйлим дә куям. Әле дә менә шуны бәйләп кердем.

Әби үзенең урынына җайлап кына килеп утырды да яңа әкиятен башлады. Шул арада оныгы — унбер яшьлек Флера — кайтып керде. Артыннан эреле-ваклы бер

төркем бала-чага ияргән. Авыл балаларына хас тыйнаклык йөзеннән бусага янында туктап калган шаян тиктормасларга якты чырай күрсәтеп түргә ымлау җитә калды — тиз генә шыбырдашып уздылар да, ничек сыйганнардыр, бер диванга урнашып та беттеләр. Кичә алар Миңҗамал әбиләренең әкиятен урамда багана башындагы репродуктордан тыңлаганнар иде. Хәзер инде менә әбинең үзеннән ишетергә кергәннәр. Җитмәсә, әкияте дә башка.

Мин утыз минут саен магнитофон тасмасын алыштырып торам. Әби шул арада, «Зирекле» чишмәсенең суына катык болгатып, салкын әйрән ясап бирә, сүз җаенда бер тамчы да аракы капмый торган кияве Сабирҗанны горурланып телгә ала, я булмаса, егерме өч ел бергә яшәп тә, бер генә авыр сүз дә әйтмәгән килене Әнвәрияне мактап куя. Шунда ук, килennең тиздән төшкә ашка кайтачагы исенә төшеп, җәһәт кенә самавар куеп җибәрә.

Өйдә үзе генә чакта Миңҗамал әби берничә мәртәбә борынгы җырларны җырлады.

**Биек тә генә тауның башларында**
**Яфрак өчен үскән яшь каен,**
**Җаныем, агымсу —**
**Үргә йөзалмыйм,**
**Күрми түзалмыйм.**

— Без яшь чакта «Сәгыйдә» көе бар иде, — диде ул. — Ничә ел көтәм инде, радиодан шул көйне һаман җырламыйлар.

**Алмалыктин алма алырга,**
**Сәгыйдә дускаем,**
**Камышлыктан юл салдым шул, гөлкәем.**
**Сез дусларны уйлый-уйлый,**
**Сәгыйдә дускаем,**
**Камыштин сары калдым шул, гөлкәем.**

Әнә шулай юл уңаенда Миңҗамал әби башкарган көйләр белән җиде җыр язып алынды.

Кайбер тәнәфесләрдә әби үзенең гөлләренә су сибә. Ә гөлләре бик күп аның. Барысы да шау чәчәктә утыра.

— Ике шатлыгым бар минем, — ди әби, — берсе — чебиләр, икенчесе — гөлләр. Гомер буена кына гөлен яраттым.

Әби гөлләр турында тәфсилләп, онытылып сөйли. Бу вакытта аның шагыйрь йөрәкле булуы аеруча сизелә. Табигате белән шагыйрь кешеләр бик күп бу **дөньяда.** Шуларның бик азы гына шигырь яза. Калганнары язмыйлар, ләкин алар барыбер шагыйрь җанлы булудан туктамый. Миңҗамал әби дә әнә шундый язмый торган шагыйрьләрнең берсе. Хәер, язмый торган дию бик үк төгәл дә булмастыр. Ара-тирә үзе өчен генә шигырьләр дә, җырлар да чыгаргалый ул. Мәсәлән, аның Ташкентта олы кызында кунакта вакытта чыгарган алты куплетлы «Ташкент калалары» дигән җыры бар. Үзбәк кияве Ильяс әллә нигә бер килгән әбисен озаграк тотарга тели, әби исә берничә көннән үк кайту ягын каера. Шул чакта туган авылын сагыну хисе аның күңеленнән җыр булып ташып чыга:

**Ташкент калалары бигрәк матур,**
**Шундый микән башка калалар!**
**Кошлар очып җитмәс җирләргә дә**
**Китерә икән газиз балалар.**

**Ташкент калалары гел таш кына —**
**Йортка чыксам, ташка абынам,**
**Ташкент калалары бик матур да,**
**Туган авылымны сагынам.**

**Ташкент калалары зур булса да,**
**Кайбер урамнары киң түгел,**
**Ташкент калалары бик матур да —**
**Туган авылыма тиң түгел.**

Туган җирен, туган авылын, аның гүзәл табигатен ярату әбинең балаларына да күчкән. Мәсәлән, улы Хаҗип авылдан китүне уена да кертмәгән. Ул унике яшеннән үк колхоз атларын карый. Армиядә хезмәт иткәндә дә бар сораштырып язганы атлар һәм таллар була. Миңҗамал әби аңа, хат белән бергә, конвертка тал яфраклары да салып җибәрә. Армиядән соң да һәм бүген дә Хаҗип яраткан эшендә.

Әбинең ишеген шакыганда, мин һәр көнне бүген инде соңгы эш көнебез булыр, дип уйлыйм. Ләкин ул мине: «Улым, тагын бер әкият искә төште бит әле», яисә: «Тагын ике әкият табылды лабаса»,— дип каршылый. Бик яхшы. Табыла торсын. Әкиятләр саны инде егерме дә булды, егерме биш тә булды, утыздан да узды, ләкин әбинең хәтер сандыгындагы хәзинәнең һаман да беткәне юк. Әкиятләре нинди диген әле! Пушкин әйтмешли, һәркайсы бер поэма.

Фольклор әсәрләре халык телендә яши. Бу җәүһәрләр чыннан да җәүһәр булсын өчен, аның бөтен поэтик гүзәллеге чагылсын өчен, аларны чын талант ияләреннән язып алу зарур. Миңҗамал әби, минем карашымча, әнә шундый талантларның берсе.

Әкият сөйләү беренче карашка һәркем башкара алырдай гади эш булып тоелса да, чынлыкта ул аерым шәхесләр эше. Бу әсәрләрне талантлы башкару өчен, минемчә, төп өч шартның булуы зарур. Беренчесе — әкиятне ихлас күңелдән ярату. Икенчесе — бик яхшы хәтерле булу. Өченче шарт — әкиятләрне әледән-әле сөйләп тору. Миңҗамал әби үзенең әкиятләрен кич утырып кул эше эшләгәндә дә, басуда ял арасында да, хәтта больницада ятканда да сөйләгән. Балалары, аннан соң оныклары, шулай ук күршедәге балалар аның әкиятләрен тыңлап үскәннәр. Аларның кайсы да булса: «Әби, әкият сөйләче» дисә, ул аларның үтенечен һәр вакыт канәгатьләндерергә тырышкан. Фәрхәт исемле малай аның хәтерендә аеруча нык уелып калган.

— Бигрәк тә ярата иде инде әкиятләрне, — дип искә ала әби аның турында. — Бер мәлне башым бик авыртканда килеп керде бу: «Әби, әкият сөйләмәссеңме икән дип килгән идем», — ди. «Улым, мин әйтәм, бүген башым бик авырта шул, җитмәсә, чәй эчәргә шикәр-конфетым да бетеп киткән». Малай йөгереп чыгып китте дә бераздан тагын килеп керде. Минем өчен әнисеннән бер уч конфет сорап алган. «Әби, мин шофер булачакмын, үзеңне машинага утыртып әллә кайларга алып китәрмен әле»,— дия иде. Чыннан да әлеге малай тәки шофер булды бит. Хәзер Лениногорскида автобус йөртә. Сүзендә торды: автобусы белән килеп, кунакка алып китте үземне, биш кич кунып кайттым.

Әйе, әкият ярату — һәр сабыйның табигатенә хас сыйфат. Аны хәтта табигый ихтыяҗ дияргә мөмкин. Атаклы балалар язучысы Корней Чуковский үзенең «От двух до пяти» дигән китабында: «Җиде-сигез яшькә кадәр әкият һәр нормаль бала өчен иң кирәкле азык — тәмле-томлы нәрсә түгел, бәлки бик мөһим һәм гаять туклыклы икмәк»,— ди. Әкиятнең зарур нәрсә булуы бик күптәннән танылган. XVIII гасырда яшәгән немец философы һәм мәгърифәтчесе Гердер: «Әгәр сабыйга беркайчан да әкият сөйләмәгән булсалар, аның күңелендә эшкәртелмәгән кыр кала һәм шуннан соңгы елларда инде бу кырны эшкәртү мөмкин булмаячак», дигән.

Ышанып әйтергә мөмкин, Миңҗамал әби тәэсирендә булган Фәрхәтләрнең күңелендә «эшкәртелмәгән кыр» калмаган. Югыйсә, олылар рәтенә кергән, инде үзе әти булган кеше сабый чакта әйткән сүзен онытկан да булыр иде, һич югында, әлеге вәгъдәсен хәтерләп, елмаеп кына куяр иде. Ә әкият аны игелекле һәм мәрхәмәтле, сүзендә нык тора торган чын кеше итеп тәрбияләргә булышкан.

... Менә мин Миңҗамал әбиләрнең кызгылт-кәрән төстәге капкасын соңгы мәртәбә ачып керәм. Бүген инде әкият язмыйбыз, бары тик саубуллашасы, әбигә тагын бер кат рәхмәт әйтәсе, аңа сәламәтлек һәм озын гомер теләргә генә калды.

Әбине, бизәкле яулыгын бәйләтеп, берничә мәртәбә фотога төшердем.

— Үзеңә бик зур рәхмәт инде, улым, — диде әби. — Югыйсә, үлеп-китеп китәрмен дә әкиятләрем эзсез югалыр дип борчылып тора идем.

Әйе, болай дип теләсә кем әйтә алмый. Үзе турында түгел, киләчәк турында кайгырта әби. Моны хәтта дәүләт биеклегеннән торып фикерләү дип бәяләргә мөмкин.

Казанга кайткач, озак та үтми, Миңҗамал әбидән хат килде. Гарәп хәрефләре белән тигез итеп язылган бу хатта илле өч табышмак теркәлгән һәм янә дә җиде әкиятнең искә төшүе турында хәбәр ителгән иде.

Әйе, мондый бай репертуарлы информаторга соңгы унбиш елда бер генә экспедициябезнең дә юлыкканы юк иде әле. Гомумән, институт оештырган экспедицияләр тарихында да бу икенче очрак кына.

... Колхоз радиосыннан чыгышта мин Миңҗамал әби турында хөрмәткә лаек колхоз ветераны буларак түгел, бәлки оста әкиятче буларак кына сөйләдем һәм аны «авылыгызның горурлыгы» дип атадым. Соңыннан уйлап куйдым: арттырыбрак җибәрмәдемме икән? Шул вакыт атаклы рус әкиятчеләре исемә килеп төште. Иван Федорович Ковалев (1885—1966), Анна Куприяновна Барышникова-Куприяниха (1868—1954), Анна Николаевна Королькова (1893 елда туган) һ. б. әкиятчеләр белән илебезнең төрле шәһәрләрендә махсус очрашулар оештырылган, аларны атаклы кешеләр тыңлаган, алар Язучылар союзына член итеп алынганнар һәм, ниһаять, хөкүмәт орденнары белән бүләкләнгәннәр, ә әкиятләре аерым китаплар булып басылып чыккан. Шуларны уйладым да тынычландым: юк, арттырмаганмын икән, хәтта әле барысын да әйтеп тә бетермәгәнмен, чөнки халкыбызның рухи җәүһәрләрен күңелендә кадерләп саклаган Миңҗамал әби — ул үз авылының гына түгел, хәтта районның һәм бу төбәкнең генә дә түгел, бәлки гомумән татар фольклорының, милли культурабызның да горурлыгы ич.

Марсель Әхмәтҗанов

# ТАТАР ШӘҖӘРӘЛӘРЕ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ

Шәҗәрә — гарәп теленнән кергән сүз. Татарча агач дигән мәгънәне белдерә. Буыннарның өзлексез алмашынып торуын күп ботаклы агачка охшатып, бабаларыбыз нәсел тарихы турындагы истәлекләрне нәсел агачы яки шәҗәрә дип атаганнар. Шәҗәрәләр язма һәм телдән сөйләү рәвешендә буыннан-буынга күчә килгәннәр.

Гасырлар дәвамында татар шәҗәрәсе күп үзгәрешләр кичергән. Бездә шәҗәрәләрнең аерым нәсел, гаилә тарихына караган төрләре аеруча киң таралган. Шул ягы белән ул башкорт, казакъ, төркмән халыкларындагы ыру-кабилә шәҗәрәләреннән нык аерылып тора. Ыру-кабилә мөнәсәбәтләренең иртә җимерелүе бездә андый төр шәҗәрәләрнең югалуына китергән. Алар урынын ыру шәҗәрәсенең бер тармагы булган нәсел шәҗәрәсе алган. Билгеле, ыру шәҗәрәсе кинәт юкка чыкмаган, аның аерым эзләре урта гасыр татар морзаларының, шулай ук тарханнарның нәсел язуларында бик озакка хәтле сакланган. Тик бу язмаларның күбесе безгә килеп җитмәгән. Мәгълүм булганнарыннан Баранс, Олыс бий нәсел язуларында ыру шәҗәрәсе билгеләрен очратырга мөмкин.

Нәсел язуларының безгә килеп җиткән иң борынгы язма фрагментлары XIII—XV гасырлардан калган болгар-татар эпиграфика истәлекләрендә очрый. Дәүләт архивларында һәм басма чыганакларда XVII гасырда язуга беркетелгән шәҗәрә үрнәкләре шактый. XVIII—XIX гасырларга караган чыганаклар саны исә тагы да ишлерәк.

Берничә гасыр дәвамында татар шәҗәрәләре сыйфат ягыннан акрынлап үзгәрә килгән. Җәмгыять тормышында барган тарихи үзгәрешләр шәҗәрәләрне дә читләтеп узмаган, билгеле. Бу үзгәрешләрнең күбесе антропонимика һәм титулатура өлкәсендәге яңалыкларга кайтып кала. Ләкин шәҗәрәләр форма һәм төр ягыннан XIX гасырның икенче яртысына хәтле биз әз үзгәргән.

XIX йөзнең икенче яртысыннан соң нәсел шәҗәрәләренең яңа төрләре барлыкка килә (шул ук вакытта традицион нәсел шәҗәрәләре дә яши бирә). Элеккеләреннән аермалы буларак, нәсел язуларына теге яки бу фамилиягә бәйле тарихи хәбәрләр өстәлә башлый. XIX гасырның икенче яртысында шушы яңа төр нәсел язулары җирлегендә региональ тарих, ягъни авыл, төбәк тарихына караган язмалар күбәя. Бу урында кыскача гына булса да региональ тарих формалашуга китергән сәбәпләрне күрсәтеп узу кирәктер.

Тормыштагы яңа тенденцияләр тәэсирендә һәм милләт булып формалашу процессында татар халкының үз тарихы белән кызыксынуы көчәя. Бу — бер. Икенчедән, Х. Әмирхан, Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйриларның тарихи хезмәтләре тәэсирендә региональ тарихларга ныклы җирлек хәзерләнә. Соңгысы аеруча зур игътибарга лаек. Беренче тарих китаплары язып бастырган мәгърифәтчеләр үз әсәрләрендә татар шәҗәрәләренең бай мирасын бик киң файдаланганнар. Бу үрнәк һәвәскәр тарихчылар

өчен беренче тәҗрибә булган. Сакланып калган документлар Мәрҗанинең җирле тарихчылар белән тыгыз бәйләнештә булганлыгын раслыйлар [1].

Авыл, төбәк тарихларының беренче үрнәкләре үзләренең төзелешләре ягыннан Х. Әмирхан, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри китапларын хәтерләтәләр. XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башларында бу тарихларның кайберләре басылып та чыккан. Мисал төсендә М. Тукаевның «Тарихы Эстәрлебаш», М. Сүнчәләйнең «Иске Кыйышкы тарихы» исемле хезмәтләрен, Р. Фәхретдиновның Сәгыйт бистәсе, К. Насыйриның Зөя өязе, А. Блашовның Әҗе авылы хакындагы китапларын күрсәтергә мөмкин. Кульъязма хәлендәге төбәк тарихлары тагы да күбрәк булган, тик аларның бик азы гына фәнни китапханәләргә эләгеп калганнар. Казан китапханәләрендә саклана торган әһәмиятле кульъязмалар арасында Әхмәт бине Хафыйзетдинның 1910—11 нче елларда язылган «Тарихы Бәрәңгеви», К. Биккуловның «Яңа Тинчәле тарихы», И. Урмановның «Әҗе авылы тарихына материаллар», И. Туйкинның «Зәй-Каратай тарихы» кебек әсәрләр бар.

XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башларында авыл тарихларын җыйнау һәм булдыру юлында күренекле татар галиме Р. Фәхретдинов зур эш башкара. 1975 елда Казан шәһәрендә Р. Фәхретдиновның укытучы Ф. Хәдимовка адресланган бер хаты табылды. Ф. Хәдимов галимгә «Бәйрәкә авылы тарихы»н язып җибәргән булган. Хатны тулысы белән китерәбез:

«Хөрмәтлү мулла [2] Фәхертдин әфәнде! Тәхия [3] вә сәлам. Ошбу ел беренче май тарихлы «Бәйрәкә каръясе хакында»гы тарих сәхифәгез сәламәт килүб тапшырылды. Матлубемезнең [4] фәүкында [5] гүзәл бер әсәр булган. Үз сәмаңез берлә... «Асар»га дәреҗ кылырмын [7]. Сезгә тәкърар рәхмәт укучы. Моннан соң шундый тарихи хәбәр ишетсәңез, йәки иске йазулар күрсәңез, хәбәр итүб торуыңызны арыз кыламыз... [8].

Ризаэтдин бине Фәхертдин. 1925 ел, 18 май, Уфа, Тукай, 5.»

Соңгы елларда уздырылган археографик экспедицияләр вакытында әлегәчә мәгълүм булмаган күп кенә авыл тарихлары табылды. Алар арасында Г. Габәши тарафыннан төзелгән «Чыршы авылы тарихы», Ф. Хәдиминең «Бәйрәкә тарихы», Г. Заһидуллин язган «Бәрәзә авылы тарихы», Г. Хәмитовның «Түбән Ушма һәм Тат. Парзы авыллары тарихлары», Афзалетдин бабайның «Айдар авылы тарихыннан» язмалары (соңгы кульъязманы филология фәннәре кандидаты Ф. С. Фасеев тапкан), Нурдидә апа Гаффарованың «Күгәй авылы хакында» хәбәрләре, Г. Фәтхуллин язган «Иске Шалты тарихы» һ. б. кульъязмалар бар.

Татар шәҗәрәсе нигезендә региональ тарих жанры барлыкка килү хакындагы фикерне башлап М. Усманов язып чыккан иде [9]. Ләкин авыл тарихлары, жанр буларак, әле бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән һәм барланмаган. Соңгы елларда авыл тарихларының билгесез кульъязмалары табылу аларны жанр буларак системалы төстә өйрәнү мөмкинлеген бирә.

Биредә авыл тарихларының эволюциясе, аларның төзелеше һәм әһәмияте турындагы кайбер фикерләр әйтелер.

XIX гасырның соңгы чирегендә аерым нәселләрнең тәфсилләп язылган һәм авыл тарихы исеме белән йөртелә торган шәҗәрә үрнәкләре барлыкка килә. Шушы ук вакытта нәсел шәҗәрәләрен берләштергән күмәк җәмәгать шәҗәрәләре җыентыклары да күренә башлый. Шәҗәрәләр үсешендәге бу этап 1910 нчы елларга хәтле дәвам итә. Аерым нәселләрнең киң планда язылган тарихларыннан Әхмәт бине Хафыйзетдинның Урмат нәселенә багышланган «Тарихы Бәрәңгеви» әсәрен, М. Тукаевның «Тарихы

[1] Семипалат шәһәреннән Әхмәтвәли Монасыйпов, Мәрҗани үтенече буенча, «Симипулат тарихы» исемле әсәр язган. («Шура» журналы, 1915 ел, 2 сан, 47 бит); М. Усманов Ш. Мәрҗани белән Гали Чокрый арасындагы бәйләнеш турында яза. («Агыйдел» журналы, 1966 ел, 3 сан, 81—85 битләр.)

[2] Мулла — бу очракта укымышлы, галим кеше мәгънәсендә кулланылган.

[3] Тәхия — яхшы теләкләр.

[4] Матлуб — теләнгән, эзләнгән.

[5] Фәукында — артыгы белән.

[6] Сәмаңез — буйсынып, буенча.

[7] Дәрҗ кылырмын — кертермен, бастырырмын.

[8] Арыз кылу — сорау, үтенеч.

[9] Татарские исторические источники XVII—XVIII вв. Рус телендә, Казан, 1972 ел, 194 бит.

Эстәрлебаш» (Тукай нәселенә багышланган), Растмөхәммәд шәҗәрәсенең Яңа Кенәр вариантын (Н. Ибраһимов тапкан) һ. б. күрсәтергә мөмкин. Кумәк шәҗәрә җыентыкларыннан Олы Мәңгәр авылының 49 нәселне берләштергән шәҗәрәсе билгеле.

1910 нчы еллардан соң күмәк шәҗәрәләр төзелешендә яңалыклар күренә башлый. Үсешнең бу этабы XX гасырның 20 нче елларына хәтле дәвам итә. Күмәк шәҗәрәләрнең 1910 елдан соңгы үрнәкләрендә төп үзгәреш шул, аларда нәсел таблицалары белән янәшә авылның тарихына бәйләнешле киң мәгълүматлар бирелеп бара. К. Биккулов тарафыннан төзелгән «Яңа Тинчәле тарихы», мәсәлән, шундый әсәр. Ләкин бу төр шәҗәрә-тарихларның саны кимрәк.

1920 нче еллардан соң шәҗәрә-тарихлар җирлегендә авыл тарихлары формалашып җитә. Үзләренең элгәреләреннән аермалы буларак, бу дәвердә аларда күп тармаклы нәсел таблицалары бирелми инде. Күп очракта авылга нигез салган кешеләр һәм аларның соңгы нәселләре генә аталып үтелә. Бу тарихларның үрнәкләре чагыштырмача күбрәк мәгълүм: Чыршы тарихы, Бәрәзә тарихы, Бәйрәкә авылы тарихы, Түбән Ушма тарихы, Котлымбәт авылы тарихы, Айдар тарихы, Шалты тарихы, Нарат Елга тарихы һ. б. шушы төркемгә керәләр.

Нәсел шәҗәрәләре кыска гына тарихи чор эчендә (100 ел чамасы) күмәк шәҗәрә, тәфсилле нәсел шәҗәрәсе, шәҗәрә-тарих һәм авыл тарихы дигән дүрт яңа тармакның үсүенә сәбәп булганнар. Яңа төрләрнең барлыкка килүе прогрессив карашлы татар галимнәренең һәм укытучыларының эшчәнлегенә бәйле.

Авыл тарихлары, революциядән соң тәмам формалашып җитеп, яңа жанр буларак яши бирәләр, камилләшәләр. Аларның жанр буларак берлеге тема ягыннан гына түгел, төзелешләренең тәңгәллеге белән дә раслана. Авыл тарихларының (шул исәптән шәҗәрә-тарихларның да) төзелешенә күз салсаң, аларның күп кенә уртак яклары булганлыгы ачыклана. Алар нигездә түбәндәге схема буенча язылганнар:

1. Авылның географик урыны, җирләре, борынгы табигый хәле.

2. Авылга нигез салган бабалар, аларның хәзерге нәселләре, авылның исемен халык этимологиясеннән чыгып аңлату.

3. Авылның җир-сулары белән бәйләнешле легендалар.

4. Мәчет, мәктәп-мәдрәсәләр тарихы, аң-белем таралышы, авылның атаклы шәхесләре.

Бу жанрның чыганак базасы күп төрле булган. Тарихлар борынгы риваятьләр, шәҗәрәләр, рәсми документлар, метрика дәфтәрләре, эпиграфик материаллар һәм вакыйгаларның шаһиты булган кешеләрнең истәлекләре буенча язылганнар. Авторлар материалга сак караганнар. Мөмкин булган очракта аларны рәсми документлар белән чагыштырулар үткәргәннәр. Яңа Тинчәле авылы салыну турындагы легендада авылны өч кеше нигезләгән дип әйтелә. Ләкин авыл тарихын төзүче бу хәбәрнең рәсми документ белән туры килмәвен, авылга башта 23 кеше килеп утырганын исбатлый. Шуныңсы әһәмиятле, легендада әйтелгән исемнәр документтагы исемнәр белән туры килә. Димәк, легендада күпмедер күләмдә реаль тарих чагылган дигән сүз.

Авыл тарихларының тарих фәне өчен әһәмияте күптән исбат ителгән нәрсә. Алардагы хәбәрләрне бүтән чыганаклар ярдәмендә гомумиләштерсәң, кыйммәтле фәнни нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Бу материаллар шулай ук халыкның рухи тормышыннан күп кенә хәбәр бирәләр. Бәрәзә авылы тарихында, мәсәлән, төрле мәҗүсилек йолалары турында язылган. Бәйрәкә авылы тарихы бу авылда 20 нче елларга хәтле яшәп килгән хатын-кызлар җыены турында хәбәр итә.

Авыл тарихлары тел тарихын өйрәнүчеләр өчен дә кыйммәтле чыганак булып тора. Беренчедән, аларда борынгы кеше, авыл, җир-су исемнәре чагылса, икенчедән, кайбер диалекталь үзенчәлекләр урын ала. Бәрәзә авылы тарихы моның кызыклы мисалы булып тора. Бу язма истәлектә Казан арты сөйләшләре өчен хас булган «ң» урынына «н» авазы кулланып сөйләшү язуда чагылган, шул урынга хас булган тушы (шушы), тиш (чиш) кебек диалектизмнар да урын алган. Шулай ук әдәби нормага сыймаслык «җ»лаштыру (җул, җар, җорт һ. б.) да күзгә ташлана.

Шулай да диалектизмнар белән аерылып торган истәлекләрнең саны күп түгел, алар башлыча Казан артында ешрак очрый. 20—30 нчы еллардагы истәлекләр революциягә хәтле гамәлдә булган әдәби тел йогынтысында язылган. Аларда кайбер архаик сүзләр һәм рус теленнән кергән алынмалар да шактый урын алып тора. Авыл та-

рихларына ясалган күзәтү бу материалларның әһәмиятле тарихи һәм тел тарихы чыганаклары икәнлеген раслыйлар. Түбәндә региональ тарих үрнәкләреннән кайбер өзекләр китерелә.

## БӘРӘЗӘ АВЫЛЫ ТАРИХЫ[1]

*Кулъязмадан өзекләр*

«... Йәнә мәшһүр нәсел Таракан Ишморад мулла нәселе. Мондан Тараканнықылар, Ишминекеләр таралмышдыр. Ганинекеләрне Бүре Гани дип йөргәнләр. Бабалары мирзадан, Алат авылы янында мирза шәһәре — Мугай[2] шәһәре диләр, шундан күчеп килеп утырганлар. Азанчы Хөснетдин бабалары да Мугай шәһәрендән килгән булган. Мөселманнар арасында аралаш яшәгән мәҗүси бабалар язылa. Мари белән мари чирмешләре булмыш. Мари исемендә йөрүчеләр бар да мари балаларыйдан: Тәхфи, Фәтхулла, Шәмси вә башка балалары мариныкылардыр. Мирафа мәҗүсидер. Ишәү, Ишбай баба да мәҗүси кызын никахламышдыр. Шәмси Әтәчләр бабалары [белән] Вәлиләр бер тамыр. Таҗи Тинтәкләр, Фәтхулла Мари, Галәми Мөхетдине, Нәзирнекеләр пләмәсе белән Нәзир нәсәбе, Мәҗит, Насир, Гобәй, Сиражи, Миңлебай — бар да бер нәсел. Шәмәк углы Мөхәммәдрәхим чирмеш кызын никахлаган. Йәнә Исмәгыйль исемле кеше булган, Исмәй дип йөреткәнләр...

1802 елда Бәрәзә бик көчле ут казасы белән казаланган. Таракан Ишморад булган урын Батыршалар урынында булган. Зур йортлы Ишминекеләр бабалары булган Ишморад ишан урманда... йөргәндә Әлкәй чишмәсе янында качкын булып ятучы кешеләрнең ашъяулыклары җанындагы чәйнекләрен алып кайткан. Шул ачудан качкынларның берсе, хатыннар киеме киенеп, кечкенә арба тартып, җалтыратып тәңкә тагып, арыш урагы өстендә һәр халык басуда, төш вакыты, кыйбладан искән эссе, көчле җилдә Ишморад муллага ут салган...

## ТҮБӘН УШМА ТАРИХЫННАН[3]

Мамадыш районы Ишки авылы хакында борындан ишетелеп калган хәбәрләргә караганда, Казан әтрафындагы Чирмеш иле дигән авылдан күчеп килгәнләр, имеш. Килүчеләр [дә]н Алман, Ишки исемле адәмләр башлап килүчеләр булган.

Морзалар авылы — Югары Ушма. Безләр яшь вакытымызда бу авылны Йәрмәкәү (Ярмөхәммәд) дип руслар әйтәләр иде. Анда Ярмөхәммәд морза булган диләр. Әле без белгәндә дә «бу — Ярмөхәммәднең кабере» дип йөриләр иде. Зур юл өстендә бер кабер бар иде.

Беренче килеп утырган кеше Ушма исемле мари, имеш. Бу чирмешнең кайдан килүе турысында бер сүз дә мин ишетмәдем. Ушманың беренче утырган урыны хәзерге көндә Мадийар яки Марилар тавы дип йөри торган тауның җәйге кояш чыгышы ягындагы итәгендә...

Икенче килеп утырган кеше Котыш (Габделкотдус) бабай, үзенең аркадашлары белән килеп утырган, имеш. Бу кеше Котыш авылыннан килгән икән. Котыш (Габделкотдус) авылы менә кайда булган: хәзерге Хафизовка — Ник күчтем авылы утырган урында булган. Бу бик иске заманда Котыш авылы дип мәшһүр булган. Хәзерге изгеләр чишмәсе дип йөртелә торган чишмә Котыш авылының чишмәсе булган, имеш... Язгы эшләр беткәч, шул тирәдәге авыллар Котыш авылында йәрминкә, зур базар (җыен — М. Ә.) ясыйлар икән.

Ушмага өченче килеп утырган кеше Идегү бий исемле бер мирза, имеш...

Ушмада «Малай» нәселләре дигән нәсел бардыр. Бу нәселнең чыгышы шул икән:

---

[1] Бәрәзә авылы тарихы турындагы кулъязма 1973 елда Арча районының Олы Бәрәзә авылында табылды. Аны Г. Заһидуллин (1876—1947) язган булган.

[2] Шушы авылның легендалары буенча Арча районының Олы Бәрәзә авылы янындагы Рус Алаты урынында нугайлар торган. Алат янындагы үрне әле дә «Нугай тавы» дип атыйлар. Олы Бәрәзәнең яртыдан күбрәк халкын нугай нәселләре дип саныйлар. М. Ә.

[3] Мамадыш районының Түбән Ушма авылында яшәүче Хәмитов Габдулла (1893 елда туган) агай язган. Г. Хәмитов биргән күчермә 1973 елны безнең сорау буенча эшләнде. Кулъязма институт архивында саклана.

көннәрдә бер көн, кайсы тегермәндер, бер тегермән буасы өстендә бер яңа гына тудырып ташлаган бер ир бала (малай) табалар. Бу бала үсәдер, үрчидер. Менә бу баладан Ушмада «малайныкылар пләмәсе» башланадыр. Менә шушы нәсел белән Ушманы дүрт бабадан башланган дип әйтәләр.

Ушма зиаратының (каберлек) төш ягында бер биек текә тауны Кирәмәт тавы дип йөртәләр. Шул ук иске вакытдагы аталган исем белән. Менә шул исәбдән Ушма да мариларның килүен әйтә торган кирәмәтләре икән. Кирәмәткә бармаганда авылда keләү әйтә торган бер йортлары бар икән. Шул вакытда Ушмада бер Бәшәр исемле адәм булып, чирмешләрнең keләүләренә каршылык итә икән. Марилар Бәшәрне яратмыйлар икән, сине Юмы (мариларның мәҗүси алласы — М. Ә.) ачуланыр әле дип әйтәләр икән...

Мамадышлар Пугачевны чиркәү кагып, зурлап каршы алганлар, имеш. Пугачевлар каршы килгән кешене Мамадыш тавы өстендә асканлар, имеш. Әнә шул каршыларның кайсыларын Ушманың «Таган асты» дигән урамында асканлар, имеш. Таган асты дип аталуга сәбәб шул икән...

## БӘЙРӘКӘ ТАРИХЫННАН[1]

... 1661 елда язылган таш күренде. Ул таш Биккол Табай углының 1661 елда вафат булуын белдерә...[2] 1900 елның игътибарлы кешеләре тарафыннан сөйләнгән тарих хәбәрләренә караганда, Биккол Табай углы Бәйрәкә авылының балаларын шул вакытның тәртибе буенча укытучы (абыз агай) булып озак гомерләр яшәгән икән...

Бәйрәкә елгасы буенда җирләшү өчен иң элек кемләр килгәннәр? Бу хакта борынгы Бәйрәкә кешеләре өч төрле фикерне хикәя кылып сөйләделәр.

Беренче фикердә сөйләнә торган урамнарда, тегермәннәрдә, сүз ярышларында булып уза торган «Вәтский Пәлән» ягы Малмыж төбәге Китәк авылының Рака исемле кеше Бәйрәкә елгасына иң элек килеп утырган дип сөйләнәдер иде.

Икенче фикердә Казан ягы Зөя төбәге Үтәк авылыннан Тамту бабай[3] нәселендән килгәнләр. Үтәк авылы ул үзе 1193 нче елларда төзелгән, соңгы вакытта мәшһүр авыл булып әверелгән, базары, ярминкәләре белән танылган икән. Үтәк авылыннан килгән кешеләрнең нәселләрен белдерә торган шәҗәрә язулары табылмады. Шулай да алар Бәйрәкәнең югары очында булганлар...

Өченче фикердә сөйләнә торган кеше — Казан ягы Кукмара суы буендагы Сәрдек авылыннан Хәсән углы Хөсәен килгән. Аның нәсел-нәсәбләрен белдерә торган шәҗәрәсе Сәрдек авылында да булган. Бәйрәкә авылына килгәч тә языла барган. Хәсән улы — Хөсәен, аның улы — Айыт. Менә шул Айытдан Бәйрәкә авылына аның нәселе тарала. Бәйрәкәдә Айытов фамилиясе башлана дип тамгаланган шәҗәрәгә языла барган ир кеше җаны 1908 нче елларда 250 кеше күренәдер иде. Язылмый калганлары тагын да күбрәк булгандыр. Бәйрәкә авылының шул очтагы кешеләреннән алдынгы, күренекле кешеләрне шул шәҗәрәдән эзлиләр иде, очраталар иде. Андан соң Бәйрәкә авылына күчеп килгән кешеләрнең авылын егермеләп авылга илтеп тоташтыралар иде. Кукмарадан, Урбаудан (Арбур — М. Ә.), Балыклыдан, Әтнәдән, Азкайдан (Адай — М. Ә.), Арлаудан, гомумән Казан ягыннан һәм типтәр-башкорт нәселләреннән беренче ревизия вакытында җыелып бер авыл (Бәйрәкә) булып закунлашканлар...[4]

... Бәйрәкә авылына күрше булган авыллар Бәйрәкә авылыннан соң килеп утырулары искәртә торган бер вакыйганы хәтерләп үтсәк тә була торгандыр. Шулай бер заманда, борынгы тормышта Бәйрәкә авылында ут сүнгән икән, бер төрле ыспасуб белән дә ут тергезә алмаганда, бер кешене йөгерек атка менгезеп, егерме биш километрда булган авылга — Балтачка җибәргәннәр ди. Ул андан бер чиләк утлы күмер алып кайткан ди, диделәр...

---

[1] 1887 елда Баулы районының Бәйрәкә авылында туган Фәхертдин Хәдимов 1950—60 нчы елларда шуны яңадан язган. Кулъязма ике төпкә төпләнгән, авторның үзендә саклана.
[2] Бу таш Бәйрәкә зиратында сакланмаган. Ләкин Биккол Табай углы, чыннан да, булган шәхес. Кайбер мәгълүматларга караганда, ул XVIII гасыр башларында яшәгән.
[3] Тамту бабай шәҗәрәсе Зеленодольск районы Мулла иле авылында сакланган.
[4] Беренче ревизия 1719, ә икенче ревизия 1744—45 нче елларда уздырылган.

# ЧЫРШЫ ТАРИХЫ[1]

## БЕРЕНЧЕ ДӘВЕР

1374—75 нче елларда Алтын Урда хөкүмәте белән Мәскәү кенәзе Иван Калитаның уртанчы улы кенәз Димитрий II көч сынашып карамакчы булалар[2]. Бу вакытда Алтын Урда хөкүмәтендә Мамай морза исемле кеше хан булып тора. Шул рәвешдә, 1374 елның башларында Мамай морза хан белән кенәз Димитрий II[3] арасында зур сугыш башлана. Сугыш зурга китеп, кенәз Дмитрий шул сугышта Алтын Урда хөкүмәтенең шимал һәм шимали шәркыйә йаклардан җиңгеп ала. Хәзерге кендә Вйәткә губернасы тирәләрен кенәз Димитрий һәрбер җиңгеп алган урынларда татар морзаларын, татар алпавытларын чукынырга өнди, аларны түбә җир, урман, су һәм башка маллар бирү белән кызыкдыра. Менә шул вакытда күб кенә татар морзалары һәм алпавытлары, кенәз Димитрийнең сүзен тотып, диннәрен ташлап, рус динен кабул итеп төб җирле-сулы булалар. Ләкин араларында моңар риза булмайынча җанүб ягына таба качып китүче татар алпавытлары да аз булмаган. Шул рәвешдә, Алтын Урда хөкүмәтенең төн ягындарак булган Мамазау дигән виляйәт була. Хәзер Малмыж дип атала. Шул ук Мамазау виляйәтенә табигъ булган Адай исемле авылдан Шәйех баба, Хәлфә баба, Морза баба һәм алардан башка тагын исемләре мәгълүм булмаган алты кеше җанүбкә таба качалар. Бу вакытда Мамазау виляйәтендә Мәмәтхуҗа морза, Мамай морза ханның кече угылы баш була. Чөнки бу качкан бабалар диннәрен ташларга разый булмыйлар. Хәлфә бабай үзе корьән хафиз булган. Бу Адай авылы кече Вйәткә сувы буйына салынган зур гына бер татар авылы була. Хәзерге кендә рус авылына әйләндереп «Андреевка» дип аталып йөртелә. Безнең югарыда күрсәтелгән бабаларыбыз качып килә-килә хәзерге Татарстан җөмһүрийәтенә, Арча кантонына Төбийаз авылындан агып килә торган суның бер култыгына урнашалар. Суның ул йагында алар шул урында 1375 нче ел килеп урнашалар. Ләкин соңындан ул тирә куе урманлык белән кабланган булганлыкдан, сазлык булып, йаз-көз бик уңайсыз булганга һәм йырткыч хайванларның җәберләренә чыдаша алмайынча, 1592 йылны бу урындан 2 — 3 чакрым йугарырак вак куваклык һәм имәнлек арасына утыралар. Боларны 1375 йылдан 1591 йылга кадәрлек утырган урынлары хәзерге вакытда «йорт» диб атап йөртәләр.

## ИКЕНЧЕ ДӘВЕР

Алар шушы урынга барып тыныч кына утырганда, анда йахшы гына көчле кизләү табалар. Бу кизләү үзе көчле булу өстенә, йазгы сулар да каты булу сәбәбле, бу йылга [да] зур убкын хасил була. Җәй көннәрендә шушы убкынлыкда зурлар һәм балалар койына торган булганлар. Бу убкын һәр вакытда бу тешәлеп торганлыкдан, шул бу тешәлеп торган урынына керүчеләр, кирәк зурлардан, кирәк балалардан булсын, батып үлгәләгәнләр. Шундан соң халык, бу убкынлыкдан шикләнеп, бу су безнең нәселебезне калдырмас, бу урындан күчәргә кирәк, дийә башлыйлар. Шундан соң болар 1676 елны бу урынны ташлап, бер чакрым чамасы йыраклыкта булган бер елгалык урынга күчеп утыралар. Бу икенче урынлары хәзерге кендә «Сая юлы кизләү» дип атап йөртәләр. Болар бу урында 84 ел торалар...

**Искәрмә:** бу тарихка материал Адаев Гәрәйнең бабасыннан калган Корьән битләреннән, Русия тарихыннан һәм Татар тарихыннан алынды. Тарихны җыючы Габәши.

1928, 14 февраль.

[1] 1974 елда Казанда яшәүче С. Садыйкова һәм В. Садыйков тарафыннан Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына бүләк ителде. Ул мәгълүм татар тарихчысы Хәсәнгата Габәшинең үз кулы белән язылган. Кульязма кыскартылып бирелде.

Чыршы авылы тарихы өч дәвергә бүленә. Беренче дәвер 1375—1591 елларны (216 ел), икенче дәвер 1592—1676 елларны (84 ел) үз эченә ала. 1677 елдан авыл тарихының өченче дәвере башлана.

[2] Мамай 1373—1378 елларда рус князьләре белән Урта Идел буйларында сугыш алып барган.

[3] Димитрий II — князь Дмитрий Иванович Донской.

*Хөрмәтле укучы! Бүгенге поэзия, аның иҗтимагый һәм рухи тормышыбыздагы роле, гомумән, әдәбиятыбызның авангардында баручы бу өлкән һәм мәңге яшь жанрның аеруча актуаль һәм әһәмиятле мәсьәләләре турында җитди, принципиаль фикер алышу максаты белән, журнал үзенең битләрендә яңа рубрика ача. Бу санда сезнең игътибарга әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин белән шагыйрь Равил Фәйзуллин әңгәмәсе тәкъдим ителә. Ул ике әдипнең үзара фикер алышуы тәртибендә язылды.*

*Шартлы рәвештә «аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр яки поэзиянең гражданлык йөзе» дип исемләнгән бу материалда, безнең карашка, шактый кызыклы мәсьәләләр күтәрелә яисә көн тәртибенә куела. Шулай да авторлар бүгенге татар поэзиясенең барлык җитди проблемаларын һәм актуаль мәсьәләләрен тулысынча колачлап алуны максат итеп куймыйлар һәм моңа бер әңгәмә белән генә ирешү мөмкин дә булмас иде. Шул ук вакытта авторларның кайбер фикерләре һәм тезислары бәхәсле, дискуссион булу ихтималын да искәртергә кирәк.*

*Киң катлам поэзия сөючеләребез, язучы һәм шагыйрьләр, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләре, бүгенге поэзиябез турындагы бу сөйләшүдә үзләрен дулкынландырган һәм борчыган мәсьәләләр буенча актив катнашырлар дип уйлыйбыз.*

# «АҢЛАЕШЛЫ» ҺӘМ «АҢЛАЕШСЫЗ» ШИГЫРЬЛӘР ЯКИ ПОЭЗИЯНЕҢ ГРАЖДАНЛЫК ЙӨЗЕ

ШАГЫЙРЬ **РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН** ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ **ИБРАҺИМ НУРУЛЛИН** ӘҢГӘМӘСЕ

**И. Нуруллин:**

Поэзия мәсьәләләре һәр вакыт игътибар үзәгендә булып килде. Бүген дә көн тәртибеннән төшкәне юк. «Литературная газета» битләрендә бу турыда фикер алышу өзлексез дәвам итә. Шактый еллар элек «Социалистик Татарстан» газетасында да поэзиядә Тукай һәм Җәлил традицияләренә кагылышлы фикер алышу үткәрелгән иде. Традицион һәм ирекле шигырьгә бәйләнешле бәхәс тә булып алды. Янәсе, кайсы яхшы һәм кирәк, кайсы яшәргә хаклы? Бәхәссез ки, тиешле идея-художество таләпләренә җавап биргән тәкъдирдә традицион шигырь дә, ирекле шигырь дә кирәк һәм һәр икесе файдалы эш башкаралар. Минемчә, бәхәс, әгәр шулай әйтергә яраса, «аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр тирәсендә барырга тиеш иде. «Аңлаешлы» шигырь дигәндә, мин барлык поэтик чараларны, эмоциональ, ягъни тирән хис белән сугарылган әһәмиятле фикерне укучының йөрәгенә, йөрәге аша аңына җиткерүгә хезмәт итә торган шигырьләрне күздә тотам. «Аңлаешсыз» дигәннәрендә исә, киресенчә, ул чаралар фикерне (әгәр ул булса!) яшерүгә, томан белән өртүгә хезмәт итте- реләә. Ирекле һәм ак шигырь беренче тәргә карый алганы кебек, традицион, шигырьнең дә «аңлаешсыз» булуы мөмкин.

**Р. Фәйзуллин:**

Шигырьләрнең, Сез әйткәнчә, «аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» булулары — бер яктан, шагыйрьнең талантына, осталыгына, икенче яктан, укучының үз әзерлегенә, әдәбиятны аңлау дәрәҗәсенә бәйле. Һәрхәлдә, бу юнәлештә сөйләшкәндә укучыны ур-

тага алып әңгәмәләшү хәерле. Гомумән без поэзиягә кагылышлы бүтән мәсьәләләр хакында да фикер алышырбыз дип уйлыйм. Чөнки шигърият турында сөйләшү ул минем өчен, асылда, бөтен татар әдәбияты турында сөйләшү кебегрәк тә. Әгәр без фәлән йөз еллык әдәбиятыбыз бар дибез икән, алар — иң әүвәл шигъри сөйләмгә корылган әсәрләр. Әгәр әдәбиятыбыз бүтән халыкларга беркадәр (кызганычка каршы, аз) таныш икән, алар иң әүвәл Тукайны, Җәлилне беләләр. Инде бүгенгә килсәк, башка жанрларның куандырырлык җимешләр биреп, үсеп-формалашып килүен таныган хәлдә, шигърият әдәби хәрәкәттә үзенең традицион лидерлык хәлен һаман саклап килә әле. Кайсы яктан алсаң да: кыю, кирәкле фикерләр әйтү ягыннан да, әсәрләрнең сәнгатьчә нәфислеге, камиллеге ягыннан да. Дөньякүләм әдәби «ярминкәгә» алып барырлык новелла, хикәя, повесть, роман, пьесаларыбыз берәм-сәрәм генә булса, бүтән халыкларга да күрсәтә алырлык шигъри әсәрләребез байтакка җыйнала дип беләм мин. Бер генә факт китереп үтик: «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе» сериясендә чыккан 200 томлык китапларда бездән — борынгыдан алып бүгенгегә кадәр — 17 шагыйрь катнаша. Кызганычка каршы, проза әсәрләребез бу авторитетлы басмада бер генә исем белән дә чагылыш таба алмады. Әлбәттә, монда жанрның үз өстенлекләре дә бар. Әйтик, традицияләрнең зурлыгы, кыскалык, ритмлылык һ. б.

Тагын шуны да әйтик: әдәбиятта актив эшләп килүче өлкән һәм урта буын вәкилләренә иш булып, шигърият сафына күтәрелгән байтак талантлы яшьләребез бар. Бу исә алга таба да шигъриятнең гүзәл үрнәкләре туачагына ныклы ышаныч бар дигән сүз. Шуңарга да карамастан, мин үзем, шәхсән, бүгенге шигъриятебез турында шактый уйланам һәм беркадәр борчылам да. Әниләр әйтәләр бит: баланың хәсрәте үзе үскән саен арта гына бара... Шуның кебек, шигъриятебез дә үсә тора, проблемалары ишәя тора. һәр үсү, белгәнебезчә, каршылыклар белән бара. Әйтик, поэзия үсә, ә китапларыбызның тиражлары ишәйми, менә дигән шигырьләр белән янәшә зәвыксыз, халтура әйберләре байтак урын ала бирә, яхшы шигъри үрнәкләребез бар дибез, ләкин аларны бөтенсоюз һәм дөнья укучысына тиешле дәрәҗәдә күрсәтә алганыбыз юк... Миңа калса, без хәзер һәммәбез дә беркадәр аптырашлы хәлдә калдык шикелле. Шагыйрьләр дә, укучылар да, хәтта тәнкыйтьчеләр үзләре дә. Шигырьләр, шигырьләр, шигырьләр... Арада бик күп яхшы шигырьләр. Ә шигърият үзе, гомумән, кая таба бара? Процессның барышы ничек? Бүтән халыклар шигъриятенә нисбәтендә ничек?.. Төптәнрәк уйлап баксаң, эш бит болай: язылган әсәрләребезгә комментарийлар, аңлатмалар алуга караганда, без (бу очракта, шагыйрьләр) **әйдәүгә, барыр юлларны, маякларны бергәләп ачыклашуга мохтаҗ.** Минемчә, әле тәнкыйть шигъриятебезнең үсү тенденцияләрен ачыклау, барыр юлларны билгеләү процессында үз ролен үтәп җиткерми шикелле. Бу хакта Сезнең фикерегез ничек?

**И. Нуруллин:**

Мин үгезне мөгезеннән эләктерергә теләгән идем. Сез исә максатка уратыбрак һәм чигенү белән килү юлын сайлыйсыз. Бәлки шулай кирәктер.

Иң элек мин татар әдәбиятында поэзия бүтән төрләрдән, аерым алганда, прозадан өстенрәк тора дигән мәгънәдәге раславыгызны шик астына алыр идем.

Әйе, «зур стажлы» татар әдәбиятында «шигъри сөйләмгә корылган әсәрләр» күп гасырлар буе өстенлек алып килде. Ләкин бу барлык әдәбиятларга да карый торган хәл бит. Кайчандыр хәтта фәнни трактатлар да шигырь белән язылган. Реализм әдәби юнәлеш буларак мәйданга килгән дәверләрдә исә эпик жанрлар алга чыкты, әдәбиятның җитлегү дәрәҗәсе проза белән, аеруча роман белән үлчәнә башлады. Бу закончалык татар әдәбиятына да карый. XX гасыр башында ук инде бирегә проза активлашты. Моннан соңгы чорларда да ул үз урынын бирми килә. Дөрес, соңгы елларда проза бездә беркадәр сүлпәнәя, ә поэзия җанлана төште. Әмма прозадагы бу хәлне мин үтеп китә торган күренеш итеп карыйм. М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар», Ш. Бикчуринның «Каты токым» һәм Г. Ахуновның «Идел кызы» романнары, Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын», А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» һәм М. Зариповның «Үзеңнеке — үзәктә» повестьлары әнә шундый оптимизмга нигез булып торалар.

Башлыча Р. Гамзатов, К. Кулиев, М. Кәрим исемнәре белән бәйләп карала торган авар, балкар һәм башкорт әдәбиятлары турында сүз барса, Сезнең

тезис, әлбәттә, дөрес булыр иде. Бу очракта исә зур прозасы белән ир булып җитешкән татар әдәбиятына кыска ыштан кидерү сыман нәрсә килеп чыга.

«Шигырь тәнкыйте»нең үз бурычын үтәп җиткерү-җиткермәвенә килгәндә, бу үзе аерым зур мәсьәлә. Тик шуны гына әйтим: «проза тәнкыйте» яисә «драматургия һәм театр тәнкыйте» турында да Сез әйткәнне кабатларга мөмкин булыр иде. Һәм, гомумән, язучылар җәмәгатьчелегенең әдәби тәнкыйтьтән канәгать булган чагын мин хәтерләмим.

**Р. Фәйзуллин:**

Иң әүвәл бер нәрсәне ачыклау мөһим — ул да булса шигъриятнең иҗтимагый тормышта тоткан урыны мәсьәләсе. Әлбәттә, һәр халыкта, аның тарихи үсеш шартларына һәм рухи культура традицияләренә карап, бу мәсьәлә үзенчә куела һәм аңлатыладыр. Куелган соравымны татар шигърияте мисалында, хәлемчә тәфсилләп, шәрехләп китмәкче булам. Булган заман: бездә мәкаль, җыр яшәгән, «Кыйссаи Йосыф» кебек поэмалар, бәетләр сөйләнелгән (дөресрәге, көйләнелгән), телдән-телгә, кулдан-кулга йөргән, кучерелгән. Ул чорларда әле сүз сәнгатенең бүтән төрләре әллә ни таралыш алмаган. Димәк, халыкның бөтен рухи тормышы, акыл-хикмәте шушы тезмә формадагы әсәрләрдә фокуска тупланып чагылыш тапкан. Чөнки бүтән юл юк, мөмкинлек булмаган. Инде гасырлар аша бүгенгә килик. Кешенең рухияте сәнгатьнең әллә никадәр яңа төр һәм жанрларын тудырды. Сүз сәнгате үзе генә дә күпме төр һәм жанрларга бүленеп, мөстәкыйль үсеш алды. Һәр жанр реаль тормышның мәгълүм бер кисәген чагылдыруда билгеле бер монополия алды шикелле. Чыннан да, киносценарий буенча экранда күрсәткәнне шигырьдә әйтеп бетереп булмаска мөмкин, романда тасвирлаганны поэмада чагылдыру авыр һ. б. Канатлы сүзнең, җырның (шигырьнең) халык язмышының хәлиткеч вакытларында үткен һәм дәһшәтле корал була алганын истә тоткан хәлдә, көндәлек тормышта без еш кына поэзия атлы затлы жанрның нәфис иңнәренә күтәрә алмаслык йөкләр өймибез микән, дөресрәге, өяргә тырышмыйбыз микән? Шигъриятнең символы да гыйбрәтле: борынгы мифлар буенча Пегас-Тулпар ат (димәк, көчле дә булырга тиеш ул, күпмедер йөк тә тарта алырга тиеш), ләкин канатлы ат шул ул! Канат янына тәртә куеп булмый. Сез үзегезнең миңа биргән соравыгызда «әдәби тәнкыйтьтә» хезмәт бүленеше «яши бит», дисез. Әдәби жанрлар арасында да шундыйрак «бүленеш» булырга тиештер?

**И. Нуруллин:**

Шигъриятебезнең иҗтимагый тормышта тоткан урыны. Минем дә теләгем сүзне нәкъ шушы мәсьәләдән — лирик поэзиянең иҗтимагый роле мәсьәләсеннән башлап китү иде. Әмма Сез бу мәсьәләне поэзиянең әдәби төр буларак үзенчәлегенә кайтарып калдырасыз, дөресрәге, шушы ягын калкытыбрак куясыз. Бусы артык каты чикләвек түгел. Дөрес әйтәсез, әдәби төрләр һәм жанрлар арасында да «хезмәт бүленеше» яга. Лириканың, мәсәлән, үз предметы, үз объекты, үзенең «чи материалы» һәм, димәк, үз бурычлары бар. Бүтән жанрлар башкарырга тиешле эшне шигъриятькә йөкләү, билгеле, лириканың үзенә дә, гомумән әдәбиятка да файда китермәячәк.

Мин исә икенчерәк нәрсәне күздә тотам: поэзия кемгә һәм ничек хезмәт итәргә тиеш?

Сезнең соңгы еллардагы шигырьләрегез, Равил, минем карашымча, фикер тирәнлеге һәм шул фикерне укучыга җиткерүгә хезмәт итә торган үтемле поэтик чаралар эзләү һәм табу белән аерылып торалар. Әмма кайчандыр Сез, минемчә, «аңлаешсыз» диган поэзиягә күпмедер өлеш керткән идегез. Үзегезгә кайбер яшьләрне дә иярттегез. «Наз» исемле җыентыгыгызга «Нюанслар иле»н кертүегезгә карап, «аңлаешсызлык» принципларыннан баш тартмагансыз диган фикергә килдем.

Җыентыкны ачабыз да түбәндәге юлларны укыйбыз:

Әсир

**Вазада җикән-камыш.**
**Ханым күлмәк салгандагы җил**
**ул бик аз шул...**

Хәзергә мин бу язманың шигырь булу-булмау мәсьәләсен бер якта калдырып торам да, шигъриятьне аңламаучы кеше данын күтәреп булса да, ачыктан-ачык әйтәм: кат-кат укып та, уйланып та, бернәрсә дә аңлый алмадым. Ни әйтергә теләде шагыйрь? Хатынның сылулыгы да җикән-камышның исен китерә алмады дипме? Ул чагында кем әсир? Ни өчен әсир?

Ныклы иманым миңа болай ди: бер үк шигырь, әйтик, академикка да, сыер савучыга да аңлаешлы булырга, академикны да, савымчыны да дулкынландырырга, рухи баетырга тиеш.

Поэзиянең иҗтимагый ролен мин шулайрак аңлыйм. Сезнең бу хактагы фикерегезне ишетәсе иде, Равил.

**Р. Фәйзуллин:**

25 яшендә үпкә чиреннән вафат булган Әсгать Фәхри болай язган. «Сез, бәлки, гаҗәпләнә торгансыздыр? Гаҗәпләнерсез дә шул, чөнки шагыйрьләрнең эшләре гаҗәбрәк. Без чәчәкләрдән сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр ясыйбыз». Сүзләрдән — чәчәкләр... Сез, Ибраһим ага, үлән-чәчәкләрне күреп, танып, исемләп күп беләсездерме, әйтә алмыйм, үзем, оятыма каршы, бик күп чәчәкләрне исемләп белмим. Күбесен таныйм, кай тирәләрдә үскәнен чамалыйм, әмма байтагының исемен, хасиятләрен белмим. Үзем туып-үскән тирәдә бу шулай, чит-ерактагы үлән-чәчәкләр турында әйткән дә юк! Тиешле мәгълүматым булмагач, мин аларны аңлыйм, беләм дип әйтә алмыйм, әлбәттә. Шигырьләр белән дә эш шулайрак тора. Гомумән, миңа шигырьне аңлашыла яки аңлашылмый дигән төрләргә бүлеп карау сәер. Кемгә ничек! Берәүгә— тирәнрәк аңлашыла, берәүгә — алай ук түгел. Алыйк бөтен халыкка аңлашыла дип танылган Тукайны гына: кем күпме һәм нәрсә аңлый бит! Һәммә кеше бертигез һәм бертөслерәк аңласа, Тукай турында йөзләгән тикшерүчеләрнең хезмәтләре дә кирәк булмас иде. Шулай ук Тукайның замандашы Дәрдмәнд иҗатын да төрле кеше төрле дәрәҗәдә аңлый дип беләм. Ул да бит татар халкының талантлы шагыйре!

Дөресен әйтим, шигырьнең бер күз йөртеп чыгуга ук үтә күрәли аңлашып җитүен, шәхсән, мин үзем өнәп тә бетермим. Бөтен нәрсә кинәттән ачылып, тәмам аңлашылып бетсә, дөнья ничек кызыксыз булыр иде! Телдә «тылсым», «сихри» һәм башка сүзләр бар. Болар яшәештәге бөтен нәрсәнең дә «аңлашылып» бетмәвенә ишарә итә. Шигырьләр генә аерым чыгарма булып тормыйлардыр. Шигырь — 2 x 2 = 4 түгел. Нигәдер бездә шигырьне, анатомия театрындагы шикелле, кисәкләп аңларга һәм аңлатырга тырышалар. Шигырь иң әүвәл хис аша акылга тәэсир итәргә тиеш. Бездә исә, кызганычка каршы, еш кына шигырьне тоймыйлар, ә өйрәнәләр.

«Аңлашыла» дигәннән, мәсәлән, халтура шул кадәр яхшы аңлашыла ки, хәтта бөтен материаль мотивлары белән... Мин үзем аңлавы гомергә җитәрлек шигырьләр ягында. Мәңгелек шигырьләрне гомер буе укысаң да, алар һәрчак ниндидер яңа яклары белән ачыла һәм аңлашыла бара.

Инде соравыгызның ахыргысына, турыдан-туры миңа караган өлешенә җавап биреп карыйм. Кыска шигырьләрне моннан 15 ел элек яза башлаган идем һәм бүген дә дәвам итәм. Аларның бер өлеше — 70 ләп миниатюра моннан 13 ел элек — 1964 елда «Казан утлары»нда басылып чыкты. Алар, кемнәрдер уйлаганча, «мөгез чыгарырга тырышу»дан түгел, рухи ихтыяҗ булганлыктан язылган әйберләр. Хәзер уйлап карыйм: бәлки бу күренеш (бу очракта бүтән яшьтәшләремнең дә шигырьләрен истә тотып әйтәм) — 50 нче еллар поэзиясендәге тасвирчылыктан, акланмаган озынлыктан, мәгънәсез риторикадан туеп, кыскалыкка, фикер әйтүгә омтылу, бәлки буш һәм ялган поэзиягә яшь бер кешенең (дөресрәге, берничә студент-шагыйрьнең) үзенә күрә бер протесты булгандыр. Шул еллардагы бер шаяру искә төшә: кайчак шигырь китапларын ача идек тә, шырпы тартмасы куя идек, шул шырпы тартмасы каплаган юлларны (7—8 юл) юри укып карый идек. Автор шул 7—8 юлда берәр нәрсә әйтә алганмы, берәр поэтик табыш бармы? Ә чын шагыйрь әйтергә тиеш! Бу — яшьлек шаяруы, әлбәттә, шулай да Мирсәй Әмир мәзәгендәге шикелле «нәрсәдер бар монда!» Дөрес, «Нюанслар иле»ндә чыккан миниатюралар арасында уңышлысы яки уңышсызрагы булырга мөмкин. Мисалның да уңышлы яки уңышсызын (бу Сез китергән «Әсир»не аклау өчен әйтү түгел) китерергә мөмкин. Бусы — икенче мәсьәлә. Эш — принципта. Әгәр 1964 елда матбугатта 70 ләп кыска шигырь эчендә 700 ләп сүз (бу

урында рационализмда гаепләмәссез дип уйлыйм) чыгарганмын икән, мин бу сүзләр өчен һәм аларның мәгънәви нагрузкасы өчен җавап бирәм. һәм ул миниатюраларда беркадәр мәгънәви һәм поэтик табышлар бар дип беләм. Шунысы гаҗәп: оппонентлар ни өчен шул вакытта берничәшәр мең юллы, шактый буш бүтән әсәрләрне күрмәделәр соң? Гаҗәп. Бу яңалыкның тышкы ягына ягъни, формасына гына игътибар итү түгелме соң? Бу — үзе бер формаль караш яки формализмның үзе түгелме соң?

Ә тулаем алганда, «Нюанслар иле»ндәге шигырьләрне чагыштырмача дөрес аңлап анализлаган кеше — яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев булды. («Казан утлары», 1974 ел, 6 сан.) Бу мәсьәләдә мин аның фикере белән килешәм.

**И. Нуруллин:**

«Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» дигән сүзләргә икебез ике мәгънә салып сөйләшәбез икән ләбаса. Беренче атаманы мин поэзиянең магистраль юлыннан бара торган талантлы шагыйрьләр иҗатына, ә икенчесен шигъри ребус төзергә яратучы шагыйрьләрнең тегеләйме-болаймы формализмга тартым экспериментларына карата кулланам. Сез исә чын шигърияттнең катлаулы һәм бай эчтәлекле булганлыгы һәм бу эчтәлекне укучының тиз генә чумырып бетерә алмавы турында сүз алып барасыз.

Әйе, даһи шагыйрьләрнең әсәрләре заманнан-заманга көчәеп яши, һаман яңа ягы белән ачыла. Бу әсәрдән алган тойгы да, фикер дә кешедә төрлечә булырга мөмкин. Әмма шунысы бәхәссез: укучы (хәзерлекләме ул, түгелме, барыбер) бер укуда ямсә тыңлауда ук дулкынланырга, күңеле һәм акылы өчен шигырьдән күпмедер азык алырга тиеш. Шул очракта гына укучыда кабат уку, ятлау теләге туарга, шигырь аны уйландырырга мөмкин. Шактый билгеле шагыйребезнең «Ат» исемле шигыре, белмим, бу таләпкә җавап бирә микән... Сүз «әкияттән дулап чыккан» ат турында бара. Башта ярыйсы гына укыла: сары тояк, ак бәкәл, озын нәфис сыйрак, киерелгән танау һ. б. Кинәт тәртелеп калам:

> **Ул — давылда һәм кояшта**
> **Үз төсен югалткан байрак.**

Ярсу ат белән байрак арасында нинди уртаклык бар? Тагын укый башлыйм. «Ә ике күз — ике беләү» дигән сүзләргә абынып, ат күзе белән беләү арасында охшаш билге табарга азапланып утырам да дәвам итәм. Тагын тукталып калам:

> **Аңында ашкыну кошы, —**
> **Ул кан күрде микән чыкта —**
> **Кошның ике канаты очы**
> **Колак булып бәреп чыккан.**

Соң нәрсә әйтергә теләде шагыйрь? Җавап соңгы юлда: «Юк, мин аңа атланмыймын». Ягъни бик билгеле хакыйкать: без сугыш теләмибез. («Илгә дошман басып керсә дә, атланмассызмы?» дигән сорау биреп бәйләнеп маташмыйм инде, хәерле булсын.) Шундый юлларны укыгач, М. Светловның илленче елларда рус «новаторларына» карата әйткән түбәндәге сүзләре хәтергә төшә: «Яшь шагыйрьләрнең күбесе шундый кыландырып язалар ки, ни турында сүз барганны да тиз генә чамалый алмыйсың. Оригинальлек артыннан куууларында, банальлектән качарга тырышуларында алар гаҗәеп банальлек күрсәтәләр».

Ачык булса кирәк, сүз шигырьдәге уй-тойгыны гәүдәләндерә торган шигъри сурәт һәм алымнарның укучыга якын һәм аңлаешлы булырга, ягъни беренче укуда ямсә тыңлауда ук шигырьнең бер бөтен эмоциональ тәэсир бирергә тиешлеге турында бара.

Такташны да тыңлап карыйк.

> **Бишьеллыкның бөек гигантлары**
> **һаман үсә, һаман күккә таба үрелә.**
> **Башларыннан инде сез яшәгән**
> **Коммунизм кыры күренә.**

Кайсыбыз гына өй түбәсе ямсә агач башына менеп, офыкның киңәйгәнен күреп үсмәгән! Шунлыктан әлеге строфадагы поэтик сурәтне без бик җиңел кабул итәбез

һәм аңа салынган гаять тирән фикерне «йотып» җибәрәбез. Ә бит җитлеккән Такташның барлык шигырьләре дә шундый ачык, төгәл, кирәк икән, «үтә күренмәле». Нишлибез инде, Равил туган, Такташны да сез өнәп бетермәгән шагыйрьләр җөмләсенә кертәбезме?

Дәрдмәндкә килсәк, әйе, ул талантлы шагыйрь. Ләкин аны Тукай белән бер тактага куюың гына төзәтмә кертүне таләп итә. Биредә «милләт» белән «халык» төшенчәләре бутала булса кирәк. Мәгълүм булганча, В. И. Ленин соңгы төшенчәгә эшче белән крестьянны гына кертә. Дәрдмәнд һич тә Тукай мәгънәсендә халык шагыйре түгел иде. Чөнки аның уй-кичерешләре күп кенә очракта халыкның (башлыча крестьянның) иң төп, иң зур теләк-омтылышларына аваздаш булып җитә алмады.

**Р. Фәйзуллин:**

Сезнең сүз сөрешеннән борчулы шундыйрак фикер аңлашыла: «Ни өчен бүгенге кайбер талантлы дигән яшьләребез Такташча язмый икән?» Шундук берничә сорау туа: ни өчен нәкъ Такташча? Такташ иҗаты бүгенге һәр яшь шагыйрь өчен әйдәүче үрнәк кочме? Ни өчен Такташ «татарча гына яңгырый, нигә аның иҗаты, Тукай иҗаты кебек, бүтән халыклар өчен дә уртак рухи хәзинәгә әверелмәде? Хикмәт авыр тәрҗемә ителүдә генә микән? Дөрес аңлашылсын: Такташка куләгә төшерергә яки аның поэзиядәге урынына «ревизия» ясарга җыенмыйбыз. Такташ — зур шагыйрь, халык күңеленә тирән кергән шагыйрь. Ул сихри таланты белән берничә дистә еллар буе, үзеннән соң килгән байтак сәләтле каләм ияләрен үзенә «буйсындырып» килде. Бу «буйсындыру» — асылда бәләкәй Такташлар, яки «такташчыклар» тууга сәбәп булды. Такташның яхшы традицияләре яңа сыйфатта үссен өчен, таланты белән Такташтан ким булмаган көчләр килүе кирәктер шул.

Минемчә, бүгенге яшь буынның Сез кабатларга яраткан «аңлаешлылыкка» үз карашы бар. Ул — үз халкың укучысы белән бергә, совет халкын тәшкил иткән бүтән халык вәкилләренә дә беркадәр аңлаешлы була алу. Уртак максатлар, уртак интерес-омтылышлар, уртак тормыш шартлары, әйтик, саф русчалыкны, саф кыргызчалыкны, яки саф татарчалыкны гына хупламый. Ихтимал, «саф» сүзен «архи» белән дә алыштырырга ярыйдыр. Чөнки бу очракта милли чикләнгәнлек күздә тотыла. Чынбарлык милли һәм интернациональ моментларның заманча чагыштырмада булуын таләп итә. Әгәр шагыйрь үз иҗатын бүтән халыкларның да тәкъдир итүен тели икән — бу табигый. Рухи байлыгың бар икән, аны бүтәннәр белән бүлешү гаеп түгел ич! Ләкин син тәкъдим иткәнне алар ничек кабул итәр? Менә нәрсәдә хикмәт. Бу биеклеккә ничек ирешергә соң? Әлбәттә, өйрәнеп, мәгълүм биеклеккә күтәрелгәннәрдән гыйбрәт алып, бар талантыңны җигеп, фикерне үзеңчә әйтү юлларын эзләп, әдәбият арсеналында булган ысулларны сынап... Дөрес, безнең арадан да талант орлыгы булган кайбер шагыйрьләр сыналган, әзер юл белән киттеләр. Ләкин үсү юлында беркадәр ат алалганнары үзләренчә юл ярып баручылар арасыннан булды.

Эзләнүләр, билгеле, шома гына бармый. Эксперименталь характердагы әйберләр матбугатта чыккалады. Кайберләренең кызыклы гына фикерләре булып та, әчке җылылыгы җитмәү сәбәпле, укучы аларны йөрәге белән кабул итмәде, хәтта ачулы рәвештә сәерсенеп читкә дә тибәргәләде. Кайбер яшь шагыйрьләр шигырьнең хисси башлангыч икәнен онытып, акыллы математик конструкцияләр белән мавыгып алдылар. Кайберләре Көнбатыш һәм рус шагыйрьләрен шул кадәр яхшы өйрәнделәр ки, хәтта телнең милли аһәңен һәм фикерләү рәвешен онытып ук җибәрделәр. Кайберәүләр, союз аренасына бик тиз чыгарга теләп булса кирәк, ярым шигырь, ярым подстрочник характерындагы язмалар «иҗат» иттеләр.

Кыскасы, бүген халыклар арасындагы рухи бәйләнеш Такташ иҗат иткән 30 нчы еллардагыдан нык аерыла. Коммуникация һәм информация чаралары үсә барган саен Җир-планета кечерәеп калгандай булды. Кешенең, гомумән халыкның гыйлеме артты, гаҗәпсенү тойгысы кими төште. Язучы хезмәте бермә-бер авырайды. 70 нче елларда иҗат итүче язучылар хәзер замана тудырган яңа проблемалар, яңа мәшәкатьләр белән мәшгуль.

Сез «аңлашылмаган» шигырьгә мисал итеп Р. Харисның «Ат» исемле шигырен китергәнсез.

«Ат», «Ярсыган ат», «Яткан ат» шигырьләреннән торган бу триптихны мин Сез уйлаганча ук аңлашылмый дип уйламыйм. Бу шигырьләр моннан 7—8 ел элек, автор иҗатының башлангыч чорында язылган. Дөрес, алар шактый авыр кабул ителәләр. Моңа «калканга да акыл тамган (?)» кебек сәеррәк юллар да сәбәпче. Ренат — рациональ шагыйрь. Ул — уйлы шагыйрь, фикер шагыйре. Өстәвенә, ул беркадәр рәссам да. Ул шигырьгә әллә нинди буяулар, төсләр сала, шигырьне оригиналь метафоралар белән чуарлый. Бу, күрәсең, аның үзенә ошый. Ә бүтәннәргә? Зур потенциаль мөмкинлекләре булган Ренатка теләк йөзеннән шуны әйтәсе килә: халыкның гасырлар буенча яшь белән юылып, моң һәм акыл белән өртелеп килгән күңел авазы һәм ритмына сизгеррәк булырга иде.

**И. Нуруллин:**

Диалогыбыз бәхәс рәвешен алды кебек. Бу яхшы. Тик ара-тирә ул ике чукрак сөйләшүенә охшап куйгалый. Сез, мәсәлән, минем Такташ уңае белән әйткән сүзләремдәге мәгънәне үзегезчә формалаштырып, болай дисез: «Ни өчен бүгенге кайбер талантлы дигән яшьләребез Такташча язмый икән?» Мин мәсьәләне алай ук тарайтмаган идем үзе. Хәер, эш анда түгел. Минем фикерне нигездә дөрес аңлатасыз дип уйлыйк. Ләкин Сез үзегез үк оештырган җөмләдәге «анык» дигән сүзне төшереп калдырып, «ни өчен нәкъ Такташча» дигән сорау куясыз да, мәсьәләне бөтенләй бүтән яссылыкка күчерәсез. Такташча язу бер нәрсә, Такташча анык язу икенче нәрсә. Беренчесе — Такташка иярү булса, икенчесе — Такташ поэзиясе нигезендә яткан төп эстетик принципны гына тормышка ашыру була.

Мин Такташча гына түгел, бәлки Тукайча, Туфанча, Некрасовча, Твардовскийча, Светловча һәм башка талантлы шагыйрьләрчә язуны яклыйм. Ә инде аларның барысына да берьюлы иярергә мөмкин түгел. Димәк, бу шагыйрьләр өчен уртак принциптан чыгып язу турында сүз бара. Кыскасы, мин лирикада халыкчанлык һәм реализмны яклыйм.

Шул ук вакытта Бальмонт, Соллогуб, Поль Верлен, Артур Рембо, Малларме, Хлебников, футурист Кутуй, имажинист К. Нәҗмиләрчә язуны якламыйм. Икенче төрле әйткәндә, мин декадентлык күренешләренең, модернизм принципларының поэзиябезгә үтеп керүенә каршы. Хәтерем алдамаса, Малларме бугай, болай дип әйткән: әгәр шигырьне аңлап булса, ул начар шигырь. Күренә ки, «аңлаешсызлык» принцибы әллә кайдан түгел, бәлки символистлардан килә икән.

Поэзиядә иҗат принциплары, художество методлары, аерым алганда, реализм һәм модернизм мәсьәләләре һич тә эстетик проблема гына түгел, идеологик проблема да ул.

Миллилек һәм халыкчанлык мәсьәләсенә кагылып яхшы иттегез. Поэзиядә «аңлаешлылык» һәм «аңлаешсызлык» дигән нәрсә бер ягы белән нәкъ менә халыкчанлык мәсьәләсенә тоташа.

Сез болай дисез: «Уртак максатлар, уртак интерес-омтылышлар, уртак тормыш шартлары, гомумән, объектив уртак яшәеш «саф милли күренешләрне», әйтик, саф русчалыкны, саф кыргызчалыкны яки саф татарчалыкны хупламый». Шуңа күрә, сезнең фикерегезчә, хәзерге яшь буын шагыйренең теләге — «милли укучы белән бергә, совет халкын тәшкил иткән бүтән халык вәкилләренә дә аңлаешлы булу». Моңарчы килеп киткән бөек шагыйрьләр, белмим, бүтән халык укучыларына аңлаешлы булуны төп максат итеп яздылар микән? Минемчә, аларның һәркайсы үз халкы турында уйлап, үз халкы язмышы өчен тирәнтен борчылып иҗат иткән. Аларның поэзиясе бүтән халыкларга да үтеп кергән, яратып укыла башлаган икән, бу инде ике сәбәпкә бәйле. Беренчесе — бөек шагыйрьне тудырган халыкның тормышы, димәк, гомумкешелек яшәешенә хас сыйфат һәм күренешләрне дә үз эченә туплаган. Икенчесе — әлеге шагыйрь туган халкы тормышына тирәнрәк үтеп кергән, шундагы гомумкешелек элементларын тулырак һәм калкурак итеп күрсәтә алган. Моңа тагын сәнгатьтә, шул исәптән поэзиядә, гомумилек белән индивидуальлекнең диалектик берлеге мәсьәләсен дә өстик. Ягъни олы фикер белән сугарылган кичереш һәр вакыт шагыйрьнең шәхесенә генә түгел, бәлки милләтенә дә бәйле үзенчәлеккә ия була. «Халыкчанлык» төшенчәсе бар икән, кирәк икән, милләтләр яшәгән дәвердә ул рус, кыргыз яисә татар халыкчанлыгы рәвешендә генә гәүдәләнә ала. Әнә шундый халыкчанлыктан мәхрүм

булган булсалар, әйтик, Пушкин, Байрон яисә Гейне шул кадәр дан казана алырлар иде микән? Яки менә М. Кәрим, К. Кулиев, Р. Гамзатов һәм безнең С. Хәким милли үзенчәлекләреннән башка танылa алырлар идеме? Юк, бу һич тә милли чикләнүчәнлек түгел. Сүз зур шагыйрьләрнең беркайчан да космополит булмаулары турында гына бара.

Шагыйрьне бүтән халык вәкилләре дә аңласын өчен, дисез сез, алдынгы әдәбият шагыйрьләреннән гыйбрәт алырга, алар арсеналындагы ысулларны сынарга кирәк. Әлбәттә, бусы да кирәк. Әгәр ул шагыйрьнең бүтән халык укучылары игътибарын җәлеп итәрлек бай эчке дөньясы һәм олы фикере булмаса? Хәер, мин икенче мәсьәләгә кучә башлаганмын икән. Иң әүвәл әйтелгәннәргә карата Сезнең фикерне ишетәсе килә.

**Р. Фәйзуллин:**

Зур һәм талантлы язучы иҗатында гомумкешелеккә хас мотивларның булуы турында бәхәсләшмәбез дип уйлыйм.

Инде соравыгызның ахырында «әгәр ул шагыйрьнең бүтән халык укучылары игътибарын җәлеп итәрлек бай эчке дөньясы һәм олы фикере булмаса?» диган шик белән килешеп бетмәс идем. Гыйбрәтле тарихы булган һәр халыкның үзенә лаек бүгенге җырчылары табылмас микәнни? Бездә дә зур шагыйрьләр бар. Өлкән һәм урта буыннан мисал китермичә, чагыштырмача яшьрәк буыннан бер генә исем — М. Әгъләмовны гына әйтеп үтәр идем. Аның фикерләрен бәләкәй димәс идем мин. Халыкның рухи язмышы турында җитди уйланырга җирләк бирә аның күп кенә әсәрләре. Ихтимал, Мөдәррикнең кайбер шигырьләре бүтән милләт укучыларына да кызыксыз булмас иде (мәсәлән, үзенең шигъри куәте белән мәгълүм рус шагыйре Н. Рубцовтан бер дә ким санамас идем мин Мөдәррисне). М. Әгъләмов бер мисал гына. Бүтән исемнәр дә китерергә мөмкин булыр иде. Эш, мөгаен, күрә белүдә, таный, бәһали һәм күтәрә белүдәдер. Игътибар иткәнегез бармы? — бүгенге шигырь китапларының тиражлары, түгәрәкләбрәк алганда, уртача 3000. Сан ягыннан бездән күп кечерәк милләтләрдә дә нәкъ шундыйрак тираж. Шунысы аяныч — бездә бөтен шигырь китаплары да, шагыйрьләрнеке дә, «шигырьчеләр»неке дә бер чама тираж белән басыла. Мондый «тигезлек»нең укучы зәвыгын тәрбияләүдәге роле аңлашыла булса кирәк. Сүз үзеннән-үзе практик мәсьәләләргә — пропаганда, ихтыяҗны өйрәнү, китап басу һәм таратуны оештыра белү һ. б. килеп тоташа. Бу хакта сөйләү — безнең беркадәр теоретик характердагы әңгәмәбездә Сезнең өчен диссонанс булып тоелырга мөмкин. Ләкин нишлисең, язучы кеше өчен «меркантиль» бу мәсьәлә шулай ук зур әһәмияткә ия.

Язучы яки шагыйрь өчен әсәрләренең киңрәк дөньяга чыгуы нинди куәтле стимул икәнен әйткән дә юк. Биюченең итәкләре бии-бии кыскара диләр бит. Менә бу очракта поэзия тәнкыйте (гомумән, тәнкыйть) ярдәмгә килергә тиеш. Киң катлам укучыларга акны карадан аерырга булышырга тиеш. Тәнкыйтьченең шагыйрьне ничек язарга өйрәтә алуына шикләнәм мин, ә булышуга килсәк, ул чын мәгънәсендә булыша алыр иде. Бу җәһәттән безнең бүгенге тәнкыйтьчеләребез үзләренең төп миссияләрен үтәп бетермиләр шикелле. Сез бу хакта ничек уйлыйсыздыр? Бәлки шагыйрьләр яки язучылар тәнкыйтьтән артыкны өмет итәләрдер? Бәлки без язучы белән тәнкыйтьче арасындагы бәйләнешне тиешенчә аңламыйбыздыр? Кызык, нинди тәнкыйтьчеләрнең нинди шагыйрьләргә конкрет ярдәме турында Сез нинди исемнәр китереп әйтә алырсыз икән? Мин үзем бүгенге поэзия тәнкыйтьчеләренең фикри ярлылыкларына хәйран калам. Кайтам да, Г. Ибраһимовның моннан 65 ел элек чыккан «Татар шагыйрьләре»н укыйм. Дөрес, ул хезмәттә Тукай иҗатына карата ялгыш карашлар, хата фикерләр дә бар. Ләкин анда шәхес бар, шәхеснең кызыклы дөньясы, күзәтүләре, гомумиләштерүләре, ахыр чиктә, бүтәннәр өчен, шул җөмләдән шагыйрьләр өчен, яхшы мәгънәдәге файда бар. Һәрхәлдә, шуңа охшашлы «тере» хезмәтне күргәнем юк әле минем.

Инде халыкчанлык мәсьәләсенә килсәк, бер генә штрихны шәрехләп үтмәкчемен: халыкчанлык катып калган төшенчә түгел, ул да заман белән үзгәрә. Кайчандыр талантлы шәхес тарафыннан тудырылган берәр образ яки канатлы сүз индивидуаль

башлангычтан гомумилеккә күчә, ягъни гомумхалык кулланышына керә, халыклаша. Ихтимал, бүген беркадәр сәер яки аңлашылып бетмәгән шигъри күренешләр дә еллар үтү белән аңлашыла төшәр.

**И. Нуруллин:**

Язучы, үзенең талантына сокланып, фил сөягеннән ясалган тәрбәгә кереп бикләнмәсә, чын-чыннан халык улы булса, халык бәхете өчен көрәш ябшәү девизына әйләнсә, аның иҗатында, әлбәттә, «гомумкешелеккә хас мотивлар» булмый калмый.

Укучының зәвыгын тәрбияләүдә, чын шигърьне эрзацтан аерырга өйрәтүдә әдәби тәнкыйтьнең роле турында да шаять бәхәсләшмәбез. Татар совет тәнкыйтенең үз өстенә йөкләнгән бурычны үтәү-үтәмәү мәсьәләсе турында безнең сүз булган иде инде. Бу урында тик шуны гына әйтим: талантлы һәм күренекле шагыйрьләребезнең тәнкыйть адресына кайта-кайта ачы сүзләр әйтүе борчылып уйланырга мәҗбүр итә. «Шигырь тәнкыйте» өлкәсендә, күрәсең, эшләр чынлап та шәптән түгел.

Шагыйрьләрне пропагандалауның кирәклеген мин шулай ук инкарь итәргә җыенмыйм. (Чын прозаик һәм драматурглар да моңа мохтаж.) Әмма тарихта мондый хәлләр дә булгалаган: халык кайчак, тәнкыйтьне бар дип тә белмәстән, үз шагыйрен үзе табып ала. Мисал эзләп торасы юк: Тукай! Бөек шагыйрь үлгән көнне үк Ф. Әмирхан болай дип язган иде: «... аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды». Гали Рәхим дә шул фикерне язып чыкты. «Аның халыкка мәгълүм булуы тәнкыйть аркылы булмады... Халык үзенең җырчысын үзе аралап табып алды». Сүз Тукайның интеллигентчыл даирәләргә генә танылуы турында түгел, бәлки революциягә кадәр үк иң караңгы татар авылларына кадәр үтеп керүе хакында бара. Теге яки бу талантлы шагыйрьнең уй-фикер һәм хис-тойгы дөньясы халык күңеленә авааздаш түгел икән, бернинди пропаганда да аңа ярдәм итә алмый.

Сезнең бу сүзләргә җавабыгыз, әлбәттә, әзер: мондый шагыйрьнең, бүген танылмаса да, киләчәктә танылуы мөмкин. («Ихтимал, бүген беркадәр сәер яки аңлашылып бетмәгән шигъри күренешләр дә еллар үтү белән аңлашыла төшәр».) Үз заманында беркемнең дә игътибарын җәлеп итмәгән шагыйрьнең күп еллардан соң данга күмелә алуына шикләнеп карыйм. Киләчәктә танылу «теориясе», минемчә, практик яктан да зарарлы. Формалистик трюклар ярдәмендә булса да күренергә, игътибарны үзенә җәлеп итәргә теләгән шагыйрьгә бу теория гаҗәеп кулай: мине киләчәктә аңларлар!

Бүгенге көн татар совет поэзиясен тагын да югарырак итеп күрергә теләсәм дә, аның уңышларын инкарь итәргә җыенмыйм. Бездә бөтенсоюз укучысына тәкъдим итәрлек олы фикерле зур шагыйрьләр барлыгына да шигем юк. «Картлар» арасыннан да, яшьләрдән дә. М. Әгъләмов турындагы сүзләрегез белән дә килешәм. Фикер дә бар аңарда, шигърият тә. Чөнки, С. Хәким әйтмешли, «ул традицион стильдә» яза. Дөресрәге, ул җеп очын яшереп маташмый, формалистик күнегүләр белән шөгыльләнми. Димәк, әйтер сүзе, укучыга җиткерергә теләгән фикере бар. Шул шигъри фикернең сыер савучыны гына түгел, бәлки әлеге академикны да баетырлык булып, тагын да тирәнәеп зураюын гына телиргә кала. Моның өчен даһи фикер ияләренең гасырлар буенча тудырган рухи хәзинәсен үзләштерү белән бергә, тормыш китабын вакыт уздыру өчен түгел, бәлки шул тормышны яхшырту хакына җентекләп укудан бүтән юл юк.

Менә без эзләнү мәсьәләсенә әйләнеп кайттык. Бүтән халык укучыларына да танылу өчен, дигән идегез сез, «мәгълүм биеклекләргә ирешкәннәрдән гыйбрәт» алырга, «фикерне үзеңчә әйтү юлларын» эзләргә, «әдәбият арсеналында булган ысулларны» сынарга кирәк. Болары да кирәк, билгеле. Әмма эзләнү дигәннән шуны гына аңласа, шагыйрьнең эше хәтәр. Эзләнү ки, минемчә, беренче чиратта, шагыйрьнең үзен, үзенең тормыштагы, көрәштәге урынын эзләү. Эзләнү ул җәмгыятьнең катлаулы, каршылыклы үсешен аңларга тырышу, тормышта нәрсә туа, нәрсә үлә, «яңа» дигәннең кайсысы уңай яңалык, кайсысы социалистик яшәү принципларына туры килми — шуларны тотып алырга, мәгънәсенә үтеп керергә омтылу.

Монысы булмаганда, форма өлкәсендәге эзләнү белән генә ерак китеп булмаса кирәк.

**Р. Фәйзуллин:**

Диалогыбызны тагын бер кат күңелдән кичергәч, бер бик гади сорау туды: Сез бүгенге шагыйрьләрдән кемнәрне укыйсыз соң? (Сүз укыйсы килеп укыла торган кешеләр турында бара.) Һәм Сез аларда нинди уңай һәм җитешмәгән яклар күрәсез? Әңгәмәнең башында ук Сез мине «аңлаешсыз поэзиягә шактый өлеш керткән» кеше дип әйттегез. Шактый сәер һәм уйландыра торган бәя бу. Шул уңайдан тагын берничә сорау: «аңлаешсыз» поэзия тарафдарларына тагын Сез кемнәрне кертәсез? «Аңлаешлы» поэзия вәкилләре итеп кемнәрне таныйсыз? Әйтик, урта һәм яшьрәк буын шагыйрьләреннән.

**И. Нуруллин:**

Вакыт сыйдырган кадәр күбесен күздән кичерергә тырышам. Әмма безнең максат минем симпатия һәм антипатияләрне ачыклау булмаса кирәк.

Инде Сезгә килсәк, «аңлаешсыз» поэзиягә күпмедер өлеш керттегез» дип әйткәнмен икән, кайбер башлангыч шигырьләрегезне һәм «Нюанслар иле»н генә күздә тоткан идем. «Ирекле» һәм «ак» шигъриятегез белән дә мин Сезне, тулаем алганда, «аңлаешлылык» тарафдары итеп карыйм.

Рәшит Әхмәтҗанов исә традицион «классик» стильдә генә яза, халык иҗатын да мул куллана. Менә аның «Яшрен сөйсәң дә...» дип башланган шигыренең беренче һәм дүртенче (соңгы) строфасы:

**Яшрен сөйсәң дә, сөюне**
**Ай күрә, кояш ала.**
**Ала да давылга бирә,**
**Давыл дәрьяга сала...**

Аңладыгызмы берәр нәрсә? Уртадагы ике строфа да ачыклык кертми, киресенчә, аптыраулы сорауларны гына арттыра. Һәрхәлдә, мин берни аңлый алмадым. Һәм, гомумән, шушы шигырьне эченә алган «Ак канатлар» китабында шигъри ребуслар тулып ята. «Тагын кемнәр?» дип, якадан алып сорамасагыз иде. Фикеремне ачык әйттем, шигырь сөючеләр дә, шагыйрьләр дә кемнәр турында сүз барганны шаять чамалыйдыр.

Инде минем дә Сезгә бер сорау бирәсем килә. Безнең поэзиябезнең торышы, барышы һәм киләчәге мәсьәләсе Сезнең күңелгә, әлбәттә, тагын да якынрак. Бу турыда мин фәкыйрегез белән чагыштырганда күбрәк уйланасыз, шагыйрь буларак та уйланасыздыр. Әллә ничаклы күзәтүләрегез бардыр, утырган фикерләрегез. Татар поэзиясенең, шул исәптән «яшь поэзиянең» бүгенге хәле, үсеш тенденциясе һәм перспективасы турында ничек уйлыйсыз?

**Р. Фәйзуллин:**

Дөресен әйткәндә, «яшь поэзия» төшенчәсе миңа бик үк аңлашылып бетми. «Яшь» яки «карт» поэзия юк ул, бер генә поэзия бар, бер генә шигърият. Яшәлгән гомерләре буенча яшьрәк иптәшләр турында сүз бара дип уйлыйм. Яшьләр турында сөйләшү ул киләчәк турында сөйләшү дигән сүз. Ә киләчәк турында матур сөйлисе килә. Ләкин матур сөйләү өчен ныклы җирлек, какшамас ышанычың булуы кирәк. Биредә байтак исемнәр санап китәргә мөмкин булыр иде, хикмәт санауда гына түгел. Яшьләре белән 30 тирәсендә булган бер төркем шактый кызыклы шагыйрьләр бар. Ә 18—20 яшьлек, Тукайлар, Бабичлар кебек кабынган йолдызлар күренми. Ә 30 яшьлек шагыйрь яшь шагыйрь түгел. Күренәсе талант бу яшькә хәтле күренә инде ул.

Яшь әдәби көчләрне үстерү язучылар җәмәгатьчелегенең һәр вакыт игътибар үзәгендә булып килде. Үткәргән семинарларның исәбенә чыгу да мөмкин түгелдер. Язучылар союзы оештырган киңәш-семинарларда 20 ләп мәртәбә катнашкан «яшь язучы» иптәшләр бар. Ә мәгънә! Яшь көчләр, үсәр өчен, канатланыр өчен, өсәр бастырырга тиеш. Матбугатта чыгу — үсүне тәэмин итүче иң зур фактор. Әдәби мәйданыбызның шактый тар булуы яшьләрнең әдәбиятка мулрак килүен тоткарлый, әлбәттә. «Идел» альманахы даими чыга торган журналга әверелгәч (моңа безнең ышаныч зур), хәл беркадәр яхшырыр дип уйлыйбыз. Яшь иҗат көчләре турында КПСС ҮК кабул

иткән мәгълүм карар да яшьләр белән ныграк эшләүне таләп итә бит. Ләкин яшьрәк иптәшләр шуны онытмаска тиешләр: бу зур карар һәр яшь иҗатчыга зур җаваплылык та өсти, әдип исемен югары йөртергә чакыра.

Эзләнү турында өстәп әйткән сүзләрегезнең бөтенесе белән диярлек килешәм. Иҗат кешеләре арасында «туу» төшенчәсе бар. Яңа әсәр туды, яңа шигырь туды, җыр туды һ. б. Я, кайсы аны яңалык ачам дип, теге яки бу принципка туры китерәм дип тудыра икән! Иҗат итү процессы, гомумән, художество талантының табигате турында, кызганычка каршы, без бик аз беләбез. Бу — әдәбият фәненең, гомумән сәнгатьнең иң өйрәнелмәгән өлкәсе. Иҗат процессының кайбер серләрен киләчәктә философлар, психологлар ачарлар әле дип уйлыйк.

Бу урында тагы шуны да искәртеп үтик: яшь шагыйрьләр халык поэтикасының күркәм традицияләрен кирәк дәрәҗәдә үзләштерсеннәр, үстерсеннәр өчен, алар бу юнәлештә билгеле бер мәктәп тә үтәргә тиештер бит. Икенче төрле әйткәндә, әдәби мираска кул җитәрлек шартлар кирәк. Борынгы дәвер авторлары, игътибарга лаек прогрессив мирас калдырганнары, әлбәттә, күбрәк басылырга тиеш. Соңгы 10—15 елда борынгы әдәбият үрнәкләрен дөньяга чыгару эше бераз сүлпәнәя төште кебек.

Әңгәмә барышында шуны да хәтердән чыгармаска иде: без, эталон рәвешендәрәк, «Тукай — халык шагыйре» (шагыйрь белән халык арасындагы идеаль аңлашу мәгънәсендә) дип белдерәбез. Ә бит XX йөз башындагы «халык» төшенчәсе белән XX гасыр ахырындагы «халык» төшенчәсе арасында аерма да бик зур. Уртак казаныш рәвешендә совет халкы дигән төшенчә барлыкка килде. Милләтләр үзара бик нык якынайды. Замана бөтенләй бүтән. Тукай кебек бул дип әйтү җиңел, ә бүгенге заман Тукае нинди булырга тиеш? Менә монысына җавап табу авыр. Кайчакта без эстетик казанышларны бәяләгәндә иске акча белән алыш-биреш иткәндәге хәлдәрәк калмыйбыз микән? Ә курс күптән алышынган...

Инде конкрет бүгенге поэзиягә килик. Бер сорау: Сез бүгенге шагыйрьләрнең тематик диапазонын (күтәрелгән проблемалар һ. б.) ничегрәк характерлыйсыз? Бу юнәлештә, бүтән халык шагыйрьләренә нисбәттә, Сезнеңчә, бездә хәл ничегрәк?

**И. Нуруллин:**

Поэзия өлкәсендә специальләшкән тәнкыйтьче бу сорауга, ихтимал, азмы-күпме тулы җавап бирә алыр иде. Мин исә гомуми тәэссоратым белән генә уртаклаша алам. Татар совет поэзиясе, тулаем алганда һәм үзенең иң яхшы вәкилләрен күздә тотканда, минемчә, заман белән бергә атлап бара. Әмма тынычланырга урын юк. Поэзиянең кулы тимәгән күренешләр әле байтак булса кирәк.

«Яшь поэзия»дән бер мисал китерим. Игътибар иткәнегез бар микән, безнең поэзияне берара сугышка каршы көрәш темасы басып китте. Принципта бу начар түгел. Әмма шунысы сәер: андый шигырьләрне күбрәк, үзе сугыш ялкынында көеп чыккан шагыйрьләр түгел, бәлки сугыштан соң туганнар яза иде. Димәк, бу буын шагыйрьләренең (барысының да димим) үз заманы, үз чордашлары турында әйтер сүзләре җитенкерәмәгән.

Тагын бер күзәтүем белән уртаклашыйм. Ни өчендер соңгы вакытларда «сюжетлы» шигырьләр кимеде. Һәрбер шагыйрь — һәм олысы, һәм кечесе — үзен такъдим итәргә, үзенең уй-фикер хәзинәсен укучыга тагарга тырыша. Ярый ла, ул кызыклы шәхес булса, хәзинәсендә игътибарга лаеклы «энҗеләр» табылса... Некрасов поэзиясе, мәгълүм булганча, «сюжетлы» шигырьләрдән тора диярлек. Пушкин һәм Лермонтов та андыйлардан качмаганнар, ә Маяковский, Исаковский, Твардовский, Дм. Кедрин, Такташ, Туфан, С. Хәким? Теләсәләр безнең яшьләр дә андый шигырьләрне яза алырлар иде. Зөлфәтнең «Мәхәббәт» исемле көчле шигырен хәтерлик.

«Халыкчанлык» төшенчәсенең заманнан-заманга үзгәрә баруы турындагы фикерегез белән килешәм. Шулай да шигърияттә халыкчанлыкның әһәмиятенә бәя биреп җиткермисез кебек тоела. Әйе, «совет халкы дигән төшенчә барлыкка килде, милләтләр үзара бик якынайды». Бу — дөрес. Ләкин бит сез ни өчендер татарча язасыз. Вл. Солоухин — рус телендә, Р. Гамзатов — аварча. Берсе дә эсперанто кебегрәк телне кирәксенми бугай.

**Р. Фәйзуллин:**

Әйе, сюжетлы шигырьләребез кими төште шикелле. Бу тенденцияне ничек аңларга, ничек бәяләргә? Бәхәссез, сюжетка корылган, тиешле художество таләпләренә җавап бирерлек әсәрләр күбрәк булырга тиеш. Шулай ук 50 нче еллардагыча, вакыйганы коры сөйләп чыгуга, тасвирчылыкка корылган әсәрләргә дә кире кайту ихтыяҗы юктыр. Ул елларда су буе хәтле нинди генә озын-озын язмалар сырламады безнең агайлар!.. Заманнар үтү белән, әлбәттә, укучы ялыкты андый язмалардан, йөз чөерде андый «сюжетлардан». Халык тормышындагы рухи үзгәрешләр белән бергә фикергә сусау артты, драматик хискә, кешелеклеккә... Шуңа күрә дә 60—70 нче еллар поэзиясе тасвирчылыктан, вакыйга сөйләүдән нык арынды... Әмма икенче чиккә ташланды — артык рациональләнде, артык акыллыланды, фәлсәфиләнде.

Сюжетлы шигырьләр турында сөйләгәндә, бүгенге шигъриятнең тагын бер характерлы моментын да искәртеп узарга кирәк дип беләм: һәр чын шигырьнең үз сюжеты да бар бит әле! Традицион мәгънәдә аңлашыла торган сюжет түгел, — эчке, фикер сюжеты дип әйтимме... Фикер агышының поэтика фәне билгеләгән кануннарга сыеп бетә алмау хикмәтләре бар шул!

Инде поэмаларга килик.

Поэма хакында әдәбиятчылар күптәннән бәхәсләшәләр, ләкин бер төгәл фикергә килгәннәре юк, ихтимал, килә дә алмаслар... Чөнки яңа әдәби күренешләрнең әледән-әле хасил булып торуы да ниндидер бер тотрыклы нәтиҗәгә килергә ирек бирми. Әйтик, күптән түгел генә Р. Харисның «Рәссам» исемле әсәре басылды. Поэмамы бу, юкмы? Кистереп әйтү кыен. И. Юзеевнең «Таш диварлар авазы» поэмамы, юкмы? Яки үземнең «Көрәшчеләр» нәрсә? Публицистик диалогмы яки шигъриятнең бүтән төреме? Кыскасы, хәзер безне поэманың классик төшенчәсе канәгатьләндереп бетерми, ә яңа формалары турында фикер туплап бетерә алганыбыз юк. Шулай да һәрбер шагыйрьдә кайбер шәхси күзәтүләр бар дип беләм. Шул исәптән, минем дә. Мәсәлән, заманында чын поэма рәвешендә кабул ителгән «Таныш моңнар» кебек әсәрләр искерде. И. Юзеев моны үзе дә аңлый булса кирәк, шуңа күрәдер, ул бүтән формадагы күләмле әсәрләр яза башлады. Кызганычка каршы, кайчак шулай да була, автор үзе эзләнүләрендә инде әллә кая алга киткән була, ә кемнәрнеңдер аңында фәлән жанрның, бу очракта поэманың, гәүдәләнеше булып әлеге искерә төшкән әсәр кала. Бу бер. Икенчедән, соңгы вакытта яңарак төр поэмалар белән беррәттән, бериш шагыйрьләр билгеле бер эзлекле композициясе булган яхшы шигъри цикллар белән чыгыш ясый башладылар. Ул цикллар гадәттә яхшы укыла, чөнки алар фикри яктан тыгызрак һәм мәгънәлерәк була, өстәвенә, алар кыска һәм табигый (поэмада, телисеңме-теләмисеңме, жанрның классик кануннарын үтәү беркадәр ясалмалыкка китерә). Ясалмарак поэмаларга караганда төзек шигырь цикллары күбрәк ошый төшә миңа. Гәрчә андый шигырь циклларына караганда, поэманың теләсә кайсына, хәтта беркадәр йомшаграгына да тәнкыйтьчеләр игътибарлырак. Күрәсең, күләмлерәк жанрлар күбрәк булган саен әдәбият зуррак була дип наив аңлаудан киләдер бусы. Гомумән, поэма турында сөйләшү зур әзерлек һәм тәҗрибә сорый. Бу хакта С. Хәким, С. Баттал, И. Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Мингалимов, Ә. Баянов, М. Шабаев, Р. Харисов һ. б. иптәшләр үзләренең уй-фикерләре белән уртаклашсалар, әлбәттә, кызык булыр иде, мәсьәләгә беркадәр ачыклык керер иде.

Ә шигъриятнең тематик киңлеге, күтәрелгән темаларның актуальлеге һәм зурлыгы мәсьәләләренә килгәндә, «белеп язу», «белгәнне язу» турындагы фикерләрегез белән тулысынча килешәм. Бу бик мөһим, һәр сәнгатьнең төбендә ята торган нәрсә дип беләм. Тормышны белмичә, дөресрәге, тиешенчә белмичә, аны тагын да яхшырту турында авыз ачу да мөмкин түгелдер. Шагыйрь кешегә тормышны прозаик кебек белмәсә дә ярый дигәнрәк фикер дә яшәп килә. Бу — дөрес фикер түгел. Ихтимал, шагыйрьгә күбрәк тә белү кирәктер әле, чөнки ул кыска формада — яшәешнең асылы турында, «төше» турында әйтергә тели. **һәр әдипнең үз белгәне, үз мөмкинлеге, үз зарурлыгы, үз кирәклеге бар.** Талантка җәмгыятьнең таләбе дә әнә шуларга бәйле рәвештә ташламасыз һәм каты булырга тиеш. Табигатьтән бирелгәнне талант дөрес юнәлештә һәм кирәккә сарыф итәме? Ул үзенең тиеш рухи биеклегендәме? Монда үзеннән-үзе шагыйрьнең гражданлык йөзе, гражданлык сыйфатлары мәсьәләсе килеп баса. Шагыйрь, гомумән әдип, асылда үзеннән кача алмый. Шигъриятта маска белән

яшәп булмый. Шагыйрь үзенең күңелен, үзенең йөрәген — яралымы ул яки саумы, барыбер — бүтәннәргә курыкмыйча, яшермичә ачып сала алуы белән шагыйрь дә инде! Тикмәгә генә шагыйрьнең фидакарьлеген аның ихласлылыгы белән бергә бәйләп карамыйбыз бит! Актер шагыйрьләрне танымыйм. Шигърият уен аренасы түгел. Тукай әйтмешли, «кирәк түгел мәгънәсе юк көлке уен!» Куян йөрәкле булып та, арыслан авазы чыгарырга азапланучылар очрый. Андый хәлдәгеләр көлке һәм кызганыч, әлбәттә. Шагыйрь гражданлыгы минем өчен шул: үз өстеңә, үз өлешеңә тигәнне авырсынмый күтәрә алу. Ә халык кадәр халыкның үзенең талантлы уллары күтәрергә тиеш йөге һәрчак була. Авыры да, җиңеле дә. Кайчак бездә шулай да килеп чыга: шагыйрь космик мәшәкатьләр өчен шул кадәр борчыла, дөньяның әллә кайсы кыйтгаларындагы ташларны елата, ә үзе йөри торган сукмактагы каны саркып яткан ташны күрә алмый яки күрергә теләми... Шунысы сәер, халыкара вакыйгаларның берәр эффектлырагы турында берәр газетада хәбәр укып, шул ук хәбәр турында шул ук газетада берәр риторик «шигъри» чыгыш ясаса, кайберәүләр шундук үзенә зур гражданин шагыйрь исемен дәгъвалый. Күрәсезме, бөтен дөнья гаме йөрәгем аша уза минем! Андыйларга ышанмыйм мин. Бар, күр, бел, аннан инде күргәнеңә мөнәсәбәтеңне белдер, кирәк булса сөрән сал, кычкыр, өндә, халыкларны күтәр!.. Зур мөмкинлегең (һәм субъектив, һәм объектив яктан) юк икән, үз биеклегеңнән, үз белгәнеңне яз! Камыр кыңгырау кагырга яратучыларга караганда, С. Хәким кебек, артык кычкырмый-нитми генә халык гамен кайгыртып йөрүче затлар күбрәк ошый миңа. Шагыйрьнең гражданлыгы, намуслылыгы, иманы ныклыгы, принципиальлеге, «үз йөген» күтәрүдә чыдамлылыгы, егетлеге һ. б. турында Сезнең дә фикерләрне ишетү яхшы булыр иде.

Кем нинди телдә яза һ. б. мәсьәләләргә килсәк, мин, әлбәттә, татар телендә язам. Чөнки белгән (анысы да чагыштырмача) бердәнбер телем ул. Әлбәттә, беренче чиратта, үз халкым өчен язам. Ә менә ул халыкның укучысы бик чуар, төрле телле бит. Менә эш нәрсәдә! Үз телеңдә язу гаҗәп түгел, авыр да түгел, ә язганыңны үз халкың вәкилләренә җиткезү кыен хәзер. Сүз монда шөһрәт яулау турында бармый, үз эшеңнең табигый нәтиҗәсе турында уйлану, борчылу турында бара. Туган телләрен белмәгән ватандашлар күпме хәзер! Мисалга ерак барасы түгел: әле Казанда, үз тирәмдә миңа дустанә мөнәсәбәттә булган байтак яхшы кешеләрне беләм. Аларның күбесе белемле, заманның катлаулы һөнәрләрен үзләштергән, саф күңелле кешеләр. Татар сәнгате белән кызыксыналар, аның үсеен телиләр, уртак эстетик казанышларда безнең өлешне дә күрәселәре килә. Шул исәптән, бүтән халыклар да сокланырлык шагыйрьләребез турында хыялланалар. Ә үзләре, күп очракта, нихәтле генә парадокс булмасын, шигъриятнең бөтен нечкәлекләрен аңларлык дәрәҗәдә ана телен белмиләр. Дәрт бар, дәрман юк шикелләрәк килеп чыга. Алар безнең иҗат белән фәкать тәрҗемә аша гына таныша алалар. Бу әле Казанда шулай, ә бүтән республикаларда яшәүчеләр нишли? Кыскасы, укучыларыбызның шактый зур бер интеллектуаль контингенты татар шигырен (ул үзе аны үзебезнең татар шагыйрен укыйм дип укый) рус телендә укый, бәһали, горурлана, тәнкыйтьли... Я, хуш, хөрмәтле шагыйребез бу очракта нишләргә тиеш? Яхшы шигырь ул сыер савучыга да, академикка да бер чама аңлашыла дип тынычланып торырга тиешме? Юк! Шагыйрь кеше, гомумән, һәр әдип, югарыда искә алынган укучылар тибы турында да нык уйланырга һәм истә тотарга тиештер. Авылдагы бер катлам укучылар контингенты белән генә чикләнергә ярамый, минемчә. Ихтимал, тора-бара аның да күпмедер өлеше әле югарыда әйтеп үтелгән категориягә күчүе мөмкин.

**И. Нуруллин:**

Поэзиянең принципиаль мәсьәләләренә нисбәтән бер үк караштa торуыбыз, билгеле, мине шатландыра. Шагыйрьнең гражданлыгы, намуслылыгы, иманы ныклыгы, принципиальлеге, «үз йөген» күтәрүдәге чыдамлылыгы, «егетлеге» турындагы фикерләрегезгә рәхәтләнеп кул куям.

Сез тагын минем өчен кадерле булган һәм студентларыма күп еллар буе тукып килә торган бер фикеремне, авызымнан алып дигәндәй, әйтеп бирдегез. Әйе, шагыйрь, әйтик, прозаиктан ким белмәскә, бәлки әле күбрәк тә белергә тиеш! Берәү кул арбасына салып йөк илтә, икенчесе — үз җилкәсендә. Йөкләрнең авырлыгы тигез булсын өчен соңгысының икеләтә-өчләтә көчле булуы кирәк түгелме? Әнә шуның ши-

келле, прозаик, типик характерлар иҗат итеп һәм аларны үзара тормышчанрак мөнәсәбәткә куеп, тормышның берәр ягын үзе аңлаганга караганда тирәнрәк итеп ачып бирергә мөмкин (әдәбият тарихында андый очраклар еш булган). Шагыйрьгә исә мондый мөмкинлек бирелмәгән. Ул үз исеменнән сөйли. Дөнья турында дөрес һәм тирән фикер әйтү өчен, аңа, димәк, тойгы-хис үткенлегеннән тыш, гаять зур акыл көче, фикерләү куәте һәм тирән белем кирәк.

Шул уңайдан яңадан өйрәнү һәм эзләнү мәсьәләсенә кайтмый булмый. Бөек фикер ияләренең идеяләре яктылыгында тормыш китабын җентекләп уку — өйрәнү һәм эзләнүнең төп юнәлеше дигән фикерне әйткән идем бугай.

Тормыш китабы... Нәрсә бу? Шагыйрь, минемчә, барыннан да элек, үз даирәсен, үз төбәген, үз халкын энәсеннән-җебенә кадәр яхшы белергә тиеш. Юк, бу милли чикләнү дә түгел, бөтәннәрне өйрәнүнең кирәклеген дә юкка чыгармый. Бит Җирне аңлау өчен Айга баралар, Марс яисә Венерага космик аппаратлар җибәрәләр. Башка халыклар белән танышмыйча, үзеңне дә аңлап булмый.

Ярый, шагыйрь фикер иясе дәрәҗәсенә күтәрелде ди, үз төбәген биш бармагы кебек белә ди. Соң ул әйтергә теләгәнен ничек, нинди алым һәм чаралар ярдәмендә җиткерергә тиеш? Без форма өлкәсендә эзләнү мәсьәләсенә килдек. Фикер булсын, эчтәлек булсын, шуңа лаеклы форма үзеннән-үзе табыла диючеләр белән мин килешмәс идем. Форманы да эзләргә кирәк. Биредә дә халык поэзиясе, Кол Гали, М. Колый, Тукай, Такташ һәм Туфаннар традициясеннән үсеп чыга торган үз стилеңне булдыру, ачыклау өчен син планетаның күп гасырлар дәвамында яшәгән бөек шагыйрьләренең тәҗрибәсен өйрәнергә тиешсең. Шул исәптән хәтта модернизм һәм башка шайтанизм шагыйрьләренекен дә.

Әмма хикмәт шунда: нәрсәне алырга һәм нәрсәне кире кагарга?

Модернизм шагыйрьләренең иҗат принциплары, белмим, безнең поэзия өчен кулай була алырмы? Бит модернист ул — үтә чыккан индивидуалист. Аның уй-фикер һәм хис-тойгылары үтә субъектив. Менә ни өчен аның шигырьләре саташып сөйләшүне хәтерләтә.

Модернист шагыйрьнең уй-хис дөньясы һәм поэтикасы белән укучыларның киң катлавы арасында аваздашлык була алмавын исбат итеп торасы юк дип беләм.

Рус совет поэзиясендә, бөтән халыклар, шул исәптән татар совет поэзиясендә бер төркем шагыйрьләр катлауландырып яза башлап, аерым алганда, үтә «ассоциатив» шигырьләр ярдәмендә новаторлыкка дәгъва итәләр. Юк, мин аларны модернистлар димим. Күбесенең «оригинальлеге» модернистлардан арткан киемгә төренүләрендә генә димәкче булам. Әңгәмәбезнең башында «аңлаешсыз» шигырьләр дигәндә, мин нәкъ менә шуны күздә тоткан идем.

Поэтик фикерең зур икән һәм поэтик формаң укучының кабул итү аппараты белән принципта каршылыкка керми икән, сине һәркем (гомумән, берни укымаучылар турында сүз бармый) укыячак, ләззәт алачак, аның эстетик зәвыгы үсәчәк. Үз телендә сөйләшми һәм укымый башлаган милләттәшләребезнең игътибарын җәлеп итәр өчен дә шуннан бөтән юл юк.

**Р. Фәйзуллин:**

Сез, «хикмәт шунда: нәрсәне алырга һәм нәрсәне кире кагарга?» дисез. Чыннан да, нәрсәне алырга, нәрсәне кире кагарга соң? Бу очракта шагыйрьләргә поэзия тәнкыйтьчеләре дә ярдәмгә килергә тиеш. Иҗат эше — тудыру эше, иҗади экстаз вакытында шагыйрь үз язганы турында объектив ук фикер йөртә алмаска да мөмкин. Нәрсәне кире кагарга (монда мин идея-эчтәлектән бигрәк, форма турында әйтәм)? Әгәр безнең бәхәскә (әңгәмәгә) кушылучылар табылса, алар дәвам итәрләр дип уйлыйм. Шулай да эзләнүчеләр турында берничә авыз сүз.

Нигә дип без әле модернизм шагыйрьләренең иҗат принциплары турында сөйләшәбез? Бүгенге татар поэзиясе алдында шундый куркыныч бармыни? Кемнәр алар «модернистлардан арткан киемгә төренүчеләр»? Р. Харисмы, Р. Мингалимовмы, Роберт яисә Рәшит Әхмәтҗановмы, Р. Фәйзуллинмы, Р. Гатауллинмы? Миңа калса, бүгенге татар поэзиясендә эзләнүчеләргә караганда, эзләнергә теләмәүче, үз-үзләреннән канәгать, шома һәм буш, тук һәм мәгънәсез шигырь язучы тезмәчеләр хәвефлерәк. Уйлап карыйк: Сез уйлаганча, «аңлашылмый» торган шигырьләр, әйтик, бер елга

купме чыга икән? Китап нәшрияты чыгарган җыентыкларны карыйк, газет-журнал битләрендә басылган шигырьләрне барлап чыгыйк. Уртача әзерлекле укучы өчен аңлашылмаган 10 нан артык шигырь табылыр микән? Ышанып әйтәм, «аңлашылмый» торган шигырьләргә караганда, бернинди аңлауның да кирәге булмаган буш шигырьләр ун, йөз мәртәбә күбрәк. Әлбәттә, аңлашылмый торган шигырьләр кирәк дип әйтергә теләмим. Күбрәк эзләну кирәк дим, ә ул исә шома гына бармый, брак та булгалый, ләкин аңа карап эзләнү туктарга тиеш түгел. Фәкать эзләнү генә кызыклы ачышларга китерергә мөмкин. Шунысы сәер, безнең тәнкыйтьчеләребез аз гына яңалыкка да консерватив күсәк белән ташланырга шундый әзерләр ки, йоклый алмаган картлар кебек шундый саклар... тик халтурага гына дөм саңгыраулар.

Ә ассоциатив фикерләргә корылган шигырьләргә килгәндә, минемчә, монда бәхәсләшер нәрсә юк. Ассоциация — ул бер чара. Ул чара борынгыдан актив кулланышта булган. Шул ук дүртьюллык халык җырларын алыйк. Беренче карашка, бернинди уртаклыгы күренмәгән беренче ике юл белән соңгы ике юл арасында, күп очракта, ниндидер бер эчке бәйләнеш була. Ул эчке ассоциатив бәйләнешне тояр өчен күңелең бай булу гына кирәк. Әгәр бүгенге шагыйрьләр борынгыдан килгән бу алымны профессиональ иҗатта тулырак мөмкинлекләре белән файдаланалар икән, моннан поэзия баийый гына.

**И. Нуруллин:**

Бездә, билгеле, модернистлар юк. Чөнки модернизм иҗтимагый идеалларга тәпкүтәрәм кул селтәп, үз «мин»еңне бердәнбер реальлек итеп санап, шул «мин» хакына гына яшәүдән башлана. Модернистларның формаль казанышларын тәнкыйтьсез кабул итеп «ультра яңа» чаралар ярдәмендә оригиналь булырга тырышучылар, әлбәттә, бар. Бу очракта мин А. Вознесенский һәм Б. Ахмадуллина тибындагы шагыйрьләрне күздә тоткан идем. Моның кайбер чалымнары бездә дә булганлыгын искәрттем бугай.

Дөрес әйтәсез, «аңлаешлы» шигырьләр бездә чагыштыргысыз күп басыла. һәм аларның күпмедер өлешенең («күпмедер» дим, чөнки кем санаган?) дөньяга чыкмавы хәерлерәк булыр иде. Үтә «ассоциатив», ягъни кроссворд тибындагы шигырьләрне яклаганда әнә шундый уртакул, хәтта начар шигырьләргә сылтану беркадәр «тыелган алым» түгелме? Аларны чын мәгънәсендә халыкчан һәм югары художестволы шигырьләр белән янәшә куеп карарга кирәк. Шунда кемнең кемлеге ачыкланыр.

Ассоциативлык уңае белән халык җырларын бик урынлы искә төшердегез. Мондый җырларны да башлап кемдер чыгарган. Ул үз күңелендә, хыялында туган ассоциацияләрне җырга кертеп җибәргән. Бу ассоциация бүтәннәр күңелендә авазадаш булса, җырны эләктереп алганнар да һәм башкару процессында тагын да камилләштергәннәр. Ә инде авазадашлык тапмаган ассоциацияләр кабул ителмәгән, андый җырлар онытылган. «Халык шагыйрьләре»нең дә бит төрлесе булган: талантлысы, таланты чамалысы, халыкча уйлаучы һәм хис итүчесе, халыктан аерыла төшкәне.

Без бүген халык җырларының әнә шундый «сайлап алынганнары» белән генә эш итәбез. (Җыентыклардагы бик күп примитив җырлар исәпкә керми. Чөнки аларның күбесен, әйтик, очраклы авторлар чыгарган, һәм безнең фольклорчылар язып алган.) Аларда исә чын мәгънәсендәге халыкчан ассоциативлык. Бүгенге шагыйрь шул традицияне үстереп китә икән, аңа карата мактаудан бүтән сүз әйтеп булмый. Ә инде иҗтимагый мәсьәләләрне йөрәгенә бик үк якын алмый торган шагыйрь үзенең артык интим һәм субъектив ассоциацияләрен шигырьгә тутырса, яки оригинальлеккә дәгъва итә торган ассоциацияләрне гакыл белән уйлап чыгарса, мондый шигырьләр, белмим, киң катлау укучыда авазадашлык таба алырмы?

Минем теләк бер генә: шагыйрьләр «яхшы һәм төрле» булсын. Индивидуаль йөзләрен чагылдыра торган теләсә нинди поэтик чара куллансыннар, тик шигырьләре ниндидер элита өчен генә язылмасын. Китап укый торган барлык кешеләрнең дә күңеленә һәм акылына азык бирердәй булсыннар. Хәтта укымаучыларны да укырга мәҗбүр итсеннәр.

Нокта куярга вакыт түгел микән инде безгә, Равил? Әңгәмә байтакка сузылды, күп кенә уртак ноктлар ачыкланды. Барлык мәсьәләләр буенча да бер фикергә килү, минем Сезне, Сезнең исә мине үз «иманыбызга» китерү турында уйлау утопия

булыр иде. Әйдә, кайбер мәсьәләләрне укучыларга, бүтән белгечләргә һәм Вакыт исемле хакимгә калдырыйк.

**Р. Фәйзуллин:**

Шартлы рәвештә генә булса да, нокта куярга мин дә каршы түгел. Бу әңгәмәнең, полемика сәнгате күзлегеннән караганда, кайбер кимчелекләре булу мөмкинлегенә карамастан, поэзия белән якыннан кызыксынган кешеләр өчен, уйлану тәртибендә генә булса да, беркадәр файдасы булыр дип ышанам. Сөйләшкәннәрне бер кат күздән кичергәннән соң кайбер конкрет күзәтүләр һәм нәтиҗәләрдән тыш, бер нәрсә ачыклана: бүгенге татар поэзиясе турында ныклап һәм җитди рәвештә сөйләшергә вакыт җиткән икән.

**И. Нуруллин:**

Мин дә шулай уйлыйм. Безнең әңгәмәдән бүтән кимчелекләр дә табулары мөмкин. Әйтик, шагыйрьләр һәм шигырьләр ник аз телгә алынган? Нигә бу мәсьәлә, теге мәсьәлә күтәрелмәгән? Әмма бер утырып сөйләшүдә бүгенге поэзиягә кагылышлы барлык мәсьәләләрне иңләү мөмкин түгел. Фикер алышуда катнашачак иптәшләр безнең диалогны тулыландырырлар дип өметләнергә кирәк. «Шагыйрь-тәнкыйтьче-укучы» дигән «өчлек союзы» турында, мәсәлән, тәфсиллерәк итеп сөйләшергә мөмкин булыр иде.

**Р. Фәйзуллин:**

Дөрес. Чөнки бу өч инстанция арасындагы бәйләнеш принципиаль мөһим. Безнең көндәлек тормышта нәкъ шул «өч нарат» арасындагы реаль мөнәсәбәт бик катлаулы һәм буталчык.

**И. Нуруллин:**

Ул кадәр үк буталчык булмаса да, «тәнкыйть мәкаләсе башлыча кемгә адреслана?» дигән сорауга җавап биргәндә, бәхәсләр кабынып киткәли.

**Р. Фәйзуллин:**

Өч инстанциянең соңгысы да игътибардан читтә калмаска тиеш, минемчә. Поэзия дөрес аңлашылсын һәм бәяләнсен өчен, шагыйрьнең талантлы булуы белән бергә, укучының да укучы буларак талантлы булуы кирәк. Бу хакта без аз сөйлибез, аз язабыз. Әмма аннан да бигрәк, шагыйрь белән укучы арасындагы тәнкыйтьченең роле әдәби процесста һаман тиешле югарылыкта түгел, минемчә. Гадәттә, ул шактый артка калып... түбәтәйләр җыеп килүчән.

**И. Нуруллин:**

Өметне өзмик: фикер алышуда катнашачак иптәшләрнең берсе бәлки тәнкыйтьнең роле турында да язып чыгар әле. Талантлы укучыга килгәндә, мин бу оригиналь һәм эффектлы формуланы кайдадыр укыган идем. Ике төрле уйларга юл калдырмас өчен, «зәвыклы» дигән гап-гади сүзгә кайту кулайрак булыр. Таланты чәчрәп тормаган укучыны да поэзия үз тәэсиреннән читтә калдырмаска тиештер шаять.

**Р. Фәйзуллин:**

Анысы шулай да булсын. Тик бер нәрсә бәхәссез: поэзиядә тагын бик күп ачыклыйсы нәрсәләр бар. Әйтик, шигъриятебездә традицияләр һәм бүгенге чынбарлыкны иҗади үзләштерү, әдәби осталык, мәктәпләрдә бүгенге татар поэзиясен укыту, гомумән, аны пропагандалау мәсьәләләре... Болар турында җентекләбрәк сөйләшүгә поэзиябезне яратып, үсеше өчен янып яшәүче бүтән иптәшләр кушылырлар, әңгәмә барышында башлап та ахырынача чыгылмаган кайбер мәсьәлә-проблемалар турында дәвам итәрләр.

# «ТУГАН ҖИРЕМ, СӨЙГӘН ЯРЫМ...»

Мостай Кәрим поэзиясе дөньяны һәм кешене үзенчә аңлый һәм сурәтли белүе, рухи дөньяга игътибарлы булуы, фәлсәфи тирәнлеге, сәнгатьлелек чараларының байлыгы, төрлелеге белән укучының мәхәббәтен казанды. Аның дәртле һәм уйчан, ашкынулы һәм салмак, тирән идеяле һәм кичерешкә бай шигърияте иҗтимагый прогресс, халык интереслары һәм көн романтикасы белән яши, үзенә көч һәм илһам биргән туган иленә, халкына хезмәт итә, киләчәкнең физик һәм рухи камил кешесен тәрбияләү рухы белән яши.

М. Кәрим поэзиясе шәхси аша гомумине, аерым кеше язмышы аша ил, халык биографиясен чагылдыруның югары үрнәкләрен бирүе, тынгысызлыгы белән көчле. Шагыйрь үз рухына азыкны, шигъри дәртне, куәтне чынбарлыктан, туфрактан, яңгыр тамчысыннан, җилдән, ай нурыннан, кешеләр күзендәге моңнан ала, шул байлыкны талант көче, хыялы белән баетып, тулыландырып кешеләргә кайтара. «Барлык белгән һөнәремне мин кешеләр белән бүлешәм», — ди шагыйрь. Ә кешеләр аңа борчуларын, әрнүләрен, яраларын калдырып китәләр: «Шуңа аның карашында моңсулык арта бара». Лирик геройга хас моңны кешеләр язмышы, дөнья киләчәге, беренче мәхәббәт, гарәп кызы, Вьетнам, Салават фаҗигасе өчен борчылу, уйланулар тудыра.

М. Кәрим замандашы белән соклана, соклану хисен шигырь юлларына алып керә. Аның кешесе масштаблы олы дөнья, тарих белән аңлаша, табигый гүзәллекне сиземли торган шәхес:

Кеше көчле. Кулда тота каүсәсен ул
Бу җиһанның. Кеше көчле.
Бер селкетсә, тупылдачып йолдыз коелыр,
Агачтагы алма төсле...

Аннары: «Кендегемне кистеләр дә Җир шарына ялгадылар», — дип яза шагыйрь.

М. Кәрим иҗатына багышланган мәкаләләрнең, чыгышларның күбесендә «ул туган ил, туган туфрак җырчысы» дигән фикер кабатлана. Халыкчан шигъриятне туган ил матурлыгы белән соклanudан, илһамланудан башка күз алдына китерүе кыен. Пушкин, Лермонтов, Шевченко, Блок, Маяковский, Тукай, Такташ кебек олы талантлар туган илне, туган җирне үзләренчә күреп һәм җырлап шөһрәт казандылар, реализм юлына чыктылар. Россияне кура җиләге үскән кырга тиңләгән Есенин: «Минем бөтен иҗатым бер олы мәхәббәткә, Ватаныма мәхәббәткә багышланган», — дип яза. М. Кәрим исә шул ук теманы үзенчә калкытып куя, туып үскән төбәгенең ямена яңа буяулар, бизәкләр өсти.

Тамырга — дым, яфракка — нур,
Син илһамым, син көч-кәрем,
Синнән башка мин бичара,
Туган җирем, сөйгән ярым.

Поэзиягә сугыш алды елларында килеп кергән М. Кәрим үзенең тәүге шигырьләрендә ук табигать хозурлыгында кеше рухының күркәмлегенә бәрабәр буяулар таба, рухи һәм матди дөньялар арасында эчке якынлык эзли. «Сентябрьнең талгын җилле күгелҗем киче иде», «Ай йөзтүбән ятып җирне күзли», «Таныш моңның бәлки меңенче кат яңгыравы булыр шушы җыр» кебек самими гыйбарәләрдә яшь шагыйрьнең милли поэзия казанышларын үстерүгә омтылышы сизелә, ул шигырьләрдә табигатьне нечкә сиземләү бар.

М. Кәрим поэзиясенә ирлек, фәлсәфи тирәнлек, тормыш драматизмын сурәтләү осталыгы сугыш елларында килгәнен беләбез. Тормыш һәм үлем бергә атлаган, кеше яшәешенең, рухының югары үрләре сыналган ул елларда поэзия халыкның героик тавышы булырак яңгырый. Гомумән,

[1] Мостай Карим. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977.

олы тарихи тетрәүләр, фаҗигале хәлләр чорында бик күп художникларның таланты яңача ачыла. М. Кәрим дә, фикерле һәм хисле шагыйрь буларак, Бөек Ватан сугышының дәһшәтле дулкынында үсеп чыкканнарның берсе. Аның тыныч, салмак тавышы ныгый, чынбарлыкны тасвирлау алымнары байый бара.

Давыл... давыл! — Ул бит минем
Тере хәбәрем,
Якын яшен, якты яшен —
Минем сәламем.
Мин суలармын, җирдә давыл
Тынмаса әгәр,
Мин янармын, соңгы яшен
Сүнгәнгә кадәр.

М. Кәрим поэзиясе турында уйлаганда Белинскийның «иҗатка сәләтле булу талант, ә иҗатта халыкчан була алу икенче талант» дигән сүзләре искә төшә. Шагыйрь кеше кичерешләренең тирәнлеген, киңлеген, илаһилыгын ачу, шәхси-интим башлангычны, лиризмны, эчке аһәңне көчәйтү юлында, ул өзлексез кыю эзләнүләр алып бара. «Ярлар кала», «Таулар», «Туган җирем», «Чакырмагыз, таулар» кебек шигырьләр тормыш фәлсәфәсен, шәхеснең эчке кичерешләрен тулырак сурәтләү юлында эзләнүләр җимеше буларак туган камил композицияләре, нәхтәлекләре, эчкерсез интонацияләре белән хәтергә сеңәләр. Ул дөньяны үзенчә күрә белә. Күктәге айны «алтын умартага», йолдызларны «корт иленә» тиңли. Каеннар аның юлына «сары йолдызлар» сибә.

Социалистик реализм методының киң иҗат мөмкинлекләренә таянып, XX гасыр кешесенең фикерләү рәвешен, рухи-әхлакый омтылышларын, «җан диалектикасын», зиһен җегәрен тулырак ачуга омтылып, шагыйрь бер үк вакытта оригиналь һәм халыкчан булган поэзиянең югары үрнәкләрен бирде. Аның Европа-Азия циклы, Вьетнам турындагы шигырьләре, Болгар дәфтәреннән, Кабарды-Балкар дәфтәреннән кебек лириканың гадәти чикләрен киңәйтеп җибәргән, уртак кичереш, уртак иҗтимагый фикер белән бер-берсенә тартылып торган шигъри бәйләмнәре башкорт поэзиясе өчен җитди ачыш булды.

Икенче бер шигырьләрендә ул совет иленең гражданины, тынычлык сакчысы, дәүләт кешесе буларак ачыла. «Ханойда күл буенда уйланулар» шигыре шуның ачык үрнәге:

И кешелек! Нигә юл куясың
Ятлыз кулларга,
Алма кебек планетаны
Шулай торарга?

Булгәләргә җирне как дошманга
Без рөхсәт итсәк,
Буламабыз балаларга
Алма һәм икмәк.

М. Кәримнең лирик герое тыныч,ваемсыз, талгын тормышны кабул итми. «Тыныч, имин» тирәлектән ул давыллы, мәшәкатьле якларга, күкрәүле, хәтәр тауларга, дөнья язмышы кыл өстендә торган төбәкләргә юл тота:

Монда рәхәт. Шул рәхәттә
Чак-чак кына түзәм...
...Мин тауларга китәм бүген.
Хуш бул, тыныч үзән.

Чынбарлыкны шигъри күзаллау алымнары, фикерләү тибы буенча реализмга тартылып торса да, «акыл күзенә» өстенлек бирсә дә, шагыйрь романтик, ассоциатив, символик алымнарны, эпик поэзия, драма сәнгате ачышларын эшкә җигүдә дә «кеферлек» күрми. Шәхес һәм халык, шәхес һәм сәнгать, тарих һәм заман кебек проблемаларның яңача куелышы, яңа җәмгыять төзү юлындагы уңышлар шагыйрьне поэма катына, трагедия жанрына алып килде.

Халык тарихы кырыс һәм изге. Ул сүз һәм форма монументальлеген таләп итә. Халык шагыйре Салават һәм көрәштәшләре булган татар, чуваш, башкорт батырлары турында М. Кәрим фәлсәфи тирәнлек, публицистик гомумиләштерү белән үзенең шул батырлык варисы булуына шатланашатлана яза. Шагыйрь тарихи хакыйкатьне үз хыялы, хәзерге әхлакый тәҗрибә белән баета, халык җырларының камиллеген, халык мәкальләренең хикмәтле көчен XX гасыр кешесенең фикерләү үзенчәлекләре белән тулыландыра.

Поэзия кеше һәм аның бүгенге бәхете, матур киләчәге өчен көрәшнең алгы сызыгында тора, кеше рухының бөеклеген, олылыгын, илаһилыгын раслау өчен көрәшә. М. Кәримнең киң кырлы, тирән эчтәлекле интернациональ поэзиясе шуңа дәлил. «Ай тотылган төндә», «Ташлама утны, Прометей», «Салават» кебек фәлсәфи-этик драмаларында да ул кеше рухының камиллеген, кешелекнең, гуманизмның мәңгелеген җырлый. Шартлы-романтик алымнарга, ассоциатив фикерләү мөмкинлекләренә, Шекспир, Пушкин, Такташ традицияләренә таянып, М. Кәрим олы дөньяның олы проблемаларын калкытып куя, дәверне кеше язмышы, аның уй-кичерешләре аша сурәтли. Халык йөрәгендә эз калдырган масштаблы вакыйгаларны тасвирлаганда да, чорның әхлакый

проблемаларын калкытып куйганда да М. Кәрим шагыйрь булып, хис кешесе булып кала. Иҗатының буеннан-буена сузылган лиризм, шигъри рух трагедияләрдә дә кеше характерын ачу юлларын бермә-бер киңәйтә. Аларга эстетик киңлек хас. Ул башкорт поэзиясе казанышлары һәм Такташ, Исәнбәт, Бурнаш трагедияләре рухын үзенчә дәвам иттерә, яшьрәк буын татар-башкорт шагыйрьләрен яңа иҗади эзләнүләргә илһамландыра.

СССР Дәүләт премиясе лауреаты Мостай Кәримнең кешелекле моңлы, әхлакый эчтәлекле, тирән хисле поэзиясе республика, дәүләт чикләрен үтеп, матурлыкны һәм гуманизмны раслау өчен көрәшә. Ул дала киңлеге белән әрәмә ямен, Урал биеклеге белән урман моңын куша алды. Татар поэзиясенә Башкортстан табигатенең күркен, Дим, Агыйделләрнең моңын кайчандыр Ярлы Кәрим, Фатих Кәримнәр алып керде. Мостай ага да Башкортстан Кәримнәренең варисы, дәвамы булып, элгәрләре башлаган изге эшне яңа югарылыкта үстерә һәм дәвам иттерә.

Тәлгать **ГАЛИУЛЛИН.**

# АКЫЛ ҺӘМ ШИГЪРИЯТ КИТАБЫ

Табышмаклар — халык иҗатындагы иң популяр жанрларның берсе. Ял сәгатьләре, кичәләр, викториналар, КВН ярышлары һичкайчан да табышмак әйтешүсез генә узмый.

Жанрның тормышчанлыгы, яшәүчәнлеге нәтиҗәсендәдер, мөгаен, хәзерге көнгә кадәр дистәдән артык махсус табышмак җыентыгы дөнья күргән. Күптән түгел бу исемлеккә тагын бер яңа хезмәт өстәлде. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторында хәзерләнеп, Татарстан китап нәшриятында басыла торган 12 томлык «Татар халык иҗаты»ның икенче томы — «Табышмаклар» җыентыгы чыкты.

4072 табышмакны эченә алган бу китап томны төзүче, филология фәннәре кандидаты Х. Мәхмүтовның «Татар халык табышмаклары» исемле кереш мәкаләсе белән башлана. Автор табышмакларның килеп чыгуын борынгы җәмгыятьнең социаль-экономик шартларына бәйләп аңлата. Иҗтимагый үсешнең түбән баскычында яшәгән кешеләр бөтен әйләнә-тирәлекне җанлы итеп күз алдына китергәннәр. Борынгы аучы, мәсәлән, хайваннарны, киек-җәнлекләрне кеше сөйләмен аңлау сыйфатына ия дип уйлаган. Табигатькә һәм табигать күренешләренә мөнәсәбәттә дә шундый хыялый караш өстенлек иткән. Имеш, кырларда, урманнарда, елга-күлләрдә ниндидер акыллы затлар яши, алар еш кына кешеләргә зыян салып торалар. Менә шундый дошман көчләрне алдау, аларга үзләренең уй-ниятләрен белгертмәү өчен, кешеләр яшерен телдән файдаланганнар. Сунарга чыкканда киекләрне һәм ау коралларын үз исемнәре белән атау тыелган — җанварлар ишетеп качып китәр дип уйлаганнар. Алар турында сөйләшергә кирәк булганда «хайваннар аңламый торган» алмаш исемнәр, сүзләр кулланылган. Автор бу күренешнең калдыкларын хәзерге татар телендә дә шактый күп таба. Мәсәлән, Себер татарларында аюны хәзер дә «олы ата», «олы әкә», «көрән», «хуҗа» кебек исемнәр белән атап йөртәләр икән. Шулай ук еланны «кара таяк», «камчы», «каеш» кебек алмаш исемнәр белән атап йөртү гадәте сакланган. Халык үз вакытында мондый ышануларга зур әһәмият биргән, хәтта төрле афоризмнар аша аларның ни өчен кулланылганлыгын да аңлаткан:

> Елан дисәң, елата,
> Камчы дисәң, тик ята.
>
> Чуан дисәң, чыга, ди,
> Коры ботак дисәң, корый, ди.

Мәкалә авторы яшерен телнең ясалыш принципларын табышмакларның ясалу алымнары белән чагыштыра һәм алар арасында күзгә бәрелеп торган охшашлыклар күрә. Әйтик, еланның алмаш исеме — «камчы». Ә елан турындагы табышмакта: «Җиз камчыны тотып булмый», диелә. Кайбер алмаш исемнәр исә бернинди үзгәрешсез табышмак булып киткәннәр. Мәсәлән, зиратның алмаш исеме — «төтенсез авыл». Ә табышмагы — «Төтенсез авыл — ул нәрсә?» Шундый фактлардан чыгып, Х. Мәхмүтов жанрның башлангычы борынгы яшерен телдәге алмаш исемнәргә, әйберне турыдан-туры атамыйча, аның хакында читләтеп әйтүләргә барып тоташа дигән нәтиҗәгә килә.

Борынгылар табышмакка тылсым чарасы

итеп тә караганнар. Табышмак турыдан-туры йола составына кергән. Әмма хезмәт процессында кешенең чынбарлык серләренә торган саен тирәнрәк төшенүе, табигать көчләрен инде чын-чынлап буйсындыра башлавы нәтиҗәсендә, борынгы мифологик ышанулар өчен дә җирлек югала бара. Яшерен тел һәм аның белән бәйләнгән табышмакның тылсымчылык роле дә акрынлап юкка чыга. Халык табышмакка күңел ачу чарасы итеп карый башлый, шулай итеп, табышмак сүз сәнгатенең бер төре буларак үсеп китә. Х. Мәхмүтов бу фикерләрен исбатлаганда могтәбәр галимнәр В. П. Аникин, Д. К. Зеленин, И. М. Колесницкая, К. Насыйри, Н. Исәнбәт, шулай ук таҗик, башкорт һ. б. халыклар фольклорчылары хезмәтләренә таяна.

Табышмакларның тематикасы уңае белән автор үз халкыбызның материаль һәм рухи культурасына бәйләнешле үзенчәлекләргә игътибар итә. Татар табышмакларына гына хас булган тематик үзенчәлекләр эзли. Әйтик, безнең халыкта уку-язу, аң-белемгә багышланган табышмаклар аеруча күп. Моны автор борынгы бабаларыбызның уку-язу, аңбелемгә зур әһәмият бирүләре белән аңлата.

Табышмаклар, халык иҗатының башка жанрлары кебек үк, халыкның тормыш-көнкүрешен, уй-хыялларын, төрле этаплардагы социаль хәлен чагылдыра. Фольклорчы халыкның әүвәлге тормышын, социаль хәлен өйрәнүдә табышмакларның кыйммәтле чыганак булуына да аерым игътибар бирә. Аларда халыкның социаль һәм дини изүләргә карата протесты, җәберчеләргә карата иронияcе чагылыш табуны билгеләп уза. «Ишектән керә дә, түргә менеп утыра», «Башы чалмалы, акылы чамалы» (мулла), «Корыган чыршы башында котырган сарык кычкыра» (мәзин) дигән табышмакларда халык дин әһелләреннән ачы көлсә, мылтык һәм самавар турындагы табышмакларда хезмәт кешесенең социаль тигезсезлеккә карата тәнкыйди карашы чагыла.

Кечкенә генә нәл ташы,
Ханнар, биләр юлдашы.

Ике чите су булыр,
Уртасында ут булыр,
Байларны көлдерер,
Ярлыларны бөлдерер.

Теркәлеп калган беренче табышмакларны без 1303 елда төзелгән «Коман мәҗмугасы»нда очратабыз. Кереш мәкаләдә шул заманнан алып хәзерге көнгәчә табышмакларны җыю, бастырып чыгару һәм фәнни өйрәнүгә җентекле күзәтү ясала. К. Насыйри, Г. Арсланов, Х. Бәдигый, Х. Ярми һ. б. ларның табышмакларны бастыру һәм өйрәнүдәге хезмәтләре ассызыклап күрсәтелә. Н. Исәнбәт бу өлкәдә аеруча зур көч куйган галим. Ул, табышмакларны җыйнап бастыру белән бергә, аларны чын-чынлап фәнни нигездә өйрәнүче дә булды. Җыентыкны төзүче хаклы рәвештә аның бу эшчәнлегенә югары бәя бирә.

Китапның төп әһәмияте, әлбәттә, табышмакларның үзләрендә. Текстларны сайлауда төзүче зур таләпчәнлек күрсәткән диясе килә. Ул җыентыкны төзегәндә 38 исемдәге китап, газет-журнал һәм кулъязма фондлардан файдаланган. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондыннан алынган табышмаклар томның шактый өлешен тәшкил итәләр. Ул текстлар арасында әле матбугатка беренче мәртәбә чыкканнары да бар. Мәсәлән:

Атасы чарык әйләндерә,
Угылы пычагын яный.

(Күк күкрәү, яшен.)

Мине тотып ашамыйлар,
Миннән башка туй да ясамыйлар.

(Тоз.)

Утырдым төпкә,
Карадым күккә,
Тоттым ак каен,
Яладым маен.

(Орчык белән йон эрләү.)

Табышмаклар, фольклор фәнендә кабул ителгәнчә, тематик классификация ясап «Күк җисемнәре», «Җир һәм аның рельефы», «Ел фасыллары», «Табигать күренешләре», «Әдәбият, уку-язу», «Музыка кораллары» кебек 33 төркемгә бүлеп бирелгәннәр. Бүлекләрдә башта табышмакларның җавабы, ә аның астына шул җавапка караган текстлар китерелә. Бу принцип томның эчтәлеген ачык күз алдына китерергә ярдәм итә һәм китаптагы табышмаклардан файдалануны җиңеләйтә.

Томның ахырында урнаштырылган искәрмәләр бүлегендә төп өлешкә кергән табышмакларның вариантлары китерелә, текстларда очраган архаик һәм диалекталь сүзләргә, борынгы тормыш-көнкүреш детальләренә, этнографик элементларга кызыклы гына аңлатмалар бирелә. Алар табышмакларның шигъриятен ныграк тоярга, эчтәлеген яхшырак аңларга ярдәм итәләр. Мәсәлән, китапның 40 нчы битендә мондый табышмак бар:

Казыкка бәйләнгән ике атым дулый,
Дуласа да бер тирәдән китә алмый.

Җавабы — Тимер казык, Акбузат, Күкбузат йолдызлары. Бу табышмак беренче ка-

рашка бер дә аңлашылмый төсле. Баксаң, бу татар халкының күк җисемнәре турындагы бер легендасына нигезләнгән әсәр икән. Искәрмәләрдән укыйбыз: «Берсе ак, икенчесе күк атны тимер казыкка бәйләп куйганнар, имеш. Алар шул казык тирәсеннән читкә китә алмыйча һаман утлап йөргәннәр. Бервакыт аларны җиде карак (Җидегән йолдыз күздә тотыла) урлап китәргә ниятли. Болар Акбузат һәм Күкбузат артыннан, әй, чабалар, әй, чабалар, әмма һаман куып җитә алмыйлар, имеш».

Тагын бер мисал. Китапның 92 битендә «Суда сөләйман» дигән табышмак китерелә. Җавабы — сөлек. Инде искәрмәләргә күз салыйк. Анда болай дип язылган: «Легендалар буенча, Сөләйман патшаның тәхете һәр вакыт су өстендә эленеп торган, имеш. Бу хакта бахшы-шаманнарның имтом сүзләрендә дә искә алына... Сөлекне Сөләйман исеме белән атау алар арасындагы аһәңдәшлек белән аңлатыла».

Әлбәттә, бу табышмаклар бик борынгы булып, халыкта мифлар, легенда-риваятьләр актив кулланылышта булган заманда популяр булгандыр. Легендасы онытылгач, аңа нигезләнгән табышмак та аңлашылмас булган. Фольклорчының мондый онытыла өшкән табышмакларга «җан өреп» узуы бик әйбәт нәрсә.

Х. Мәхмүтов, искәрмәләр аша, күп кенә табышмакларны 14 нче гасыр язма истәлеге «Коман мәҗмугасы»ндагы табышмаклар белән чагыштыра, андагы борынгы төрдәшләрен күрсәтеп бара. Бу исә халык иҗаты белән кызыксынучыларга табышмак жанрының тарих дәвамында үсеш-үзгәрешен, яшәешен күзалларга ярдәм итә. Әлеге чагыштырулар тел тарихын өйрәнүчеләр өчен дә кызыклы булыр дип ышанасы килә.

Сүз дә юк, «Табышмаклар» томының уңай яклары турында әле күп сөйләргә булыр иде. Әмма бу хезмәт кайбер кимчелекләрдән дә азат түгел. Әйтик, җыентыкка урнаштырганда мөстәкыйль табышмакларны аларның вариантларыннан анык аера алмау очраклары күренгәли. «Иләгемнең кысасы аркан, төбе таш» (җылым); «Миегы озын, акылы кыска, үзе суфи, урлашырга оста» (мәче); «Сөяк авыз, ит сакал, бер йөрмешен күреп кал» (әтәч) кебек табышмаклар образлылык һәм шигърилек җәһәтеннән мөстәкыйль әсәрләр. Әмма алар вариантлар буларак искәрмәләр бүлегендә генә урын алганнар. Киресенчә, «Өй әйләнәсе кыл дилбегә»; «Өй буйлатып аркан иштем»; «Өй артында сары аркан»; «Өй аркылы аркан чорналган»; «Өй әйләнәсендә кызыл пута»; «Өй әйләнә, өйгә ефәк бәйләнә» (җавабы: өй стенасы арасындагы мүк) кебек бер-берсенә шактый якын торган табышмакларның барысын да төп текстка кертүнең хаҗәте булдымы икән?..

Табышмаклар арасына халык иҗатының башка төрләреннән адашып килеп кергән текстлар да очрап куя. 213 биттәге 3782 номерлы «табышмак»ка күз салыйк:

Җомга көне көн дәгел,
Мулла мөселман дәгел,
Һәркем мулланы мөселман дисә,
Ул да мөселман дәгел.

Аның җавабы «сүз уйнату» диелгән. Авазларның бер төрле яңгырашына нигезләнеп ясала торган мондый әсәрләр халык иҗатында аз түгел. Алар бигрәк тә балалар фольклорында нык таралган һәм алдавычлар дигән атама белән йөртелә.

Табышмакларны төркемләүдә дә кайбер чатаклыклар очраштыргалый. Мәсәлән, XXIX бүлек «Төрле темага караган табышмаклар» дип исемләнгән. Ә табышмакларның тематикасына күз салсаң, аларның күбесе бер сферадан булып күренә: магнит, электр агымы, ток, корыч кою, атом, тимерче эше, завод гудогы, фотоаппарат һ. б. Моны «физик күренешләр, техник приборлар, производство» дигән бүлек итеп бирү отышлырак булыр иде. Телевизор, радио турындагы табышмаклар да, үз оясын таба алмыйча, ничектер һәм нигәдер «музыка кораллары» бүлегенә кереп кунаклаганнар.

XXXIII бүлеккә җавабы билгесез табышмаклар тупланган. Дөрес, алар шигъри яктан да, образлылык җәһәтеннән дә игътибарга һичшиксез лаеклар. Әмма ул табышмакларны укучыга тәкъдим итеп, җавап җибәрүләрен үтенүне әллә ничә елга бер генә чыгарыла торган басма аша эшләү нәтиҗәле булырмы икән? Җавапларны көндәлек матбугатка адреслатырга кирәк булгандыр бәлки...

Сүз дә юк, бай һәм катлаулы бер жанрны һәр яктан анализлап, системага салу авыр эш. Монда ара-тирә киткән «кыешмыеш»лар гына тәэсирче хезмәтенә дә, томның дәрәҗәсенә дә әллә ни күләгә төшерә алмый. Шунысы куанычлы: һәм фәнни, һәм практик кулланма булырлык файдалы китап дөньяга чыкты. Җыентык — фольклор белгечләре, әдәбият һәм сәнгать осталары, укытучылар, тәрбиячеләр, студентлар, мәктәп балалары өчен генә түгел, ә киң катлам укучыларыбызга да күркәм бүләк.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ.

# ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ

*(1888—1938)*

Татар совет әдәбияты һәм публицистикасының беренче адымнарын, шул елларда ирешелгән беренче уңышлар һәм кайбер кимчелекләрне җәмәгать эшлеклесе һәм журналист, язучы һәм тәнкыйтьче Ф. Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) эшчәнлегеннән башка күз алдына китерү дә кыен.

1888 елның 22 мартында элекке Спасс өязе (хәзер Әлки районы) Карамалы авылында туып, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алган Фатих бик яшьли кулына каләм ала. 1906—1917 нче елларда «Йолдыз», «Аң», «Ялт-йолт», «Мәктәп», «Ак юл» кебек вакытлы матбугат органнарына актив языша. Һәм шул ук елларда беренче сәхнә әсәрләрен укучы һәм тамашачылар хөкеменә тәкъдим итә («Мөкатдәс хезмәт» (1907), «Безнең заман» (1909), «Ямьсез тормыш» (1915).

Революция алды елларында ул Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укыта һәм шушы еллардан алып аны гомеренең соңгы көннәренәчә күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов белән олы дуслык һәм теләктәшлек хисләре бәйләп тора.

Ф. Сәйфи-Казанлы Октябрь революциясенә кадәр үк актив тәнкыйть эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. Рус әдәбияты һәм эстетик фикере белән яхшы таныш булган авторның бу еллардагы эзләнү һәм тәҗрибәләре аерым игътибарга лаеклы. Шул уңайдан, аның әдәби-эстетик фикеребез үсешенә җитди өлеш керткән «Ялтыравыклы ялган» дип исемләнгән күләмле мәкаләсе[1] бигрәк тә кызыклы. Яшь авторның фәннитеоретик уйлануларыннан гыйбарәт булган бу хезмәтнең беренче өлешендә сүз татар әдәбияты өчен XX йөз башы шартларында зур әһәмияткә ия булган әдәбият һәм сәнгатьтә гүзәллек мәсьәләсе хакында бара (дөрес, икенче бүлектә Ф. Сәйфи-Казанлы Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»е уңаена шактый кискен һәм хата фикерләр дә әйтеп ташлый. Әмма, әйтеп киткәнебезчә, хезмәтнең әһәмияте аның беренче өлешендә).

Тәнкыйтьче, мәкаләнең башында ук, вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле кабатланып торган: «Татар тормышы, бүгенге хәятыбыз ямьсез һәм күңелсез, нигә аны әдәбиятта күрсәтергә», кебек фикерләргә каршы чыгып, аларның әдәбият һәм сәнгатьнең асылын аңламыйча әйтелгән сүзләр булуына игътибар итә. «Нәфис әдәби әсәрнең кыйммәте аның бөтенлегендә, мөхәррир яисә шагыйрьнең хыялында сурәтләнгән әмәлнең дәреслегендә, әсәр эчендәге кешеләр һәм күренешнең тәнасебендәдер»[2], — дип чыга Ф. Сәйфи-Казанлы. Аның өчен чынбарлыкның әдәбиятка мөнәсәбәттә беренчеллеге бәхәсле мәсьәлә түгел. Ләкин безне бу һәрракта тәнкыйтьченең тормыштагы гүзәллек белән әдәбияттагы гүзәллек арасындагы үзара мөнәсәбәтне ачыклау процессында әйтелгән фикерләре кызыксындыра. Табигать үзенең бөтенлеге

[1] «Тормыш», 1916, 393 сан.
[2] Т ә н а с е б е н д ә — типиклыгында.

белән матур дип чыга ул. Сүз уңаена шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Ф. Сәйфи-Казанлы гүзәллек мәсьәләсен аңлатуда Н. Г. Чернышевский фикерләренә аеруча якын килә. Ф. Сәйфи-Казанлы Чернышевскийның эстетик мирасы һәм бигрәк тә «Сәнгатьнең чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтләре» хезмәте белән якыннан таныш булган дип әйтүгә нигез бар. Аның теоретик фикерләрендә бөек рус эстетигының тәэсире үзен турыдан-туры сиздереп тора. Ләкин шул ук вакытта тәнкыйтьченең мөстәкыйльлеген дә күрми китәргә ярамас. Мәсәлән, сүз табигатьтәге гүзәллек турында барганда, Н. Г. Чернышевский анда яшәүче күпчелек җанварларның гүзәл булуын нигезләп чыга. Шулай да табигатьтә гүзәллектән мәхрүм калган нәрсәләр дә бар. Шундыйларның берсе — бака. Ул үзенең тышкы кыяфәте белән бездә соклану тойгысы тудыра алмый, дип яза Чернышевский[1]. Ф. Сәйфи-Казанлының да, тормыштагы (табигатьтәге) гүзәллек турында сүз чыккач, бака мисалына тукталуы бер дә очраклы түгел. Ләкин ул, Чернышевскийдан аермалы буларак, баканың да үз тирәлегендә матур булуын аңлатып чыга: бака — бер карашка, ямьсез һәм чиркандыргыч нәрсә, ләкин... «...табигатьтә ул матур, табигать кануны каршында ул нәфис, (...) сазлыктагы тормышы белән ул да матур», — дип яза тәнкыйтьче. Димәк, әдәбият һәм сәнгатькә килсәк, автор түбәндәгечә аңлата: «Әдәби әсәрнең дә кыйммәте, матурлыгы аның бөтенлегендә, үткәрергә теләгән әмәленең дә дөрескә әсас ителүендәдер». Шул рәвешчә, Ф. Сәйфи-Казанлы, тормыштагы гүзәллек белән сәнгатьтәге гүзәллек арасында зур уртаклык булуын күрсәтеп, кешенең гүзәллекне бәяләү критерийлары табигать һәм тормыш матурлыгы тәэсирендә формалаша дигән әһәмиятле нәтиҗәгә килә. Дөрес, тәнкыйтьче тормыштагы гүзәллек белән сәнгатьтәге гүзәллекнең һәркайсына аерым тукталып, аларның специфик үзенчәлекләрен, гүзәллек төшенчәсендәге объективлылык һәм субъективлыкны аңлату югарылыгына күтәрелми әле. Сәнгатьнә гүзәллек тә иҗади шәхеснең чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәте нәтиҗәсендә формалашучы бердәнбер категория түгел бит. Чынбарлыкның эстетик байлыклары гүзәллектән тыш тагы күп кенә башка категорияләрдә дә чагылырга мөмкин (героик, трагик, комик һ. б.). Тәнкыйтьче әле иҗат процессындагы чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтне дә, нигездә, сәнгатьчә гүзәллек белән генә бәйләп аңлата. Ләкин шул характердагы күп кенә җитешсезлекләргә дә карамастан, мәкаләдә күтәрелгән эстетик фикерләр үз чоры өчен гаять зур әһәмияткә ия булалар. Ф. Сәйфи-Казанлының сәнгатьчә гүзәллек турындагы бу кечкенә трактаты, барыннан да элек, татар әдәби-эстетик фикеренең үсеше процессында өлгергән хезмәт булды.

Бөек Октябрьдан соң Ф. Сәйфи-Казанлының иҗтимагый-политик, әдәби иҗат, тәнкыйть һәм публицистик эшчәнлеге тагы да активлаша төшә һәм үсеп китә. Ул төрле елларда «Ирек», «Безнең юл», «Эш», «Чулпан», «Кызыл шәрык» кебек вакытлы матбугат органнарында эшли, даими рәвештә чыгыш ясап килә. Аның «Дошманнар» (1921), «Хикәяләр җыентыгы», «Авыл хатлары» (1925), «Инвалид» (1928), «Ике татар классигы» (1929), «Яңалиф тарихы» (1929), «Зәкуан мулла шәҗәрәсе» (1930), «Өч нарат» (1930), «Зәңгәр алан» (1933), «Зөбәрҗәт» (1936) кебек хезмәтләре һәм әдәби әсәрләре аерым китап булып укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Бу чорда Ф. Сәйфи-Казанлы тарих, халык мәгарифе һәм авыл хуҗалыгының актуаль мәсьәләләре белән даими кызыксынып килә, шул өлкәләргә караган хезмәтләр белән дә чыгыш ясый. Казан педагогия институтында һәм марксизм-ленинизм институтында укыта. Гомумән, Ф. Сәйфи-Казанлы зур тормыш юлы үтеп, күп кырлы һәм бай әдәби мирас калдырган әдипләребезнең берсе булып тора.

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ.**

[1] Н. Г. Чернышевский. Избр. эст. произведения. М., 1974, стр. 75.

# ДӘРҖИЯ АППАКОВА

*(1898—1947)*

Беренче тапкыр мин аны Матбугат йортында күрдем. Баскычтан төшеп килә. Сугыш елларының студент паегына яшәп, чүрәкәй үрдәк хәтле генә калган кызга ул олы, олпат күренде. Өстендә нинди мехтандыр, ул чагында «манто» дип йөртелгән тун, башында каракүл бүрек, бүрек өстеннән кызыл йон шарф салган.

Үзем шикелле үк әдәбият җене кагылган, буш вакыты булдымы, Матбугат йортының бишенче катындагы консультация бюросына шигырь тотып йөгергән дус кызым ул үтеп киткәч:

— Дәрҗия Аппакова, — дип пышылдады.

Кылт итеп «Кечкенә Бануның тарихы» дигән китап исемә төште. Һәрнәрсәне белергә, серенә төшенергә тырышкан кечкенә Бану, сабак укытудан бигрәк садака җыярга яраткан явыз, комсыз абыстай...

Дәрҗия Аппаковаңы мин еш очрата торган булдым. Ул үзе дә һиндәй яшьләрнең бу йорт тирәсендә нинди эш, ни өметләр белән йөрүләрен төшенә иде булса кирәк, коңгырт күзләрен тутырып карап үтә иде. Аның яше дә, талчыккан түгәрәк битенә нур бөркеп караган күзләре дә еракта калган әнине хәтерләтеп, сугыш һәм уку авырлыгыннан шиңә төшкән күңелне һәрчак тергезеп җибәрә иде.

Ул вакытта әле мин аның тормышын — яшь чагында Казанда балалар укытуын, комсомол өлкә комитетында эшләвен, театр мәктәбендә укып актер булырга әзерләнүен һәм, ниһаять, Урта Азиягә китеп, озак еллар шунда эшләвен, шунда китаплар язуын — берсен дә белми идем. Минем өчен Дәрҗия Аппакова дигән язучы бар иде дә, аның «Кечкенә Бануның тарихы» дигән китабы бар иде.

Кызганычка каршы, Казанга кайткач, ул озак яшәмәде. Бирегә зур өметләр, матур хыяллар белән килгәндер, югыйсә. Әле аның Гариф Гобәй, Әминә Бикчәнтаева, Кадрия Ишукова, Җәвад Тәрҗеманов кебек танылган балалар язучылары белән яңа гына аралашып киткән, безнең кебек каләм сынап маташкан яшьләр белән таныша гына башлаган вакыты иде. Сугыштан соңгы беренче китабын «Шыгырдавык башмаклар»ны чыгарып кына өлгергән иде әле. Илле яше дә тулмыйча, арабыздан китте.

Әсәрләре калды. «Сәнәкчеләр» калды, «Мәмәт һәм Аман карт» калды, «Лули» калды, «Михнәт» романы калды. Әле һаман уйналып килә торган «Тапкыр егет», «Илдус» пьесалары, әкиятләре калды. Аның бу китаплары рус, казакъ, үзбәк, инглиз һәм еврей телләренә тәрҗемә ителде.

Дәрҗия Аппакова талантлы балалар язучысы иде. Ул аларга халкыбызның михнәт белән үткән көннәрен, матур киләчәк өчен барган көрәш турында сөйләде. Балаларны әдәпле, гадел, ярдәмчел, батыр булырга өйрәтте. Фикерләрен укучыларына җиткерү өчен ул әдәбиятның төрле алымнарыннан, төрле жанрларыннан файдаланды: повестьлар, кыска хикәяләр, әкиятләр, пьесалар язды. Күп әсәрләрендә балаларның сөйкемле образларын иҗат итте. Аның гадәттә «кире тип» дип йөртелә торган типлары да гел кире генә түгел иде. Алар үзләре кылган яман эшләрдән ояла, үкенә беләләр, ничек тә бер яхшылык эшләп, үзләрен акларга тырышалар. Тәҗрибәле педагог буларак, Дәрҗия Аппакова бер вакытта да балаларга турыдан-туры акыл өйрәтмәде. Аның геройлары үзләре нәтиҗә ясый торган булдылар. Һәр вакыт кирелләнеп, әйткәнне эшләмичә, үзенчә торырга яраткан Сара, мәсәлән, җир астына барып эләгә. «Сараның башыннан үткәннәре» дигән әкиятендә автор җир астында барган табигый процессларны оста күрсәтә: җир асты куышлыкларында елгалар ярала, төрле катламнар арасында алтын-көмешләр утыра, башка төр минераллар барлыкка килә. Бу эшләрнең берсенә дә катнашырга, кагылырга хакы юк Сараның. Чөнки ул

җир өстендә берни дә эшләмәде, бер нәрсәгә дә осталыгы юк, монда аның бөтен эшне бозып куюы бар. Менә шундый гыйбрәтле һәм укырга күңелле итеп язылган әкиятнең ахырында укучыларны тагын бер кисәтеп куюның кирәге каламы икән?

Күп йөргән — күп күргән, диләр. Дәрҗия Аппакова да күп җирләрдә эшләп, күп халыкларның тормышы белән танышкан язучы. Бу аның әсәрләреннән дә ачык күренә. Татар кызы Бану, төркмән малае Мәмәт, кечкенә Митяй, чеган балалары һ. б. бер-берсенә охшамаган тормышлары укучыны бердәй җәлеп итә: аны шатландыра, борчый, уйландыра, кыюландыра. Әнә шулай укучыны үзенә иярте алган китап бәхетле китап ул. Шундый китапларны иҗат иткән язучыны һәр вакыт рәхмәт хисе белән искә алалар.

Ләбибә **ИХСАНОВА**.



# ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ

Безгә бала вакытта Закир Сәмитов китапларын укырга туры килде. Әмма аның турында бик җылы сүзләр ишетеп өлгергән булсак та, үзе белән очрашу бәхетенә ирешә алмадык.

Безне, Әтнә районы Куәм мәктәбе укучыларын, әдәбияттан З. Сәмитовның туганы Шамил Сәмитов укыта иде. Ул җидееллык мәктәптә әдәбият түгәрәген оештырып җибәрде һәм без «Яшь көчләр» дигән кулъязма журнал чыгара башладык. Укытучыбыз Ш. Сәмитов безгә татар язучыларының тормыш һәм иҗат юлларын сөйли, аларның әсәрләре белән таныштыра, безгә темалар биреп иншалар яздыра, шулай итеп, бездә әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли иде. Без бер-беребездән уздырырга тырышып китаплар укыйбыз, кайберләребез шигырьләр, хикәяләр дә яза башлады. Әдәбият түгәрәгенең бер утырышында укытучыбыз безгә Закир Сәмитовның «Авылда май бәйрәме» дигән бер пәрдәлек сәхнә әсәрен укып күрсәтте. Бу пьеса Кызыл Армия сафында хезмәт итеп, туган авылына кайткан сугышчы тормышыннан иде.

Закир Сәмитов 1901 елда хәзерге Волгоград өлкәсенең Кара Яр районы, Ташлы Яр авылында туа. Әтисе Закирны үзе шикелле сәүдәгәр итәргә тели, әмма кечкенәдән үк авылдашларының аһ-зарын, Идел буенча баржа тартып барган бурлакларның моңлы җырларын ишетеп үскән яшүсмер Закир башка юлны сайлый.

Ул кечкенәдән үк рус һәм татар язучыларының китапларын укый, Пушкин, Лермонтов шигырьләрен күңелдән белә, Көнчыгыш шагыйрьләре Фирдәүси, Хафиз, Рудакиларны укып хыяллана, үзе дә шигырьләр яза. Төпчек бала булгангамы, әтисе Камалетдин һәм әнисе Назбикә аны, башка улларына караганда, якынрак күрәләр — иркәләү сүзләре, ягымлылык мулрак була. Ул халык арасында җырланган җырларны, мәкаль һәм әйтемнәрне, әкият һәм бәетләрне язып ала. Биш-алты яшьтән гармунда уйный башлый, үсә төшкәч, авылның оста җырчыларыннан берсе була.

Аның туган авылы Иделгә борын булып чыгып торган күк ташлы биек яр өстенә урнашкан. Яр астында комлык. Риваятьләргә караганда, бу авылга беренчеләрдән булып Сәмит улы Сәйфелмөлектән туган Шәмсетдин нигез салган. Шәмсетдин унсигезенче йөзнең башларында килеп, бу авылның исемен «Ташлы Яр» дип куша. Руслар һәм калмыклар аны «Каменный Яр» дип йөртәләр.

Шәмсетдин биш бала атасы була. Гаиләне туйдыру авыр булганлыктан, ул, Кубань ягына китеп, үзе ясаган әйберләрне игенгә алыштырган. Соңга таба авыл халкы да шул кәсеп белән көн күрә башлаган һәм аларны чумаклар дип атаганнар. Җирләре уңдырышсыз булганлыктан, алар терлекчелек һәм кустарьчылык белән дә шөгыль-

ләнергә мәҗбүр булганнар. (Авыл зиратында Шәмсетдин Сәйфелмөлек улы Сәмитовның кабер ташы әле дә саклана.)

Шәмсетдиннең Фәхретдин, Таҗетдин, Баһаветдин, Фазлетдин, Гомәр исемле уллары була. Баһаветдиннең өченче улы Камалетдин — Закир Сәмитовның әтисе. Баһаветдиннең балалары үзлекләреннән укый-язарга өйрәнәләр, рус телендә китаплар укыйлар, аз-маз булса да русча сөйләшә беләләр. Шулар арасында татар хатын-кызларыннан беренче язучы Газизә Сәмитова да үсә. Закирның әтисе Камалетдин заманында алдынгы фикерле кеше була, ул армиядә писарь булып хезмәт итә. Соңыннан туган авылына кайтып яши башлый, халык арасында могтәбәрле кешеләрнең берсе була.

Беренче бөтендөнья сугышы башлану белән Камалетдин Сәмитовны фронтка җибәрәләр. Унөч яшьлек Закир исә солдаткаларга фронттан килгән хатларны укый, унбиш-егермеләп баланы җыеп сугышлы уйный. Үз кулы белән агач мылтыклар ясый, аларга тимер чыбыктан штыклар куя...

Февраль революциясе була. «Патшаны бәреп төшергәннәр!» дигән хәбәр Идел буена утырган Ташлы Ярга да килеп җитә. Аннары давыллы Октябрь көннәре... Закирга инде 16 яшь. Ул беренчеләрдән булып комсомол сафына керә һәм Идел аръягындагы Маляевка авылында укытучылар хәзерли торган курста укый. Шушы чорда Маляевкага аклар һөҗүм итә. З. Сәмитов Кызыл Армия сугышчылары сафына басып, акларга каршы көрәшә. Ләкин көчләр тигез булмый, сугыша-сугыша чигенергә туры килә. Бер бәрелештә аларның күбесе һәлак була. Яралы Закир көч-хәл белән авылга кайтып җитә. Бу турыда аның энесе Шамил Сәмитов болай дип яза:



«Мин бүгенгедәй хәтерлим, биек яр астында — Идел буенда комда кызынып ята идек. Безнең янга наган таккан яралы якынлашып килә. Бу Закир абый иде. Аның каршысына йөгердем. Ул карлыккан тавыш белән:

— Авылда кемнәр? — дип сорады.

— Кызыллар! — дидем. Ә әтисенең куптән түгел вафат булуын әйткәч исә, ул башын түбән иде. Аннары тиз-тиз атлап ярдан менеп китте. Без малайлар да аннан калышмадык.

Таң алдыннан авылга аклар бәреп керә... Кемдер яралы Закир абыйның комсомол булуын акларга әйтә. Ак офицер аны печәнлектән өстерәп төшерә һәм атып үтерергә әмер бирә. Бу хәлне авыл кызы Зәйнәп (соңыннан ул Закир Сәмитовның тормыш иптәше була) күреп ала һәм тиз генә Закирның туганы Сираҗетдин агайга йөгерә. Олы яшьтәге Сираҗетдин акларның штаб начальнигыннан үзенең туган тиешле кешесен атмауларын ялварып сорый.

Штаб начальнигы аңарга: «Комсомолны коткарып булмый!» — дип кенә җавап бирә.

Озак ялвара торгач, начальник мәрхәмәтле булырга теләп:

— Ул сәүдәгәр малае моннан соң кызылларга ияреп йөрмәсен! Кара аны! — дип бармак яный. — Хәзер үк комсомол билетын утка яксын!

Аклар киткәч, Закир абый авылда Совет власте төзү, ятим балаларны укыту, мәктәпләр ачу кебек эшләрдә актив катнашты».

Илдә гражданнар сугышы дәвам итә. Закир Сәмитов үзе теләп фронтка китә, дошманнарга каршы батырларча сугыша, кызыл командир булып җитешә, 1919 елда Коммунистлар партиясе сафына керә.

Закир Сәмитов гражданнар сугышында күрсәткән батырлыклары өчен исеме язылган сәгать һәм браунинг белән бүләкләнә. Соңгы елларда ул инде майор була.

Сугыш кырларында туп, пулемет һәм мылтык тавышлары тынгач, ул яшь сугышчылар әзерләүгә күп көч куя, татар-башкорт полкларында политрук була. 1927 елдан

1933 елга кадәр Казанда чыга торган «Кызыларммеец» дигән хәрби газетада эшли. 1937 елның декабрь аена хәтле Татарстан Язучылар союзының әдәбият фонды вәкиле булып хезмәт итә.

З. Сәмитовның китаплары күп түгел. Ул яшьләрне туган илгә бирелгәнлек рухында тәрбияләү максатыннан чыгып пьесалар, очерклар, мәкаләләр яза, русчадан тәрҗемә итә. Ул язган яки төзегән китаплар арасыннан «Кызыл Армия ударниклары», «Яшь кызылармеец нәрсә белергә тиеш», «Отряд һәм звенолар», «Колхоз-совхозларда осоавиахим эшләре», «Авыл клубы» һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

З. Сәмитов басмачыларга каршы сугышларда һәм походларда катнаша. Бу турыда да аның очерклары бар. Шагыйрь Һади Такташ белән маневрларда йөргән көннәре турында ул «Такташ маневр кырларында» дип исемләнгән кызыклы гына язма белән дә чыгыш ясый. Бу истәлек 1936 елда Фатих Кәрим төзегән «Һади Такташ турында» дип исемләнгән китапта басылып чыккан. Әсәрнең документаль булуы белән бергә бу әсәрендә З. Сәмитов Такташның без белеп бетермәгән якларын ачып бирә, маневр күренешләрен, кызылармеецларның уй-кичерешләрен, батырлык сыйфатларын калку итеп күрсәтә. Менә бер өзек:

«1927 елның көзе. Такташ «Нептун» пароходының түбәсендә шинелен җилкәсенә салып, соңгы шигырьләрен укып барганда, күктә яңгыр болытлары «маневр» ясап йөриләр иде. Ә Такташ, шигырен бүлеп:

— Туктагыз, ашыкмагыз, без дә маневрга барабыз. Әнә шунда юлны бозып безнең көчебезне сынарсыз. Ә хәзергә безне җебетергә җыенмагыз, — дип болытларны шелтәләп, пассажирларны көлдереп куйды.

«Нептун» Зөя елгасына борылу белән, яр кырыеннан бер көтү ак казлар күренүгә, Такташ көлеп җибәрде. Бәлки аның:

> **Кыр казлары, зинһар, мактанмагыз,**
> **Ерак түгел безнең арабыз,**
> **Сез очсагыз, без дә калышмабыз,**
> **Әле**
> **Сезне узып оча алабыз.**
> **Еллар үтәр, менә күрерсез —**
> **Фәнне эшкә җигә белербез,**
> **Күктә гуләйт итеп йөрербез, —**

дигән юллары исенә төшкәндер. Ул үзенең бунтарьлыгын сөйләп китте. Болай да озын булмаган юл сөйләшә-сөйләшә тагын да кыскарды».

Әсәр Һади Такташның маневрда күргәннәре турында язылган. Шагыйрь монда батыр кызылармеец буларак күз алдына килеп баса. Ул авыр сынаулар уза, походларда сапер булып катнаша, шигырьләр яза, күчмә редакциядә дә эшли.

З. Сәмитовның хәрби темага караган зур әсәрләреннән берсе «Комдив Чанышев» дип атала. Революцион эшчәнлеген Казанда башлаган, гражданнар сугышы вакытында Беренче татар укчы бригадасының артдивизион командиры һәм комиссары булган, басмачыларга каршы батырларча сугышкан, гражданнар сугышыннан соң дивизия командиры итеп күтәрелгән Якуп Чанышев турында язылган беренче әсәр бу. «Комдив Чанышев» утызынчы елларда ук язылуына карамастан, әле дә үзенең кыйммәтен югалтмаган очерк. Анда без патша Россиясенең караңгы почмагында үскән егетнең Октябрь көннәрендә халык бәхете өчен көрәшеп йөрүен, яшь Совет республикасын саклауга үзеннән зур өлеш кертүен ачык күрәбез. Әсәр сәнгатьле итеп, оста художник кулы белән язылган.

Мәгълүм булганча, Бөек Ватан сугышында Якуп ага Чанышев тагы да зуррак батырлык һәм кыюлык үрнәкләре күрсәтте, орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде, генерал-лейтенант дәрәҗәсенә кадәр күтәрелде.

Утызынчы еллар башында З. Сәмитов Мирсәй Әмир белән Урта Азиягә иҗади командировкага бара. Төрле шәһәрләрдә булып, алар анда кызылармеецлар һәм командирлар белән очрашалар. Урта Азиядәге татар-башкорт укчы полкларында басма-

чыларга һәм чик бозучыларга каршы баһадирларча көрәшкән сугышчыларны күреп сөйләшәләр, алар турында мәкаләләр һәм очерклар язалар. Закир Сәмитовның шундый очеркларыннан «Орденлы Салихов» дип исемләнгәне 1931 елның апрель аенда «Атака» журналында басылган. Түбәләре мәңгелек кар белән капланган таулар арасындагы яшерен юллардан кинәт һөҗүм итүче басмачылар өеренә каршы батырларча көрәшкән чик сакчылары турында сөйләнелә ул очеркта. Алар арасында Галимҗан Салихов дигән татар егете аерата зур каһарманлык үрнәкләре күрсәтә. Ул басмачылар башлыгын тере килеш кулга ала. Батырлыклары өчен аңарга Сугышчан Кызыл Байрак ордены бирелә.

Урта Азиягә барулары турында язучы Мирсәй Әмир исә түбәндәгеләрне сөйләде: «Без Закир Сәмитов белән бергә Казанда чыга торган «Кызыларммеец» газетасында эшләдек. Газетаның редакторы язучы Кави Нәҗми иде. Шунда эшләгән елларда Урта Азиядәге татар-башкорт полкларында хезмәт итүче якташларыбызның сугышчан тормышларын яктырту максаты белән ерак сәфәргә — ком сахраларына, кар сулары шарлап аккан биек таулар итәгенә юл тоттык. Монда без хәбәрчеләребез, укучыларыбыз белән очраштык, әдәби түгәрәкләр төзедек, ул вакытта Фәрганәдә хезмәт итүче командир-шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй белән дә очраштык. Закир Сәмитов белән без икәүләп күп нәрсәләр күрдек, язу өчен бик күп материаллар җыйдык, басмачыларга каршы сугыш булган урыннарны карадык. Батырлык һәм кыюлык күрсәткән кызыларммеецлар турында очерклар яздык. Бу сәяхәттә күргәннәребез турында без Закир Сәмитов белән икәүләп бер китап та әзерләгән идек, ләкин дөньяга чыгартырга өлгермәдек».

Коммунист, кызыл командир, язучы-журналист Закир Сәмитов, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Тинчурин, К. Нәҗми, Г. Толымбай, М. Әмир, А. Шамов, Х. Ярми, И. Туктар һәм башка язучыларның якын дусты була, алар белән аралашып эшли, әдәбият фонды вәкиле буларак, язучыларның матди тормыш-көнкүрешен яхшыртуга күп көч куя.

Ул бигрәк тә Г. Ибраһимов белән якыннан аралашып яши. Ул өлкән әдипнең соңгы көннәрендә аның янында була. З. Сәмитов аңарга зур хөрмәт һәм ярдәм күрсәтә.

З. Сәмитов 1938 елда үлә. Кабере Казанның Архангельский зиратында.

Татар әдәбияты үткәндәге традицияләре һәм бүгенге казанышлары белән кыю рәвештә алга атлый. Аның үткән юлында З. Сәмитов та үзенчәлекле урын алып тора. Халык мондый кешеләрне онытмый, хөрмәтләп искә ала, исемнәрен мәрмәргә алтын хәрефләр белән яза.

**САМАТ ШАКИР.**

# УЧАК ҖЫЛЫСЫ

*Рәис Даутовка 50 яшь*

Ул учак ягарга ярата.

Көне буе бакчада әвәрә килеп йөргәннән соң дача өе каршында ут тергезеп җибәрә... Якты көздә үк урманнан коры-сары җыештырып чыга, бакчадагы чыбык-чабыкны да бер урынга җыештырып бара, аннары, көз бәйләнә башлагач, арып-талып учак урыны каршындагы утын кискәсенә килеп утыра. Ашыкмыйча гына, ниндидер бер пөхтәлек белән дигәндәй, чыбык-чабыкларны кисеп өеп куя да ут ягып җибәрә. Учак терелеп, ялкын телләре дәртләнеп сикерешә башлагач, иркен сулап куйгандай була — тәмәкесен кабыза, күкрәген тутырып бер суыра, кулына берәр чыбык алып, учакны ара-тирә рәтләштереп ала.

Инде караңгы да төшә.

Ялкын телләре, җилдә тузгыган ат ялыдай, лепер-лепер килеп сикерешәләр дә, учак тамырыннан өзелеп, караңгылыкта эреп югалалар, алар урынына тагын яңалары терелеп чыга. Ул әнә шуларга карап уйланып утыра. Йөзендә ялкын шәүләләре уйный — чырае бер яктырып, бер караңгыланып китә, әйтерсең лә тарих үзе чагыла аңарда.

Ут һәм Кеше... Әнә шулай учак ягып утыруда бер мәгънә бар сыман. Бәлки мәгарәләрдә беренче тапкыр ыру учагын тергезеп җибәргән ерак бабалар җаны-рухының безнең тамырларда тилпенеп, сулкылдап куюыдыр ул?! Әйе, әйе, мөгаен, шулайдыр...

Учак тере булганда җанга җылы, тәнгә рәхәт, күңелгә хәвефсез шул. Кешеләргә генә түгел!.. Җылы барын сизенеп, әнә Шарик та аның аяк астына килеп елышкан. Хуҗасы:

— Ай инде, ай инде! Бигрәк тәти инде үзе, — дип, башыннан сыйпауга, ул аяк астына тагын да сыенарак төшә. Мондый чакта Шарик нишләргә белми: иркәләнә, назлана, тутырып хуҗасына карап ала — сөенеч, бәхет тулы күзләре менә-менә җиргә тамып төшәрләр төсле тоела. Учак җылысыннан бигрәк, күңел җылысын тоеп иркәләнә бугай ул.

Бар шундый кешеләр — алар, кичке караңгылыкта өмет булып кабынган учаклар шикелле, үзен чолгап алган мохитка җылылык, яктылык биреп торалар. Алар янына, җылы эзләп, кешеләр килә — яшьләр дә, өлкәннәр дә, танышлар да, таныш түгелләр дә. Без аның белән менә дүртенче ел инде бер бүлмәдә утырып эшлибез, менә дүртенче ел инде мин үзем шул учакның җылысын тоеп яшим. Хәер, бер мин генә микән?!

Аның янына еш кына әдәбиятыбыз аксакалы Сибгат ага Хәким кереп утыра. Сүз, әлбәттә инде, әдәбият турында, иҗатлары бөреләнеп килүче яшь көчләр — алмаш турында бара. Теге яки бу яшь әдипнең егәр көче ничегрәк, ут тамыры тирәннән киләме, бер җил исеп кую белән сүнеп китмәсме — әңгәмә әнә шулар хакында. Күреп, сизеп торам — Язучылар союзына кабул итү комиссиясендә бергә эшләгәннәре өчен генә түгел, әле болай, кеше буларак, милли әдәбиятның бер вәкиле буларак, кабынып килүче яңа учакка утын-сары ташларга әзер торалар алар.

Язмышлар турында чын күңелдән кайгыртa алган кешеләр — бәхетле алар. Андый кешеләр күңелендә Кешене ярату дигән сүнмәс учак яна. Шундый кешеләрнең берсе ул Рәис абый.

Бер генә әдәбият та бөекләрдән генә тормый. Бөекләр, Атлант кебек, әдәбият күге гөмбәзен иңнәрендә тотып торсалар, бөекләрне үз җилкәләрендә бик күп «әдәбият хадимнәре» күтәреп тора.

Рәис абый әнә шул бөекләрне үз җилкәсендә күтәреп торучыларның бер вәкиле, татар әдәбиятының намуслы, тырыш «хадиме». Дөрес, ул шагыйрь дә, прозаик та түгел, пьесалары да сәхнәдә уйналмый, «башкаларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә». Бу сүзләрне юри куш җәяләр эченә алдым әле. Ни өчен дисәң, беренчедән, тәрҗемә эшен «икенче сортлы» иҗат итеп караучылар да очраштыргалый бит (гәрчә алай булмаса да), икенчедән, «әдәбият хадиме» дию белән гомумән теге яки бу язучының әдәбиятка карата булган мөнәсәбәте турында бер-ике сүз әйтәсе килә. Тирән ышануымча, Рәис абый үз-үзенә пешәр-пешмәс, урта кул повесть-мазар язарга рөхсәт итмәс иде. Чөнки ул әдәбиятны артык нык ярата, күңеле авыртыр дәрәҗәдә аңлый, хөрмәт итә. Бар ич шундый категория кешеләр — урта кул булып калмас өчен, әдәбиятка хыянәт итү ихтималыннан шикләнеп, «язучы» булмый калучылар. Аларның бу батырлыкларын аклап булмаса да, аңлап була. Әдәбият дигән изге йортка аяк салмый керүчеләргә караганда, аларның бу адымнары, мөгаен, мең мәртәбә гуманлырактыр да әле. Ләкин Рәис абыйның, алардан аермалы буларак, татар әдәбиятында үз урыны, үзе генә терелткән учаклары бар. Ул баш-аягы белән әдәбиятка кереп чумган, ул әдәбият дөньясында яши, һәр күзәнәге әдәбият һавасы белән сулый.

Һәрбер агымсу үз үзәнен таба, ди. Ул юлында нинди генә борылмалар ясамасын, тау-ташларга очрамасын, барыбер үз диңгезенә барып коя. Рәис Даутовның андый диңгезе — әдәбият, әдәбиятның да тәрҗемә өлкәсе. Аның бер анкетага биргән җавапларында мондый гыйбрәтле юллар бар, озынрак булса да шуларны күчереп үтәсе

килә: «Мин чын мәгънәсендә китап культы яшәгән гаиләдә үстем. Безнең гаиләдә һәммә кешегә, шул җөмләдән әти-әнигә дә, «китап җене» кагылган иде. Мәрхүм әнием Тукай шигырьләренең барысын диярлек күңелдән белә һәм яшьрәк чагында үзе дә шигырьләр язгалый иде. Табигый, әдәбият сөюче һәр яшүсмер кебек, минем үземдә дә иҗат дәрте уянды, һәм ул елларда, үзем өчен генә дигәндәй, шигырьләр, хикәяләр язарга да азапланып маташтым. Әмма ул балалык, яшьлек чорында мине иң дәртләндергән нәрсә — ул да булса үзем укыган дөнья әдәбияты җәүһәрләрен татар телендә күрү теләге иде. Шул эчке теләк-дәрт, ихтимал, минем әдәбиятның тәрҗемә жанрында тукталып калуыма сәбәп булгандыр. Хәтеремдә, шул мәктәп елларында ук мин Микеланджелоның берничә сонетын һәм Ронсарның үзәмә бик ошаган шигырьләрен, рус теле аша, татарчага тәрҗемә иткән идем».

Менә шулай «уйнап» башланган эш аның гомерлек шөгыленә әйләнеп китә. Бүгенге көндә татар укучылары М. Твенның «Янки король Артур сараенда», Д. Фенимор Куперның «Соңгы могикан», Ф. Достоевскийның «Җинаять һәм җәза», А. Купринның «Атышу» әсәрләрен, Э. Хемингуэй «Хикәяләр»ен Рәис Даутов тәрҗемәсендә укыйлар. Ләкин хикмәт санда гына түгел бит әле...

Әйтик, татар әдәбиятында тәрҗемә үсешенең төп өч этабын күрсәтергә мөмкин. Октябрьга кадәр һәм аннан соңгы беренче унъеллыкта «ирекле тәрҗемә» методы өстенлек иткән. Ә 30 нчы еллар башыннан 50 нче еллар ахырларына кадәр нигездә «механик тәрҗемә» дип яманаты чыккан юнәлеш канат җәя. Бу юнәлешләрнең һәр икесе җитешсезлекләрдән азат түгел иде. Беренче юнәлеш оригиналдан читкә алып китте, икенчесе җаны-рухы суырылган төссез, хиссез тәрҗемәләрнең күбәюенә китерде.

60 нчы еллар башында, әлеге «механик тәрҗемәгә» каршы реакция сыйфатындарак, яшь тәрҗемәчеләр арасыннан яңа бер дулкын күтәрелде. Бу агым елдан-ел көч җыя барып, хәзерге көндә үзен тәмам танытып өлгерде. Шулай итеп, татар теленә тәрҗемә итү эшенең фәнни теоретик принциплары эшләнде — «иҗади тәрҗемә» барлыкка килде.

Конкрет алганда, Рәис Даутов нинди принципларга таянып эш итә соң? Бу сорауга ул бая искә алып үткән анкетага җавапларында бик ачык әйтеп үтә: «Тәрҗемәчеләрнең иң изге вазифасы — теге-яки бу әдәби әсәрне эчтәлек, стиль, образлылык хасиятләренә хилафлык китермичә, икенче бер телдә мөмкин кадәр адекват, тәңгәл гәүдәләндерергә омтылу. Мин монда нәкъ менә «гәүдәләндерү» сүзенең асыл мәгънәсенә ишарәлим. Шул асыл мәгънәсендә тәрҗемәченең эшен актер хезмәте белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Актер да бит образ-персонажның эчке дөньясына тирәнтен кереп, сәхнәдә аны автор тасвирлаган яки күз алдында торткан эмоциональ югарылыкта гәүдәләндерергә тырыша. Тәрҗемәче дә шулай: бүтән телдә язучы әдипнең рухи дөньясын, фикерләү формаларын, әсәрендәге фикри-әдәби хасиятләрне йөрәге аша үткәреп, ул үз ана телендә бу әсәрне яңабаштан корып, гәүдәләндереп бирергә бурычлы».

Практикада Рәис Даутов шушы бурыч-принциптан читкә тайпылмаска омтыла һәм шуңа күрә язу стиле, фикерләү формалары белән үзенә якынрак торган язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итә.

Сәхнәдә уйналган һәрбер рольдә оста актерның индивидуаль сыйфатлары ачык сизелгән кебек, тәрҗемә әсәрендә дә, табигый, тәрҗемәченең үз стиль үзенчәлекләре, язу манерасы чагылмый калмый. Ләкин, тәрҗемәче үзе оста стилист булганда, андый «югалтулар» оригиналның гомуми эмоциональ яңгырашына сизелерлек зыян китермиләр, аерым очракларда исә аны баетып кына җибәрәләр.

«Җинаять һәм җәза» романының татарча яңгыравы моңа ачык мисал булып тора ала. Бу тәрҗемәдә Ф. Достоевский рухы тулысынча саклангaн хәлдә, татар тел үзенчәлегенең халыктан, Тукайлар, Ибраһимовлардан килә торган байлыклары, хасиятләре дә аеруча калку чагылды. Менә шуңа күрә дә бу әсәрнең татарчага тәрҗемә ителүе бөтен татар әдәбиятының тәрҗемә өлкәсендәге казанышларыннан берсе булды.

Искә төшерергә тырышып уйлап утырдым, ләкин аның бер генә эшне дә аннанмоннан гына, ашык-пошык башкарганын хәтерли алмадым. Өйдә, эштә, бакчада —

һәркайда һәрнәрсәне җирено җиткереп һәм, әйтергә кирәк, анализлап, бәртеклап эшләргә тырыша ул. Коры рационализм гына түгел бу (аңарда иҗат фантазиясе дә җитәрлек), ә бәлки табигатьтән бирелгән байлык — эчке рухи культураның югары булуы турында сөйли торган бер дәлил. Бу сыйфат, бер яктан, озак еллар Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләү дәверендә камилләшкәндер, икенче яктан, характерына хас шушы төсмерләр аны әйбәт редактор иткәндер.

Рәис Даутов үз гомерендә өч йөзгә якын китапка фатиха биргән — халык күңеленә мәгърифәт кошлары очырган кеше. Өч йөзләп китапка аның күңел җылысы салынган. Үзенең «мин чын мәгънәсендә китап культы яшәгән гаиләдә үстем» дигән сүзләрен искә алсак, әлеге саннарның асыл мәгънәсенә төшенү кыен булмас. Китапны ул кешеләрне яраткан кебек ярата, китапка карата аның күңелендә ниндидер бер аерым җылылык, хөрмәт яши.

Китап тудыру җиңел хезмәт түгел, фәлән генә битле җыентыкка да дистәләгән кешенең акыл һәм физик көче кергән була. Ләкин нәшриятта аның чын хуҗасы — редактор.

Менә ул «сигнальный экземпляр»ны карап утыра. Беркемне дә күрми, ишетми — китапка чумган. Ничек басылган, буяулары әйбәт төшкәнме, төпләнеше ничек, формат сакланганмы? — барысын-барысын тикшерә. Өстәлгә бастырып куя да, еракка китеп карап тора — читтән ничек күренә икән? Әгәр китап тулаем күңеленә хуш килсә, йөзе яктырып, нурланып китә. «Әйбәт редактор» булу өчен чыннан да автор белән кулгакул тотышып эшли алу, әдәби зәвык, эрудиция генә җитмидер, ә бәлки китапны аңлау, ярату хисе дә зарурдыр.

Хәзер Рәис Даутов татар әдәбияты классикларының әсәрләрен редакцияләү буенча специальләште — Тукай, Ибраһимов томнары аның редакциясендә дөнья күрде.

... Ул учак ягарга ярата.

Аның учагы һәр вакыт тере, учак урыны һәр вакыт җылы. Чөнки учагын ул кешеләр, халык күңеленнән сирпелгән очкыннардан кабызып җибәргән.

**НАИС ГАМБӘРОВ.**

# АЛЬБЕРТ ЯХИН



Альберт Яхинның Шамил Усманов иҗатын өйрәнеп фәнни хезмәт язганын белгәч, баштарак мин гаҗәпләнебрәк тә торган идем. Ни өчен нәкъ менә Шамил Усмановны сайлады микән? «Чаян» журналында озак еллар буе коммунистик принципиальлек белән башкарган гаять катлаулы һәм үзенчәлекле эшен якыннан күргәч таптым мин бу сорауга җавапны: комиссар Усманов шәхесе, эше һәм көрәше белән яшь галимнең үзендә дә уртак сыйфатлар бер икән...

Яңа дөнья өчен көрәшкән Шамил Усманов турында язган кешенең юмористик, сатирик хикәяләр авторы булып китүе мине бер дә гаҗәпләндермәде. Тормышка мөнәсәбәтнең комиссар Усмановча дәвам итүе иде бу — яңа дөнья, яңа кеше өчен актив һәм компромиссыз көрәш.

Гражданлык рухын, гражданлык пафосын гадәттә җитди жанрлардан гына көтәләр. Бу очракта, минемчә, юмор-сатира кебек сугышчан жанрга бәя биреп җиткерелми. Язучының гражданлык активлыгы юмор-сатирада аеруча нык күренә. А. Яхинның «Әйттем исә кайттым» дип исемләнгән китабындагы алтмыш алты хикәя моның ышандыргыч дәлиле.

А. Яхин — кыска хикәяләр остасы. Көлке ясауның барлык нечкәлекләрен, алымнарын төшенгән, закончалыкларын үзенчә ачкан, бу өлкәдә дөнья әдәбияты үрнәкләреннән яхшы хәбәрдар.

Юмор, сатира — безнең әдәбиятта яңа авторлар ифрат сирәк килә торган жанр. «Чаян» битләрендә еллар буе мыштым гына каләм чарлаган Гатауллинның Яхин булып ачылып китүе, күп кенә уңышлы хикәяләрне туплаган китап белән үзен кинәт күрсәтүе тагын да сирәгрәк очрый торган хәл. Сатириკны Язучылар союзына алу бу авыр жанрга игътибар белдерү, җанландырып җибәрү, яшь авторларны кызыктырып куярга әйбәт форсат булыр. Язучы Яхинның юмор-сатирадагы бай тәҗрибәсе галим Яхинга да бик ярап куяр, яңа ачышларга китерер дип ышанам.

Прозаик, драматург һәм галим Альберт Яхинны СССР Язучылар союзына член итеп тәкъдим итәм. Әдәби иҗатта да, җәмәгатьчелек эшендә дә бик кирәкле шәхес булыр ул.

**ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ.**

# ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИН

Лирон Хәмидуллин татар әдәбиятына зур тормыш тәҗрибәсе белән килгән язучыларның берсе. Ул, кулына каләм алып хикәяләр язу эшенә керешкәнче, күп еллар тимер юлда һәм башка урыннарда хезмәт итә. Башта Уралда берникадәр вакыт кара эшче булып эшли, аннары, техникумны тәмамлагач, махсус белем алгач, берничә ел тимер юлда мастерлык вазифасын үти, бригадир була, ахырда Казан шәһәр тимер



юлында участок начальнигы дәрәҗәсенә чаклы күтәрелә. Ун-унбиш елга сузылган бу вакыт эчендә ул гади эшчеләр, мастерлар, бригадирлар, урта һәм югары белемле белгечләр белән якыннан аралаша, аларның йөреш-торышларын, гадәтләрен, психологияләрен, үз-үзләрен тотышларын өйрәнә, тормышлары, көнкүрешләре белән таныша,— кыскасы, алар арасында яши, алар белән бергә эшли. Соңыннан, язучы булу нияте белән кулына каләм алгач, ул иҗади көчен, беренче нәүбәттә, үзе яхшы белгән тимер юл эшчеләре тормышына багышлый, аларның авыр хезмәтләрен, көрәшләрен, бер-берләренә булган мөнәсәбәтләрен, укучылар күңеленә сеңеп калырлык итеп, әдәби чаралар белән тасвирлый.

Л. Хәмидуллин ике китап авторы. Берсе — «Юлда» исемле хикәяләр җыентыгы, ә икенчесе повесть — «Дала иртәсе».

Җыентыгына алты хикәя тупланган. Билгеле, хикәяләренең барысы да бер үк дәрәҗәдәге әдәби осталык белән иҗат ителмәгән. Яхшылары, укучыларның күңелләрен чын-чынлап җәлеп итәрлекләре булган кебек, беркадәр кимчелекләре дә юк түгел. Болары — үсү кимчелекләре, яшь авторның әдәби тәҗрибәсе камилләшә бару белән бергә бетәргә тиешле кимчелекләр. Әмма алты хикәянең өчесен — «Буранда», «Юл караучылар» һәм «Кыш уткән юл буйлап» исемле хикәяләрне мин авторның әдәби уңышы итеп саныйм. Бу хикәяләрдә укучыларны таңга калдырырлык гадәттән тыш вакыйгалар юк, әлбәттә. Гади вакыйгалар, тимер юлчылар тормышында әледән-әле очрап тора торган эшләр, эпизодлар тасвирлана аларда. Ләкин менә шул гади вакыйгаларны да Л. Хәмидуллин укучыларның күңелләрен биләрлек, дулкынландырырлык, уйландырырлык итеп иҗат итә белгән. Автор, сюжет җепләрен сузганда, җәелдергәндә булсын, геройларның характерларын ачканда булсын, һәр җирдә җыйнак, матур буяулар, детальләр, сүзләр тапкан, аларны оста файдаланган. Моны мин әдипнең осталыгы, әдәби сизгерлегенең үткенлеге, талантлылыгы итеп атыйм.

«Дала иртәсе» — яшь әдипнең иҗади көчен зуррак, киңрәк полотноларда сынап каравы. Моны да ул уңышлы башкарып чыккан дип исәплим.

Повестьның эчтәлеге, берничә сүз белән генә әйткәндә, түбәндәгедән гыйбарәт: кайдадыр еракта, бер республика читендә, зур күләмдә никель рудасы табылган. Социалистик илебез промышленностен тагын да кызурак темп белән үстерү өчен никель кирәк. Һәм бик кирәк! Хөкүмәтебез аны тизрәк казып алуны һәм тиешле урыннарга җиткерүне планлаштыра. Рудаңы инде чыгаралар... Ләкин аны әзлексез ташып тору, зур магистральгә чыгару өчен тимер юл тармагы юк. Л. Хәмидуллин геройлары язгы пычракта менә шул тармакны салалар. Һавалар начар, юллар бозык, тракторлар, машиналар бата, зур механизмнарны тиешенчә кулланып булмый. Өстән карлы яңгыр явып тора, салкын җил исә. Торак урыннар җитешми, хәтта кайбер урыннарда бөтенләй юк. Иң гади бытовиклар да аз... Шуңа карамастан, тимер юлны салырга кирәк. Салмыйча, планны арттырып үтәмичә ярамый...

Салалар, никель шахталарына барып җитәләр. Менә шушы фидакарь хезмәттә авторның геройлары төрле яклап ачылалар, үзләренең кем икәнлекләрен, нинди эшче, нинди җитәкче икәнлекләрен күрсәтәләр. Бер якта эшчеләрнең тормышларына, көнкүреш хәлләренә кул селтәп, бары километрлар артыннан куучы, үзен һәм коллективны уңай яктан гына күрсәтергә тырышучы төзелеш начальнигы Михаил Горлов; икенче якта планны арттырып үтәүне дә, эшчеләрнең тормыш шартларын яхшыртуны да бердәй кайгыртучы баш инженер, яшь белгеч Бәһрам Бикташев. Болар төп образлар. Көрәш нигездә шулар арасында бара. Алардан тыш, әсәрдә дистәләрчә башка образлар да бар: «коммунизм юлын» төзү өчен ерак өлкәләрдән килгән дәртле егетләр, кызлар, комсомолецлар, партиясез яшьләр. Алар чын күңелдән рухланып эшлиләр, барлык авырлыкларга, мохтаҗлыкларга түзәләр, хезмәт батырлыклары күрсәтәләр... Кызганычка каршы, арада күз буяучылар да, дәүләт акчасын каерырга гына карау-

чылар да юк түгел. Намуслы һәм тырыш коллектив аларны читкә кага, мәрхәмәтсез фаш итә...

Л. Хәмидуллин оста тәрҗемәче дә. Аның дистәгә якын тәрҗемә әсәрләре бар. Шуларның иң зурлары, аны Язучылар союзы члены итәрлекләре: Әсгать Мохтарның «Чинар» романы, Ә. Әлимҗановның «Отрар хатирәсе» исеме белән бергә кушылып басылган ике повесте. Л. Хәмидуллин бу тәрҗемәләрдә оригиналның әдәби-художество сыйфатын, милли үзенчәлекләрен тулысынча саклаган. Тәрҗемәләре әдәби тәңгәл, адекват. Җиңел укылалар.

**АФЗАЛ ШАМОВ.**

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН



Поэзиябездә шигырь язучы яшьләр шактый күп, шулай да, кызганычка каршы, соңгы елларда укучыларның игътибарын җәлеп иткән яшь шагыйрьләребез берничә генә. Шул берничә дигәндә мин Роберт Миңнуллинның фамилиясен атар идем. Роберт соңгы биш-алты ел эчендә бик актив иҗат итте. Ул инде — китап авторы. Университет тәмамлаган. Журналист. Күп кенә яшьләр алына алмаган социаль-политик темаларның поэтик яңгырашын табарга омтыла һәм еш кына моңа ирешә дә. Иҗатына лирика һәм юмор хас. Яшь автор әнә шул ике агымны кушарга омтыла. Шигырьләрендә җылылык, шаянлык, оптимизм әнә шуннандыр.

Мин әле Робертны балалар поэзиясендә дә ачылып китәр дип уйлыйм һәм ышанып кәтәм. Соңгы вакытта балалар өчен уңышлы шигырьләр язуы шуны раслый.

Робертка тормышның тирәнрәк катламнарына үтеп керү, фәлсәфи уйланулар юнәлешендә күбрәк эшләргә кирәк. Яшь шагыйрьгә мондый югары таләпне бик житди куя алабыз. Чөнки Робертның моңа кадәр язган иҗаты — җанга ятышлы, укучыларның күңеленә үтеп керерлек. Ә бу — поэзия сорый торган таләпләрнең иң мөһиме.

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ.**

## МАНСУР ВӘЛИЕВ



Мансур Вәлиев соңгы елларда күзгә чалынган һәм игътибарны үзенә җәлеп иткән яшь әдәбиятчыларның иң өметлесе. Язган хезмәтләре әлегә күп булмаса да, дөньяга чыккан кадәресендә бу иптәшнең әдәбият мәсьәләләренә җитди караштa торуы ачык сизелде. Әдәбиятны тормыш белән бәйләп карау, зур таләпләрдән чыгып фикер йөртү хас аның язганнарына. Шуның өстенә ул әдәби әсәрне аңлау гына түгел, шактый нечкә тоя да белә (бигрәк тә поэзияне). Ә бу яшь тәнкыйтьче өчен аеруча кирәк сыйфат.

**ӘМИРХАН ЕНИКИ.**

# ТӨРЕКЧӘДӘН ИКЕ МӘСӘЛ

Төрек фольклорының исламга чаклы иң борынгы әсәрләрендә үк инде әдәбиятның бик күп жанрлары үсә башлавы билгеле: мәсәлән, **эсатир** — героик эпосларга якын мифлар, **кыйсса** һәм **менакыйб** — тарихи җирлекле легенда-хикәятләр, Кер-оглы турында дастаннар, **романтик хикәяләр, мани** — күңелле дүртьюллыклар, **ташлама** — яманлыкны хурлау җырлары һ. б. Язма әдәбият исә биредә XIII гасыр урталарында башлана. Әйтелгән жанрлар арасында, әлбәттә, киң таралган **анекдотлар**, тәкърәмә дип аталган каламбурлар (үткен сүз уйнату) һәм мәсәл дә була. Соңгырак елларда дәүләт идарәчеләреннән күләп язган әсәрләре булган әдипләр күренә башлый (Йосыф Нәби, Аләлетдин Сабит, 1635 елда солтан әмере белән буып үтерелгән Омер Нефи һ. б.). Без бу санда төрек халык иҗатыннан алынган ике мәсәл тәкъдим итәбез.

## Томау

Бер үк тауда яшәгән-көн күргән ди берничә җәнлек-җанвар. Көннәрнең берендә алар үз эшләре турында сөйләшергә-киңәшергә җыелалар. Әйтеләсе фикерләрнең бөтенесе әйтелеп беткәч, инде саубуллашканда арыслан әйтә икән:

— Нишләп болай бик сирәк җыйналышабыз соң әле без? Бер-беребезне күрүләребез менә ничек күңелле бит. Әйдәгез иртәгә дә очрашыйк. Барыгыз да миңа килегез. Бөтенесе турында сөйләшербез.

Җәнлек-җанварлар, моңа килешеп, икенче көнне күмәкләп арысланга киләләр.

Үзенең тәбрик сүзләрен арыслан бик ерактан башлый:

— Дусларым минем, ә хәзер әйдәгез эчкә узыйк. Әмма ләкин кичерегез: ни дисәң дә арыслан өе бит — бераз сасырак ис тә бардыр бәлки.

Шул чакны арада ишәк күренә.

— И аллам, нинди әшәке ис монда, — дип чыраен сыта ул. — Ничек бу сасыга чыдыйсыз?

Ачудан ярсыган арыслан ишәкне җиргә егып сала һәм әйтә:

— Әх, син, әшәке җан, әгәр без бирелә ис бар дибез икән, бу бит бары тик тыйнаклыктан гына әйтелә. Карагыз әле бу юньсез затка!

Сүзгә маймыл кушыла:

— Гафу ит, безнең солтаныбыз, ишәк бирелә, әлбәттә, ишәк чумарын иште. Синең өеңдә бит мускус исләре аңкып тора. Бирелә без нәкъ гөлләр бакчасында утырабыз кебек.

Арысланның җене тагын да чыга төшә һәм ул, бер тәпие белән бәреп, маймылны җиргә аудара һәм куркытып кисәтә:

— Әх, син, маймыл, миннән көлеп шаярмакчы иткән булдың, янәсе?! Өеңдә нинди ис барын хуҗа үзе белми дип уйлыйсыңмы әллә син?

Төлке ягына борылып исә арыслан әмер бирә:

— Алла хакына дөреслекне син әйт.

Куркудан калтырап, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән генә әйтә үз фикерен төлке:

— Кичер мине, остазым. Мин менә атна буе инде томаудан азапланам. Миңа тагын бер атна-ун көн узгач килергә рөхсәт итсәгез икән.

## Тугры дуслык

Төлке белән елан дуслаша-әшнәләшә. Алар бер зур елга аша икенче ярга йөзеп чыгарга тиешләр икән.

Төлке еланнан сорый:

— Мин йөзә алам, ә син ничек?

— Төлкекәем-апакаем, мин бит бөтенләй йөзә белмим. Әгәр рөхсәт итсәң, мин синең муеңга уралыйм да теге ярга шулай бергә чыгыйк, — ди елан.

Хәйләкәр төлке еланның бу сүзләрендә бернинди ялган да күрми кебек. «Ярый!» дип килешә ул.

Елан төлкенең муенына урала һәм судан башын чыгара. Шаулы елганың нәкъ көчле агымлы уртасына җиткәч исә елан төлкене буа башлый. Иптәшенең мәкере аның башына нинди бәла төшергәнен тиз аңлап ала төлке, әмма чигенер хәл юк инде.

— Нишлисең син, дускаем? Кызган мине, мин бит сиңа яхшылык эшләдем! — дип ялвара төлке.

Әмма елан һаман кыса да кыса икән төлкенең бугазын.

Котылыр чара эзләп, төлке кинәт һушыннан язган булып кылана башлый һәм муенындагы еланы-ние белән берничә мәртәбә салкын суга чумып-чумып ала.

Тегесе исә, курка калып, төлке муеныннан ычкына. Ә төлкегә бары шул гына кирәк тә. Еланны ул башыннан эләктереп ала һәм аны буа да, тешли башлый. Рольләр алмашына. Төлке еланны рәхимсез кыса да кыса. Инде җаны чыгар хәлгә җиткән еланны ул теге як ярга алып чыккач җиргә сузып сала. Бөтен буена туп-туры булып сузылсын өчен ул аны тарткалап та, типкәләп тә бик озак маташа — әйтерсең такта турайтырга тырышкан столяр...

Кәкре-бөкре урыннарын бетергәч, каты кычкырып әйтә икән төлке соңгы сулышта яткан еланның колагына: «Дуслык дигән нәрсә дә нәкъ менә шундый туры булырга тиеш».

Шундый була төлкенең еланга иң соңгы һәм бик урынлы киңәше.

### ТУКСАН ЕЛ ҮТКӘЧ

Үткән елның 18—22 декабрь көннәрендә Казан студентларының Владимир Ульяновның актив катнашы белән 1887 елда үткәрелгән сходка датасы тантаналы төстә һәм киң күләмдә билгеләп үтелде. Республикабыз башкаласы студентлары аны үз фәнни-теоретик конференцияләре белән университетның Актлар залында башладылар. Икенче көнне исә шунда ук СССРның урта һәм югары белем министры В. П. Елютин, ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре В. А. Житнев, КПСС Үзәк Комитетыннан, ВЦСПСтан һәм илебезнең 63 югары уку йортыннан вәкилләр катнашы белән Бөтенсоюз күләмендәге фәнни-теоретик конференция үткәрелде. Опера театрында узган тантаналы кичә һәм концертта шулай ук күп кунаклар катнашты һәм чыгыш ясады. Бу бәйрәмне сходка датасына багышланган митинг, студент яшьләрнең политик җыр конкурсы, факеллы маршы һәм бүтән бик күп чаралар бизәде. Тантанада катнашучыларга Леонид Ильич Брежневтан котлау сүзе килде.

### ӘДИПЛӘР ЙОРТЫНДА ЗУР КИЧӘ

Классик әдибебезнең 90 еллыгы уңае белән илебез башкаласындагы укучылар һәм тамашачылар өчен махсус оештырылган бу кичә СССР Язучылар союзының А. А. Фадеев исемендәге Әдипләр йортында үткән елның декабрендә үткәрелде. Аны РСФСР Язучылары союзы секретаре Николай Шундик ачты һәм алып барды. Язучы-революционер турында кыска, әмма киң колачлы, тирән эчтәлекле сүзне филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан АССР Министрлар Советы председателе урынбасары Мансур Хәсәнов сөйләде. Г. Ибраһимов иҗатының бөеклеген бәяләп, аның хәзерге шакертләре шундый ук революцион рухлы, партияле, халыкчан традицияләрне үз иҗатлары белән ничек үстергәнлеге Николай Богданов, Анатолий Иванов, Роберт Бикмөхәммәтов, Валентин Сорокин, Владимир Чивилихин чыгышларында бик ачык чагылды. Үзенә берләштергән 74 әдәби оешманың барысының да иҗаты һәм оештыру эшләре турында зур игътибар белән даими кайгыртканы өчен шагыйрь Зәки Нури РСФСР Язучылар союзы идарәсенә «Классик сәлам һәм рәхмәт билгесе бу!» дип, Галимҗан Ибраһимовның Татарстан әдипләре алып килгән зур портретын тапшырды. «Бер горурлык хисе» дигән шигырен татарча укып, кичәнең әдәби өлешен Сибгат Хәким тәмамлады. Соңыннан республикабыз сәнгать осталары чыгышын мәскәүлеләр бик кызыксынып тыңлады һәм карады.

### РУС ТЕЛЕНДӘ ЧЫГАЛАР

1978 елның тематик планнары буенча Мәскәүдәге Үзәк нәшриятлар Татарстан әдипләренең түбәндәге әсәрләре тәрҗемәсен бастырып чыгарачаклар:

#### «СОВЕТСКИЙ ПИСАТЕЛЬ» НӘШРИЯТЫ

1. Мирсәй Әмир. «Курай». Повесть һәм хикәяләр. 10 табак. Тиражы 30 мең.

#### «СОВЕТСКАЯ РОССИЯ» НӘШРИЯТЫ

2. Габдулла Тукай. «Водяная» («Су анасы»).
3. Рөстәм Кутуй. «Тихое, тихое поле». Повесть һәм хикәяләр. 16 табак. Тиражы 50 мең.
4. Рафаэль Мостафин. Сибгат Хәким турында монография. 5 табак. Тиражы 10 мең.
5. Равил Фәйзуллин. «Мой звездный час» («Йолдызлы чак»). Шигырьләр. 8 табак. Тиражы 20 мең.

#### «СОВРЕМЕННИК» НӘШРИЯТЫ

6. Юрий Белостоцкий. «Взлет по тревоге». Повестьлар. 20 табак. Тиражы 50 мең.
7. Вакыйф Нуруллин. «За развилком дороги» («Юллар чатында»). Повестьлар һәм хикәяләр. 15 табак. Тиражы 30 мең.
8. Геннадий Паушкин. «Слушай мои позывные». Повесть һәм хикәяләр. 7 табак. Тиражы 30 мең.
9. Мөсәгыйт Хәбибуллин. «Водовороты» («Чоңгыллар»). Роман. 20 табак. Тиражы 30 мең.
10. Шамил Бикчурин. «Твердая порода» («Каты токым»). Роман. 15 табак. Тиражы 150 мең.
11. Гариф Ахунов. «Человек ищет сокровище» («Кеше хәзинә эзли»). Повесть һәм хикәяләр. 21 табак. Тиражы 100 мең.
12. Әхсән Баянов. «Повесть горной стороны» («Тау ягы повесте»). Повестьлар. 21 табак. Тиражы 75 мең.
13. Фатих Хөсни. «Любовь под звездами».

(«Йолдызлы төндә»). Повесть. 12 табак. Тиражы 50 мең.

14. Сажидә Сөләйманова. «Красные перья» («Кызыл каурыйлар»). Шигырьләр һәм поэма. 2,5 табак. Тиражы 10 мең.
15. Мәрзия Фәйзуллина. «Только для тебя» («Бары тик синең өчен»). Шигырьләр. 2 табак. Тиражы 10 мең.
16. Илгиз Кәлимуллин. «Дорога к людям». Шигырьләр һәм поэма. 2 табак. Тиражы 10 мең.
17. Кадыйр Сибгатуллин. «Заветы отцов» («Аталар васыяте»). Шигырьләр. 3 табак. Тиражы 10 мең.
18. Рөстәм Мингалимов. «Зеленый сон» («Яшел төш»). Шигырьләр. 2 табак. Тиражы 10 мең.

### «ДЕТСКАЯ ЛИТЕРАТУРА» НӘШРИЯТЫ

19. Гомәр Бәширов. «Родимый край — зеленая колыбель». («Туган ягым — яшел бишек»). Повесть. 13 табак. Тиражы 100 мең.

## КИТАПЛАР — ДУСЛЫК ИЛЧЕСЕ

*

*   *

«Литературная Россия» газетасының редакция коллегиясе Сезне «Акчуранның жир үбүе» хикәягез өчен еллык премия алуыгыз белән котлый» — язучы Әхәт Гаффарга газетаның баш редакторы Ю. Грибов имзасы куелган шушындый котлау килде.

Бу хикәя газетаның былтыргы 43 санында Ю. Стефанович тәрҗемәсендә басылып чыкты. Аны республикабыз укучылары «Азат хатын» журналының 1976 нчы елгы октябрь саныннан укып танышканнар иде.

*

*   *

Украинаның Донецк китап нәшриятында Шамил Рәкыйповның «Атака на рассвете» дигән китабы 15 мең тираж белән рус телендә басылып чыкты.

Советлар Союзы Геройлары Батыршин белән Чернопятколарның сугышчан батырлыгы турында сөйләгән бу китап, «Таңнар һаман матурмы» повестеның яңартылган варианты булып, анда Һади Такташның Донец шахтерлары белән элемтәсе турында да яңа бүлекләр дә өстәлгән.

*

*   *

Киевтагы «Веселка» нәшрияты Октябрьнең 60 еллыгы уңае белән илебез туган-даш әдәбиятларыннан украинчага тәрҗемә итеп балалар өчен «Октябрь йолдызы яктысы» дигән исемле китап чыгарды. Авторлары — дүрт дистәгә якын. Анда Татарстаннан шагыйрь Зәки Нуриның партизан хикәяләреннән берсе урын алган.

### «КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ БИЛГЕСЕ БЕЛӘН»

**Im Zeichen ☆ des roten Sterns**

Erinnerungen an die Traditionen der deutsch-sowjetischen Freundschaft

DIETZ VERLAG BERLIN

Утыз алты очерк һәм мөстәкыйль мемуар әсәрләр тупланган бу китапның исеме әнә шундый. Авторлары — һәммәсе немецлар: фашизмга каршы, Советлар Союзы белән дуслык өчен көрәштә актив катнашкан галимнәр, язучылар, культура эшлеклеләре һәм эшчеләр. Шушы ике ил халыкларының революциядән соңгы җимереклек, интервенция, гражданнар сугышы һәм икенче бөтендөнья сугышы елларында бөтен кыенлыкларны җиңеп чыныккан, маягы кызыл йолдыз билгесе белән символлаштырылган дуслык юлын истәлекле фактлар һәм художестволы детальләр җирлегендә сурәтлиләр алар. Башта Берлинда немец телендә дөнья күргән бу китапны 1977 ел азагында Мәскәүдәге «Прогресс» нәшрияты русчага тәрҗемә итеп чыгарды. Аның тышлыгына ук чыгарып язылган «Фашизмга каршы көрәшчеләр — Муса Җәлил, атаклы музыкант Сермус һәм бүтән интернационалист-геройлар турында» дигән искәрмәсе бар.

## ИҖАТ БӘЙРӘМНӘРЕ

*

*   *

Күренекле тәнкыйтьче, әдәбият белгече, профессор Галимҗан Нигъмәтинең тууына 80 ел тулуга багышланган кичәдә галим турында сүз белән язучы, филология фәннәре кандидаты Мөхәммәт Мәһдиев чыгыш ясады. Нигъмәти турында аны яхшы белгән шәкертләре истәлекләр сөйләделәр. Казан педагогия институтының төп бинасындагы актлар залында 26 декабрьда үткәрелде бу тантана.

*

*   *

Зур әдип, әдәбият белгече һәм тарихчы Газиз Гобәйдуллинның (Г. Газиз) тууына 90 ел тулуга багышланган гыйльми советның киңәйтелгән утырышын СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Галимҗан

Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты үткән елның 13 декабрендә үткәрде. Докладларны профессор М. Гайнуллин һәм өлкән фәнни хезмәткәр С. Алишев сөйләде.

## УКУЧЫЛАР БЕЛӘН БЕРДӘМЛЕК

Казан дәүләт педагогия институты студентлары язучы Гомәр Бәширов белән очраштылар. Анда әдипнең «Җидегән чишмә» исемле яңа романы тикшерелде. Роман авторы үз иҗаты, яңа бу әсәренең ничек язылуы турында сөйләде, укучылар исә аңа карата үз фикерләрен әйттеләр.

* * *

Казан авыл хуҗалыгы институтының студентлар шәһәрчеге. Шыгырым тулы зал. Бер-бер артлы чыгыш ясаган хезмәт һәм сугыш ветераны сүзен, аннары артистлар башкарган җыр яңгыравын, аннары шагыйрь сөйләгәнне яшьләр йотылып тыңлыйлар: Зәки Нури һәм елмаюлы, һәм чәнечкеле яңа шигырьләр укый.

Бу кичәнең түрендә яңа китапларга да киң урын бирелгән. Укучы аны автограф яздырып күпләп алырга тели. Истәлекле очрашуны йомгаклаганда уртак бер фикергә киленә: укучы белән очрашуга әдипләр һәрчакта да китап белән бергә килергә тиешләр.

* * *

Мәскәүдә СССР Язучылар союзының балалар әдәбияты буенча советы «Балалар әдәбиятында Ленин, партия һәм революция» дигән темага пленум үткәрде. Пленум эшендә, Казаннан совет члены Ләбибә Ихсанова катнашты һәм «Татар балалар әдәбиятында Ленин образы» дигән темага чыгыш ясады.

## ЯШЬЛӘРГӘ — ЯШЕЛ УРАМ

Язучылар союзы яшьләр комиссиясенең чираттагы утырышы булды. Анда Казан педагогия институтындагы әдәби түгәрәккә Гөлшат Зәйнашева, «Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы әдәби түгәрәккә Әхсән Баянов шефлар итеп билгеләнде, Арча, Биектау, Саба, Балтач районнарындагы яшь язучыларның конференциясен апрель аенда үткәрү турында карар кабул ителде.

## «АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫ, ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ...

Язучылар союзы партия оешмасының ачык җыелышында күптән түгел әнә шул темага эшлекле һәм игътибарлы сөйләшү булды. Әдипләр әдәби һәм иҗтимагый-политик бу журнал битләрендә басылган проза һәм поэзия әсәрләренең сыйфатын уңай бәяләде һәм үзләренең журналда тагын да активрак язышырга кирәклеген әйттеләр.

## «70 НЧЕ ЕЛЛАР КОРЧАГИННАРЫ»

1975 елның ноябреннан 1977 елның гыйнварена кадәр дәвам иткән иҗат яшьләре конкурсы «70 нче еллар Корчагиннары» дип исемләнгән иде. Аны ВЛКСМ өлкә комитеты, ТАССР Культура министрлыгы коллегиясе, ТАССР Язучылар һәм Художниклар союзлары, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге оештырды.

Конкурс барышында күп кенә югары идеяле яңа әсәрләр туды, иҗат яшьләренең осталыклары камилләште. Иҗат яшьләре Бөтенсоюз удар комсомол төзелешләрен, бүгенге тормышның актуаль проблемаларын яктыртуга зур игътибар бирделәр.

«70 нче еллар Корчагиннары» конкурсының оештыру комитеты тарафыннан тәкъдим ителгән йомгакларны карап чыкканнан соң жюри рәсем сәнгате, әдәбият һәм театр сәнгате өлкәләрендә ирешкән уңышлары өчен бер төркем яшь иҗатчыларны җиңүчеләр дип тапты. Язучылардан Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим, Роберт Батуллин, Камил Мостафин, Җәмит Рәхимов һәм Фәннур Сафин конкурс лауреатлары итеп танылдылар, аларга Мактау грамоталары һәм бүләк бирелде.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР САФЫ ИШӘЯ

Татарстан Язучылар союзы тәнкыйть секциясенең чираттагы семинары булды. Анда яшь тәнкыйтьче Әмир Мәхмүдов иҗаты тикшерелде. Фикер алышуларда катнашкан Х. Хәйри, Ф. Мусин, Н. Ахунжанов, А. Әхмәдуллин, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, Р. Сверигин, М. Хәбибуллин, Ә. Шәрипов, Ш. Маннапов, Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев һәм башка иптәшләр яшь тәнкыйтьче иҗатын нигездә уңай яктан бәяләделәр, аңа тагын да камилләшү юнәлешендә файдалы киңәшләр әйттеләр.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

*
* *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яшь тулу уңае белән язучы Әхсән Баянов «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде.

*
* *

Татарстан радиосының үткән ел азагында бәйрәм ителгән 50 еллыгы уңае белән һәм радио тапшыруларда бик актив катнашканнары өчен республикабыз Министрлар Советының Телевидение һәм радио комитеты язучылар Зәки Нури, Әхсән Баянов, Гәрәй Рәхимне һәм «Казан утлары» журналының сәнгать бүлеге өлкән редакторы Рим Шириаздановны, очерк һәм публицистика бүлеге редакторы Хәмзә Зариповны, хатлар бүлеге редакторы Роберт Миңнуллинны Юбилей грамотасы белән бүләкләде.

## ЛУНАЧАРСКИЙ КАЗАНДА

Илебезнең иң беренче мәгариф халык комиссары Анатолий Васильевич 1924 елның көзендә Казанга килә. Менә аның шул уңай белән Казанга, ул чакта республикабызның мәгариф халык комиссары, язучы Шәһид Әхмәдиевкә язган хатыннан кайбер юллар:

«Беренче октябрьда Казанда булам... Минем чыгышлар планы түбәндәгечә күздә тотыла: беренче числода үземнең «Канцлер һәм слесарь» дигән пьесама кереш буласы сүзне әйтергә телим. Аннары нинди дә булса популяр темага лекция укырмын, әлбәттә. Түләүле булуы яхшы — чөнки аның бөтен килере минем карамактагы ятимнәр файдасына тотылачак... Сездә үтәсе өч көнемнең бер кичен Казан укытучылары, — бәлки студентлары да — җыелачак аудиториядә «Совет иленең культура төзелеше» дигән темага чыгыш ясау өчен файдалануны теләр идем. Һәм, шуларга өстәп... Казан эшчеләре каршында «Союзыбызның эчке һәм тышкы хәле» турында, аннары Ленин темасына чыгышлар ясый алам».

Республикабыз совнаркомы һәм Үзәк Башкарма комитеты халык мәгарифе торышы турында Луначарский белән әңгәмә оештыра. Ул Казанның партия, совет һәм профсоюз оешмалары активы җыелышында халыкара хәл турында, Казан университетының актлар залында культура эшләре темасына чыгышлар ясый, уку йортларында була, аларда милли кадрларның бик күп хәзерләнүен белеп куана. Кыска гына вакыт эчендә Анатолий Васильевич татар рабфагында, политехник техникумда, полиграфистларның һөнәрчеләр мәктәбендә, коммуна-мәктәптә, ятимнәрне тәрбияләгән балалар шәһәрчегендә, татар театрында булырга өлгерә.

*Хөрмәтле укучыбыз!*

Сезне журналыбызның дүртенче саны белән таныштырабыз.

Ул шагыйрь Роберт Миңнуллинның «Ленин язы» дигән шигыре белән ачыла. Тукай премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев шигырьләре дә даһи юлбашчыга багышлана.

Бу санда Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» повесте тәмамлана. Шамил Маннаповның «Тугрылык» дигән кечкенә хикәяләр циклы бирелә. «Замандаш» конкурсына яшь язучы Камил Кәримовның «Тәнәфес» хикәясе тәкъдим ителә.

Мәҗит Рафиков, Мөдәррис Әгъләмов, Әхмәт Гадел, Әдхәт Синугыл, Илсөяр Ганиева шигырьләрен укырсыз.

Мәхмүт Хәсәнов һәм Альберт Хәсәновларның очерклары табигать байлыгы һәм аны саклау проблемаларына кагыла.

Апрель ае Габдулла Тукай туган ай да. Шул уңай белән журналда әдәбият белеме галиме Нурмөхәммәт Хисамовның «Тукай иҗатында борынгы әдәбият традицияләре», музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗановның «Тибрәтмәктә күңел кылларын» дигән мәкаләләре, язучы Атилла Расихның «Әнием хатирәләреннән», журналыбызны даими укып баручы, пенсиядәге укытучы Вәли Хаҗиевның «Әллүки» ничек туган» дигән истәлекләре басыла.

Быел күренекле тарихчы Шиһаб Мәрҗанинның тууына да 160 ел тула. Бу күренекле вакыйганы «Казан утлары» журналы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре Мөнир Йосыпов мәкаләсе белән билгеләп үтә.

Гадәттәгечә, «Әдәби тәнкыйть», «Китап күзәтү», «Нәниләр дөньясы», «Яшьләр иҗаты», «Елмаеп та, көлеп тә...», «Безнең календарь» бүлекләре, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары Сезне күп санлы шигырьләр, фәнни мәкаләләр, информацияләр белән таныштырыр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210